ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

1.2009





**Фатих Кәрим**
**(1909—1945)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2009

**1**
**(1035)**

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

*НАШИРЕ:*
***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***



*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир,**
**Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина,**
**Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**


---


*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 541-38-77.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Еллар узган саен гамь арта ........ 5

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Мөхәммәт МИРЗА. Адәм баласы. Бишьюллыклар ........ 13
Нур ӘХМӘДИЕВ. Мөнирстан. Роман ........ 18
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Шатлыкларым, булды, җиңүләрем... Шигырьләр ........ 53
Илүсә НӘБИУЛЛИНА. Гөлҗиһан өянкәсе. Хикәя ........ 58
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Сынадың, тормыш, сынадың... Шигырьләр ........ 63
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Кош булып очар идем... Роман ........ 67
Ленар ШӘЕХ. Дөнья хозурында. Шигырьләр ........ 103
Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Хәтерлим, хәтерлим... Шигырьләр ........ 105

ХӘТЕР

Нурихан ФӘТТАХ. Беренче шигырь күк балачак... Истәлекләр ........ 108
Гомәр БӘШИРОВ. Күңел дәфтәре ........ 142
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы. Хатирәләр ........ 156

ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Фатих КӘРИМ. Моң һәм көч. Төрле еллардан шигырьләр ........ 122
Фатих Кәрим турында әдипләр ........ 126

ПУБЛИЦИСТИКА

Тәфкил ВАФИН. Мәкруһлар ........ 128

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Радик ФӘИЗОВ. Вәзенгә сыймаган уйлар ........ 137
Фәрит ХАТИПОВ. Өр-яңа эчтәлек ........ 164

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Әнвәр ХӘЙРИ. Бөек галимебез ........ 153

Ә. ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУНЫ КАРШЫЛАП

Фактлар дәфтәреннән ........ 154

ФӘН

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ........ 168

КИМ МИҢНУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Кем ул Ким Миңнуллин? ........ 174

ЮМОР–САТИРА

Дамир ГЫЙСМЕТДИН. Хикәяләр ........ 179
Ринат АБЗАЛОВ. Тафтограммалар ........ 181

"Казан утлары" архивыннан ........ 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 186

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


"Слово главного редактора": Р. ФАЙЗУЛЛИН. "С каждым годом все больше забот".
"Проза и поэзия": романы Р. МУХАМАДИЕВА "Взлететь бы птицей..." (окончание), Н. АХМАДИЕВА "Мунирстан", рассказ И. НАБИУЛЛИНОЙ "Ива Гульжихана"; стихи М. МИРЗЫ, И. ГИЛЯЗОВА, Г. БАЙРАМОВОЙ, Л. ШАЕХА, Л. ГИБАДУЛЛИНОЙ.
"Память": Н. ФАТТАХ. "Детство как первый стих" (продолжение), А. РАШИТ. "У каждого... своя судьба" (продолжение), Г. БАШИРОВ. "Дневниковые записи" (продолжение).
"Публицистика": Т. ВАФИН. "Отпавшие" (продолжение).
"К 100 летию Ф. Карима": стихи поэта; писателей о Ф. КАРИМЕ.
"Литературная критика": рецензия Р. ШАРАФИЕВА на книгу З. МАНСУРОВА "Душа беззавестности полна", Ф. ХАТИПОВ. "Новая суть старого романа".
"К 150 летию Р. Фахруддина": А. ХАЙРИ. "Великий ученый".
"К 100 летию А. Еники." Из тетради фактов.
"Наука": Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень"; статья М. ВАЛИЕВА к 50 летию К. МИННУЛЛИНА.
Юмор и сатира.
Наши юбиляры.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: 2009 год—год Спорта; поэт Раниф ШАРИПОВ.


# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*


"Word of chief editor: R. FAYZULLIN. "There are more and more worries every year."
"Prose and Poetry": novels by R. MUHAMADIEV "Fly as a bird..." (ending), N. AHMADIEV "Munirstan", story by I. NABIULLINA "Gulgihana's willow tree"; verses by M. Mirza, I. GILYAZOV, G. BAYRAMOVA, L. SHAEH, L. GIBADULLINA.
"Memory": N. FATTAH. "Childhood as a first poem" (continuation), A. RASHIT. "Everyone has his own destiny..." (continuation), G. BASHIROV. "Diary records (continuation).
"Publicism": T. VAFIN. "Fallen down" (continuation).
"To 100th anniversary of F. Karim": verses by poet; writers about F. Karim.
"Literary Criticism": review by R. SHARAFIEV of the book y Z. MANSUROV "Soul full of devotion", F. HATIPOV. "New heart of old novel.
"To 150th anniversary of Robert Fakhruddin: A. HAYRI. "Great scientist."
"To 100th anniversary of A. Eniki." From notebook of facts.
"Science": F. Garipova. "History of our villages", article by M. VALIEV to 50th anniversary of K. MINNULIN.
Humor and satire.
Our jubilees.
From photo archive of magazine.
Diary of social cultural life.
On our covers: 2009, Year of Sport; poet Ranif SHARIPOV.



★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.



Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.12.2008, график буенча 22.12.2008.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–1731 Тираж 4788.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2008 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

# ЕЛЛАР УЗГАН САЕН ГАМЬ АРТА

“Ахырзаман алдыннан кырык ел кырык көннән дә тизрәк узар” дип ишеткәли идек бәләкәй чакларда. Гомернең бик тиз узуын үзендә тойгач, гасабиланып, кайчак ышана язасың бу сүзләргә. Дөрес, сырхау кешеләргә, зиндандагыларга, кавышу көннәрен көткән гашыйкларга вакыт бик озак үтә кебек тоеладыр... Әле кайчан гына яна XXI гасырга аяк басабыз дип мәш килеп йөрдек, инде бу гасырның да сигез елы үтеп киткән... Сау кешегә унынчы елы да житәр, егерменчесе дә...

Яна елга кергәндә һәр кеше үткәнен, соңгы елларда кылынган гамәлләрен искә алып, киләчәктә ничек яшәү турында нинди дер хыял-планнар кормый калмыйдыр; үз дөньясындагы хәлләрне башкаларныкы белән чагыштырып, гыйбрәтләр аладыр, китапчалап әйтсәк, үзенең җәмгыятьтәге урыны хакында да уйланадыр. Табигыйдыр, мин дә уйланам, соңгы вакытларда ешрак уйланам. Гомерлеккә дип сайлап алган һөнәр-эшемнең нәтиҗәсе бүтәннәргә кирәкме? Кирәк булса, ни дәрәҗәдә кирәк һәм ул ничек бәяләнә? Шәхсән үзем рухи һәм матди канәгатьлек табаммы? Ахыр чиктә, бер шигырьдәгечә әйтсәк, “бәхетлеме кеше дөньяда?..” Мондый уйланулар иҗат кешеләре өчен аеруча хас булса кирәк.

Мин ярты гасыр чамасы татар әдәбиятының үзәгендә кайнаган кеше. Шуңа күрә Яңа ел алдыннан журнал өчен язылган бу кереш мәкаләмдә дә төп сүз Әдәбият турында, аның нигезен тәшкил иткән Туган тел турында, аның дәрәҗәсен билгеләгән Галиҗәнап Китап турында, аны илһамланып тудырган Иҗатчылар турында булыр.

Безнең буын Китапны (бу очракта иң әүвәл әдәби китапны истә тотып әйтүем) изгеләштереп, аны могҗизага санап яшәгән бәхетле буыннарның берсе. Без Китапка табындык, ул да үзен олылаганнарга мәрхәмәтле булды, аң-белем бирде, дөньяны танып белүдә маяк булды, тәрбияләде, кеше итте. Хәтерлим, студент елларында кулга берәр яхшы китап эләксә, кош тоткан кебек, сөенә идек. Моннан утыз-кырык ел элек, берәр зур язучының яңа әсәре журналда басылса яки китап булып чыкса, аны укыр өчен китапханәләрдә озын-озын чиратларга языла лар иде. Атаклы язучының теге яки бу яңа әсәрен укымасак, ничектер унайсызлык тоеп, үзенне зыялы саный алмый идек.

Гомумән, китап безнең халык тормышында аерым бер зур урын тоткан. Шуңа күрә дә, үткән гасыр мәгълүматларына караганда, татарлар китап бастырып чыгару буенча Россия империясендә иң алдынгы урыннарның берсендә булган. Күрәсең, хакимлеген җуйган халыкта китап күпмедер дәрәҗәдә дәүләти (әйтик, мәгърифәт өлкәсендә) функция дә үтәп килгән. Хәзер вәзгыять бик нык үзгәрде. Күпләр аңында китап байлык саналмый бүген. Хакимият тә аны инде артык көчле идеологик коралга исәпләми. Дәүләт карамагындагы китап сөючеләр җәмгыятьләре гөрләп эшләп торган заманнар узды. Күпләр китаптан йөз чөерде. Китапның статусы төште, ул асылда товарга әйләнде. Әдәбиятны чүп басты. Акчасы булган һәр теләгән кемсә “китап” чыгара башлады...

Япон яки немец кебек халыкларда китапка мөнәсәбәт ничектер, белеп бетермим, ә безнең шартларда чын әдәбиятның хәле менә шулайрак. Китапханәләрдә ачып та каралмаган басмаларны, нәшрият складларында сатылмыйча яткан өем-

өем китапларны күргәч җан әрни... Сәбәпләрен төрлечә аңлаталар. Берәүләр моны телевизор, интернет нәтиҗәсе ди, берәүләр яшь буынны битарафлыкта, әхлаксызлыкта гаепли. Һәркайсында күпмедер хаклык бардыр, бәхәсләшмим... Шулай да бу хәлгә төшүебезнең иң төп сәбәбе—идеологик ориентирларның тиз вакыт эчендә капма-каршы якка үзгәрүе, минемчә. Кичә генә коммунизм төзергә әзерләнүчеләр капылт кына капитализмның күндәм тарафдарлары булды да куйды! Базар мөнәсәбәтләренә күчтек, дидек бит. Ә базарның Алласы, әлбәттә, әхлак түгел, акча. Моннан берничә ел элек биш яшьлек улым әйтеп куймасынмы: А хәрефе акчадан башлана... Менә шулай...

Бер шагыйрьнең мондый юллары бар: “Бөтен прогресслар да регресс була, әгәр Кеше эчтән таркалса...” Уйландыра. Фәннең иң бөек казанышлары, асылда, Кешенең үзен харап итүгә юнәлтелгән. Хәрбиләр, Җир шарын пеләш итәрлек көч бар, дип мактана. Ә китап, бу очракта әдәбият, гомумән сәнгать, моңарчы кешене Кеше итүгә хезмәт итте. Китап—цивилизация казанышының бер билгесе, халыкларның күп гасырлар, мең еллар буе җыелып киленгән бөек хәзинәсе. Китап—хәтер ул. Кешелек үз хәтерен җуймаска тиештер бит инде!..

Язучылык хезмәте турыдан-туры тел белән бәйле. Ул аның “эш коралы”, яшәү чыганагы, язмышы. Хәер, үзен туган халкы вәкиле дип санаган һәркем өчен тел—язмыш булырга тиеш. Төптән уйлап карасаң, тел—безнең иң төп байлыгыбыз. Анда безнең рухыбыз, тарихыбыз, иманыбыз, хәтеребез... Ул—үзенә һәммәсен туплаган бөек көч. Заманында җинелгән халыкның бар байлыгын талап ала алганнар, илләрен җимереп тузгытканнар, яндырганнар, изге җирләрен мәсхәрәләгәннәр... Әмма тел дигән төп байлыкны тиз генә юк итә алмаганнар. Чөнки, Тел дигән төшенчә Үлемсезлек дигән сүз белән янәшә, үзенчә аның синонимы. Туган телебезнең тарихи язмышы гаять катлаулы, аянычлы. Кайчандыр дөнья тоткан халыкара дипломатик телләрнең берсе булган хәзинәбезне бетерер өчен әллә ничә гасырлар буе рәхимсез һөҗүм бара. Шулай да, күп санлы инквизация чорларын үтеп, һаман исән кала алган үзе. Нажар Нәҗми әйткәнчә:

*Ассалар да, киссәләр дә,*
*исән калдың, татар теле!*

Хәзер дә әле, галимнәр белдергәнчә, төп дөнья телләренең ундүрте арасында исәпләнә ул. Әмма...

Моннан бер ел чамасы элек, 2007 елның декабрендә Россия халыкларының (рустан тыш) телләренә янә бер җимергеч удар ясалды, үзенә күрә бер яңа ел “бүләге” булды. Ул да булса—Дәүләт Думасы карары һәм Президент В. Путин имзасы белән мәгариф стандартларыннан милли-төбәк компонентын төшереп калдыру турында 309 нчы сан белән беркетелгән антиконституцион федераль закон. (Бу җәһәттән Президентның Казанда, 2002 елда ясаган чыгышындагы сүзләре хәтергә килә: “Абсолютно недопустимо, если кто-то говорит о том, что нужно сокращать изучение родного языка”.) Мәгънәсе—милли телләрне мәктәпләрдән сөрү. Максаты—балаларда гомумроссия үзаңы тәрбияләү. Икенче төрле әйткәндә, алардан урыс ясау. Мин моңарчы, гомумроссия үзаңын башка милләтләрнең үзаңыннан (үзаңны телдән башка күз алдына да китереп булмый) укмаша дип уйлый идем. Шунысы сәер: аларча, җирле элита мәктәпләрне үз сәяси максатларына ирешү өчен файдалана, мәктәпләрдә милли телдә укыту Россиянең бердәмлегенә яный икән! Таныш нәрсә: кириллицадан бүтән имляга күчү мәсьәләсендә дә мондый “дәлилләр” янгыраган иде инде (чынында, менә шундый законнар Россияне таркатуга этәрергә мөмкин). Кеше хокукларын боза торган мондый канунның соңгы чорда булганы юк иде әле. Әйтик, совет чорында туган телдә укымау яки укытмау турындагы фикер башка да сыймый иде. Ә болай,

статистикага баксаң, милли мәктәпләрне бетерү процессы бик хутлы бара икән. Моннан өч ел элек илдә 712 татар мәктәбе саналса, хәзер ул 490га калган... Әмма шунысы гаҗәп: безнең чиновниклар биргән хисап-отчетларда туган телдә укыту гөрләп бара. Татарча укытыла торган мәктәпләр республикада 59% тәшкил итә икән! Татарча укый торган балалар саны 1991 елда 12% булса, 2008 елны ул 53%ка менгән! Кәгазьдә әйбәт бит! Мәскәүне сискәндерерлек дәрәҗәдә әйбәт. Мәктәп классларындагы тәрәзәләр татарча авазлардан зеңләп тора диярсең!..

...Канашевич заманнары хәтергә килә. Телен онытырсан, тарихын җуйдырсан, көй-моннарыннан биздерсән, үзаңын бетерсән, чукындыру да күпкә җиңел булачак. Татар гаиләләрендә нәсел шәҗәрәләренең иң өстәге үсентеләренә игътибар итсән, аларда чиркәү күнеленә хуш килә торган исемнәрне шактый күреп була. Үз илеңдә, тарихи туган җиреңдә үзеңне икенче сортлы итеп сизү кыен. Татар фамилиясе йөртеп тә, үз халкы мәнфәгатьләрен күптән оныткан кешеләр, бәлки, үзләрен алай хис итмидер, ә Туган Тел варисларының бу мәсьәләгә фикере бердәм һәм катгый. Бу җәһәттән моннан нәкъ бер ел элек Татарстан Язучылар берлеге идарәсе белдерүеннән кайбер өзекләр китерү урынлы булыр:

"Дәүләт Думасы һәм Федерация Советы тарафыннан кабул ителеп Россия Президенты кул куйган әлеге закон Россиядәге милли мәктәпләрдә туган тел һәм әдәбиятны укытуны, туган халык тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүне нигездә юкка чыгаруга корылган.

Федераль закон мона кадәр Россиядәге милли мәктәпләрдә әлеге фәннәрне укыту һәм өйрәнүдә милли-төбәк компонентын юкка чыгара, икенче төрле әйткәндә, ул Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешен чикли.

Әлеге законны тормышка ашыру милли мәктәпләрнең ябылуына, гамәлдә мәгариф системасының кире «житлеккән социализм» чорына кайтуына тиң. Бу исә халыкара закончалык актларын, милли республикалар законнарын, Россия Федерациясенең үз Конституциясен тупас бозу.

Нәтиҗәдә меңъеллык тарихы булган татар әдәбиятына алга таба үсүеннән тукталу куркынычы яный."

Күрәсең, югары даирәдәгеләр Россиядә милли мәсьәләләр инде хәл ителде дип уйлыйдыр. Юкса, Президент юлламаларында, житәкчеләрнең илкүләм чыгышларында, күнел хакы өчен генә булса да, милли мөнәсәбәтләр, милли мәдәният, әдәбият-сәнгать турында хет бер кәлимә сүз әйтерләр иде! Совет чорында "формасы белән милли, эчтәлеге белән интернациональ" дигән кагыйдә сыман тәгъбирләр сәясәтчеләрнең һәрдаим телендә иде. Элек СССР составында яшәп, соңрак мөстәкыйльлек алган халыкларда безнең алга карачкыдай килеп баскан әлеге законнарның, проблемаларның булуын күз алдына китерү мөмкинме? Юк, әлбәттә. Ә бит күптән түгел генә күпмилләтле державаның, арттарак булса да, гомумсафында идек. Соңгы вакытларда, рус кына түгел, россия милләте (америкалыларга иярептер инде) дип тә сөйли башладылар. Шулай икән, димәк, Координацион үзәк—милли мәсьәләләр буенча министрлыклар да кирәк түгел булып чыга. Әмма берәүгә дә шуны онытмаска иде: милли мәсьәләләр—алар мәңгелек. Гомумяшәеш, көндәлек тормыш шуны раслап килә.

*Җире уртак, дибез, эше, таңы...*

*Ә шулай да*
*һәр кавемнең*
*аерым-аерым каберстаны.*

Тукай сүзләре искә төшә:

*Без сугышта юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез.*

*Шул халыкныңмы хокукка хакы юк?—*
*Хаккыбыз уртак Ватанда шактый ук!*

Әйе, хакыбыз яки хаккыбыз зур. Нәселем тарихыннан бер генә мисал: минем ерак бабам, ягъни әтинең бабасы патша армиясендә егерме биш ел хезмәт иткән. Бабам гражданнар сугышында һәлак булган. Әти Ватан сугышында яраланып, гарипләнеп кайтты. Үземә дә солдат шулпасын чөмерергә туры килде. Улым Себер якларында хезмәт итте... Без әле яллы казаклар яки гаскәриләр династиясеннән түгел, нигездә, игенчеләр нәселеннән. Бернечә буын шушы уртак Ватанны саклаган, яклаган, ил-күз алдында бурычлы булып калмаган. Мондый мисалларны миллионнар китерә алыр иде. Ватан сугышы чорындагы Советлар Союзы Геройлары арасында татарларның беренчеләрдән булуы да искә төшә. Соңрак, СССР дигән илнең нык үсешендә Татарстанда—минем илжиремдә чыккан "кара алтын"—нефтьнең хәлиткеч роль уйнаганы да хәтергә килә. Мине, шушы җирнең хакыйкый гражданы һәм халык язучысы буларак, телемне кысрыклый һәм кимсетә торган мондый мәкерле кануннар рәнҗетә һәм кимсетә. Россия "индеецлары" булып саналасы бер дә килми. Балаң дәүләт мәктәбендә фәннәрне туган телендә укый алмасын да, туган телемдә язган әсәрләремне укучылар бетерелсен дә, ничекләр итеп илһамланып иҗат итәргә кирәк? Каләмең үзеннән-үзе кулыңнан төшәр...

Үзенне япа-ялгыз итеп сизсәң, ул шулай булыр иде дә. Әмма бу мәсьәләдә без ялгыз түгел. Гавам-халык дәррәү күтәрелеп чыкмаса да (милли аң түбәнрәк шул!), бик күпләрне кузгатты әлеге кыланмыш. Җавапсыз кабул ителгән канунга җавап таләп ителә башлады. Төрле милли республикаларда, өлкәләрдә яшәүче сәясәтчеләр, зыялылар кузгалды... Ноябрьдә Казанда узган зур киңәшмә шуны күрсәтте. Монда РФнең Мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчеләре, әлеге законны әзерләүчеләр дә катнашты. Россиядә яшәүче егермедән артык төбәкнең дәрәҗәле вәкилләре бу законсыз законга бердәм каршы чыкты. Шунысы факт: хәрәкәт башында Татарстан торды, аның җитәкчеләре үзләренең саллы дәлилләре белән Мәскәү вәкилләрен дә уйга салды. Горурлык хисе кичердек җитәкчеләребез өчен. Бәхәсләрнең ахыры ничек булып бетәр, әйтүе кыен. Үз араларында Жириновский кебекләр һәм башка шовинистлар өере шактый булган Думаның үз сүзен кире алуы икеле. Шулай да, яхшыга юрыйк.

Миңа калса, татарның бүгенге көндәге иң мөһим бурычы—туган телне саклап калу. Тел исән булса, сәнгать тә, көй-моң да, әхлак та сау калыр. Шуңа күрә, тел сагында торган кешеләр фидакарь саналырга, аларның кылган хезмәтләре тиешенчә бәяләнергә хаклы. Телебезне, милли рухыбызны читтән килеп сакламаслар. Әдәбият-сәнгать—спорт түгел. Спорт димәктән, уенчылар хөрмәттә хәзер. Сәясәт—уен булгач, югары даирәләргә, бәлки, уйлаучыларга караганда, уйнаучылар күбрәк ошыйдыр? Мин үзем дә спортка мөкиббән кеше, әмма шунысын беләм: спортчыга Ходай Тәгалә физик һәм ихтыяр көче бүләк итсә, иҗатчыга—илаһи көч насыйп әйләгән! Кайсы зуррак? Тарих—соңгысын тамгалый. Заманында гладиаторларны да халык шашып тамаша кылган. Чорлар узгач, алар онытылган. Ул чорларның истәлеге булып сәнгать әсәрләре калган. Әгәр Спартакны беләләр икән, аны да халык хәтере аша, миф-легендалар, сәнгать аша беләләр. Безгә, татарстанлыларга, күпчелек халык мохтаж яшәгән елларда, зур акчалар бәрабәренә сатып алынган (бу очракта чит-ят спортчылар белән төзелгән контрактларны әйтүем) җиңүләр белән артык шапырынырга яки беркатлы фанатларча эйфориягә бирелергә кирәкмидер. Легионерлар килер дә китәр, ә менә тел сагында торучы фидакарь затлар ахыргача үз халкы белән булып, ахыргача аның шатлык-кайгысын уртаклашыр. Шау-шулы Олимпиадалар да, Универсиадалар да булыр, Сөләйман пәйгамбәр әйтмешли, барысы да үтәр... Әгәр тарихи туган җиремдә, телем, моң-көем юкка чыкса, андагы зиннәтле корылмаларның, күктерәр биналарның минем өчен ни кызыгы булыр икән? Замандашым, халык язучысы Нурихан Фәттах та мондый сүзләр язып

калдырган иде: “Әгәр тиздән минем телем бетә икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә жырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе—йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым”.

Яшәешнең, халык тормышының кайсы ягы турында уйлансам да, уй-фикеремнең очы Туган телгә барып тоташа. Күрәсең, эшем-һөнәрем, профессиям белән дә бәйледер инде бу. Күп еллар элек бер танышым, Тукайның “Туган теле”н бераз үзгәртеп, болай дип укып биргән иде:

*И Туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп кыен күрдем син Туган тел аркылы!*

Аптырагач әйткәндер инде... Чыннан да, соңгы дәвердә татар теле тулы хокуклы булып яңгырасын өчен ижтиһат итү юлында күпме асыл башларның маңгайлары ярылды! Чагыштырмача кыска гына вакытта берничә тапкыр алфавит-имля алыштырып кара әле! Юкка дип әйтерлек күпме көч-жегәр сарыф ителгән! Мәдәният-мәгърифәт тарихында парадоксаль-уникаль күренеш. Ә “әткәм-әнкәмнең теле” дигәнгә искәрмә өстәргә туры килә хәзер. Телебез, әйтик, синең белән минем өчен әткәм-әнкәм теле булса, хәзерге күпчелек яшьләрнең әнкә телләре бүтән бүген!.. Сабыйның теле башка телдә ачыла, чөнки аның әти-әнисе туган телен оныткан инде. Телебездә без аңлаган Ана теле (мәктәп көндәлекләрендә шулай яза идек) дигән гажәеп матур сүзтезмә югалып бара...

Гомумән, татар теле генә түгел, бүтән телләр дә алынма яки чит-ят сүзләр хисабына гажәеп үзгәрешләр кичерә хәзер. Бу үзгәрешләрне гел яхшы якка дип әйтмәс идем. Мисал өчен унбиш-егерме сүз язып үтим: *Президент, бизнес, дефольт, толерантлык, спид, казино, инфляция, шоу, стресс, интернет, фонограмма, террор, мафия, наркоман, риэлтор, рейтинг, сепаратизм, банкомат, саммит, рэкэт, олигарх*... Тагын йөзләрчә сүз тезәргә мөмкин. Боларны без радио-телевидение тапшыруларыннан яки газет-журналлардан булсын көнозын укып-ишетеп торабыз. Моннан утыз-кырык ел элек аларның кайберләрен ерак илләрдә яңгырап торган, безгә ят атама-терминнар итеп кенә белә идек, кайберләре безнең сөйләмдә гомумән юк иде. Төптән уйлап карасаң, дөрестән дә, алар бит безнең бүгенге чынбарлыкны чагылдыра. Аның каравы балачактан ук безнең өчен газиз сүзләр, әйтик, *намус, әхлак, вөждан, тәүфикъ, инсаф, амәнәт, самими, шәфкать, мәрхәмәт*... кебек сүзләрне көннән-көн сирәгрәк ишетәбез. Хәер, болар турында сөйләү үзе бер аерым тема.

Уйландыра: бүгенге көндә телебез кайларда саклана, нинди даирәләрдә яңгыравын дәвам итә соң? Әлбәттә, гаиләдә. Әлбәттә, мәктәптә (дөресрәге, булырга тиеш). Хезмәт-эш урыннарында (шәһәрдә—азрак, авылда—күбрәк. Халыкның иң зур күпчелеге шәһәрдә, авылда яшәүчеләр елдан-ел кими). Тагын кайларда? Радио-телевидение каналларында. Сәхнәдә—театрларда, тамаша-концерт залларында... Дин йортларында—мәчет-мәдрәсәләрдә. Базар-мазарларда... Әмма затлы, классик телнең нигез-куышы—әдәбият, матбугат. Халыкның гасырлар буе жыйналып, чарланып килгән асыл җәүһәрләре—аларда. Бәс, шулай икән, милли матбугатка—китапларга, газет-журналларга аерым бер игътибар, нәшриятлар, басмаханәләр житештергән рухи кыйммәтләрне киң халык массаларына житкерүдә аерым бер дәүләти караш булырга тиештер бит инде. Татар телендә чыккан матбугат бик аз тарала. Безгә һәр данә кадерле. Әгәр гаилә өстәлендә туган телдәге берәр газета-журнал ятса, аны яше-карты, берсе булмаса икенчесе укый, карый ала. Тиражлар үткән дистә еллар белән чагыштырганда көлке дәрәжәдә аз хәзер (элегрәк йөзәр мең, яртышар миллион белән чыккан журналларның тиражы күп дигәндә ун мең данә). Димәк, күпме рухи һәм матди чыгымнар тотылган хезмәт нәтиҗәсенең файдалы эш коэффициенты

түбән булып чыга. Ә сәяси яктан? Төрле дәрәҗәдәге эш башында утырган идарәчеләрнең мотлак күпчелеге татар телендәге матбугатны укымый. Бик үк югары даирәләргә сикермичә, әйтик, министрлык яки район җитәкчеләреннән Россиядә иң абруйлылардан саналган безнең "Казан утлары" журналын кемнәр генә яздыра һәм укый икән? Ә бит егерменче елларда, милләтнең совет чорындагы күтәрелеш елларында җитәкчеләр һәммәсе укыган, контрольлек иткән, юнәлеш биргән, кирәк чакта, тәнкыйтьләгән, кинәшкән. Матбугат алар эшенең табигый бер өлеше, кайчакта ориентир да булган. Эш—үткәнне сагынуда түгел, бүгенге өчен әрнүдә. Ә кызыксынган, укыган кеше өчен шактый ук югары кимәлдә безнең татар матбугаты! Тирән эчтәлекле, хакыйкатькә тугры, кыю фикерле мәкалә-чыгышлар җитәрлек аларда. Укы, чагыштыр, гыйбрәт ал. Тармак яки хосусый басмалар гына түгел, рәсми газета-журналлар да заманча, халыкчан рухта чыга бүген. Газеталардан берничәсен генә әйтеп узыйм. Зур тарихлы "Ватаным Татарстан"да, шулай ук аның яшь аркадашы "Мәдәни җомга"да еш кына милләт гамен кайгырткан гаҗәеп кыю материаллар дөнья күрә. "Шәһри Казан" да бер-ике ел эчендә укып туймаслык газетага әйләнде. Яше-картының яраткан газеты, демократик рухлы, чагыштырмача күп тиражлы "Татарстан яшьләре" күпкырлылыгы, халыкчанлыгы белән үз югарылыгында кала бирә. Балалар һәм үсмерләр газетасы "Сабантуй" да дөньяны танып-белергә өйрәтә торган бай материаллары белән күпләрне җәлеп итәрлек. Әлеге дә баягы бер генә бәла: тиражлары аз. Мәскәүне дә куркытырлык "күп татар мәктәпләре"н исәпләгәндә, бу газетаның тиражы бик зур булырга тиеш иде кебек, ә ул нибары 7 мең чамасы (60 нчы еллар ахырында газетаның элгәре—"Яшь ленинчы" 100 меңнән артык данә белән чыга иде). Бүген шулай. Югарыда әйтелгән милли телләрне кысрыклауга юнәлтелгән әлеге мәкерле закон үз көченә керсә (ул 2009 елның сентябреннән гамәлгә ашырыласы) нәрсә була!..

Җыйнап әйткәндә, матбугатыбызны таратуда, халыкка җиткерүдә бик күп кадерле вакытны, форсатларны кулдан ычкындырдык... Русларда да тиражлар бик зур түгел бит, дияр кемдер. Пәри башка, җен башка, ди халык. Державалы, күпсанлы халыкның матбугаты югалмас ул... Ә безнең өчен матбугат—дәүләти институт та, милли университет та, таяну ноктасы да. Инде ун елдан артык республикада татар телен дәүләт теле сыйфатында тормышка ашыру Программасы эшләп килә. Татар матбугатын халыкка күпләп җиткерү—бу Программаның үзәк өлеше булырга тиеш иде. Кайберәүләр, игътибарны матбугаттан читкәрәк юнәлтеп, күпләрне интернетка юлламакчы. Интернет белән туган телне үзләштерү яки үстерү, М. Мәһдиев әйтмешли, едва ли! Үткән гасыр урталарында, көндәлек тормышта телевидение пәйда булгач, экраннардан фильмнар, спектакльләр күрсәтелгәч, кайбер акыллыбашлар, театрлар бетәчәк дип сөрән салды... Тормышка ашмады андый фаразлар. Экран экран булып, спектакль тере тамаша булып үз урынында калды. Кешенең китап белән аралашуы, берлеге дә мәңгелек, дип уйлыйм мин. Нәтиҗә—үземчә аксиома шул: телне саклыйм дисәң, төп шартларның берсе—милли китапны, матбугатны саклау.

Яңа елда, табигый, яхшыга өметләнеп, үткәннән дә күңелгә хуш килердәй вакыйга-фактларны искә төшереп канатланасы килә. Бу уңайдан конкрет вакыйгалар санаганга кадәр, шунысын ачык итеп әйтү кирәктер: соңгы елларда зур югалтулар кичерсәк тә, шөкер, бүгенге көндә күп гасырлык татар әдәбиятын заманча үстерерлек кимәлдә иҗат итүче берничә дистә зур язучыбыз бар. (Ә калган йөзләгәннәре? дияр кемдер. Борчыласы юк: биек таулар ялгызак калкып тормый, Урал тавы тезмәләре кебек, алар бер-берләренә елышып, үзләре дә бар булып, зурракларына терәк-таяныч булып тора). Бу—зур көч!

Шулай ук, җитмеш елдан артык язучыларны үзара аралаштырып, берләштереп яшәтә торган оешмабыз—Язучылар берлегебез бар. Ул уңышлы гына эшләп килә (кемнәрдер, бәлки, аның эшчәнлегеннән канәгать үк тә түгелдер... Әгәр аны җуйсак, сагынырга калмасын! Соңгы дәвердә Берлексез яшәп караган

юк бит әле!). Белүемчә, безнең Берлек кебек эшләгән оешма элеккеге СССР кинлекләрендә сирәк.

Әдәбиятыбызның нигез журналы "Казан утлары"на яна әсәрләрнең мул килеп торуы да шатлыклы хәл. Бөтен кульязмалар да югары таләпләргә җавап биреп бетермәсә дә, аларның күпчелеге ил-халык гаме белән сугарылган. Иң мөһиме—соңгы елларда яшь көчләр ишәйде. Бигрәк тә Шигърияттә. Моны 90 нчы еллардагы милли күтәрелешнең шифалы кайтавазы дип уйларга кирәк.

Моннан ике ел элек, журналыбызның мең саны нәшер ителү уңаеннан "Сүнмәс утлар балкышы" дигән, энциклопедик характердагы зур күләмле китап чыгарган идек. Ул елдан-ел халыкка күбрәк ирешеп, укучылар күңелен яулый бара. Сез кулыгызга алган "Казан утлары" журналының тәртип саны инде 1035кә житте. Яна меңнәр насыйп булсын!

Үткән ел язучыларыбыз белән укучылар арасында аралашулар күп булды, бәйләнешләр шактый ныгыды, дип уйлыйм. Үткәндәге классик һәм бүгенге күренекле әдипләребезнең үзебездә һәм бүтән төбәкләрдә дисталәгән онытылмаслык кичәләре, йөзләгән очрашулары узды. Димәк, очрашыр халкың бар, укучыларың бар. Бер генә мисал: үткән елның сентябрь аенда Ульян каласының үзәгендә бөек шагыйрь Кол Галигә һәйкәл куелды. Зур мәгънәгә ия тарихи вакыйга. Бу уңайдан Бөтендөнья татар конгрессының халкыбызның үзаңын уятуда, әдәбиятыбызны пропагандалаудагы эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Конгресс оештырган чараларда безнең язучылар да еш катнаша. Алар ерак сәфәрләрдә булып, илләр гизә, дөнья буйлап чәчелгән милләттәшләребезнең рухи мирасын барлый, үзләренең иҗат офыкларын киңәйтә. Халыкара "Алтын Мөнбәр" кинофестивалендә тәкъдим ителгән тулы метражлы чын татарча "Өч аяклы ат" фильмы үткән елның якты бер бизәге булды. Безнең авторның (А. Хәлим), иң әүвәл журналыбызда басылган әсәре буенча (режиссер Н. Жамали) эшләнгән фильм ул. Димәк, әсәрләребез сәнгатьнең бүтән өлкәләрен үстерүгә дә өлеш кертә. Үткән ел Татарстан китап һәм "Мәгариф" нәшриятларында бүгенге язучыларыбызның йөзгә якын китабы дөнья күрде...

Мәгълүм хакыйкать: халык кояш астында тулы тормыш белән яшәргә теләсә, ана өч нәрсә кирәк—хезмәт сөяргә, тарихын һәм талантларының кадерен белергә. Беренче шартны безнең халык яхшы ук үти шикелле. Әмма соңгы икесе турында кистереп уңай җавап бирү кыен. Бигрәк тә хәзер, бик күпләрнең күзләре акча күләгәсендә томаланган чакта. Элегрәк, әдәбият-сәнгать турында сүз барганда Ленинның мондый сүзләрен еш әйтәләр иде: "Талант—сирәк нәрсә!" Чыннан да, иҗатчы, әйтик, шагыйрь бөек шигырь язса, композитор берәр үлемсез көй чыгарса, рәссам мәңгелеккә калырлык картина-сурәт ясаса, алар бит бернинди акчага да биргесез илаһи ачышлар, табышлар була бит инде! Әгәр бүгенге җәмгыятьтә алар бәһаләнми икән, монда иҗатчының гаебе юк. Әйтик, бер шагыйрь татар яки чуаш телендә гаҗәеп шигырь яки поэма иҗат итте ди, ә халык, бу очракта укучы, аны бар дип тә белми икән, уйланырга гына кала. Талантлы шәхес үзенә тигәнен эшләде—бөек әсәр тудырды... (Язмамны тәмамлар алдыннан очраклы рәвештә "Звезда Поволжья" дигән газетадагы баш мәкаләгә күзем төште. Мәкалә ахырында болай диелгән: "В общем, дорогие татарские писатели, выхода не остается—будете писать на уровне Шекспира, Достоевского, язык сохранится, а не сумеете выдержать планку, похороните язык своим серым творчеством." Килешәм: бөек язучылар иҗатына тиң әсәрләр язарга кирәк. Безгә Тукай дәрәҗәсендә язганда да бик ярап торыр иде. Әйткәнемчә, кемдер үз ана телендә бүгенге заманның бөек әсәрен иҗат итте ди. Ә аны кем бәяләр соң? Мәкалә авторы Рәшит Әхмәтовме? Мәсьәлә, кемнәрдер уйлаганча, бер каптырмалы гына түгел шул. Тегe яки бу телдәге әсәрне беренче чиратта, әнә шул әсәр туган телнең варислары бәяләргә тиеш. Ул иң чын, гадел бәя булыр. Бигрәк тә шигъри әсәрләрне бәяләгәндә.) Җәмгыять, бәлки, иртәме-соңмы аны бәяләр дә, ә бит әле дөньяның бүгенгесе бар! Дөресен әйтим, хәзерге заман иҗат кешесенә яшәү

һәм иҗат итү шактый авыр. Әдәбият-сәнгать дөньясындагы төрле буын кешеләре белән аралашудан чыгып әйтәм мин бу сүзләрне. 2008 елның май аенда үткән язучылар корылтаенда җитәкчеләрнең һәм делегатларның чыгышларыннан соң, каләмдәшләр аннан рухланып, күңел күтәренкелеге тоеп чыкты дип әйтә алмыйм. Һәр иҗат оешмасының, һәр аерым иҗатчының дөнья кадәр мәсьәләләре бар. Язучылар һәм матбугат әһелләре өчен бу соңгы елларның һәммәсендә дә берәр күчеш, үзгәреш, чигенеш булмый калмады бугай... Бик күп газет-журналлар дәүләт карамагыннан акционерлар җәмгыяте химаясенә күчәргә мәҗбүр булды. Төп нәшриятләр шәһәр үзәгеннән читкә—Архангель зираты кырыена күчерелде. Үткән елда да булды хәлләр! 2008 ел Тукай рухы рәнҗетелү елы да дияр идем. Бөек шагыйрь яшәгән "Болгар" кунакханәсен җимереп, җир белән тигезләделәр. Бу вандаллыкка прелюдия шикелле, язын Тукай исемен йөрткән премияләр дә, Дәүләт бүләгенең дәрәҗәсен төшереп, нигездә, үзешчәннәргә бирелде. Тукай рухы рәнҗегәндер үткән ел, рәнҗегәндер...

Бүген кая барма, кемне генә очратма, глобаль кризис турында сөйлиләр. Язгы болыт кебек тиз генә узып китәргә охшамаган, озакка сузылыр, диләр. Шулайдыр, аңлаганнар белеп әйтәдер. Аның каты канаты, әлбәттә, һәркемне сыйпап узар. Шулай да, әлләни югалтырлыклары булмаган иҗат кешеләрен бигүк куркытмый да ул кризис. Алар инде күнеккән: үзләре төрле яктан байтак еллар буе кризис кичерәләр... Ничек кенә авыр чор булмасын, бер үтәр ул кризис дигәннәре. Акча таулары өстендә ләззәтләнеп «кызынып» ятучы дөнья магнатлары үзләре башлаган "уен"нарыннан бер туяр... Ә менә күңелләргә кара юшкын булып утырган рухи кризис ... монысы аның чыннан да хәтәр инде!

Менә шулай, мажор белән башлыйсың да, уйлана-уйлана еш кына үзеннән-үзе минор халәткә күчәсең, күчәргә мәҗбүр буласың. Кемгә ничектер, кайчак йокысыз кара төннәрдә башка шомлы уйлар килә. Һич кенә дә куып җибәреп булмый аларны. Хәтта куркыныч та булып китә. Сәгатьләр үтә, таң беленә, офыклар алсулана. Шыксыз уйлар, ниһаять, кача. Күзгә яктылык нурлары иңә. Торасың. Хәрәкәт-яшәү башлана. Дөнья ямьләнә. Үзеңнән дә шуңа яңа ямь өстисе килә... Моннан нәкъ кырык ел элек мондый бер шигырь язган идем. Шул искә төште.

## НИНДИ БЕТМӘС ЫШАНЫЧ БУ?

*Янган-көенгән чакта,*
*башың иелгән чакта,*
*кайгың өелгән чакта,—*
*беттем!—дисең... Күзең ачсаң,*
*Вөҗданың белән бергәттән,*
*Ышаныч тора сакта,—*
*кешелегеңне саклап.*

*Нинди үлмәс Ышаныч бу!*
*Үтерергә теләп аны*
*эзли Мәкер, Өметсезлек,—*
*бетереп бар дөньяны.*

*Ә ул исән һәм сине әйдәр:*
*«Утыр,—дияр,—канатыма!*
*Югалма, туган, яшәрбез,*
*тормышны ярат кына!»*

*Нинди бетмәс Ышаныч бу!*
*Инде юктыр ул, дисәм,*
*упкыныма тау була ул*
*һәм яр сала: «Без исән»!*
*Тураям шундук, зурая*
*мәгънәм һәм максатым.*
*Илһамланам, бар җиһанга*
*таралыр күк яхшы атым!*

Киләчәктә дә шушы рухтагы шигырьләр язарга насыйп булсын дим. Иҗат кешесенең канаты—илһам. Дөньядан зарланып йөрү—илһам китермәс. Илһам өчен иң әүвәл бөек көч—ышаныч кирәк. Безгә ул һәрчак юлдаш булса иде. Хәерле Яңа еллар һәммәгезгә!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
Татарстанның халык шагыйре,
Татарстан Фәннәр академиясенең
шәрәфле академигы.

*Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган "Адәм баласы" исемле шигъри тупланманың аерым өлешләре журналыбызда басылып чыккан иде инде (2007 ел 2 сан, 2008 ел, 1 сан). Автор бишьюллыклардан торган бу тупланманы тулыландырып, аерым бер китап итеп эшләгән. Циклны шәкел—төзелеше ягыннан карап, аерым бер шигъри жанр дип бәяләүче галимнәр бар (Р. Ганиева, Р. Рахмани, Ч. Зариф һ. б.). Шулай ук шагыйрьләрдән, Р. Зәйдулла да шундый фикердә. Әйе, биш юлның һәрберсе тигез үлчәүдә, алты иҗекле. Һәр строфаның өченче юлы "Адәм баласы" сүзеннән яралып-үзгәреп, эчтәлекне адресатлы итә, шигырь асылына төшенергә фикри юнәлеш бирә. Ә шигырьләрдә—халыкның хикмәтле сүзләре—мәкаль, әйтемнәр белән, тәрбияви-әхлакый гыйбарәләр, фикерләр белән ныгытылган бүгенге чор, заман фәлсәфәсе, "ачы тәҗрибә авазы"—уйланулар. Бу юлда М. Мирза яңа шигъри ачышлар ясый дип ышанабыз. Алдыгызда—"Адәм баласы"ның яңа тупланмасы.*

**Рәдиф Гаташ**



Мөхәммәт
Мирза

# АДӘМ БАЛАСЫ

БИШЬЮЛЛЫКЛАР

* * *

**Чәчәге—чәнечке...
Яфрагы—ут энә...
Адәм баласының
теленәсе күңле
шул гөлгә үреlә...**

* * *

**Төш—җисем үзәге,
матди күренеше...
Адәм баласының
килү-китүе дә –
төше бүленеше...**

* * *

**...Тапканыннан артык
һич ни югалтмаган...
Адәм баласының
күрәсен—күрәчәк
пәрдәсе каплаган...**

* * *

**Тауны урап үткән—
үтә дә зирәктер...—
Адәм баласының
кыя-тау кичкәне
барыбер кирәктер...**

* * *

**Сала, кала корган,
чуен, тимер койган...
Адәм баласына
тәкъдир:—Мәңге эш!—дип,
тәгаенләп куйган...**

* * *

**Җылы сүзе—җанга,
суыгы—йөрәккә...
Адәм баласының
дәшми торуы да
барыбер йөдәтә...**

* * *

Кояшлы иртәдә
ызгыш-талаш корган
Адәм баласының,
бәхетен киртәләп,
шайтан тозак корган...

* * *

Гарасат авылны
туздырып бетерде...
Адәм баласының
гомергә җыйганы—
давылга бер көнлек...

* * *

Юрганына карап
аягын сузмаган
Адәм баласының
юраган тормышы
хыялдан узмаган...

* * *

Яшен яшәгән дә,
ашын ашамаган
Адәм баласына
ни дип дәшәргә дә
белми аптыраган...

* * *

Тәүбә итмәс борын...
Җәзадан котылган...
Адәм баласының
калган гомеренең
кояшы тотылган...

* * *

Йөзем, хөрмә мулдан,
хурлары, бакчасы...
Адәм баласының—
шул рәхәттән качып
китмәкче—барчасы?

* * *

Кирәксә—табыла:
һәрнидән хәбәр бар...
Адәм баласына
искәртеп куелган
хәләл бар, хәрам бар...

* * *

Базарда бар да бар,
Югы—яшерелгән...
Адәм баласының
Тыелган товары—
Намус әҗереннән...

* * *

Яшәү—мәгънә эзләү,
касәсе тулыдыр.
Адәм баласының
җавабын табар җир—
киек каз юлыдыр...

* * *

Газраил-фәрештә
килер, ул—гамәлдә...
Адәм баласының
шәмдәлендә гомре
янып беткән мәлдә...

* * *

Алыш-бирешендә
рибага бармаган
Адәм баласының
җиде буынының
табары: май да бал.

* * *

Орлыгы— яралгы
карындык түрендә...
Адәм баласының
тәкъдире ни язган:
шунда ук күренә...

* * *

Яман сүз—өшетер,
Мактау сүз—эретер.
Адәм баласының
тел төбендә йөрер
бер кашык дегете...

* * *

Аллаһы:—Бул!—дигән...
Җиргә инсан иңгән...
Адәм баласына
санынча бирермен,
нәфсен тыйсын!—дигән...

* * *

Гөлләрдән гөл матур,
таулардан тау биек...
Адәм баласының
башы күккә тиер—
бай бүреген киеп...

* * *

Хәер-шәфкатьлелек
сатылмый базарда...
Адәм баласының
барыбер тарганы
бар диләр аңар да...

* * *

Хәергә тарыган—
кемдер шәфкатендә...
Адәм баласының
саваплы хәере—
Ходай рәхмәтендә...

* * *

Эзе—йөргәненнән,
эше—кылганыннан...
Адәм баласының
җирдә калганы ни
йөз ел торганыннан?.

* * *

Тик чиләнгәч арты,
иярләгән атын...
Адәм баласының
вата-вата табар
чикләвеге каты..

* * *

Корыган агачка
кош оя кормаган...
Адәм баласының
хак имандагысы
потка баш ормаган...

* * *

Сугышта тапкан мал,
барыбер таланган...
Адәм баласының
иле-ыруының
әхлагы каралган...

* * *

Хеопс өйгән—таштан...
Аксак Тимер—баштан...
Адәм баласының
һәр пирамидасы
кан-яшькә буташкан...

* * *

Күленең—кипкәне,
урманы—корганы...
Адәм баласының
утырган ботакка
балтасын органы...

* * *

Ничек карасаң да
ай—йолдыздан якты...
Адәм баласының
тартып сузганы да
айдан-айга чаклы...

* * *

Буйсыну фарыз,—дип,
кемдер алдаганмы?
Адәм баласының
җәя тарттырырлык
хәле калмаганмы?..

* * *

Кичелмәгән дарья...
Күчерелмәгән тау...
Адәм баласының
дүрт саны төзек һәм
иманы булсын сау...

* * *

Уеннан уймагы
чыгып кына торыр...
Адәм баласының
уеннан алдарак
шайтаны котырыр...

* * *

Хөсетлек—үтмәс чир,
дәвасын кем табар...
Адәм баласының
күрше бакчасына
мең ел алтын явар.

* * *

Кендеге—әбидән
Сөннәте—бабадан...
Адәм баласына
хәер-фатихада—
төшүгә табадан.

* * *

Вакытсыз картайган—
ни кылса мантымас..
Адәм баласының
фәкать хөр күңеле
таякка калдырмас...

* * *

Ал бирсә—ат елый.
Бирмәсә—ул яна...
Адәм баласының
шуңар ирешкәне
ир-ат исмен ала...

* * *

Килере билгеле—
билгесез сәгатьтә...
Адәм баласы ни
үзгәртә ала соң
алдан белеп хәтта?..

* * *

Кояш йөрешендә –
елы... фасыллары...
Адәм баласының
шуңар бәйле—җирдә
яшәү асыллары...

* * *

Атканы—таңында...
Батканы—кичендә:
Адәм баласының
гомренең яртысы—
шул ара эчендә...

* * *

Тырышкан барыбер
ташка кадак каккан...
Адәм баласының
ата ялкавы да
белә шуны яттан...

* * *

Хаҗәте—йөгәнсез...
Әҗәте—дилбегә...
Адәм баласының
шуңарга тарганы
гомергә бил бөгә...

* * *

Бик тә бай юмартка
юлыгасы килә...
Адәм баласының
һәммәсе биектән
егыласы килә.

* * *

Җиләге—тәлгәштә,
алмасы—агачта...
Адәм баласының
әле ашыйсы бар
үрелеп алгач та...

* * *

Күк җиде түбәле
Җирнең—җиде каты...
Адәм баласының
Җаны һәм җәсәде
Шуннан урап кайтты...

* * *

Хиссез мәгънә—таштыр,
Уйны уй буташтыр...
Адәм баласының
Шигырьле мизгеле—
Күкләргә тоташтыр...

* * *

Кызыл шигырь язып
Дан-шөһрәт казанган
Адәм баласының
Иҗатын җирлиләр
Үзеннән алдарак...

* * *

Ике дөньяда да мал,
дан бүлеше бар...
Адәм баласының
савабынча табар
алтын-көмеше бар...

* * *

Байлык—бер айлыктыр,
ярлылык—гомерлек...
Адәм баласына
бетмәс байлык—Иман,
оҗмахка керерлек!

* * *

Мыскалга салынган
дөнья малы, гаме...
Адәм баласына
шайтан сузып тора
тыелган тәгамне...

* * *

Җиткәннәрме барып...
Калганнармы туктап...
Адәм балалары
көтү-көтү йөри
үлән-яфрак утлап...

* * *

Түләнмәгән бурыч,
үтәлмәгән вәгъдә...
Адәм баласында
гомер бетәсе юк
бер-берсенә дәгъва.

* * *

Юраган—юш килә,
ни килсә—буш килә...
Адәм баласына
телен тешли-тешли
кыйммәтле һуш[1] килә.

* * *

Яктылык елының
үзгә фасыллары—
Адәм баласының,
нурга әверелеп,
күрер—кайсылары?..

---

[1] Һуш – акыл, зиһен, тәҗрибә.

* * *

Йөргән таш—шомара,
йөргән акча—туза...
Адәм баласының
гомере таш актарып,
акча,—диеп уза...

* * *

...Таш пулат—курасы,
туп-тулы бурасы...
Адәм баласының
һаман саен кильә
бердәнбер буласы...

* * *

...Сокландыра кайсы,
кызгандыра кайсы...
Адәм баласының,
баксаң, нәкъ шул хәлгә
омтыла һәркайсы...

* * *

Җырында хәтере
җуелмас уелган
Адәм баласының
дөньяга әйтере:
"Карурман", "Уел"дан...

* * *

Җир-Ана! Хак бәя
тирәнтен уйласаң...
Адәм баласында
җирсү—иң самим хис,
хәтерен җуймаса...

* * *

Салават күпере—
күкләрнең әләме...
Адәм баласына
чистарынган саен
җибәргән сәламе...

* * *

Авызда кара кан,
ашында таракан...
Адәм баласын Хак:
—Төкерә күрмә,—дип,
кисәтеп яраткан...

* * *

Түбәтәе җәлпәк,
шулай да чигелгән...
Адәм баласының
башы ни кияре—
тәкъдирдә, диелгән.

* * *

Кояшны каплады,
көннең уртасында...
Адәм баласына
Тулган Ай, кисәтеп,
нидер әйтте сыман...

* * *

Бөек яралышның
даһи иҗатчысы
Адәм баласының
ҖИРенә төшергән
беренче яктысын...

* * *

Котып бозы эреп,
җирне туфан басар...
Адәм баласының
кем атлысы тагын
нинди көймә ясар?!.

* * *

Чиксез мәңгелектә
тыгыз янәшәлек...
Адәм баласының
куышы—газиз Җир,
оҗмахтай яшәрлек...



Нур
Әхмәдиев

# МӨНИРСТАН

РОМАН

*Фазыл җизнигә багышлана.*
Автор.

—Исәнме, туган йорт, исәнме, ата-бабаларым нигезе?!. Нихәл, өянке—син бит мине генә түгел, ыштансыз үрмәләп йөргән әтиемне дә хәтерлисең...

Ул ишек алдын, тәүге тапкыр күргәндәге сыман, капка баганасына сөялеп, мөмкин булганның барысын да күздән кичерде.

Әллә картаеп бара инде. Моңа кадәр бер дә болай ук хискә бирелгәнен, бәгырьләре эреп, күңеле йомшаганын хәтерләми. Ә бу юлы, күзләрен яшь элпәсе каплавын тоеп, исән кулы белән керфекләрен сөртеп алды һәм якягына караш ташлады: Тимер Мөнирҗанның йомшаганын берәрсе күрә күрмәсен тагын!

Ишегенең ачкычы урынында тора микән?

Ул ашыга-кабалана баскыч астындагы бүрәнә ярыгына күз салды. Шунда! Ничек куйса, шул көе. Көненә унлаган, йөзләгән талау-үтерешле "анасын эт ялаган" шушы заманда авыл халкының әле һаман намуслы булып калуы сокландыра. Әйе, авыл халкы кешенең энәсенә дә тими, нәрсә хәрам, нәрсә хәләл икәнен, иң кадерле мирасның берсе итеп буыннан-буынга тапшыра килгән. Кая да булса киткәндә дә, өй бикләүнең ни икәнен белмәделәр—ишек келәсенә чыбык яисә каз каурые гына кыстырып китәләр иде, янәсе өйдә кеше юк. Авылда халык бер-берсен белә, һәр өлкән кеше кемнең кем баласы икәнен таный, үзе дә сизмичә, педагоглар әйткән тәрбия процессында катнаша. Дөрес, авыл кешеләре үзгәрми тормый. Кызганычка каршы, тискәре үзгәрешләр кеше күңелен тиз яулый һәм моны белмәү авылыннан күпме еллар аерылып торган Мөнирҗанның зур бәхете иде.

Ачкычы кулында килеш ишекне ачып керергә ашыкмады Мөнирҗан. Җимерелә башлаган, ләкин әле төзәтсәң файдага яраРлык абзар кураяныннан урап килде. Мал асрамаса да чебиләр тотасы булыр, дип уйлады ул. Жим болгатып чиләнмәс өчен инкубатордан зурракларын алыр, бөртек кенә сибәсең дә, шуны чүпли-чүпли, чеби дигәнең тавык яки әтәч булганын сизми дә кала ул. Миңгерәү тавык булса да җан иясе бит, иптәш булыр.

Сагыштан тансыклаган караш белән Мөнирҗан ишек алдын кабат күздән кичерде. Кеше аягы басмагач, тапталмагач, ишек алдында үлән, күр ничек

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946)—*шагыйрь, прозаик; "Аһәң", "Ак бишегем", "Яралы күк" һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Әлмәттә яши.*

үскән! Ул песи борчагы, алабута, сарут, әрем, бәбкә үләне... Кычытканны әйткән дә юк— витаминнарнын да витамины булган кычыткан чәчәк атып утыра.

—Тавык идиллиясе!—дип уйлады ул, көлемсерәп.

Идиллия кебек сүзләрне ул махсус уйлап тормый, нәкъ кирәк вакытта алар тел очына үзләре килеп кунаклый. Югыйсә кайда ул югары, урта белеме дә юк. Ә авыл мәктәбендәге җиде класснын яртысы класс почмагында басып, яртысы коридорда җил куып узды. Бигрәк шук, тиктормас, шаян иде шул. Аның каравы укыган китаплар саны буенча Мөнирҗан белән ярыша алучылар сирәктер. Университетларны бүтән җирдә узарга туры килде ана. Һәрберсе Сорбонна, Гарвард ише генә идеме...

Ул туган нигезенә кайтуына шулкадәр шат, шулкадәр шат, егет чагы булса, берәүдән дә тартынмыйча:

> Галиябану, сылуым, иркәм,
> Шулкадәрле сагындым,—

дип җырлап җибәрергә дә күп сорамас иде.

Аннан зур бакча ягына карыйсы итте. Рәхмәт төшкере, кемдер бәрәнге утырткан икән ич. Ул күрше-тирәнекеннән үзенчә чисталыгы белән аерылып тора. Чүпсез бакчага каравы ук күнелле, күзләр рәхәтләнеп китә. Әнә ич, Миргали абзыйларнын бакчасында алабута, билчән, эт эчәгесе мыжгыган. Төрмәгә килгән хатларның берсендә күршеләренең вафаты, йортларынын буш торуы хакында язганнар иде. Балалары район үзәгендә яшиләр. Ихтимал, бәрәнгене дә шулар утырткандыр, кайтып утарга вакыт житкерәлми торганнардыр.

Ул үз уйлары белән шулкадәр мавыккан иде, кемнендер:

—Әссәламәгаләйкем!—дип сәлам бирүен ишеткәч, сискәнеп китте. Ни өчендер шунда ук күтәрелеп карыйсы итмәде, тавышыннан сәлам бирүченең кем икәнен хәтеренә төшерергә тырышты. Тавыш, һичшиксез, ана таныш иде. Тик кемнеке? Кайсы авылдашыныкы? Хәтерен җилләр артык нык иләгәндер ахры—исенә төшерә алмады.

Башын күтәреп, таныш түгел кешене күргәч, анын аптыравы көчәя төште. Миргали абзыйлар белән ике арадагы койма артында үзбәк түбәтәе кигән алтмыш яшьләрдәге бер ир басып тора иде.

—Исәнмесез!—Мөнирҗан күрешергә кулын сузды һәм шул минутта аларнын күзләре очрашты. «Тукта, кайдадыр күргәнем бар бит минем бу кешене! Кайда?» Тырышты, тик барыбер исенә төшерә алмады.

—Сез әллә монда яшисезме?—Мөнирҗан Миргали абзыйлар йортына ишарәләп күрсәтте.

—Әйе. Хатыным бу якныкы. Ул кайтыйк дигәч, кайткан идек, вакытлыча монда урнашып тордык. Ә сез—яна күршеме?

—Бу минем туган нигез!—Мөнирҗан, үзе дә сизмәстән, әлеге сүзләрне шундый горурлык белән әйтте ки, әйтерсең бу нигезне күз карасы кебек кадерләп, өф-өф итеп кенә тоткан.—Кайттым әле менә...

—Кайтуыгыз мөбарәк булсын, танышыйк алайса. Минем исемем Морат.

—Ә мин Мөнирҗан атлы булам.

—Юлдан кайткач, сусагансыздыр, чәйгә рәхим итегез, Мөнирҗан әкә.

—Рәхмәт, күрше, бүтән вакытта.

—Хуп, мәйлең...- Морат хушлашып китеп барды.

Ул китте, ә Мөнирҗан үз уйлары белән япа-ялгыз калды. «Кайда күргәнем бар иде соң бу кешене?»

Бу сорау аны әле шактый интектерәчәк иде.

Мөниржан өч ел дәвамында яңгыр юып, кар ашап, җил сибереп, болай да борынгы имән такталарга тагын да кадимирәк төсмер өстәлгән баскычка утырды. Ашыкмыйча гына тәмәке кабызды һәм «университет»ларын, аларда укыган «студент еллары»н исәпләргә керешге. Алтмышны тутырып, җиденче унлыкны вакласа да, шөкер, хәтере әйбәт. Шуңа күрә гомерендә инде ничә тапкыр исәпләгән нәрсәне кабат хәтеренә төшерү әлләни авыр булмады. Сигез «университет»та барлыгы утыз дүрт ел «укырга» тиеш булган да бит, башы эшләгәч, экстерн тәртибендә унсигез ел эчендә тәмамлаган икән аларны. Менә шуннан белегез инде абзагызның кем икәнен. Ул булган «университет»ларда вакытыннан алда теләсә кемнән «имтихан» бирдертмиләр. Ә Мөниржан, монда чакта ирекнең кадерен белеп бетермәсә дә төрмәдә үзен бик тәртипле тотты. Башка тоткыннар белән конфликтка кермәде, коткыларга бирелмәде, куштанланып йөрмәде, ләкин начальствоны санлады. Сул кулы беләгеннән өзек булса да төрмәдә уздырылган концертларда бер-бер артлы татар, башкорт, урыс көйләрен тальян белән хромкада уйнап, болай да тулып ташырга әзер торган күңелләрне урыныннан кузгата, айлар, еллар буена җыелган буаларын ера иде ул. Хәтта ни каты бәгырьле закондагы каракларның күңеле йомшый: «Мунирка, Мунирка дорогой!»—дип кенә торалар, башкалардан җәбер - золым күрсәттермиләр.

Дөрес, зонада консерваторияләр тәмамлап, дөнья корифейлары әсәрләрен су урынына эчүче һәм аларны төрле уен коралларында бик оста башкаручылар да очраштыргалый. Дөнья бит... Ләкин аларның артык дөрес уйнауларымы, бүтән сәбәпме—ни өчендер тоткыннар күңелен алай ук әсәрләндерми, җилекләренә төшәрлек тәэсир итми. Бәлки Мөниржанның стажлы зек булуы да роль уйнагандыр. Бәлки союз төрмәләрен айкаган, исемнәре җинаять дөньясында танылган әллә кемнәр белән аралашкан, сыңар кулын сугышта өздергән татар абзыен төрмә авторитетлары үз кеше итеп карагангадыр. Бу хакта Мөниржан уйланмады түгел, уйланды, төгәл бер фикергә генә килә алганы юк.

Әйе, начальство да үги итмәде, тоткыннар да какмады-сукмады Мөниржанны һәм кайчакта үрнәк тәртибе өчен, ә кайчакта Бөек Ватан сугышы инвалиды булганга, амнистияләргә эләгеп, вакытыннан алдарак кайтарып җибәрәләр иде аны. Бер генә тапкырында да башыннан азагына тикле утырмады ул.

Төрмә тормышына Мөниржан шулкадәрле күнеккән иде ки, әйтерсең аның өчен иректән аерылу кәгазьдә генә булса да бар саналган хокукларыннан мәхрүм ителү түгел, күрше авылга утырмага яки командировкага гына барып кайту иде. Ә нигә командировкага димәскә, барасың, вакытыңны тутырасың, кайтасың. Уйлап карасаң, командировкага карый өстенрәктер дә әле, чөнки командировкада өс-башыңны карыйсың, тамагыңны туйдыру хәстәре турында кайгыртасың. Ә төрмәдә ашау байдан, үлем Ходайдан. Чулак булгач, Мөниржанга эшнең авырын кушмыйлар.

Зонада утырган чакларында, кемнәр белән генә аралашырга туры килмәде аңа: ул кеше үтерүчеләр, көчләүчеләр дисеңме, бурлыкны нәсел-нәсәбенең данлы традициясе санаучы эреле-ваклы караклар дисеңме —йа, Хода! Доцент, фән кандидатларын әйткән дә юк, академик, профессорлардан алып үз гомерендә мәктәп бусагасын атлап карамаучыларга тикле бар иде. Танылган артист белән рәссам, музыкантларны да хөкем төрмәнең шестеркалары белән бер рәткә куя. “Гадел хөкем” нинди генә талантларны җыеп китерми бирегә! Йә әйт инде: Николай Краденов ясаган ялган акчаларны чыныннан ничек гади күз белән аерасың? Хәтта салган баштан мәҗлестә кайсыдыр Мәскәү журналистының борынын тешләп өзгән татар язучысы белән дә утырырга туры килде. Арада энә кадәр гаебе өчен дөя

кадәр җәза алып, эчтән сызып йөрүчеләр дә, судан коры диярлек чыгып, төрмәне ял йорты урынына күрүчеләр дә җитәрлек. Монда утыручыларның кайберләре исә бөтенләй гаепсез.

Төрмәнең язылган һәм язылмаган үз законнары бар. Шул ук тоткыннар тузлар, корольләргә... шестерка-алтылыкларга бүленгән. Иректә дә шулай... бугай. Мөниржанның ишеткәне бар. Әгәр дә шушы иерархия, касталар булмаса, төрмәдә тулы анархия хөкем сөрер, ата улны, ана кызны белмәс иде.

Төрмә законнарының нинди көчкә ия икәнлеге хәтта мәзәкләргә дә кучкән. Камерага бер-бер йодрыгы ике потлы гергә тиң әзмәвердәй рецидивистны кертәләр. Ул сорап, әдәп саклап тормый, керә-керешкә мона кадәр камераны дер селкетеп торган ристанның ипиен алып ашый. Аннан соң күңеленә хуш килгән урынга менеп ята. Беркем бер сүз әйтә алмый. Закон көчләнеке.

Менә ипи хуҗасы кайтып керә. Ипиенең юклыгын күргәч, дәһшәтле тавыш белән:

—Кем ашады минем ипине?—дип, камераны яңгырата.

Яңа тоткын яткан урыныннан теләр-теләмәс кенә башын күтәреп:

—Мин ашадым. Нәрсә, әллә ошамыймы?—ди.

Аның кыяфәтен күргәч, камераның элеккеге хуҗасы шунда ук тавышын үзгәртә:

—Юк-юк, май белән ашадыңмы, әллә болай гынамы дип беләсем килгән иде.

Ничә ел утырып, шунысына төшенеп бетә алмады ул: чираттагы тоткын әле килмәгән, кем киләсен төрмә начальствосы да юньләп белми, ә мондагылар бер ай-ай ярым алдан кайдан кем күчереләсен белеп, дәрәҗәсенә карап каршы алу хәстәрен күрәләр.

Социалистик җәмгыятьнең төп үзенчәлекләреннән берсе, дип өйрәтә иде марксизм-ленинизм,—план белән яшәү. Ул барлык өлкәләрдә дә, рак метастазлары кебек, шулкадәр киң җәелгән ки, исең китәрлек. Милициягә, суд, прокуратурага җинаятьчеләрне тоту, утырту планы житкерелсә, төрмәләрдә ул җинаятьчеләрне тәрбияләү планы бар.

Төрмә җитәкчелеге үзләре черетә торган икмәкне ничек тә булса акларга тырыша. Бәлки ул кадәр тырышмас та иделәр, алар өстеннән дә начальство бар. Тәрбия өлкәсендә бигрәк тә концертлар, кичәләр уздыру гадәти бер нәрсә. Хәтта КВНнар да уздырып карадылар. Ә төрле очрашуларның исәбе-хисабы юк. Тик төрмә халкы, аның сазаган рецидивистлары теләсә кем килеп акыл сатканга риза булып утырырга яратмый, аның чыгарып саласы партбилеты юк, премиясен кисмиләр, моның өчен срок өсти алмыйлар, димәк, югалтыр нәрсәсе калмаган. Берсендә «Человек и закон» журналы баш редакторының урынбасары килгән иде, төрмә начальствосын дер калтыратып тота торган журнал димәделәр, социализмдагы гаделлек турында акыл сата башлагач, биш минуттан Мәскәү әфәндесен мөнбәрдән сызгырып куып төшерделәр.

Күп очрашуларның тагын берсе Мөниржанның бик хәтерендә калган. Ватан сугышында җиңүгә утыз ел тулуга хәзерлек көннәре иде. Төрмә клубына тоткыннарны бер Советлар Союзы Герое белән очрашуга җыйдылар. Чыгыш ясаячак кешенең исем-фамилиясенә игътибар итмәгән иде Мөниржан. Итсә, бәлки... Әй, үзе дә сугыш күрмәгән, дары исен иснәмәгән кеше түгел, кемнең ничек Герой булганын яхшы белә. Өчәр Алтын Йолдыз тагарга тиеш булып та, гвардия значогыннан башканы күрмичә кайтып китүчеләр дә күп булды. Мисал өчен ерак барырга кирәкми, ничә тапкыр үлемнән чак исән калып, кая ул орден, медале дә юк Мөниржанның. Һәм ул моңа рәнҗеми дә, чөнки сугышканда күкрәгеңә калай тагар өчен сугышмыйсың, анда ил өчен, Ватан өчен кан коясың

һәм иң зур бүләк тә—шул мәхшәрдә башыңның исән калуы. Тагын бер нәрсәгә шөкранә кылып туя алмый ул: яраланып әсир төшмәде. Әсирлектә булганнарның язмышы ничек төгәлләнгәнен яхшы белә.

Төз гәүдәле, күкрәге Герой медаленнән тыш башка бүләкләр белән дә тулы полковникның, кереп исәнләшү белән, беренче җөмләсе шул булды:

—Мин беләм, монда булыр-булмас, юк-бар кешеләр утырмый...

Тукта... Мөнирҗанга чыгыш ясаучының тавышы таныш тоелды. Әллә?.. Юктыр... Чынлапмы соң югыйсә?..

Полковник сөйли дә сөйли, бер генә дә акыл өйрәтми, ачыктан-ачык тәрбия белән шөгыльләнми, сугыш хәрәкәтләре, ничек җиңүгә ирешүләрен генә бәян итә. Хәтта кайберәүләр кебек мин шулай иттем, мин болай иттем дип тә шапырынмый.

Чебен очканы да ишетелерлек тынлык. Зал полковникның авызыннан чыккан һәр сүзне йотып, йөрәге аша уздыра. Тоткыннар бу минутта полковникның әсирләренә әверелгәннәр иде. Ә бит очрашуга кергәндә, аларның кайберләре сызгырырга җайлырак булсын өчен алдан ук кулларын сабынлап юып куйган иде.

Мөнирҗанның кешедә гаме юк, ул хатирәләргә чумып утыра. Унсигезе тулып кына үткән иде, 1944 елның җәендә ул үзе теләп фронтка китте һәм маршал Рыбалконың танк армиясенә эләкте. Авылда тракторда эшләгәнен исәпкә алганнардыр инде. Ләкин сугыш аның өчен җиде ай гына дәвам итеп калды. Җиңүне тәэмин итәр өчен киткән миллионнарча корбаннарның санын тагын бергә арттырудан Мөнирҗанны хәрби врачларның осталыгы, шәфкать туташларының керсез фидакарьлеге, Гайниягә карата булган чиксез мәхәббәте һәм Саклау урманнарыннан, Бабеч-Карамнан, Күч кулы тауларыннан җыеп ашаган балтырган, юа, кузгалак, ачы кукы, кымызлыкларның күзгә күренмәс витаминнары куәте белән ныгыган яшь организмы алып калды.

Юк, мондый ук очраклылык булырга мөмкин түгел! Әнә ич полковник үзе хезмәт иткән частьның номерын атады. Мөнирҗанның күңеленә бу сан шулкадәр тирән уелып калган иде ки, айнык чакта гына түгел, салган баштан та җиде төн уртасында уятып сора, ике дә уйламый әйтеп бирер.

Шул бит, шул үзе, аларның взвод командиры Ваня Корпухин бит бу! Мөнирҗан ничек сикереп торганын сизми дә калды:

—Ваня! Иптәш лейтенант!

Сөйләгән җиреннән полковник дерт итеп сискәнеп китте һәм кинәт туктап калды. Ул күзләре белән тавыш иясен эзләргә кереште. Шул арада төрмә замполиты Мөнирҗанга:

—Исламов, тик утыр!—дип ысылдарга һәм йодрык күрсәтергә өлгерде.

Тамаша яратучы төрмә халкы түземсезләнеп көтте: хәзер нәрсә булыр?..

Кунак полковник хәтта чайкалып куйды. Ул чайкалганда, орден-медальләре бер-берсенә бәрелеп, күңелле генә зеңгелдәшеп алдылар.

—Миша, Мөнир, рядовой Исламов, синме бу?

Полковник һаман үз күзләренә үзе ышанмый. Булмас, күренә генә торгандыр. Күренә генә дисәң, тавышы да... Аның тавышы бит. Әллә галлюцинация башланамы югыйсә?!

Полковник тагын бер тапкыр башкалар белән нәкъ игезәк кием кигән Мөнирҗанга текәлеп карап алды.

—Мөнир, син—исән? Син исән! Йа алла!—дип сөйләнә-сөйләнә Мөнирҗанга табан атлады. Идәнгә һәм тоткыннарга абына-сөртенә Мөнирҗан да урындыклар арасында калган бушлыктан аңа табан ашыкты.

Менә алар—ялтырап торган затлы киемдәге Герой һәм төрмәдән төрмәгә йөреп сытылып, изелеп беткән, арык тәнендә бетләрне аз симертмәгән мәхбүс— биш йөз кешелек залдагы мең күзнең очлы уклары кисешкән ноктада кочаклашып өч тапкыр үбешteләр дә чал чәчле башларын берберсенең җилкәсенә салып, тавышсыз-тынсыз еларга керештеләр. Бу минутта Герой белән мәхбүснең хокуклары тигезләшкән, алар бер үк хәлдә иделәр.

—Менә бит, Мөнир, көтмәгән, уйламаган җирдән...

—Ә мин, Ваня, таныгач та ышанмый тордым...

—Сине бит мин исәннәр исемлегеннән сызып ташлаган идем инде...

—Мин дә...

Шулай тагын күпме торырлар иде, тоткыннарның көчле алкышы аларны 1945 елның гыйнварыннан төрмә клубындагы чынбарлыкка кайтарды.

Төрмә түрәләре ни эшләргә дә белмичә югалып калды: карап торсаң да килешеп бетми, бүлдерсәң дә әллә ничек.

—Иван, бар, сине көтәләр,- диде аларның хәлен аңлаган Мөнирҗан.

—Соңыннан китәргә ашыкма, көтеп тор, яме!—Полковник кабат мөнбәр артына барып басты, янагы буйлап агып төшкән яшьләрен, борынын кульяулыгы белән сөртте, кесәсеннән тарак алып, чәчләрен төзәткәндәй итте.

—Гафу итегез,—диде ул, стакандагы суны йотып куйгач. -Бүген сезнең алдыгызда басып тора алуым белән мин гвардия рядовое Мөнир Исламовка бурычлы. Дөресен әйткәндә, ул Герой исеменә лаек иде. Соңыннан хатлар да язып карадым. Кызыл Йолдыз ордены белән генә бүләкләнде, диделәр. Ә мина Советлар Союзы Герое исемен японнар белән сугышканда бирделәр.

Тоткыннар гөр килде. Җинаятьчеләр генә димәгез, аларның да җаны бар, бергә утырган иптәшләре өчен горурлык хисләре бар! Янәшәсендә утыручылар шул минутта ук Мөнирҗанны күтәреп алып, өч тапкыр түшәмгә кадәр чөйделәр.

Герой исеме? Кызыл Йолдыз ордены? Мина?.. Әкият сөйләмә, Ваня, мин аларны күрү түгел, ишеткәнем дә юк. Бигрәк көтелмәгән хәбәр булды ла бу...

Корпухин истәлекләрен хәзер Мөнирҗанга бәйләп сөйләргә кереште. Мөнирҗан исә аны тыңлый да, тыңламый да. Аның башында хатирәләр гарасаты, уйлары буйсынмый, уйларның үз туксаны туксан.

Мөнирҗаннан күп булса ике-өч яшькә генә өлкәнрәк кече лейтенант аларны өйрәнү пунктыннан үз взводына кабул итеп алды. Танк йөртүче Мөнирҗан Исламов, Ходай кушыптыр инде, командир экипажына туры килде. Ут эчендә туган дуслык яндырылган балчыкка, чыныктырылган корычка карый да ныграк була икән. Кирәк чакта взводтагылар бер-берсе өчен җаннарын фида кылырга да әзер иделәр.

Ходай аларны сакламады дисәң, яшен сугар—саклады. Инде взводтагыларның дүрттән бере диярлек һәлак булды, ә командир экипажындагыларның, тьфү-тьфү, яраланганнары да юк.

—Син, Исламов, безнең бәхеткә, күлмәк киеп тугансың,- дигән иде бер тапкыр Корпухин.—Синең аркада без дә исән-сау йөрибез бит менә.—Бу вакытта аның погонына тагын бер кечкенә йолдыз өстәгәннәр иде.

Чыннан да, моңа кадәр хәвеф-хәтәрдән исән чыгуларында Мөнирҗанның табигый тоемлавы, оста маневрлары роль уйнамый калмагандыр. Югыйсә әнә, минага эләгеп, күпме танк шартлады, күпмесе янып эштән чыкты.

Әллә сәгате җиткән, әллә лейтенант күз тидерде, шул сүзләрдән соң атна да үтмәде, Н. авылына һөҗүм иткән чакта, немецлар каты каршылык күрсәттеләр. Мөнирҗаннарның танкы дошманның әллә ничә ут ноктасын

изде, пехотасын кандала урынына сытты, пулеметтан кырды. Кайнар сугыш булды ул. Инде исән-сау гына авылга керәбез дигәндә, фашист орудиесенең бер снарядны эләгеп, танкның башнясын алып ыргытты. Коточкыч шартлау тавышы һәм зур тизлектә барган танкның кинәт туктап калуы Мөнирҗанны мингерәтте. Эссегә түзми аңына килүгә, беренче эше итеп, ул як-ягына каранды һәм әрмән абзые укчы Григор Варданянның өзелгән башын күреп, тетрәнеп китте. Хәтта күпмегәдер кабат аңын да җуйды бугай әле ул. Ләкин танк дөрләп яна, эчкә төтен катыш сөрем тулган, ул күзне ачыттыра. Металл инде ут булып кызарга өлгергән, танк корпусының тимеренә кагылсаң көйгән ит исе чыга.

Мөнирҗан урыныннан кузгалды һәм, тышка сикерәм дигәндә генә, ыңгырашкан тавыш ишетеп тукталып калды. Кем булыр бу? Григорның бүтән беркайчан инде тавышы чыкмас, урыны оҗмахта булсын.

Ә командир кайда? Ничек ул үз командиры турында оныткан? Ниһаять, ачылып бетә язган һәм танк эчендәге газдан яшьләнгән күзләре белән Мөнирҗан күтәрелергә маташкан лейтенантны шәйләп алды. Озын-озак уйлап торырлык вакыт калмаган иде инде, ничек итсә итте, мең бәла белән булса да, ул Ваняны тышка сөйрәп чыгара алды. Ничек көче житкән, ничек янып үлмәгәннәр, исенә төшкән саен, әле дә булса тәненә каз тиресе йөгерә.

Алар чыгып, бераз читкәрәк китеп өлгергән иделәр—танк эчендә калган снарядлар коточкыч гөрселдәү чыгарып шартлады, як-якка тимер ярчыклары, тагын әллә ниләр очты. Лейтенантка, йә булмаса үзенә берәр ярчык тидеме, Мөнирҗан моны сизмәде, командирны үзебезнең якка сөйрәвен белде. Корпухинның чибәр йөзен танырлык та түгел, битенә кан укмашкан, аяклары яралангандыр күрәсең—җирдән сөйрәлә. Аңына килгән чакларында ул:

—Миша, калдыр, җәфаланма минем белән!—дип гозерләнде.

Бу хакта Мөнирҗан тыңларга да, ишетергә дә теләмәде. Ничек инде яралы командирыңны калдырып китмәк кирәк, аннан кеше күзенә ничек күренерсең дә шушы намусың белән ничек яшәрсең? Сүз дә юк, үзе генә булса, ул күп тапкырлар тизрәк китә алыр иде. Лейтенант, бераз булса да ана эшне җиңеләйтергә теләп, аягына басарга, үзе атларга омтылып карады. Кая ул! Алай да бер талпынуында ул ике тезе һәм терсәкләре ярдәмендә хәрәкәт итә башлады. Хәзер инде аның кай җире яралануын тәгаен гына әйтүе дә кыен иде, чөнки, танктан чыгуга, гыйнвар кары шинельгә кан белән аралашып катты.

Шул рәвешле күпме тырышканнардыр, сызгырып килгән снарядларның берсе алардан ерак түгел генә төшеп ярылды. Мөнирҗанны кар эскерте күмеп китте, һәм ул бүтәнен бөтенләй хәтерләми дә.

Бәхетләре бар икән, өшеп үлмәделәр—аларны санитарлар табып алып, беренче ярдәм күрсәтүгә, шундук самолет туры килде һәм икесен дә хәрби госпитальгә озаттылар. Мөнирҗан ике атнадан соң гына аңына килде һәм, аңына килгәч, аның беренче соравы шул булды:

—Ә лейтенант кайда?

Сорауны ишеткән медперсонал җилкәсен генә җыерды: чөнки бу сорау алар өчен артык вак иде. Сугыш тегермәне дүрт елга якын вакыт эчендә үз ташлары аша лейтенантларны гына түгел, алардан өлкәнрәк чиндагыларны да җитәрлек уздырды. Күпме үтте алар кулы аша солдат-сержанты, лейтенант-капитаны һәм башкасы. Хәтта генераллар да эләкте. Эләкми ни, сугыш бит ул качышлы уены түгел, ядрә дә бусы солдат, бусы генерал дип сайланып тормый, гамәл дәфтәренә язылган икән, килеп тия дә аудара.

Аңына килгән көн, ихтимал, Мөнирҗан гомерендә иң бәхетле көн булгандыр. Әйтергә кирәк, теге дөньядан кайтты, янадан туды бит ул.

Лейтенантны сораганнан соң бераз вакыт узгач, аның авызыннан тагын бер сүз чыкты: «Гайния!» Мөниржанның аңына килүенә сөенешкән шәфкать туташлары, телен көчкә генә әйләндереп әйтелгән бу сүзнең мәгънәсен аңларга тырышып баш ватты. Ләкин мона Мәскәү маржаларының гына көче житәрлек түгел иде. Түземсезләнеп Мөниржаннан тагын бер сүз көттеләр, ләкин яралы егетнең авызын ачарлык бүтән хәле булмады. "Гайния" дигән сүз госпитальдәгеләр өчен ачылмаган сер булып калды.

Егет хәлләнә төшкәнче, тагын шактый вакыт үтте. Ничектер беркөнне Мөниржан куллары белән битен сыпырып алырга теләде һәм сәерсенеп туктап калды: сул кулы терсәктән әз генә түбәндәрәк бөтенләй юк иде. Шул минутта ук зиһенен көйдереп: «Ә уны?»—дигән уй узды. Бәхетенә, уң кулы исән икән. Ләкин Мөниржан, моның никадәр зур бәхет икәнен аңлар дәрәжәгә житкәнче, шактый яшәргә тиеш иде әле.

Әйе, сул кулы өзелгәнгә баштарак нык кайгырды ул, ләкин, яши-яши, язмышның ике кулсыз калдырмавына, бер генә кулдан мәхрүм итүенә рәхмәтләр укып туймады. Ник дисәң, берсе булу—ике кулсыз калу белән чагыштырганда—олы бәхет. Исәне уң кул булса—бигрәк тә. Чөнки адәм баласының күбесе унагай, ул уң кул белән эшләп өйрәнгән. Өстәвенә Мөниржан гармунчы да бит әле. Шушы бармаклар гармун телләренә кагылгач, үзәкләрне өзәр моң чыга. Ә бака ягы?.. Анысын кушмый уйнарга да була ич.

...Полковник сөйли-сөйли дә: «Шулай бит, Исламов?»—дип, Мөниржаннан раслатып ала.

—Снаряд дулкыны алып аткач, мин Исламовның гәүдәсе очып киткәнен генә күрдем. Могжиза булмый диләр, менә бит, Исламовның исән калуы үзе бер могжиза булса, утыз елдан соң биредә безнең очрашуыбыз икенче могжиза.

Мөниржан полковникны тыңлый да, тыңламый да. Ул да бит командирын "үлделәр" исемлегенә керткән иде.

Чынлыкта исә татар егетенең таза гәүдәсе Корпухин өчен калкан ролен үтәде—күпләп сибелгән снаряд ярчыклары белән тишкәләнеп бетүдән коткарды. Элекке яралары өстенә бу юлы снаряд кыйпылчыгы лейтенантның нибары бер генә жиреннән—уң як кабыргасы тиресен генә сыдырып үткән иде. Калган ярчыклар Мөниржанның тәненә кереп баттылар. Хәрбиләрчә әйтсәң, дислокацияләнделәр.

Лазареттан соң аларның юллары аерылды: Мөниржан Мәскәүгә, Корпухин Казан госпиталенә эләкте. Жиңү көнен бер-берсенең исәнлеге хакында бихәбәр танкистлар икесе ике госпитальдә каршылады.

Сугышта чакта кайвакыт сагыну түгел, кычыткан жиренне кашырга да ара калмый. Ә госпитальдә... Монда вакытны ничек уздырырга белми интегәсең, сагыш баса. Сагыну хисе йөрәкне парә-парә китерә: авыл сагындыра, әти-әнисе, туганнары, дуслары сагындыра. Жанының жиденче тамырына кереп оялаган Гайния турында әйткән дә юк. Их, Гайния, кем уйлаган булай булыр дип! Сынар куллы гарип кемгә кирәк? Әллә соң янына бөтенләй кайтып та тормаскамы? Илдә чыпчык үлми диләр. Мәхәббәт ярасы да бер төзәлер, иншалла, төзәлми калмас.

Үзе шунда ук бу фикергә ризалашмаячагын аңлады: әле бит аның авылда әти-әнисе дә бар. Әгәр Гайния кире кага икән, ул чагында күз күрер.

Тере кешеләрнең сагындыруы бер хәл, анысын аңлап була, хет гармуны төшләргә кереп жәфаламасын иде, шул тальян гармуны искә төшүгә, хәтеренә Фазыл дусты килә.

Мөниржан белән Фазыл икесе бер елгылар. Йортлары да биш-алты өй аша гына. Әскәйдә исә, Сәлах карт әйтмешли, күршелек уң йортсыз бетми ул. Менә шул күрше малайлары бергә уйнап үстеләр, укырга да бер елны

керделәр. Сыйныфларында алар икесе дә иң яхшы укучылар булды. Аратирә талашсалар, сугышсалар да (малайлар арасында ни булмас), Мөниржан белән Фазыл гел бергә йөрде. Ләкин Фазылга Әскәй мәктәбендә өч кенә ел укырга туры килде—әтиләре Фазлыйәхмәт мулланы ыштансыздан күтсез дүрт баласы белән Магнитогорск якларына "халыклар атасы" Сталин әйткән "бөек социализм" төзелешенә сөрделәр. Гаепләре нидә булгандыр, анысын халык анлый алмый калды. Күрәсен, "бөек төзелешкә" укымышлы, затлы, зиһенле кешеләр кирәк булуындадыр. Чөнки Фазлыйәхмәт мулла авылның яңа икътисадый сәясәт чорында кинәт баеп, активлашып киткән Әхмәтшакир хажи, Әхмәтхан байлар артыннан кумады, хәтта сезонлы ялчы да тотмый иде. Бар эшен хатыны Хөршит абыстай, балалары белән үзе башкарды. Аның әле Мысыр, әле төрек мәкаме белән укыган Коръән аятьләрен халык яратты, үз итте, көтеп ала иде. Әскәйлеләр, җае чыкканда, үзләренең Фазлыйәхмәт муллалары белән читләр алдында мактану җаен ычкындырмады. Ләкин, өсләренә кара болыт килеп, яшен яшьнәгәч, бер гаепсез хәзрәтне дә, остабикә белән мәхдүмнәрне дә яклап кала алмадылар. Сталин ялчылары тырнагыннан коткарырсың, бар! Аларның да план үтиселәре, үзләрен күрсәтәселәре, хезмәт баскычлары буйлап югарыга үрмәлисе юкмыни! Югарыдагылар алдында кемнең соң ялтырап күренәсе килми?! Миһырбансыз сәяси арбаның ыңгырашкан тәгәрмәчләре астында калып, бер гөнаһсыз алты җан сытылды, изелде, гарипләнде. Каһирәнең атаклы Әл-Әзһәр дәрелфөнүнендә ислам дөньясының данлыклы галимголәмәләреннән сабак алган Фазлыйәхмәт Шаһи улы "бөек төзелеш" өчен ком-балчык, цемент измәсе әзерләде. Ләкин бик күпләр белән чагыштырганда алар бәхетлерәк икән—сөрелүләренә дүрт ел тулартулмас, ни могҗиза—хәзрәткә аклау килде. 1939 елның җәендә рухлары сындырылып, җаннары имгәтелгән Фазлый мулла гаиләсе Әскәйгә кайтып егылды. Алтау киткәннәр иде, бишәү кайттылар. Хәзрәтнең олы улы Котдус Магниткада калды, чөнки ул, комсомолга керү өчен, атасыннан ваз кичте һәм мулла белән остабикәнең мәңгелек күңел җәрәхәтенә әверелде.

Фазлыйәхмәт мулла Магниткадан бик бетеренеп кайтты. Хәзер инде аның моңлы мәкаме дә, ничектер, гыжлап, сызгырып кына чыга иде. Кайтканнан соң муллалыгын бөтенләй ташлады, хәтта, никах уку түгел, яңа туган балаларга исем кушудан да баш тартты. Күрәсең, тиешле органнар "доганы" аның үзәгенә үтәрлек, бар гомеренә җитәрлек итеп "укытып" җибәргәннәрдер.

Дус булып бергә уйнап үскәч, Мөниржанның Фазылга бәйле истәлекләре күп. Шуларның берсен һич кенә дә онытасы юк.

Алар беренче сыйныфта гына укыйлар иде, Мөниржанның иң өлкән абыйсы Гаяз тальян гармун сатып алды. Бик-би-ик тә уйнарга өйрәнсе килә иде аның. Килмичә соң, авылда гармунчылар күзгә кырып салырлык кына. Гармун уйный белгән егетне кызлар күз өстендә кара каш урынына гына йөртәләр. Кичләрен клубта да, берәрсе кунак-китем җыйса да, гармунчыларның исемнәре телдән төшми, урыннары һәрвакыт түрдән.

Ләкин, колагына сыер басса, син күпме генә кызыксаң да, юк икән ул. Ә Гаяз абыйсының колагына сыер гына түгел, сыер көтүе баскан иде, ахры, күпме генә тырышса да, көй һаман чыкмады.

Гармунның ялтыравыклы калайлары, дөньяга моң таратучы тылсымлы телләре Мөниржанның йокысын алды, ашаудан калдырды. Их, бер генә тапкыр булса да тотып карыйсы, тартып карыйсы иде шул гармунны! Мөниржаннан да бәхетлерәк җан иясе бөтен җир йөзендә булмас иде...

Ул өзми дә, куймый да, абыйсы янында бөтерелде:

—Абый, дим, абый, бир инде, бер генә тапкыр шул гармуныңны тотып карыйм инде...

—Кит моннан!—ди көй чыгаралмаганга җен ачулары кузгалган Гаяз.— Юмаган кулларың белән йөргән булма монда!

Мөниржан ялт кына кулларын юып килде:

—Менә, абый, юдым. Менә, ышанмасаң тотып кара, юеш!—Абыйсы ышансын өчен, ул кулын сөртеп тә тормаган иде.

Ләкин корыч та корыч, Гаяз абыйсы да корыч иде шул, кул юу гына җитмәде. Бу юлы ул;

—Сузма, дидем ич мин сиңа бисмилласыз кулларыңны!—дип җикерде.

Мөниржан алай гына бирешә торган малаймы соң!

—Абый, дим, бисмилланы хәзер үк әйтәм. Менә тыңла: әлпи, тиси... бисмилләһи иррахман иррахим...—дип бисмилла әйтергә керešте.

Ә Гаяз үзенең әле генә ни әйткәнен оныткан, Мөниржан аның гамендә дә юк, ул дәртләнеп гармун күреген тарта. Менә-менә хәзер көй чыгар сыман. Тик кая инде ул көй чыгу! Гаяз гармунга тотынса, өйнең астын өскә китереп чабышкан бәрәннәр, куркудан, морҗа арасына кереп поса. Ишек алдында тырманып тыныч кына йөргән кызыл әтәч, титибикәләрен ияртеп, абзарга ук кереп китә. Бәладән башаяк диләрме икән?

Гаяз үзен дә, өйдәгеләрне дә бер атна чамасы интектергәч, туеп, гармунын башта әбисе кыз чакта суккан җитен ашъяулыкка төрде, соныннан өйдәге бердәнбер сандыкның төбенә салып куйды һәм аның барлыгын да онытты. Ә гармун Мөниржанның төшләренә кереп йөдәтте. Сандык ул—өйдәге затлы саналган әйберләр саклана торган урын. Әбисенең:

—Улым, бар хәзинәбез менә шушында,—дигәнен ишеткәне бар Мөниржанның. Сандыкта әнисенең чулпылары, барысының да метрикәсе һәм бүтән документлары, сирәк-мирәк кенә өстәлгә чыгарыла торган тәм-том тора. Хәтта Мөниржан белән аның абый-апаларының беренче алынган чәчләре дә шунда саклана. Анысы ник кирәктер, Мөниржан һич кенә дә аңламый. Гармун ерак та түгел анысы, менә шушы сандыкта гына. Сандык ачкычы исә—чөйдә. Барысы да күрә торган урынга куйгач, ник кенә бикләләрдер ул сандыкны. Өйдә Мөниржанның сарык бәрәннәре белән япа-ялгыз калган чаклары да җитәрлек. Кулларны юып, ачкыч белән сандыкны ачасы да, бисмилланы әйтеп, ашъяулыкка төрелгән гармунны чыгарасы гына югыйсә. Ярамый! Әбисе сорамыйча алу урлашу була, ә урлашу бик зур гөнаһ, ди. Аллаһы Тәгалә барысын да күреп тора, урлашкан кешегә җәзасын бирә—аның куллары корый, ди. Мөниржанның гармун уйнап карыйсы килүе никадәр генә көчле булмасын, кулларының коруын теләми. Корыган кул белән ничек ашамак, ничек итеп ыштанынны күтәрмәк кирәк—монысын ул һич кенә күз алдына китерә алмый.

Ләкин туры юлга индерергә фәрештәләр булган кебек, бәндәләрне аздыручы, юлдан яздыручы шайтан, иблис ләгыйнь дигән нәрсә дә йоклап ятмый.

Көннәрдән беркөнне Мөниржан да мәктәптән (әбисе ни өчендер аны мәптек ди) кайтып ашап кына туйган иде, Фазыл килеп керде. Алар гел шулай инде, буш вакытлары булдымы, йә Фазыл Мөниржаннарга керә, йә Мөниржан Фазылларга.

—Әйдә уйнарга!

Бу тәкъдим никадәр генә мавыктыргыч булмасын, Мөниржан тәрәзәдән тышка күз салды да авыр сулап куйды. Тышта көз, салкын яңгыр сибәләп тора, ә Мөниржанның өстенә кияргә адәм рәтле киеме дә юк. Мәктәптән кайтканда да туңды. Шул исенә төшеп, ул калтырап куйды.

Моның ише чакта Мөниржанны ничек котыртырга белә Фазыл.

—Әй, куркак, шушы яңгырдан да шыр җибәрмәсәң!

Фазыл—мулла малае, өсте-башы Мөниржанныкы ише генә түгел. Ул

туңмас. Ни эшләргә?

Фазыл күреп тора: дусты икеләнә башлады, димәк, тагын әз генә кыздырырга кирәк.

— Әйтәм ич, куркак дип!

—Минме куркак?

—Син шул! Кайчаннан бирле гармун, гармун дип авыз суыңны корытып йөрисең, куркак булмасаң, әллә кайчан шул гармунны уйнап карар идең!

—Уйнармын да!

—Синең кебек куркактан булмый ул. Әйдә бәхәс!

—Әйдә! Әллә уйнамас дисеңме?

—Уйнамыйсың шул!

—Алайса бәхәсләшәбез. Нәрсә бирәсең?

Гармун уйнап караса, Фазыл Мөнирҗанга ике шакмак шикәр бирә дип килештеләр.

Мөнирҗан, сандык ачкычын алганчы, тәрәзәдән ишек алдына, урамга күз ташлады: аның бәхетеннән берәрсе кайтмыймы? Бер дә күңеле тартмый иде, ләкин иптәш малаеннан куркак сүзен ишетәсе килми! Эчендә җаны булган кайсы малай шундый мәсхәрәне күтәрсен ди!

Кызганыч, суга батканда тотынып калырлык салам күренми иде. Ул, тәвәккәлләп, сандык ачкычын йозак тишегенә кертте. Куркудан, дулкынланудан куллары калтырый башлады. Дулкынланырсың да, ул бит беренче тапкыр, белә торып, гөнаһ эш кыла. Ә куллары корыса? Бәлки кире уйларгадыр? Фазыл ул әйбәт малай, бер көләр дә онытыр...

Тик гармунны тотып, телләренә басып, бер тартып карау теләгенә Фазыл бирәсе ике шакмак шикәрнең онытылып бетә язган тәме килеп кушылды да, кулы аның ихтыярыннан башка ачкычны борып, сандыкны ачтырды. Бары тик сандыкларда гына була торган ят ис борынына килеп бәрелде.

Мөнирҗан гармунга үрелгәнче, Фазылга сиздермичә генә, кулларына күз төшерде: корый башламадылар микән?

Фазыл да аңардан ким дулкынланмый иде: дустының һәр хәрәкәтен күзләре белән ашардай булып күзәтеп торды.

Гармун төрелгән ашъяулыкны сүткәндә, Мөнирҗанның тыны кысылды, сулышына гүя ут капты. Әле сүткәч тә, бу тылсымлы гармунны шунда ук кулына алырга ашыкмады. Их, абыйсы бер тапкыр тотып карарга гына бирсә дә, бүгенге мондый гөнаһ эшкә кулы бармас иде. Кулыңны юу, бисмилланы әйт, диде. Ә үзе бирмәде. Алдакчы! Мөнирҗан бик рәнжеде үзенең абыйсына. Ярый, син җәлләсәң, мин аны үзем дә ала беләм!

Мөнирҗанның башында шундыйрак уйлар буталды. Ул, тәвәккәлләп, гармунга үрелде. Каешын җилкәсенә кигәнче, кабат урамга, ишек алдына күз салды. Берәү дә юк. Бисмиллаһи иррахман иррахим!

Менә хәзер бер могҗиза булыр да күптән хыялланган сихри моң ташкыны өй эченә тулыр. Өй эченә генә сыймыйча, урамга таралыр, капка төбендә үскән өянкегә, түбәдәге морҗага сарылыр.

Ләкин могҗизалар әкиятләрдә төшләрдә генә була шул. Мөнирҗан кулындагы гармуннан абыйсы тоткандагы төсле ямьсез тавышлар гына чыкты. Мөнирҗанның маңгаена, култык асларына салкын тир бәрде.

Ун минутлап гармунны җәфаларга өлгерделәр микән, бер күзен гармуннан, икенчесен урам тәрәзәсеннән алмаган Фазыл:

—Әбиең кайта!—дип аваз салды.

Бу хәбәр яшен суккандай тәэсир итте. Тиз генә ашъяулыкка гармунны төреп, әбиләре кергәнче, ике малай аны урынына салып та куйдылар.

Гармунны алганны сизүче булмады. Чөнки сандыкны көн саен ачып тору юк, ә Гаяз абыйсының гармуннан күңеле суынып өлгергән иде инде.

Кылган гөнаһлары җәзасыз калган малайлар икенче, өченче көнне дә

алдылар гармунны, чиратлап акырттылар, әмма алар өметләнгән, зарыгып көткән көй генә чыкмады. Шулай да алар күнелләрен төшермәде, мәктәптә чакта да, кайткач та гармун уйнау турындагы татлы хыяллар белән мәҗбүри сәгатьләрен уздыра торган булдылар.

Мавыгып китеп, зурлар кайтканны сизмичә, җинаять өстендә тотылу мөмкинлеге барлыгын аңларга әлләни баш кирәкми. Моны Мөнирҗан белән Фазыл да белә. Тора-бара алар Мөнирҗаннарның кара мунчаларын икесе өчен генә «консерватория»гә әверелдерделәр. Дөрес консерватория дигән сүз булуын да, аның нәрсә аңлатканын белер өчен дә бу малайларга үсәргә, бер пот тоз ашарга кирәк иде әле.

Мәктәпнең хуҗалык мөдире яки, гади халык телендә әйткәнчә, завхозы Госман абзый авылның танылган гармунчысы. Бушрак чакларында ул тәнәфестә гармунын коридорга алып чыга да малайларны, кызларны биетә. Моның ише чакта Мөнирҗан дөньясын оныта торган иде: Госман абыйсының кырыена килеп баса да аның тырнаклары җиткән юан бармакларының күз иярмәс тизлектә гармун телләре өстендә биюенә карап мөкиббән китә. Менә ичмаса гармунчы, менә ичмаса уйный. Дөньяда Госман абыйдан да оста гармунчы булмагандыр да, булмас та! Өйрәнәсе иде аңардан уйнарга! Бәлки үзеннән сораргадыр: ул ничек уйнарга өйрәнде икән?

Кыенсынып йөрде-йөрде дә беркөнне түзмәде, үзе генә чагын туры китереп, Мөнирҗан, бар кыюлыгын җыйды да Госман абыйсыннан сорады:

—Госман абый, әйт әле, гармун уйнарга ничек өйрәнеп була?

Хәйләкәр карт чыпчык күзен дә йоммый җавап бирде:

—Һи, апай, аның берние дә юк, бер гармунны яндырып, шунын көлен ашасаң, уйныйсың да китәсен.

Алай икән, имәндә икән чикләвек. Мөнирҗан элек тә кемнәндер ишеткән иде түгелме бу сүзне. Гармун яндырып, аның көлен ашау фикере малайның аң төпкеленә төшеп урнашты.

Ноябрь житте. Көннәр салкынайтканнан салкынайта барды. Иртәләрен туңдырып башлаган иде, көннәрдән беркөнне ап-ак кар төште дә бүтән эремәде. Колхоз эшеннән бераз бушаган өлкәннәр өйдә хәзер ешрак күренә. Теләсә кайчан сиздермичә гармун акырту куркыныч иде. Якмаган мунчада да салкын, бармаклар шунда ук күшегеп чыга.

Шулай да җай гел килми түгел, килә. Кичтән мунча ягып кереп, бүген иртә белән әти-әнисе Мөнирҗанның күрше авылга кияүгә чыккан олы апасының хәлен белергә, бер кич кунып кайтырга киттеләр. Абыйсы Гаязны эш белән колхоз бер атнага элеваторга җибәрде. Әбисе түбән очтагы ахирәтен күрергә төшеп китте. Моннан да җайлырак тагын нинди очрак булырга мөмкин!

Мөнирҗан башта гармунны мунчага илтеп куйды. Соңыннан Фазылны чакырып килде. Менә шунда Госман абыйсыннан ишеткән серне дустына чиште.

—Кит аннан!—Көтелмәгән хәбәрдән мулла малаеның күзләре шакмакланып чыкты.—Икмәктер!— диген!

—Икмәктер!

—Алдасам, күзләрем чәчрәп чыксын!—диген.

—Алдасам, күзләрем чәчрәп чыксын!

Моннан соң да Фазылның ышанмаска чарасы калмады.

Яндырып, гармунның көлен ашау теләге малайларда шулкадәр көчле иде, өлкәннәрдән качып мунчага кергән ике малайны хәтта изге фәрештәләр дә туктатып кала алмады...

Гармун уйнарга өйрәнү өчен бер уч көл җитәме икән, әллә тулысынча

ашап бетерергә кирәк идеме?

Фазыл гаепле төс белән басып тора иде, кинәт ул бик авыр сорау бирде:

—Мөниржан, Мөниржан, дим! Ә хәзер өйрәнергә кайдан гармун алабыз?

Менә сиңа мә! Бу хакта ничек алданрак уйламаганнар алар? Гармуннары булмагач, аның көлен ашаудан ни файда? Хәзер гармун кайдан алсыннар?

Мөниржан кинәт эсселе-суыклы булып китте: әле бит бу гармун өчен җавап та бирергә кирәк. Ни дияр, ничек җавап бирер? Гаяз абыйсының дәһшәтле кыяфәтен күз алдына китереп, ул бөрешеп, мескенәеп калды. Ләкин гармун кадәр гармунның өй түрендәге сандыктан рөхсәтсез алынуын да, аның яндырылуын да яшереп калып булмый. Гармун бит ул энә түгел. Бу очракта мин күрмәдем, белмим, дип кенә алдашып котыла алмыйсың, барыбер эзенә төшәчәкләр.

Гармун яндырганнан калган ялтыравык калайларны җыеп, Мөниржан кесәсенә тутырды. Аны хәзер бер генә уй борчый иде: гармун турында өйдәгеләргә ничегрәк итеп әйтергә?

Шушы уй ашарга утыргач та тынгылык бирмәде. Ничә тапкыр инде ул өстәл уртасындагы агач табакка үренгән җиреннән туктап калды. Мөниржан менә-менә әйтергә тели, ләкин авызын ачкач кына , тагын курку хисе җиңә.

Төпчек улының бу халәтен әүвәл әнисе абайлап:

—Улым, нәрсә булды? Ник ашамыйсың? Авырмыйсыңдыр бит?—дип сорады.

Әнисенең тавышы шулкадәр йомшак, назлы иде, Мөниржан түзмәде:

—Мин... мин гармунны яндырып, көлен ашадым,—дип әйтеп салды да елап җибәрде.

Өстәл артында утырган берничә кешедән берьюлы бер сүз чыкты:

—Ә?!

—Мин... гармунны яндырып, көлен ашадым,—дип кабатлады Мөниржан һәм өстеннән авыр йөк төшкәнен сизде.

—Алдашма!

Башкалар ни дә булса әйтергә өлгергәнче, абыйсы, йөгереп барып, сандыкны ачып карады. Карады да катып калды. Аның йөзе бер агарды, бер күгәрде. Гаязның йөзе яндырылган гармун калаена охшап калды. Тик бу халәте артык озакка бармады. Нинди тизлектә урыныннан торган булса, шул ук тизлектә, бәлки әле тизрәктер дә, табын янына килде һәм ашый торган агач кашыгы белән Мөниржанның өченче көн генә, бер тавык күкәе түләп, Миргали абзасыннан чалгы пәке белән кырдырган такыр башына менеп төште:

—Менә сиңа, тик кенә тора белмәсәң, маңка тәре!

Кызган көе ул энесенә тагын берне менеп төшәргә уйлаган иде, әтиләре тыеп калды:

—Кагылма, утыр урыныңа!

Гаптелихсан абзый кычкырмый, ләкин өйдәгеләрдән әле берсенең дә аңардан ике тапкыр әйттергәне юк.

Әтиләре кашыгын куйгач, калганнар да табакка үрелүдән тыелды.

—Йә, улым, сөйлә, кая куйдыгыз ул гармунны?

—Әйттем ич, яндырып көлен ашадык дип...

Өйдәгеләр күзгә-күз карашып алды: алай-болай бу бала саташмыймы? Әнисе түзмәде:

—Улым, әллә чирлисеңме?—дип сорады.

—Юк.

—Саташасын бугай...

—Саташмыйм.

—Алайса әйт, ниемә дип ашадыгыз инде ул көлне? Ашарга, нәрсә, икмәк беткән идеме?—Бусын Гаптелихсан абзый сорады.

—Уйнарга өйрәнер өчен.

—Нәрсә?

—Гармун уйнарга өйрәнер өчен...—Мөниржан хәзер баштагы кебек каушамый һәм курыкмый иде.

—Нинди сафсата сатасың син?

—Гармунны яндырып, көлен ашасаң гына уйнарга өйрәнәсең, диделәр.—Малайның күзе челт-челт йомылды, ул, чарасыздан, әле түшәмгә, әле идәнгә карады, өлкәннәрнең аптыраулы күз карашын күрү авыр иде ана.

Әтисе:

—Кайсы акыллы башы котыртты бу эшкә?—дип сорады.

Мөниржан әйтергәме, әйтмәскәме дип, ике ут арасында калды. Юк, әтисе сорагач, әйтми ярамас.

— Госман абый...

Бу исемне ишеткәч, әтиләре Гаптелихсан рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Ана әниләре дә кушылды. Бу көлү тавышы Мөниржанның күңелен күтәрә төште. Анын сабый күңеле күк күкрәү, яшен яшьнәүнең артта калганын аңлаган иде. Тик менә абыйсы кулына гына эләкмәскә кирәк. Гармун яндырган дигәч тә, ул бөтенләй үк башсыз малай түгел, моны гына аңларлык. Шуңа күрә, табынны җыештыргач, тиз-тиз генә дәресләрен карады да тыныч күңел белән йокларга ятты. Төшендә, ни гаҗәптер, үзенең өр-яңа гармунда уйнаганын күрде.

Икенче көнне яндырган гармун көле ашаган ике малай турындагы хәбәр бөтен авылга таралып өлгерде. Үртәп тә карадылар соң Мөниржан белән Фазылны. Әйтерсең, кешеләрнең бүтән бер эшләре дә юк. Ләкин иң гаҗәбе атна-ун көннән соң булды. Кичке ашны тәгаллләп, Мөниржан дәрес хәзерләргә утырган иде, ишектән, һич көтмәгәндә, Фазлый мулла килеп керде.

—Әссәламегаләйкем!

—Вәгаләйкемәссәлам, хәзрәт. Әйдүк, түрдән уз!

Кунакка, миндәр салып, сәкедә урын хәзерләделәр.

—Йомшакка утыр, хәзрәт.

—Әйдәгез, утырып, йортка бер дога кылыйк.

Өйдә черки безелдәгәне дә ишетелерлек булып тынлык урнашты.

Өлкәннәр шартын китереп дога кылганда, Мөниржан башын ватты: ник кергән бу Фазылның әтисе? Олы башы белән тикмәгә йөрмәс. Ул соңгы көннәрдә кылган гамәлләрен күңеленнән барлады, ләкин, гармун яндырып көлен ашаудан гайре кылган бүтән ярамаган эшен тапмады.

Хәзрәт барында шауларга ярамаганы хакында әйтеп торасы юк. Әле зурлар булып зурлар, урамда Фазлый мулланы күрсәләр, тарта торган тәмәкеләрен җиң эченә яшерәләр. Янгын каравылчысы Әкмәлетдин абзый шулай итеп үзенең чикмән җиңен яндырганы да бар.

Дога тәмам. Фазлый мулла тамагын килешле итеп кыра-кыра, исәнлек-саулык сорашты һәм әйтеп куйды:

—Карале, кем, Гаптелихсан, синең төпчегең белән безнең малай гармун яндырганнар дигән сүз йөри.

—И хәзрәт, яндырып кына калсалар бер хәл, көлен дә ашадык ди бит. Бала котырткан зурларын әйтер идем.

Зурлар, бер-берсенә карап, мәгънәле елмаештылар. Ә Мөниржан баш вата: ник килгән бу мулла абзый, әтиләренә ни әйтмәкче була? Гармун турында сүз башлады, хәзер өйдә җил-давыл купмасмы? Бәласеннән

башаяк дип чыгып сызар иде, хәзер вакыт соң. Тышта күзгә төртсәң дә берни күренмәслек карангы. Гатият тавы башында бүреләр улый. Узган атнада, фермага төшеп, колхозның тугыз сарыгын бугазлаганнар, диделәр. Шул бүреләрнең берәрсе ишек алдына килеп керсә һәм тотып алса?.. У-уу! "Әни!"—дип кычкырырга да өлгерә алмассың, ботарлап ташлар...

Куркудан аның тәннәре чымырдап китте.

—Менә шул, Гаптелихсан, кем, Минсафа килен, гармунның башына безнең малайлар бергәләп җиткәннәр. Бәс, шулай булгач, мин моны бер дә шайтан вәсвәсәсе димәс идем, икесенең дә гармун белән җенләнгән чагы. Аллаһы тәгалә шулай теләгәндер. Бирик үзләренә мөмкинлек, йөрмәсеннәр мунчада җен-пәриләр котыртып. Уйнасыннар, әйдә. Ходай тәгалә икесенең берсенә, бәлки, талант орлыгы тамызгандыр. Шәригать гармун уйнауны бик үк хуп күрмәсә дә, Ходай Тәгалә биргән сәләтенне тыеп тору да мәслихәт түгелдер. Качып-посып йөрмәсеннәр диюем... Өлкәннәрдән яшерен эш йөртү яхшыга илтмәс диюем, кем, мелла Гаптелихсан... Ут-күз дә бар дигәндәй, ыһым!

Мөнирҗанның колаклары үрә торды, тәненнән кайнар дулкын йөгереп узды. Фазлыйәхмәт мулла үзенең фатихасын бирә түгелме соң? Әтисе ни дияр тагын. Мөнирҗан, тын алырга да куркып, әтисенең җавабын көтте. Бераз тынлыктан соң, сакалын сыпыра-сыпыра, әтисе сүз башлады:

—И хәзрәт, кем уйлаган аларның хирыслыгы бу дәрәҗәгә җитәр дип. Белсәм, тыяр идемме?! Мин аны зур малайга дип алган идем, анысының рәт чыгара алганы юк. Бусы чеби генә, гармун артыннан башы да күренми торгандыр. Хәзер үкенүдән файда юк, буласы булган.

—Ник алай дисең?

—Гармун яндырылган, хәзрәт, көле ашалган. Безнең тагын берне алырлык хәл юк. Тегесен дә сарык сатып кына алган идек.

—Беләм, беләм...—Хәзрәт, сүзеннән туктап, Мөнирҗанның әле әтисенә, әле әнисенә карады.—Сезгә сугылуымның да сәбәбе дә шул иде, әгәр сез каршы килмәсәгез... мин алып килгән гармунны күрсәтер идем. Бәлки, кем, күнел шәрифләрегезгә хуш килер.

Барысын да гаҗәпкә калдырып, Фазлыйәхмәт мулла өйалдына чыгып китте һәм кулына тоткан төенчек белән кире керде.

—Мунча вакыйгасын ишеткәч, Хөршит абыстай белән мәслихәтләштек тә гармун алырга булдык. Шуны, бисмилла әйтеп, кабул кылсагыз иде...

Ул ашъяулыкка ныклап төрелгән тальян гармунны алып, Гаптелихсанга сузды. Тегесе тыйнак кына баш тартып, гозерен белдерде:

—И хәзрәт, син инде аны биргән биргән Мөнирҗан улымның үз кулына тоттыр. Белмәссең, теләгән теләкләребез фәрештәләрнең "амин" дигән чагына туры килер, төпчегебез гармунчы булып китәр.

—Барысы да Ходай кулында, кем, Гаптелихсан. Ал, улым, ал гармунны, Ходай Тәгалә сиңа сәләт ачкычлары бирсен.

Мөнирҗан әлеге күренешнең төш кенә булмавына һаман да ышаныр-ышанмас, хәлдә калтыранган кулларын гармунга сузды. Үзе әледән-әле әтисенә карап алудан туктамады.

—Бисмиллаһи иррахман иррахим...

Мәктәптә Коръән сүзләрен әйтмәскә кушалар, ләкин сабый күңеле аның җырлап торган сүзләренә үзе дә сизмәстән тартыла иде.

Малайның ихласлыгын хәзрәт бәяләми калмады:

—Бисмилла әйткәч, иншалла, Мөнирҗан балам, эшең унар. Йәгез, тагын бер дога кылыйк бу һәдиягә. Озын гомерле булсын.

Фазлый мулла чыгып киткәч, Мөнирҗанның әнисе күзендәге яшен сөртеп әйтте:

—Кеше түгел, әүлиядер бу Фазлыйәхмәт хәзрәт. Булса да булыр икән.

—Әйтмә дә инде, карчык. Ходай үзенә озын гомер насыйп итсен дә бәла-казалардан сакласын.—Аннан Мөнирҗанга карап сүзен дәвам итте.—Улым, ишетсен колагың, бу гади гармун түгел, мулла абзый биргән изге гармун. Күз караңны саклагандай сакла үзен. Ишетәсеңме, дип сорыйм мин синнән?!

Бәхетеннән кукнең жиденче катында йөзгән малай:

—Әйе, әти,—дип кенә җавап бирә алды.

Мөнирҗан ашыйсы барын да онытты, ул гармунга тагын да үҗәтләнебрәк тотынды. Гармун телләрендә, йөрергә яңа өйрәнгән мәче баласы кебек, чалый-болый атлаган бармакларга һаман саен ышаныч, ныклык иңә барды.

Ул күңелендә йөргән бүтән көйләрне дә уйнап карады. Тыңлаучылар аның нинди көй уйнаганын аңлар иделәрме, юкмы, анысы билгесез. Әмма Мөнирҗан сизде: гармун аны тыңлый, ул гармунчы булачак! Рәхмәт, рәхмәт сиңа, мулла абзый! Госман абыйсына да рәхмәт...

Дуслар арасында сер ятармы? Икенче көнне әсәрләнгән дусты янына Фазыл мәхдүм дә керде. Мөнирҗан аңа башта үзе белгәннәрне уйнап күрсәтте. Аның дустын да бик өйрәтәсе килгән иде. Ләкин Фазыл тирләп-пешеп бетте, кызарып чыкты, тик көй дигән нәрсәнең тамчысы да яралмады. Шунда аның:

—Их, көлен синең кадәр ашый алмадым бит, ашасам, мин дә өйрәнгән булыр идем!—дип ачыргаланып-өзгәләнеп кычкырганы хәтердә. Мәхдүмнең күзләреннән ике бөртек яшь гармун өстенә тәгәрәп төште.

Бер ай дигәндә Мөнирҗан күңеленнән үзе белгән көйләрнең һәммәсен дә уйнап чыкты. Ә Беренче Майга концерт куйганда, тәүге тапкыр халык алдында чыгыш ясады. Шул көннән аның хакында Гаптелихсанның гармунчы малае дип ихтирам белән сөйли башладылар.

Кара мунчага бәйле тагын бер вакыйга хәтерендә җуелмыйча сакланып калган Мөнирҗанның.

Алар ул елны җиденче сыйныфны тәмамладылар. Соңгы имтиханны бирү иртәгә авылда сабан туе буласы көнгә туры килде.

Җиде класс белем ул сиңа уен-муен түгел. Шактый кешенең әлифне таяк дип тә белмәвен исәпкә алсаң, җиде класс белемнең ни дәрәҗәдә зур икәнен чамалар өчен Әфләтүн хәким булуның кирәге юк. Җиде класс белем авыл малае өчен профессорныкына тиң. Ничек инде бу вакыйганы билгеләп үтмисең!

Котыртучы шайтаны булса, аңа ияртүче фәрештәләр табылмый калмас. Мыкый Шаһбаз сабан туе мәйданына тамак чылатып чыгарга тәкъдим итте. Янәсе, җиде классны тәмамладылар, алар хәзер олыга сан булдылар, өстәвенә татарның елга бер генә килә торган олуг бәйрәме—сабан туе. Әз генә хәмер капканнан дөньяның чите кителмәс.

“Шайтан” коткысына тагын алты малай ияртде. Мөнирҗанның күңеле тартмаган иде, чөнки моңа кадәр аның хәмер ишене авызына якын китергәне булмады. Ләкин малайлар арасында, язылмаган булса да, төркем кануннары хакимлек итә: күпчелек ни эшләсә, син дә шуларга иярергә тиеш. Моны көтү законы дисәң дә дөрескә туры килер. Югыйсә “куркак” кушаматын тагуларын көт тә тор. Ә кемнең, кайсы малайның куркак исемен күтәрәсе килсен. Эчтән калтыраган чакта да, малайларга сер бирмәү хас, тыштан ялтыраган булалар.

Җиде малайның кесәсен җиде кырып, бер селеккәч, бер “чөлли”лек сәмән җыелды. Иртәгәсен Мөнирҗаннарның кара мунчаларында очрашырга сүз куешып таралыштылар. Чөнки аның әтиләре кичтән үк Карамалыга кунакка китәргә тиешләр иде. Аракы алып килүне Мыкый Шаһбазның үзенә куштылар. Янәсе, син котырттың, гәүдәгә дә тазараксың, рәхим итеп, тап бер “чөлли”не!

Сабан туе бүген, сабан туе! Эчендә җаны булган кайсы татар мондый ямьле бәйрәмне тыныч кына каршы алыр икән. Бигрәк тә ир-ат женесеннән булганнар—кайсы атта узышып, чиккән сөлге алу турында хыялланыр, көрәшергә дип мускул кабартучылар да җитәрлек. Ел саен йөгерештә катнашучы Мәхмүт, сорап та, урлап та, көн саен берәр чи күкәй эчә—имеш, тынны озайта, хәлне арттыра.

Мөнирҗанның исә исәбе—гармун белән чыгу. Моңа кадәр мулла абзый биргән гармун белән мәйданга менмәде ул, бердән, үзен өйрәнеп кенә килә дип санады. Икенчедән, гармунга зыян китерүдән курыкты, өченчедән, кем әйтмешли, яше баш, ягъни башы яшь иде. Ә хәзер...

Ә хәзер аның гармунда уйный алмаган көе юк. Кемгә кайсы көй кирәк, барысын да сыздыра. Ул бит хәзер борын асты кипмәгән малай-шалай түгел, ул хәзер җиденче классны тәмамлаган "настояшни" егет булды. "Рамай" кирәкме? Рәхим итегез! "Баламишкин" дисезме? Анысын да уйный ул...

Мунчага иртәнге сигезләрдә җыйналырга сүз куешканнар иде. Мөнирҗанның күңеле ашкына, аның тизрәк, мөмкин кадәр тизрәк мәйданга чыгасы килә. Шаһбаз коткысына никләр генә бирелде икән? Һәркемнең күңелендә посып яткан шайтан бар диләр, шул котырткандыр инде.

Әллә бәйрәм хакына берәр көйне сыздырып җибәрергәме? Юк, кирәкмәс, гармун тавышына кеше җыйнала. Кеше җыйналса, кара мунча планы өзеләчәк.

Сәгать ни әкрен йөрсә дә, вакыт барыбер үзенекен итә—уза. Менә Сәмигулла күренде, аны гына көтеп торгандай,Шаһбаз белән Мәхмүт пәйда булды. Шаһбаз чалбарының бер кесәсе бүлтәеп тора иде.

—Тәртипме?

—Тәртип,—диде Мөнирҗан, сүзнең ни турында баруын да аңлап бетермичә. Ничек инде тәртип булмасын: ишек алдын ул кичә үк себереп, ялт иттереп куйды ич.

—Барыбыз да җыйналып беткәнне көтеп булмас, шикләнә башлаlarлар, керә торыйк,—дип, Шаһбаз мунчага табан юнәлде. Бүтәннәр дә аңа иярде.

Ул арада калган өчесе дә бәрәңге бакчасы аша килеп җитте.

Диварларын корым сарган мунчада кечкенә тәрәзә уентыгы аша төшкән яктылык каршысына кемдер басса, тышта кояш булуга карамастан, иләнмәгән күзгә эчтә берни күренми башлый. Бөтен җирдә корым. Корымга буялудан шикләнмәслек ләүкә бар да, ишектән кергәч тә җыйнак кына бер утыргыч бар. Мунча кергәндә салган киемнәрне шул утыргычка куялар.

Җиде малайга өстәл өчен ләүкә менә дигән иде. Шаһбаз, күрәсезме абзагызны, дигән горур кыяфәттә, чалбар кесәсеннән шешәне чыгарып, "өстәлгә" утыртты. Сөзәрдәй булып, барысы да күзләре белән шул "чикүшкә"гә текәлде, Шаһбазның тагын нидер чыгаруын көтте.

—Ә ыстакан?—Тынлыкны Сәмигулланың тыңкыш тавышы бозды.

—Ыстакан белән кайткач чәй эчәрсең!—Шаһбаз үзен гомердә булмаганча эре тотты.—Бер чөллине ыстаканлап ничек эчмәкче буласың, дивана?!

Тулы булмаган урта белемгә ия булучыларның берсе, тәкатьсезләнеп, сорау бирде:

—Ә нәрсәгә салып эчәбез?

—Абзаң барында кайгырма, барысы да уйланган.—Мыкый кесәләрен капшарга, актарынырга керешә. Ул бу матавыкны юри озакка сузарга тырышты, чөнки сизә: калган алты малай аның салып эчәргә нинди савыт алып килгәнен белми торып тынычланмаячак. Әнә бит, сулыш алуларын да туктатып, һәммәсе дә дүрт күз белән аңа текәлгәннәр, ашардай булып, һәр хәрәкәтен күзәтеп торалар.

Ниһаять, ул чалбарының дингез тирәнлегедәй кесәсеннән төреп бәйләнгән кульяулык тартып чыгарды һәм, аны сүтеп, бармак башы хәтле бер нәрсәне өскә күтәрде. Ләкин, мунча шактый караңгы булганлыктан, аның ни икәнен тану мөмкин түгел иде.

Сабырлыклары төкәнгән малайларның авызыннан:

—Нәрсә ул?—дигән сорау берьюлы чыкты.

—Уймак.

—Уймак?—Мөниржанның ышанасы килмәде.

—Без, нәрсә, мунчага тегү тегәргә килдекмени?

—Һи, диваналар,—Шаһбазның сер бирәсе килмәде.—Беләсезме, бер чөллидән күпме уймак аракы чыгасын?

—Юк. Ә үзең?

—Беләм.

—Күпме?

—Күп.—Шаһбаз үз тапкырлыгыннан үзе көлеп җибәрде.—Минем ишеткәнем бар: уймак белән эчсәң, башка ныграк китә икән дип. Йә, башлыйбызмы?

—Наливай!—Сәмигулла урысчалатып кына җибәрде. Ни дисәң дә, үткән ел ул Бөгелмәдәге апаларында айдан артык кунак булып кайтты, урысчасы да шуннан. Бөгелмә шәһәре гурт бит ул.

Мыкый Шаһбаз аракысын алган, салып эчәргә уймак алып килергә дә онытмаган, ә кабымлык алып килергә кирәксенмәгәнме, әллә акылы җитмәгәнме...

Шаһбаз уймакка сак кына аракы салды, янәсе, тамчысы да әрәм булмасын. Ул уймакны ике бармагы белән чеметеп кенә күтәрде һәм, авызларын карга балаларыдай ачып, күзләрен аңа текәгән малайларга дәште:

—Диваналар, монда карагыз, менә ничек эчәләр аны!

Шаһбаз уймакны иреннәренә якын китерде. Уймакның ничек бушаганын күргәне күрде, күрмәгәне юк.

Икенче булып уймак Сәмигуллага эләкте. Эчкәннән соң ул:

—Ват ита да!—диеп, шакмаклы күлмәгенең җиңен иснәгән булды. Кыланчык!

Мөниржанга да чират җитте. Уймакны бушаткач та, ул башта берни аңламый торды: эчтеме, әллә эчмәдеме? Чөнки уймактагы тамчылар бугазына барып җитмәде, тел астына төштеме, тел өстендә эреп югалдымы—аңламыйча калды. Ләкин ул авызының тәмсезләнгәнен тойды һәм бу тәмсез сыекчаны шунда ук төкереп ыргытасы килде, ләкин иптәшләреннән яхшысынмады.

Уймак озакламый тагын бер әйләнде, тагын, тагын... Әйләнешләр арткан саен, малайларның моңа кадәр пышылдап кына чыккан кыяр-кыймас тавышлары күзгә күренеп көчәйде, бөердән чыга иде инде.

Әз эчелсә дә, еш кабатлый торгач, "шайтан суы" үзенекен итте: Мөниржанның күзләре әлҗе-мөлҗе килә, һәм башы әйләнергә кереште. Хәзер инде аның башкаларда эше юк, хәер, башкаларның да анарда эшләре юк иде, ахры—ул аракыны ничек эчеп бетергәннәрен дә, кемнең кайчан чыгып киткәнен дә хәтерләрлек хәлдә түгел иде—аяклары сыгыла башлагач, башкаларны аралап, аулаграк урынга барып чүгәләде дә йоклап китте. Йоклап китәр алдыннан "сабан туе" дигән төшенчә хәтер төпкеленнән яшен кебек сызылып узды. Хәзер бара ул сабан туена, хәзер, ятып бераз хәл генә җыя да...

Аның юклыгын башкалар сизмәде дә, чөнки барысын да уймак кыздырган иде. Ләүкәдә, монаеп, ялгыз гармун торып калды.

Мөниржан, уянгач, башта үзенең кайда икәнлеген абайлый алмады, чөнки мунчада гүр караңгылыгы иде. Нигә соң шушы кадәрле караңгы,

әллә соң күзләрен ачмаганмы? Юк, күзләре ачык. Ходаем, әллә ул чынлап та үлдеме икән? Мөгаен кабердә ята торгандыр. Алай дисән, кабердә кул-аяклары болай иркен хәрәкәтләнә алмас иде—үлгән кешене бит аны кәфенгә төрәләр...

Ул торып басарга теләде, тик, чак кына күтәрелүгә, башы белән шык итеп нәрсәгәдер бәрелде һәм кире чүгәргә мәҗбүр булды.

Болай утырып та булмый иде. Мөниржан башы белән борылып карагач, шатлыгыннан чак кычкырып җибәрмәде: кайдандыр саран яктылык сирпелә иде. Ул әле башта үзен куандырган яктылыкның мунча тәрәзәсеннән төшүен аңламады. Тумыштан бирелгән инстинкт аны шул яктылыкка табан хәрәкәтләнергә мәҗбүр итте. Ниһаять, Мөниржан мунчаларын танып алды. Шатлыгыннан ул күзләренә чыккан яшьләрне сөртеп тә тормады. Куанычыннан, бәлки, кычкырып аваз да салган булыр иде, әмма коргаксып кипкән авызында аңкауларына ябышып каткан телен әйләндерә алмады.

Тукта, ә малайлар кайда? Алар җәмгысы җидәү иде бит, барысы да мәйданга китеп беткәннәрме? Болай торса, Мөниржан Сабан туена соңга кала ич! Ул, гармунын култык астына кыстырып, мунчадан атылып чыкты. Урамда сыерлар мөгрәгән, сарыклар бәәлдәгән, кәҗәләр кычкырган тавышларны ишетеп, малай тораташтай катып калды. Бу ни хәл: Сабан туе көнне көтү чыкмый иде бит.

Шунда ул Мөниржаннарның малларын урамга куучы Камилә карчыкны күрде. Кунакка китәр алдыннан әнисе Камилә әбидән сыерларын савып, малларын көтүгә кууын сораган иде.

Димәк, Сабан туе күптән тәмамланган, ул ләүкә астында бер көн, бер төн уздырган. Моның шулай икәненә, өстенә карагач, тагын бер кат инанды: бәйрәмгә дип кигән чиста күлмәге корымга буялып беткән, бу хәлдә кеше күзенә күренерлеге калмаган иде.

Мөниржан кабат мунча алдына кереп, күрше карчыгының капкадан чыгып киткәнен көтеп торды. Шулай итеп ул кеше алдында мәсхәрә булудан котылды һәм бу хакта берәүгә дә, хәтта Фазыл дустына да сөйләмәде. Бергә эчкән малайлар да ул көн турында сүз кузгатмадылар.

Мөниржан, әле сугыш беткәч тә, госпитальдә озак ятты. Ә Иванның яралары күп булса да җиңел булып чыкты—Казан кызларының шифалы кулы вә сулышы килеште, ахры—май башларында ул сафка кайтырлык хәлгә килде һәм Җиңү көненнән соң озак та үтмәде, капитан чинына күтәреп, батальон командиры сыйфатында Корпухинны японнарның иманнарын укытырга җибәрделәр.

Гвардия рядовое Мөниржан Исламов та август азакларында аякка басты. Сул кулының җинен җилфердәтеп авылына кайтып төшкәндә, халык бәрәңге алуны тәгәлләп килә иде.

И яшьлек, нинди кодрәтле син! Үлемнән калып, ярты ел урын өстендә яткан Мөниржаннан да кабат кеше ясадың бит!

Мөниржанның кайтуына әти-әнисе, туганнарының и сөенүләре! Күпме вакыт хәбәрсез югалып торган чагында җитмешкә җитеп килүче карт белән карчык улларының исән булуына ышанычларын җуя башлаганнар иде. Дөрес, җиңү кул сузымы җирдә генә икәнен беләләр, дошманны инде поляк, чех җирендә кыйныйлар. Шулай булса да ул, өненә куып кертелгән яралы бүредәй, каршы тора, соң чиккә җитеп тартыша. Армия көн саен зур югалтуларга дучар. Әнә ич авылда үле хәбәре килмәгән бер генә йорт та калмады диярлек. Шуңа күрә тап-таза, дүрт саны төгәл булып киткән Мөниржанның яралардан әле ныгып җитмәгән, чулак хәлендә кайтып керүе диндар ата-ана тарафыннан алар гаиләсенә Аллаһы Тәгаләнең күрсәткән миһербаны буларак кабул ителде. Кара инде урам аша күршеләре Кәлимулла

карт белән Зәкия карчыкны: аларның берсеннән-берсе таза, кышларын бүре бастыра торган алты улының алтысы да һәлак булды. Бу кайгыга ана йөрәге ничек түзгәндер, Кәлимулла карт күзгә күренеп акылга жиңеләйде. Кырык елдан артык бергә гомер итеп, тырнак белән дә чиртеп карамаган Кәлимулла хәзер карчыгының тәнен кара яндырганчы кыйный башлаган. Хәсрәт өстенә хәсрәт Зәкиягә.

Әйе, күп асыл ирләрнең башын ашады сугыш дигән зәхмәт. Заманында тавышларыннан каланча селкенеп, калае зеңгелдәп торган авылда ир заты дигәннәр күзгә кырып салырлык кына калган иде. Андый вакытта, әлбәттә, булган кадәресенең бәясе нык арта. Бигрәк тә яшьрәкләренең. Балык юкта кысла да ярый, дип тикмәгә әйтмиләрдер.

Ә Мөниржан яшь, ярадан соң ныгып килә, сул кулы юк икән, исән китмәсен, иң кирәкле жире, аллага шөкер, үз урынында...

Ихтимал, Мөниржанның кайтуына ата-анасыннан кала иң нык сөенүче Гайния булгандыр. Бәлки ул ныграк та сөенгәндер әле. Сөенми ни, көтәм дип вәгъдә биреп, ут эченә озаткан сөйгән егете бит... Сүзендә дә торган иде, тик...

Мөниржан кайткан көнне Гайния кичке уенга чыкмады. Көзнең кара пәрдәсен тишеп чекрәеп карап торган йолдызлар астында Мөниржан озак йөрде Гайнияләр очында. Тик капкаларын шакырга жөрьәт итмәде. Үз чамаңны бел, егет, дип, хисләрен йөгәнләргә тырышты. Ул кем дә, син кем!? Ул авылның иң чибәр кызы, ә син таралып яткан жирдән тегеннән-моннан жыйнаштырып, кеше кыяфәтенә керткән бер адәми зат. Житмәсә, чулак. Ниндирәк күлгә кармак салырга дигәндә үз урыныңны белергә кирәк!

Ә Гайния бу вакытта тавышсыз елый-елый шешенеп беткән иде. Атылып чыгар, муенына асылынып, шашып-шашып үбәр иде Мөниржанын, әмма үзен жиңәр көч тапмый, тузгып беткән чәчле башын мендәргә тәвә кошы сыман тирәнрәк яшерергә һәм ялгызы газап чигәргә мәжбүр.

Мөниржан исә баш вата: аның кайтканын ишетеп чыкмадымы бу Гайния, әллә ул үлем белән тартышып, бер хәбәрсез ятканда, бүтәнне табып өлгергәнме? Тапса, кем икән ул? Шушы уй ана тәрәзә шакырга, Гайнияне чакырырга да ирек бирми. Иң яхшысы, иртәгәне көтәргә кала.

Кыз икенче көнне дә клубка чыкмады. Ләкин бер авылда яшәп, хәтта качып йөргән очракта да, очрашмый калу мөмкинме? Гайниянең эш урыны әллә кайда жәһәннәм читендә түгел ләбаса, колхоз идарәсендә генә. Мөниржан аның хисапчы булып эшләгәнен белә иде.

Өченче көндә ул түзмәде, идарә халкы төшкелеккә таралыр алдыннан кәнсәләргә китте. Гайниянең чыкканын көтеп алып, көпә-көндез булса да, өенә озатып кую иде исәбе. Сугыштан яраланып кайткан солдатка моны гына гафу итәрләр әле. Авыл халкы киң күңелле ул.

Капка төбендә бераз таптанып торырга туры килде ана. Шуннан соң гына әүвәл, титак-титак атлап, баш хисапчы Мисбах, бераздан Разия дә чыгып, өйләренә табан атлады.

Гайния ник чыкмый соң? Бәлки ул идарәдә түгелдер, өенә алданрак кайтып киткәндер? Бәлки гел районда дыр. Ә нигә кереп карамаска? Юлны бикләп куйган кеше юк ич. Ишек ачык, кер дә кара.

Гайния районда да түгел, өенә дә кайтып китмәгән иде. Мөниржанның капка төбендә басып торуын күрмәгән булса, ул да Разия апасыннан калмыйча кайтып китәсе һәм өендә ярмаланып пешкән кабыклы бәрәңгене туйганчы ашап, күңел хушлыгы кичерәсе кеше иде. Югыйсә иртәнге якта ярты телем арыш ипие белән ике чынаяк сөтле чәй генә эчкән ласа ул. Ашау дисәң, хәтере калыр, тик торганнан эчәк чайкау шунда... Ичмасам, шикәре дә юк. Анысының тәме онытыла башлады инде, күрмәгәнгә биш былтыр.

Гайниянең чыгасы, Мөнирҗанның кочагына ташланасы килә. Әллә сагынмадымы? Әллә аның турында уйламадымы? Ничекләр генә әле! Уйламаса, сагынмаса, төшләренә кереп саташтырыр идемени?! Бигрәк тә киткән мәлләрне еш күрде ул аны төшендә. Аннан соң Җинү турында хәбәр алгач...

—Авылның эре бәрәңгесенә сәлам!

Гайния бу төрттерүдән дерт итеп китте, ләкин сер бирмәскә тырышты.

—Исән-сау кайтуың белән котлыйм.—Кыз ике кулын сузып күрешә һәм, егетнең үзен кочагына тартып алуыннан куркып, җәһәт кенә урындыгына барып утырды да, кул астына нинди хисап кәгазьләре эләксә, шундагы саннарны шалт-шолт чутта суга башлады: сулга биш төймә дә, унга өч төймә, тик сорауларың белән бәгырьгә тимә.

Кыз күңелендәге давыл-гарасатны сизми, аңламый Мөнирҗан. Бу кыланышларын аның оялчанлыгыннан, каушап калуыннан дип уйлый. Күрешмәгәннәренә елдан артты ич. Аерылышкан чакта Гайниянең әле унҗидесе яңа тулып үткән иде.

Йотардай булып, Мөнирҗан күзләрен Гайниягә текәде. Бигрәкләр дә чибәр шул каһәрең! Бер кашык су белән йотарлык дип мөгаен шундый кызларга әйтәләрдер. Тикмәгә генә, төшләренә кереп, сугышта да, госпитальдә дә саташтырмагандыр. Адәм затыннан түгел, җен кавеменнәндер бу Хәниф абзыйның кызы. Булган булсын дигәндер инде, хур кызларын көнләштерерлек гүзәл йөзнең нәкъ маңгай уртасында Ходай Тәгалә кечкенә генә кара-кучкыл миң дә яраткан. Бусы ник кирәк, ир-ат халкын шуның кадәр ник үртәргә иде инде! Валлаһи, миһербансызлык бу, һәр егеттә бер генә йөрәк икәнен онытты микәнни Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре ...

Шайтан алгыры, яраткан кызың янына кергәч, нидер сөйләшергә кирәк ич. Вакыты да әйбәт, беркем комачауламый. Тик ни диергә, элекке телгә җорлыгы онытылып беткән, ахры.

—Ыһым-ыһым, бигрәк эшем иясе булып киткән икән берәүләр...

Мөнирҗан ни әйтер икән дип куркып утырган Гайния җиңел сулап куйды: уф, уенчак тонда башлагач, суга батмаячак ул, тотынырга саламы бар...

Шалт-шолт чут төймәләрен сала-сала, кыз кинаягә киная белән җавап кайтарды:

—Хисапчының бар белгәне дебет, кредит инде аның, Мөнирҗан...

—Рәхмәт, исемемне хәтерлисең икән әле. Урамга да чыкмагач, оныткансыңмы әллә дигән идем.

—Онытылыр да инде, күпме сулар акты, җилләр исте...

—Безнең өскә пуля, ядрә дә яуды әле...

—Яугандыр, сүзем юк. Тик тылдагыларга да җиңел булмады.

—Бәхәсләшмим, Гайниябану...

Гайниябану... Аларның бит мәхәббәте шаярышып «Галиябану»ны җырлаудан башланды. Беркөнне Мөнирҗан тальянын алып урамга чыкты. Тыныч вакыт булса, яңа төшкән карга куанып, кешеләр каз өмәләрен башлар иде. Тыныч кич, үзенә күрә сагындырып килгән суыгы бар, житмәсә көне буена ап-ак кар төште.

Менә хәзер ай яктысында уннарча төскә кереп, кар бөртекләре җемелдәшә. Күктәге йолдызлар урамга чыккан һәркемгә күз кыса, ымсындыра, нидер вәгъдә итә, күңелне алгысыта.

Мөнирҗан ул көнне тракторын иртәрәк куйган иде, мунча кереп, каз бүтәкәләреннән пешерелгән бәлеш ашады. Чөнки әнисе белән Мөршидә апасы бүген казларын суюны төгәлләделәр (ә казлары унган иде, егермегә тулган иде), һәм, их, булган булсын инде дип, сугыш чорында күпләр

тәмен дә оныткан бәлеш салырга ниятләделәр. Нидән диген әле—каз бүтәкәсеннән! Тәмленең дә тәмлесе. Деликатес! Дәүләт башлыкларының да төшенә кермәс. Юлий Цезарь белән Александр Македонскийга насыйп булды микән каз бүтәкәсеннән авыз суынны корытырдай тәмле бәлеш ашарга? Югыйсә дөньяның күпме илләрен яулап алган, буйсындырган хөкемдарлар бит үзләре. Андый бәлешне ашасалар, бәлки, дөньяны канга батырып йөргәнче, өйләрендә кикереп кенә тик ятарлар иде.

Бәлеш шулкадәр тәмле иде ки, хәтта тышының алабута кушкан оннан басылганына да игътибар итүче булмады.

Кем әйткәндәй, тамагы тук, өсте бөтен. Мондый чакта яшь йөрәк ни эшләсен? Дөрес, урамга әйди. Еракта сугышлар бара, кан коела, биредә ачлыктан шешенеп яки теләсә ни ашаудан агуланып үләләр, ә тормыш дәвам итә, нидер тели, дәгъвалый.

Чыра яктысында күпме утырырга була?! Түзмәде Мөниржан, гармунын муенына элде дә күзгә карангы төннең ак кар белән түшәлгән урамына атлады. Чыгып житүгә уйнап та җибәрде һәм, үзәкләрне парә-парә китереп, тальяннан моң түгелә башлады. Фәкыйрьләнгән йортлардагы имгәтелгән, җәрәхәтле җаннар өчен авылның ул чактагы тальяны берүзе оркестрны да, филармонияне дә алыштырды. Тыныч, тук тормышта тальян моны татар күңеленә алай ук тәэсир итә ала микән?

Әйтерсең, койма ярыклары, утсыз тәрәзәләр аша Мөниржанның чыгуын карап-күзәтеп кенә торганнар, бер-бер артлы аның янына башта егетләр, соңрак кызлар жыйналды. Түбән очтан Гайнияләр дә менеп житте.

Күпме жыр жырланды ул кичтә. «Идел бит ул», «Юксыну»ларны жырлаганда туган моң авыл күге буйлап йөзде-йөзде дә Мөниржаннар өянкесенең кышкы йокыга талган ботакларына менеп кунаклады. Колач житмәс өянке бу рәхәттән ни эшләргә белмәде: кыш дип тормады, тамырларына хәтле татлы сут үрләде.

Тальяннан «Галиябану» көе агыла. Көтеп кенә торганнар диярсең, Гайнияләр шунда ук жыр башладылар. Шул чакта аларга кушылган Мөниржан, аңлапмы, аңламыйчамы, жырның сүзләрен үзгәртеп башкарды:

Минуты ай, сәгате ел,
Гайниябану, сылуым-иркәм,
Шулкадәрле сагындым.

Ник алай жырлады? Югыйсә Гайниягә карата хисләре барын-югын кешегә фаш итү түгел, моңа кадәр үзе дә аңламый иде.

Шаяртуга каршы Гайния дә шаярту белән җавап бирде:

Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә, ватып ал.
Сөюләрең чыннан булса,
Мөнир бәгърем, жанкисәгем,
Тәрәзәдән тартып ал.

Башкалар сүз берләшкәндәй кинәт туктады. Хәзер инде дөньяда бары тик мәхәббәткә сусаган ике яшь күңел генә калды. Хәлил—Мөниржан һәм Галиябану—Гайния.

Ул кичтә Мөниржан беренче тапкыр Гайнияне озата барды һәм бу сукмакта аның эзе сугышка алынгач кына күмелде. Ләкин жылы хисләр хатларга күчте.

Үткәннәрне исенә төшереп, Мөниржан әкрен генә жырлап куйды:

Гайниябану, сылуым-иркәм,
Шулкадәрле сагындым.

Мөнирҗанның бераз карлыкканрак тавышына кушылып, Гайния чак кына: «Мин дә!»—дип ычкындырмады. Күңеле шуны теләде, ә теле киресен сукалады:

—Куй, Мөнирҗан, эш урынында тузга язмаганны сөйләмә! Кеше әлләни уйлар...

—Үзең бит кич чыкмыйсың. Мин, юләр, хатка көтәм дип язгач, ышанган идем. Синең өчен генә тере калдым.

«Әйтмәле шул сүзне, Мөнирҗан, телмә әле болай да утта янган күңелемне!» Гайния чут төймәләрен сугыштырудан туктады.

—Аңа күптән бит инде, Мөнирҗан. Соңга табан хат та язмадың. Ярар, синең эшең беткәндер, минем төшкелеккә кайтып киләсем бар.

Кискен карарга килеп, Гайния урыныннан кузгалды һәм киенер өчен чөйдә эленеп торган куфайкасына үрелде. Ләкин Мөнирҗан, үлсә үлә, күңелен бораулаган сорауны бирми кала алмый иде. Шуңа күрә ул кызу-кызу адымнар белән ишеккә юнәлгән кызны, юлына аркылы төшеп, исән кулы белән тотып алды.

—Гайния, әйт дөресен, бүтән берәүне таптыңмы, әллә гариплегем күңелеңне суыттымы?

Ычкынырга теләп тартылып карады Гайния, ләкин файдасыз: Мөнирҗан тимер кыскычка әверелгән иде. Бәхетеннәнме, әллә кызганычка каршымы, шул минутта ишек ачылып китте һәм аннан таза гына гәүдәле ир-ат килеп керде.

—Көпә-көндез бу ни хәл бу?—дип сорады ул калын тавышы белән бухгалтериянең тар диварларын яңгыратып.

Гайния дәшмәде, башын түбән иде дә чыгып шылды. Мөнирҗан башта: «Анда синең ни эшең бар?»—дип сорамакчы булган иде дә олы кешегә тупас сүз әйтүне килештермәде. Сүзсез генә кыз артыннан атлады. Артыннан теге адәм:

—Матри аны, көпә-көндез кәнсәләргә килеп, кызларга бәйләнеп йөри башласаң, фронтта булган дип тормам!—дип калды.

Мөнирҗанга аның сүзләре әллә бар, әллә юк иде. Кызу адымнары белән йөгерә-атлап барган Гайнияне куып җитеп сорады:

—Кем ул, нинди бәндә?

Гайния теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

—Прсидәтел...

Мөнирҗанның бу очрашу кәефен җибәрде, аның инде Гайнияне дә озатасы килми иде. Ул әле кызның кәҗәләнү сәбәпләрен белми, ләкин күңеленнән ант итте:

—Ничек кенә киреләнсәң дә, минеке булырсың, кызый!

Бу сүзләрне егет мин-минлеген итәр өчен генә әйтмәде, чыннан да аның киләчәккә планнары Гайния, бары тик Гайниябану белән генә бәйле иде. Шушы кыска гына вакыт эчендә кызның үзен бөтенләй онытып бетерүенә ышанасы килмәде аның.

Күңеленнән Гайниянең дә Мөнирҗанга бер кәррә дә хыянәт иткәне булмады. Ул аны һаман да озатып калган көндәгечә ярата. Бәлки, көчлерәктер дә әле. Мөнирҗан шуны аңламый, кулы гариплеген телгә алды, юләр бәндә. Бу заманда бер кулы терсәккә кадәр юк икән, шуны гариплеккә санаргамы? Бигрәк тә чын күңеленнән сөйгән, үзеңне аңа багышларга җыенган кешене?! Ирләргә бит хәзер кытлык, кайсы алам дисә, аяксызмы ул, кулсызмы—шуңа тагылырга гына торалар. Ләкин Гайния сау-сәламәт ирләр буа буарлык булса да, аларны бер читкә этәреп, барыбер

Мөниржанны, шушы чулак Мөнирен, ана «Гайниябану» дип дәшә белүче Мөнирне сайлар иде.

Мөниржанның кайту хәбәрен ишеткәч, елады-елады кыз һәм бүтән еламыйм дип үз-үзенә сүз биргән иде инде ул. Сүзендә торалмады, өйләренә кайтып житүгә, ярмалы бәрәнге суынып, бизгә әверелде дип тормады, печәнлеккә менде дә үкси-үкси янә яшь түкте...

Март айлары иде. Жиңү турындагы хәбәрне ишетергә зар-интизар булып, халык исән калган соңгы көчләре хисабына яши. Көннәрнең берендә баш хисапчыны районга отчет белән чакырдылар. Башка көннәрдә салмыш йөреп, атна буена баш төзәткән Мисбахның кая анда барырлыгы! Кәнсәләрдә чут төймәсе тартканда да, бармаклары калтырап, саннарны бутап бетерә иде. Хисапчы кызларның мона исләре китми, алар башбухның бу гадәтенә өйрәнеп беткәннәр, шуна күрә аның кулы тигән исәп-хисап кәгазьләрен кабат энә күзеннән үткәрәләр.

Югыйсә Мисбах отчет төзергә кирәклеген дә, ул отчетны районга алып барып тапшырыр вакыт житкәнен дә белә иде. Әмма туя белмәгән бер тамагына баш була алмады.

Ул бу хәлендә отчетны үзе генә ерып чыгуына бик үк ышанып бетми. Күзенә бер сан биш булып күренә бит. Ярдәмгә тагын бер хисапчыны алырга кирәк. Тик кемне?

Мисбахтан кала Разия апалары өлкәнрәк санала. Гөнаһ шомлыгына күрәдер, аның сыерының жилеме тулып, менә-менә бозауларга тиеш иде. Бозаулы сыер—сөтле сыер, авыл кешесенең бар карап торганы сыерда. Шуңа күрә ул районга бару хакында Гайниягә гозерләнде.

Ярты ел элек кенә сыер сауган жирдән хисапчы итеп күчерелгән Гайниянең, моны ишетүгә, коты очты.

—Булмый-булмый, Разия апа, бер дә рәтен-чиратын белмим, бутап бетерермен,—дип теше-тырнагы белән каршы торып маташты кыз.

—Соң, апаем, өйдә калдырыр кешем юк. Бозауласа, кем чүбен салдыра? Март булса да, әле салкын, ул түбәсез лапаста бозавы катып үләр. Бер юлга сүземне тыңла инде, Гайниякәем!—дип Разия апасы үтенеп сорагач, күнми чарасы калмады. Чөнки тагын берәрсенә сылтарга мөмкин түгел, син дә мин, Мөхәммәт тә мин, дигәндәй, алар бухгалтериядә үзләре генә.

Алдан сүз куешканча, Мисбах белән Гайния караңгылы-яктылыда кузгалдылар. Жиңел чанага Стәрле болынынннан чабылган хуш исле печән салынган. "Ни булмас"ка дип алынган капчыктагы сарык калжасы чанадагыларга унайсызламаслык итеп урнаштырылган. Чүпрәккә төрелгән ике «Бөгелмә малае» хакында Гайния белми дә калды. Хәер, белсә ни кылыр иде. Мисбахмы соң юлга запассыз чыгучы!

Кояш чыгарга иртә булса да, көне якты, жил дә әлләни юк, тыныч диярлек. Әле вакыт бар, ашыкмаска да була, шуңа күрә бухгалтер атын кауламый. Бурлы айгыр юлны белә, әле юыртып ала, әле адымга күчә. Нәсел айгырын теләсә кем жикми, ул күтәрәмгә калган колхоз алашасы түгел, үз кадерен үзе белә.

Махмырдан чатнаган башы белән дә отчетларын уңышлы тапшырасыларына әлләни шикләнми Мисбах. Ник дисәң, андагыларның барысы да таныш, Мисбах абзыкаем, дип өзелеп торалар. Өзелми ни, аларның да тамагы бар. Сарык калжасы тикмәгә генә «атка утырып» йөрми ләбаса. Ашаган авыз ояла, ди халык. Боларның да оятлары бөтенләй бетеп житмәгән. Өстәвенә, отчетлары да тегеннән-моннан гына түгел, жиренә житкереп төзелгән. Разиядә тәжрибә ун кешелек, бу Хәниф кызы да бик уңлы булып чыкты. Тизрәк эшне бетерергә дә, бер яртыны башларга, башны төзәтергә кирәк! Ул, шуны уйлап, хәзердән үк ләззәт хисе кичерә. Хәзер үк эчеп куяр иде

дә, район хатыннары салмыш баштан килгәнне яратып бетермиләр.

Ат юырта. Бер толып эчендә терәлеп диярлек утырган унсигез яшьлек кыздан аңкыган дәртләндергеч ис утыз биш яшьлек айныр-айнымас ирнең аңын томалый, ярымайнык башында, үзе дә сизмәстән, хайвани хисләр уята.

Баш бухгалтерның отчет мәсьәләсендә өметләре бу юлы да акланды. Әллә терәге нык булу ярдәм итте, әллә чыннан да отчетлары тел-теш тидерерлек түгел, төштән соңнарга аларның эше тәгәлләнде. Калҗаның да кирәге чыкмады.

Район үзәгенә килеп, эшен бетерүгә кайтып китәргә ашкынып торучылар күптер. Әмма Мисбах түгел. Эшен тәгәлләгәч, район үзәгендәге бердәнбер ашханәгә кереп чыгу аның өчен экваторга килеп җиткән диңгезчеләрнең Нептун бәйрәме уздыруы кебек традициягә әверелгән һәм менә сигез ел дәвамында бу гадәтенә аның хилафлык китергәне юк. Хәтта кышын, йоклап китеп, ярдан тәгәрәве һәм аягын авырттырып чатанлап калуы да шул салдым аркасында иде. Бәла кичергән кайберәүләр саграк кылана яки яман гадәтләрен бөтенләй дә ташлый. Ләкин Мисбах элек ничек булса шулай калды, әле ныграк та азмаса.

Бу юлы да ул атын ашханә ишеге төбенә үк китереп туктатты. Отчетны уңышлы тапшырган куанычтан Гайния ашап тормаска, хәзер үк кайтып китәргә дә риза иде. Кая ул—Мисбах абыйсы ай-ваена куймады. Бу мәсьәләдә аның принцибы нык иде: кәҗәне печән кибәненнән аерып алырсың, ә Мисбахны, бер яртыны бушаттырмый торып, алып кайтып китәм димә.

Ашханәдә Мисбахны таныйлар гына түгел, андагы кызлар чатан хисапчының һәр гадәтенә кадәр ятлап бетергәннәр: өстәл берничә минуттан сугыш чорында күрергә мөмкин булган ризыклар белән тулды. Чанадагы бәсләнгән, иртәдән бирле Мисбахның авыз суын корыткан шешәне дә җылытып китерделәр. Ризык күргәч, ярты көннән артык ризык түгел, бер йотым су да эләкмәгән Гайниянең ашказаны асты бизләре котырынып эшләргә кереште. Өйләрендә ашаган ризыклары да һаман да шул бәрәңге, Тукай әйткән татарның сабырлыгы гына ич. Бәрәңге үзе дә: "Алып баруын барам, кайтуын үзегез чамаларсыз",—дип әйткән ди. Ашказанында берьюлы йөз бүре туй уздырган кызның хәзер үк өстәлдәге ризыкларга юлбарыстай ташланасы, чәйнәп тә тормыйча берсе артыннан берсен тамагына озатасы килде. Ләкин тәрбияле, диндар гаиләдә үскән авыл баласы, өстәвенә, хисапчы кеше, бушка ашатмаганнарын, ашагач түләргә кирәк булачагын белә. Шушы хакыйкать исенә төшүгә, Гайния сузыла башлаган кулын ничек кире тартып алганын сизми дә калды, оялуыннан кулларын хәтта өстәл артына ук яшерде. Шешә ачу белән мәшгуль булса да, Мисбах моны күреп калды һәм исе китмичә генә:

—Аша, аша, кыенсынма!—диде.

—Мисбах абый, ни бит, болар кыйммәттер. Аннан соң бик үк ашыйсым да килми,—дип ялганларга кереште.—Мин бер стакан чәй генә эчәм...

Карт чыпчыкны алай гына ышандырырсың!

—Юкны сөйләмә!—диде ул, каршы килергә урын калдырмыйча.—Ни булмас дип, мин командировочный алган идем, колхоз эше белән йөрибез бит, шул акчадан түлибез. Мисбах абыең булганда курыкма! Маладис, Гайния, егет икәнсең, отчетны бик уңышлы тапшырдык. Моны юмасаң, Ходай гафу итмәс!—Ул ике стаканга яртылаш аракы койды.

—Син ни эшлисең, Мисбах абый? Әллә саташасыңмы? Шушы яшемә җитеп, авызыма якын китергән нәрсәм дә түгел.

—Ярар, әйттем исә кайттым.—Мисбах аракы хакында бүтән сүз кузгатмады. Үзе бер стаканга салганны голт-голт эчеп бетерде.—Эчмәсәң эчмә, ашау мәҗбүри.

Гайния ашауны тиз тотты. Йа хода, биргән ризыкларына меннән-мен шөкер дип, эченнән генә дога да кылды сугыш барган елларда алдынгы терлекче буларак Ленин-Сталин комсомолы сафларына кабул ителгән кыз. Ни эшләргә?

Чыгып кына китәр иде, тышта кыш, кая барсын. Мисбах абыйсының ашханәдәге "эшен" тәгәлләгәнен көтүдән бүтән чарасы калмады. Ә Мисбах ашыкмый. Хәзер инде ул эчми, йотып-йотып кына куя һәм күзгә күренеп мәлҗерәя бара. Үзе туктаусыз сөйләнә, үз сүзеннән кызык табып көлеп тә ала. Ашханә хатыннары аның бу кыланмышларына күптән ияләшеп беткән, сизелеп тора, ул монда үз кеше. Әнә ич, әстәгъфирулла тәүбә, бер симезрәк официанткаиың бүлтәеп торган артына Мисбах кулы белән чәпелдәтеп алгач, тегесе шаркылдап көлде генә. Әнекәем лә! Ничек оялмыйлар? Юк-юк, Гайния, кияүгә чыккач та, ул тирәсенә хәтта иренен дә кулын якын китермәс!

Мисбах белән теге хатынның кыланышларыннан һәм башына килгән мондый уйдан оялчан кыз кая карарга да белмәде. Ахыр чиктә дивар янәшәсендәге өстәл артына куелган урындыкка барып утырды.

Утыра торгач, ул йокымсырап киткән иде, шуна күрә бухгалтерның ашханәдәгеләр белән исәп-хисапны ничек ясаганын күрми калды.

...Мөнирҗанның иртәгә фронтка китәсе көне. Су буйларыннан урап йөри торгач, алар Гайнияләрнен капка төбенә кайттылар. Шуны гына көтеп торган сыман, таң әтәче кычкырып куйды.

—Бар кайт инде, Мөнирҗан...

—Бер кочаклатмыйсың да, иртәгә китәм бит...

—Оялмыйсыңмы? Ал кулыңны!—Кыз егетнең сузыла башлаган кулын читкә этәрде.—Әнә, кайткач, әниең кочакласын!

—Әле син шулаймы, тискәреләнәсенме?—Мөнирҗан гармунын коймага элеп куйды.—Болай булгач, бер үпмичә җибәрмим мин сиңе!

Мөнирҗан кочагына алды дигәндә генә, Мисбах аны йокысыннан уятты:

—Кайтыйк, Гайния, монда йокы симертеп ятып булмас.

Уфалла, ул йокымсырап киткән икән.

Урамга чыксалар, ис-акыллары китте: алар кергәндә тып-тын калган табигать хәзер котырыпмы котыра. Кай арада шундый көчле буран кузгалгандыр. Әле урамда, авыл эчендә шулай, кырда—япа-яланда—күз ачкысыздыр инде ул.

Исереккә дөнья тубыктан диләр. Бураннын котырынуына Мисбах эһ тә итмәде.

—Утыр әйдә, кузгалыйк,—диде ул һәм Бурлы айгырның тезгенен чиште дә толып эчендәге Гайния янәшәсенә ауды.

—На, малкай!

Шуны гына көткән һәм ничә сәгать буена суыкта басып торырга мәҗбүр булган нәсел айгыры, дилбегә кагуга, алга ыргылды.

Мисбах абыйсы кызны вакытсызрак, төшнең ин тәмле вакытында уятты. Ул уятмаган булса, Мөнирҗан кочаклап үбәр идеме икән Гайнияне? Оялмас идеме?

Шушы уйдан кыз тәненең кызышып китүен тойды. Мөнирҗан белән алар үбешү тәмен дә белмичә аерылышканнар иде. Кочаклашулары да... Хәер, чын-чынлап кочаклашу булмады да инде ул. Хәзер мена хаты да килми. Исәнме ул, юкмы—бер Ходай гына белә.

Гайниягә кинәт ямансу булып китте, ул үзен искиткеч ялгыз хис итте. Әллә Мөнирҗан анда берәрсен тапканмы? Фронтта кызлар да күп ич. Марҗаларны бик әрсез була дип тә сөйлиләр. Андый чибәр егетнен муенына асылынырга гына торалардыр... Ичмасам, Мисбах абыйсы гырлый-гырлый

йокламасын иде. Өстәвенә аракы исе җил уңаена гел аның борынына килә.

Март бураннарының көчен үзе юлда татып карамаган кеше генә белми. Югыйсә әле караңгы төшеп өлгермәгән булырга тиеш, тик күзгә төртсәң дә берни күренми. Бөтен дөньяны ак пәрдә урап-бөтереп алган. Көчле җил телефон баганаларын егардай булып көчәнә, елый, сызгыра, юлда калган бәхетсезләрдән ихахайлап көлә һәм, күз ачып йомарга да өлгермисең, сине кар белән күмеп ташлый. Толып эчендә булуына да карамастан, Гайния инде туңа да башлады һәм, үзе дә сизмичә, Мисбахка елышарак төште. Кыз, иске булса да, мамык шәлен алмаганына үкенде. Югыйсә әнисе каткат әйтеп караган иде.

Терәлеп утыргач, җылырак икән шул. Мисбах абыйсы да туңа торгандыр. Ул да, иртән көн җылы һәм тыныч булгач, шулай ук җинелчә киенгән. Әле хәзергә аны аракы йоклата.

Бурлы айгыр башта ару гына барды. Район үзәген чыгып күпме киткәннәрдер, бераздан ул адымнарын әкренәйтә төште дә, ни сәбәптәндер, шып туктап калды һәм гаепле төстә башын чанага табан борып, кешнәп куйды. Гүя ул: «Нишлибез, кая барабыз?»—дип сорарга тели иде.

Дилбегә тотарга тиешле кеше йоклый, ә бу юлда сирәк йөргән һәм мондый гарасатны беренче тапкыр күргән Гайния кайсы якка киткәннәрен дә, кая килеп җиткәннәрен дә ничек әйтә алсын? Ул ашыгып Мисбахны уятырга тотынды:

—Мисбах абый, Мисбах абый, дим! Тор әле, адаштык бугай!

Күпчелек очракта авылына кайтып җиткәч, капка төпләрендә генә уяна торган Мисбах йокы исереклеге белән баштарак берни дә аңламады. Күп тапкырлар кабатлый һәм җилтерәтә торгач, ниһаять, аның башына томанлы гына булса да «адаштык» сүзенең мәгънәсе барып җитте:

—Ничек адаштык?

—Ат туктады, беркая да бармый,—диде Гайния гаепле төс белән.

Мисбах, чанага басып як-ягына карамакчы иде, аягында басып кала алмады, кинәт исеп куйган җил аны чанадан эшереп төшерде. Күз ачып йомганчы, ул ак кар өеменә әверелде һәм, үрмәләп диярлек, чанага кире менде. Дилбегә кыз кулыннан кинәт айнып киткән ир кулына күчте. Ләкин ат булып ат белмәгәнне, мондый мәхшәрдә адәм баласының ничек башы җитсен. Гасырлар буена адашкан чакларда адәм баласын, коткарса, бары тик ат кына коткарган. Ат та коткара алмаса, катып үлүеңне көт тә тор. Ә башкалар сугышта кан койганда, тылда гел үк начар яшәмәгән утыз биш яшьлек Мисбахның да, унсигезен генә тутырган, үз районнарыннан гайре беркая да чыгарга һәм җан сөйгән егете белән үбешергә дә өлгермәгән, киләчәк тормышын фронттан кайтасы Мөнирҗан белән корып, балалар үстерергә хыялланган кызның да үләсе килми. Җан бит ул никадәр авырлык вә катлаулылык белән иңсә, шундый ук авыр чыга да.

—На, малкай!

Бурлы айгырның дилбегәсен ул берничә тапкыр кагып карады—башка вакытта метрлы киртәләрне дә сикереп кенә үтә торган Бурлы айгыр бу юлы урыныннан кузгалмады. Атның чарасыз икәнен күргән Мисбах дилбегәне йолкудан туктады.

Буран торган саен ныграк котырды. Житмәсә, чып-чынлап караңгы да төште. Моңа кадәр атның башы, дугасы күренсә, хәзер сырты да чак шәйләнә иде.

Атны бәлки җитәкләп юлга чыгарып булыр...

Мисбахка берни әйтеп тормыйча, Гайния чанадан төште. Аның төшүен күрсә дә, йомышы бардыр дип, Мисбах кыздан ник төшүен сорап тормады, чөнки үзе дә ат янәшәсендә, җил унаена каратып, артык йөгеннән янарак

кына арынган иде.

Жил Гайнияне йолкып алып ыргытырга теләде. Ләкин чанадан төшсә дә, кыз төшеп калганнардан түгел иде. Сигез яшьтән утау утап, унике яшеннән сәнәк тотып үскән кавем—бирешергә теләмәде—егылып китәм дигәндә, тәртәгә тотынып өлгерде, сонынннан чана үрәчәсенә чытырдап ябышты. Бу инде үлем ябышуы, аерсаң, бармакларын келәшчә белән генә аерырлык иде.

Жил Гайниянең башындагы яулыгын йолкып алды. Кыз аны бер кулы белән чак тотып өлгерде. Бушап калган изүләренә кар тулды һәм яндырып тән буйлап аска төшеп китте. Соңгы көчен жыеп, ул чанадагы әле янарак кына жылы булган, ләкин суынырга өлгергән урынына менеп ауды. Тунудан калтыраргa, тешләре тешкә тими дерелдәргә тотынды. Мисбах:

—Ахмак!—дип аның кылган гамәленә бер сүз белән бәя бирде дә тунудан бичара калган кызның авызына куен кесәсендә тоткан шешәдән, Гайния ни дә булса анлап өлгергәнче, аракы койды. Шешәне бушатып бетерүдән аны кызның чәчәве генә туктатып калды.

—Мисбах абый, кирәкми!

Ләкин аның кичегеп әйткән сүзләре жил белән, ак пәрдәле буран белән кышкы кырның караңгы төнендә йотылып юкка чыкты. Озакламый ж-ж дип ажгырган буран да, жил коткысына бирелеп, кеше бимазалаган кар бөртекләре дә, тунган аяклардан әкрен-әкрен югарыга үрмәләгән әрсез суык та онытылды, Гайниянең тәнен рәхәт изрәү биләп алды.

—Мисбах абый, нишлибез?

—Тире жыеп, күн эшлибез,—дип жавап бирде Мисбах, башка жавап тапмагач.—Безнең исән калу-калмавыбыз Бурлы айгырга бәйле. Кая теләсә, шунда алып китсен, куйыйк үз иркенә. Коткарса, ат кына коткара,—дип кабатлады ул.

Әле генә эчкәнен үзе дә сизми калган аракы дигән шайтан кызның эчен яндыра, миен томалый. Шуңа буран катыш шомлы билгесезлек килеп кушыла. Гайния көч-хәл белән:

—Үзең беләсең, Мисбах абый,—дию белән чикләнде.

Буран котыруын дәвам итте, атның ыңгырчагын салдырырга, дугасын каерып алырга яисә сындырырга теләп көчәнде. Ә Бурлы айгыр, бичара, һаман басып торуын белде. Яннан искән жил басымыннан колхоз бияләренең төшенә кереп йөдәткән нәсел айгыры, вакыт-вакыт чайкалып куйса да, аягында кала бирде. Гади, бер мескен алаша булса ул күптән авар, яки басып торган жирендә ятып, чүлдәге дөя шикелле, давылны уздырып жибәрер иде. Юк, ярамый, киләчәктә туасы уннарча, йөзләрчә колыннар хакына, чанадагы кешеләр хакына ул үзен сакларга тиеш. Атның гаять дәү баш миендә дә, караңгы кырдагы шикелле, буталчык уйлар хакимлек итә бугай.

Бурлы айгыр туктап калган урынында торды-торды да, бер фәрман да булмагач, әкрен генә кузгалып китте. Аның кая таба атлаганын буран каршында көчсез калган ни Мисбах, ни аракы тәэсиреннән ошбу дөнья белән ахирәт арасына күчә барган Гайния сизмәде.

Ат каядыр билгесезлеккә атлавын дәвам итте. Мисбах дилбегәне үрәчәгә бәйләп куйды һәм аңа бүтән кагылмады.

Бурлы айгыр күпме атлагандыр, чанадагылар вакытны чамалый алырлык хәлдә түгел иделәр. Атның табигать тарафыннан бирелгән сизгерлеге алдамады—буран белән тартыша-тартыша атлый торгач, берзаманны аксак бухгалтерның кысык күзләре район үзәгенең сугыш чоры рөхсәт итә алган кадәрле якты утларын күреп алды.

Районга киткәндә, кайчан кайтасыңны белмисең. Бигрәк тә кичен бюрога чакырсалар. Бюроның кайсы-берсе ярты төнгә кадәр сузыла.

Кунмый ни хәл итәсең. Ә кунакханәләр юк. Шуңа күрә һәр колхоз район үзәгендә үзенең фатирын тотарга тырыша.

Ат Азнакайга килеп керде. Хәзер кая барырга? Мисбах Гайниядән:

—Кунар урының бармы?—дип сораган иде, кыз ишетмәдеме, әллә йокы исереклеге белән аңламадымы, дәшмәде. Ул дәшми дип урамда калып булмый, колхоз фатирына юл тотарга кирәк. Хатыны ягыннан туганнары булса да, Мисбах аларга барып торуны кирәк санамады. Бергә икән бергә, буран басылгач, кайтып китүе җиңелрәк булыр.

Колхоз фатиры Доха исемле карчыклар өендә урнашкан иде. Доха түтинең ире Колымада ашыга-ашыга «социализм» төзегәндә үлгән, кызлары кияүдә, ә бердәнбер улы Рәфыйк Курск дугасында хәбәрсез югалган.

Житмешкә житеп килә торган карчыкка йортында колхоз фатиры тоту бик җиңелдән түгел, элек булса, ике дә уйламас, бу мәшәкатьле эштән баш тартыр иде. Ник дисәң, өең һәрвакыт җылы, түшәк-ястыкларың житәрлек, самавырың кайнап чыгарга әзер торырга тиеш. Көн уртасында да, төн уртасында да килеп керүләре мөмкин. Аларның бер генә кеше дә, унау да булулары бар. Сыйсаң сый, түзсәң түз—караңгы чырай күрсәтә алмыйсың.

Ләкин мохтаҗ заман өчен икенче ягын да онытырга ярамый фатир кертүнең: ат аунаган жирдә төге калган кебек, бу хезмәтләре өчен кунып чыгучылар да буш итми, колхоздан да тама. Һәр кабым ризык исәптә чакта, кысанлыкка вә мәшәкатькә генә түзәрсең.

Колхоздан Мисбах белән яшь хисапчы кыз килеп кергәч, Доха карчык шуңа күрә гаҗәпләнмәде. Киресенчә:

—Әйдүк, әйдүк, Алланың рәхмәте белән киләсез!—дип, шатланып каршы алды. Шатланмас җиреңнән шатланырсың, әтрәк-әләм өзелмәсә дә, баш хисапчы көн дә фатирга кереп тормый. Ә ул юмарт, бер дә буш кул белән йөрми.

Гомер эчмәгән аракы Гайниянең туңган-өшегән тәненә шулкадәр тәэсир иткән иде ки, ул әле хәзер дә ни булганын аңлап бетермәде. Колхоз фатиры барлыгын белсә дә, килеп караганы, Доха түтине дә күргәне юк иде.

Доха түти казан астына ягып җибәрде. Колхозның яшь бәрән итенең тәмле исе, борын аша узып, җылы ризык тансыклаган ашказаны бизләрен кытыкларга керешТе. Учактагы тере усак күмерләре җиде литр сыешлы жиз самавырга салынды.

Бу минутта кеше хыяллана алырга сәләтле оҗмах шушы: казанда ит пешә, самавырда чишмә суы менә-менә кайнап чыгам дип пышылдый. Сугыш еракта, буранның куркыныч тавышы гына морҗа аша үкереп куя һәм өй тәрәзәсен ак яулык сыпырып-сыпырып уза. Самавыр инде ике тапкыр сүрелеп, өченчесенә кайнады. Бәрән шулпасына умач уып салгач, фатир хуҗасы әйтте:

—Кызым, Мисбах улым, үзегез бүлеп ашагыз инде. Мөсәппихәттәйнең сугышта оныгын үтергәннәр, елый да елый, куна керергә чакырган иде. Каршы килмәсәгез, китәр идем...

Ничек инде мондый чакта каршы киләсең. Мисбахтан алда Гайния җавап бирде:

—Ярар, әбкәй, борчылма.

Доха карчык тәмле йокы теләде һәм үзе дә сизмәстән, кәҗә белән кәбестәне бер йортта калдырып, Мөсәппиха карчык өенә табан теркелдәде.

Гайнияләр йортында бәрән ите көн дә пешеп тормый. Ит салымын түләүдән калганын сатып, йортта тормыш алып бару өчен кирәк-яракны юнәтәләр.

Көне буена кичерешләрдән һәм бурандагы өшү-тунулардан котылгач, ризыклы җылы өйдә Гайния кинәт туарылып, изрәп китте. Ит шулпасының

исе селәгәенне агызырлык. Әгәр дә Мисбах абыйсы янәшәдә булмаса, ул хәзер үк арыш оныннан уган умачка, авызына керүгә эрим дип торган калжага бүре кебек ташланыр иде. Әмма...дөньяда әдәп дигән нәрсә бар. Житмәсә, ул бит әле кыз бала.

Мисбах та ашарга каршы түгел. Ләкин ул Гайниягә күрсәтмичә генә "арыш малаен" шешә авызыннан гына берничә тапкыр голт-голт итеп алырга өлгергән, ә аракы исә ашыйсы килүне күпмедер дәрәжәдә баса төшкән иде.

Доха түти әллә бирергә онытты, әллә чыннан да булмаганмы, Гайния ашны һәркемгә аерым бүләрлек савытлар тапмады. Шуна күрә, зур агач табакка сосып, умачны өстәл уртасына утыртты. Итне дә шунда турап салды. Инде ашарга да мөмкин. Гайния, кашыгына шулпа эләктереп, кабарга гына жыенган иде, Мисбахның:

—Стоп! Ашыкма, Гайния!—дигәнен ишеткәч, авызына китергән кашыгын ихтыярсыздан кире төшерде һәм сораулы карашын юнәлдерде.

Мисбах, аксакларга хас булмаган житезлек белән, мич башына жылытырга куйган шешәсен алып килеп өстәлгә утыртты һәм каяндыр чәркәләр сөйрәп чыгарып, аларга аракы койды.

—Бүген, Гайниякәй, син—героиня. Отчетны тапшырдык, буранда адашып үлмичә, исән калдык. Болар өчен дә эчмәү гөнаһ булыр.

Мисбах шул сүзләрдән соң Гайния белән чәкештереп, үзенә салганны йотып куйды. Ә кызның күтәрелә башлаган кулы кире төште. Моны күреп, Мисбах:

—Ну-ну, алай ярамый,—дип, мескен кызның чәркәсен кулына алды һәм аның авызына сузды.

—Кирәкми, Мисбах абый, эчмим.

Гайния берничә сәгать элек кенә, буран сызгырып торганда, үзенең берничә йотым эчкәненә әле булса ышанып бетә алмый. Гомердә булмаганны, ул, Гайния... аракы эчсен әле. Әллә соң төш кенә булдымы икән?

Мисбахның әле бу кадәр телгә осталыгын белми иде Гайния.

—Син нәрсә, понимаешь, суык тигереп чирләргә, сугыш чорында эш калдырып өйдә ятарга уйлыйсынмы? Мисбах абзыең әйтә икән, эч, ике әйттертмә! Яланда эчтең бит, укаң коелмады. Әллә син шешә авызыннан гына эчәргә өйрәнгәнме? Мә, алайса, шешәдән эч! Син мине ник эчә дип уйлыйсың? Дару булсын дип, чирләмәс өчен эчәм мин, бик беләсең килсә! Үпкәнә бер салкын тидерсәң, син кемгә кирәк? Иптәш Сталинга таза, сау-сәламәт кызлар, егетләр кирәк. Син, комсомолка башың белән, иптәш Сталинга каршымы?

Мәсьәләне Мисбах абыйсы болай ук кискен куяр дип уйламаган иде Гайния. Сталинга каршымы, дип үк сорый бит. Нинди куркыныч сүзләр. Сталинга, халыклар атасына, бөтен дөньяга бәхет, тынычлык өләшүчегә канэчкеч капиталистлардан башка кем каршы булсын. Кирәк икән, Гайния иптәш Сталин өчен, аның эше өчен гомерен дә бирергә риза. Мондый гаепне күтәргәнче, агу эчүен яхшырак.

Ул авызына Мисбах терәгән шешәне көч-хәл белән этәреп, чәркәсен иренена якын китерде. Исәбе ирен тигезеп куюда гына иде, ләкин абзый кеше инициативаны үз кулына алды: эчеп бетерергә мәжбүр итте. Әллә ялгыш юлдан китте, Гайния чәчәде. Кызны чын күнелдән кызганды Мисбах, аркасына йомшак кына суккалап, тынычландырды, аннан авызына кашык белән шулпа каптырды.

—Курденме, үтә ул. Аның урынына сиңа суык тими, йокларга да әйбәт булыр,—дип тынычландыргандай итте. Эчәргә бүтән кыстамады.

Аракы кызның тәненә таралып, Гайнияне рәхәт изрәтте. Аның йокысы

килә башлады.

Ашап-эчеп туйгач, Гайния үзенә чаршау эчендәге агач караватка, юлдашына сәкегә урын җәйде һәм, Мисбах абыйсына тыныч йокы теләп, ятагына үрмәләде.

Мисбахның шешәне төпләмичә ята торган гадәте юк. Хәтта, иртән торгач, баш төзәтергә кирәк буласын белсә дә. Аракысы азайган саен, ул аны эчүне мөмкин кадәр озаккарак сузарга тырыша.

Бу көнне дә ул ярты төнгә кадәр утырды. Гайния инде күптән йоклый. Аның тигез генә сулавы ара-тирә тирән тын алу белән бүленә.

Адәм баласының башына соңгы йотым җитә диләр. Мисбах та бирешми утырды-утырды да соңгы тамчысы тәмам башына китте. Хәзер тизрәк ятарга, йокларга кирәк. Әле бит иртән торасы, кайтасы, дебет-кредитлар санап, чут сугып утырасы бар.

Ятар алдыннан тышка чыгып керде. Аны танып, Бурлы айгыр иркәләнеп кешнәп куйды. Буран әле һаман улый иде.

Кереп, үзенә җәелгән түшәк янында Мисбах ашыкмыйча гына чишенде. Ул инде лампадагы утны сүндерергә әзерләнгән иде, чаршауның ябылып бетмәгән җиреннән ихтыярсыздан Гайниягә күзе төште. Өй җылы булгангамы, кызның юрганы кырыйга тибәрелгән, икегә үргән толымының берсе күкрәгенә төшкән, күлмәгенең өстәге сәдәфе ычкыну сәбәпле, тыгыз имиләре яртылаш ачылган. Борылгалап ята торгач, күлмәк итәге сыдырылып өскә менгән. Аның һушыңнан яздырырлык тыгыз балтырларын, таза ботларын күргәннән соң, Мисбах акылын югалту дәрәҗәсенә җитте. Бер хәчтерүш сәрхүштән ажгырып торган иргә әверелде. Шушы кадәр матурлык, гүзәллек каршысында үзен тыеп кала алмады ул. Чыраны сүндерергә барып йөрү вакытны бушка уздыру, олы мәгънәсезлек саналыр иде, ул, бар көчен җыеп, аны өреп кенә сүндерде дә, өстендәге калган киемен салып ыргытып, кызның кочагын чумды һәм, ни эшләгәнен белмичә, аны татлы иреннәреннән, кагылган саен тыгызлана барган ими очларыннан үбәргә кереште.

Төшендә Мөнирҗаны белән кавышкан кыз карышмады. Йокы һәм аракы исереклегеннән, Мисбахның туктаусыз назлауларыннан аның ихтыяры сынган, ни булганын аңларлык хәлдә түгел иде. Мисбах аны тәмам үзенеке иткән чакта да:

—Кадерлем, бердәнберем минем!—дип рәхәт ыңгырашып алды да авыртулы ләззәт дөньясына чумды. Кызның, саташып, берничә тапкыр: «Мөнирем, Мөнирҗаным!»—дигәнен Мисбах хәтта ишетмәде, ул инде күптән үз-үзенә хуҗа булудан туктаган иде.

Гайния таң әтәчләре кычкыра башлагач уянды һәм үзалдына елмаеп ятты. Нинди тәмле төш күрде ул бу юлы. Мөнирҗаны исән, исән, алар шундый ләззәтле итеп яратыштылар, алар бергә! Шунда ул тәненең авыртуын, моңа кадәр татып карамаган сәер халәттә тоеп, ни булганын аңларга, исенә төшерергә тырышты. Әле генә рәхәт иде бит. Тукта, ул нинди таныш түгел өйдә соң? Аптыраганнан Гайния үзен капшарга кереште һәм, ялангач икәнен белеп, сискәнеп китте, тәненә салкын йөгерде. Борынына тынчыган кан исе бәреп керде. Нинди кан исе булырга мөмкин? Айлыгы узганга әле ун көн дә юк ич. Күкрәкләре ник авырта? Өйләрендә анадан тума чишенеп йокламаганны, ни эшләп монда ялангач калган? Әллә Мөнирҗан белән яратышулары төштә булмыйча, өндә булдымы икән? Алай дисәң, Мөнире кайда?

Гырлаган тавыш ишетеп, кыз чыбылдыктан башын чыгарып карыйсы итте. Инде бераз яктыра башлаган һәм өйдә ни барын шәйләргә мөмкин иде. Иң башта ул сәкедә ятучы шәрә Мисбахны күреп, өнсез калды. Мисбахның киенеп торырлык хәле калмаганмы, әллә җылы өйдә кирәк санамаганмы,

чалкан яткан да йоклаган. Өйгә төшкән иртәнге саран яктылыкта аның күкрәген каплаган куе кара йоны кендек астына кадәр сузылганы һәм балтырлары белән тоташканы күренә. Кызны кинәт яшен суктымыни: Мөнирҗан дип кемне кочканын, бу буранлы төннен үзенә төзәтеп була алмаслык нинди фаҗигага китергәнен кинәт аңлаудан ул эсселе-суыклы булып китте. Тәне куырылды. Нинди ахмаклык, Мөнирҗанның кулын биленә дә тигертмич ут эченә җибәрде бит. Нинди әшәке кеше син! Гайния, үз-үзеннән җирәнеп, ашыга-ашыга киенә башлады. Киенеп беткәч, өстәлдә кукраеп утырган буш шешә белән берни сизми гырлый-гырлый йоклап яткан аксак шайтанның чыраена тондырасы килде. Шул мизгелдә үк бу уеннан кире кайтты. Хәзер аңа яшәүнең мәгънәсе калмаган иде, чыгып, тизрәк асылынырга теләде. Шул ук вакытта эчке бер тавыш үз-үзенә кул салуның, ягъни мордар китүнең бик зур гөнаһ икәнен исенә төшерде. Мордар китүчеләрне уртак зиратка да куйдыртмыйлар бит шәригать буенча.

Ул үзенең нинди хата ясаганын минут саен ныграк аңлый бара иде. Гарьләнүдән ачыргаланып, баскыч төбенә чыкты да үксеп еларга кереште һәм туктаусыз үзен битәрләргә тотынды. Бердәнберен, ирең өчен кадерләп саклап тоткан гыйффәтең белән шушы кадәр ахмакларча саубуллаш инде. Ахмак, аңгыра, ачык авыз! Еламас жиреннән еларсын. Мөнирҗаны кайткач, аның күзенә ничек күренер? Юк, иң яхшысы, Мөнирҗанны онытырга, онытырга, онытырга!

Бурлы айгырның назлы кешнәве Гайнияне аңына китерде: ничек кенә булмасын, тормыш дәвам итә, ул яшәргә тиеш...

Бурлы айгыр үзен тәртә арасына хатын-кыз кертә, дип карышып тормады, чөнки озакка сузылган сугыш елларында бу табигать иркәсен кем генә җикмәде дә, кем генә утырып йөрмәде.

Жигеп бетергәч, Гайния кереп эш кәгазьләрен алды да йоклап яткан Мисбахның гаурәтенә җирәнгеч караш ташлап, чанага чыгып утырды. Бәхетеннән, буран басыла төшкән. Их, кичә котырмаган булса иде ул—Гайния башына бу бәхетсезлек килмәс иде.

Бурлы айгырга дилбегәне бер кагу житте—сәгатьтән артык вакыт узуга, юл булмаса да, үзе генә белгән билгеләр буенча кичә генә дөньяның иң бәхетле, бүген исә иң бәхетсез кызын авылына алып кайтып житкерде. Авылын, жил ыжгырып торган сараен, төн чыкканчы ул да сагынып өлгергән иде.

Язмыш бер шаяртса, усал шаярта. Шушы төндә Мәскәү госпиталендә гвардия рядовое Мөнирҗан Исламов, айдан артык һушсыз ятканнан соң, аңына килде һәм авыз ачып әйтә алган беренче сүзе «лейтенант кайда?» булса, икенче тапкырында «Гайния» булды.

Очрашу тәмамлангач, кабат Мөнирҗан янына килеп, Корпухин аны кочаклап алды, үзе туктаусыз сөйләнде:

—Менә бит, ышанмас жиреннән ышанырсың могҗизаларга! Йә әйт инде, биредә сине очрату могҗиза түгелмени? Тере икәнлегенне белсәм, моңарчы жир астыннан да тапкан булыр идем мин сине!

Очрашуга ул чыннан да бик шат иде һәм бу шатлыгын Мөнирҗанга ничек аңлатырга да белми иде.

—Менә бит , ә! Менә бит нинди очрашу!

Полковник Мөнирҗанны, ниһаять, кочагыннан ычкындырды.

—Туктале, сине ни өчен утырттылар?—Аннан үз соравыннан үзе уңайсызланды.—Хәер, кыен икән, әйтмәсән дә була.

Ник кыен булсын? Ул кеше үтермәде, кемнеңдер хәләл малын урлап яки хатын-кыз көчләп кермәде. Аның бар бәхете вә бәхетсезлеге—вак

хулиганлыктан. Исерек көенә берәр түрәгә кыек карадымы яки катырак сүз әйттеме, кемгә дә булса әз генә бәйләндеме—статьялар аны көтеп кенә тора, хәтта чиратка басалар. Ванядан ник яшерергә, бик теләсә ул төрмә начальнигыннан барыбер сорап белә ала ич. Мондый герой-полковникка алар әйтми калырмы? Юк, калмас.

Мөнирҗан җавап бирергә дип авызын ачкан иде, өлгерә алмый калды: Корпухин янына колония түрәләре килеп басты. Тумыштан Ходай акылны мул биргән һәм Союз төрмәләрен айкап чыккан тоткын үзенең хәзер биредә артык икәнен белә, чөнки кадерле кунакны сыйларга алып китәчәкләр. Ул элеккеге взвод командирының кулын нык кына кысты да, кемдер сүз әйтергә өлгергәнче, ишеккә табан атлады.

Их, Ваня, Ваня, бу очрашуга Мөнирҗанның да ничек шат икәнен белсәң иде!

Уйларына бирелеп, Мөнирҗан казармага табан атлады. Ләкин анда кайтып җитү насыйп булмады. Клубтан илле-алтмыш метрлар китеп өлгердеме икән:

—Гражданин Исламов, бире кил!- дигән әмер ишетеп, туктап калды. Тагын бүтән берәр Исламов бармы, әллә аңа кычкыралармы? Кычкырса, кем кычкыра?

Биредә синең күңелең йомшаганны күрергә тиеш түгелләр, шуңа күрә исән кул аркасы белән күзенә ихтыярсыздан бәреп чыккан яшьләрен сөрткәч кенә борылды ул. Надзиратель кычкырып туктаткан икән. Ул йөгерә-атлап янына килеп җитүгә:

—Әйдә, тиз бул, сине начальник чакыра!—дип, берни аңламаган Мөнирҗанны ашыктыра башлады.

Исламовны туп-туры ашханәгә алып керделәр. Анда да каядыр эчкә—түрәләрнең аеруча дәрәҗәле кунакларны кабул итү бүлмәсенә. Мондый бүлмәнең барлыгын төрмәдәге һәр тоткын белә, тик бүлмәнең үзен күрергә, эченә керергә туры килгәне юк иде әле. Мондый бәхет тагын кайсы ристанга эләксен.

Өстәлгә төрле ризыклар, көмеш чәнечке-калаклар куелган, «Шампанское» шешәсе белән янәшә ике «Столичная», бер әрмән коньягы кукраеп утыра. Колония башлыгы һәм аның ике урынбасары, Корпухин әле кул юып торалар иде.

—Мунирчик, син кая качтың? Очрашу хөрмәтенә мыек чылатмый ярамый ич.—Кулын ашыга-ашыга сөртеп, Корпухин Мөнирҗан янына килеп басты.—Кыенсынма, Валерий Афанасьевич белән сөйләштем. Рәхмәт ана, каршы килмәде.

—Килмәсә дә, Ваня, сез—товарищлар, ә мин гражданин гына бит. Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый. Китим мин, ашыгызга таракан булып төшмим. Бик теләсәң, яңадан күрешербез.

—Юкны сөйләмә! Әлбәттә, яңадан да очрашырбыз. Тик мин сине хәзер дә янымнан җибәрмим яки үзем дә синең белән китәм.

Аларны төрмә башлыгы бүлдерде:

—Исламов, отставить разговоры! Иптәш полковник әйткән икән—закон. Мондый зур бәйрәм хөрмәтенә ярый-ярамыйга күз йомсаң да ярый. Сезнең очрашу—тарихи вакыйга. Аннан соң бездә фронтовиклар бүтән юк та бугай, ә, комиссар?—Ул тәрбия эшләре буенча урынбасарына карады.

—Богатырев бар иде, ярты ел элек үлде. Хәзер, Валерий Афанасьевич, бер Исламов кына калды.

Мөнирҗан хәтерли: фамилиясе Богатырев булса да, буе шактый карсак Мәскәү урысын утырткаННар иде. Ниндидер базаның мөдире булып, зур житмәүчелеге чыккан булган.

—Начальникны коткардым, үземнең тамчы да гаебем юк,— дип зар

елаганы бар иде Николай Кузьмичның.—Менә күреп торырсың, озак утырмыйм мин монда. Шеф тиз арада чыгарырга вәгъдә итте.

Курск дугасы һәм сугышның тагын дистәләрчә мәхшәреннән исән калган, ике тапкыр Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән, биш тапкыр Сталинның рәхмәт хатына лаек булган элеккеге снайпер, алтмышка житеп килүенә карамастан, күңелендә беркатлы сабый булып калган иде. Шул гомер яшәп тә, ул түрәләрнең, асларына су керә башлагач, вассалларын кочаклап, койрык төбен ялап, табан асларын үбәргә әзер булып та, куркыныч узуга вәгъдә-антларын онытуларын, күрәсең, башына да китерми.

Үзен коткаруларын бер ел көтте ветеран. Өметләре алдануга ышанып, бераз булса да тынычланырга өлгермәде, язмыш дигән кодрәт иясе нечкә күңелле Николайның башына янә кусәк белән орды: усал телләр Мәскәүдә калган хатыны Анастасиянең хыянәте турында хәбәр житкерделәр.

Их, Настенька, Настенька, майлы күз! Сагышыннан ни эшләргә белмәгән Николайның йөрәгенә янә дә ут өстәдең? Ул болай да дөрләп яна иде ич.

Югарыдан килгән әмер шундый булды: Николай Кузьмич бар гаепне үз өстенә алсын, ә мондагылар аны рәнжетергә ирек бирмәячәкләр. Хәтта, хөкем иткән очракта да, озак утырмас, аны коткарырлар һәм калган тормышын Василий Кузьмич рәхәттә уздырыр. Бары тик рәхәттә генә... Яшь хатыны кочагында...

Алар уйлаганча, алар вәгъдә иткәнчә генә гына барса иде дөнья! Богатыревтан кала берәүгә дә жил-янгыр тимәде. Иректә калганнар башта шау-шу бераз тынсын әле дип йөрделәр, соңрак, һәркемнең үз тиресе үзенә кадерле, Николай хакында бөтенләй оныттылар. Гүя ул бөтенләй булмаган да.

Онытып кына калсалар, ярты гына бәла булыр иде, котылырына ярты елдан чак кына артык калган Николай Кузьмичка аның фәрештәгә тиң санаган Анастасиясенең база башлыгы Афанасьев белән романы турында хәбәр килеп ирешә.

Алтмышка житеп килсә дә күңелендә сабыйлыгын саклаган Николай Кузьмич бу хәбәрне күтәрә алмады: ике-өч көн буена балтасы суга төшкән адәмдәй башын иеп, беркем белән дә сөйләшмичә йөрде-йөрде дә бер төнне венасын кисте. Аны күреп алганда, гәүдәсе суынып беткән иде инде. Төрмә табиблары янына бары тик үлемен раслату өчен генә алып бардылар.

Анастасия әле күптәнме генә чөкердәшеп пар күгәрченнәрдәй яшәгән иренең жәсәде артыннан килеп мәшәкатьләнмәде.

Үзен-үзе үтерүләр генә түгел, бер-берсен үтерешләр дә булгалап торган тоткыннар арасында Богатыревның мордар китүе әлләни искитәрлек вакыйга саналмады. Кемгә дә булса ялгыш та зыяны тия алмаган Николай Кузьмич турында әз генә шауладылар да шуның белән бетте, тындылар. Бар иде кеше, юк инде кеше. Рәсәйнең бер кешелек проблемасы кимеде.

Ашханәнең кунак бүлмәсендә ике-өч тосттан соң хужалар да, полковник та жылына төште. Мөниржан баштарак бик кыенсынып утырды, ник дисән биш тапкыр утыруга тугызынчы төрмәгә эләкте, әле бер тапкыр да колония начальнигының үзе белән салырга туры килгәне юк иде. Торабара аракы аның кан тамырларына таралды, ул үзен иркенрәк хис итә башлады. Әйтерсең, ул мондагы меңләгән ристанның берсе түгел, сугыш каһарманы Корпухин, төрмә башлыгы һәм аның "айт" дигәнгә "тайт" диярргә әзер торган урынбасарлары белән бер үлчәмгә күчте. Ничектер шулай килеп чыкты, бик күптәннән аракы эчеп караганы булмаса да ул чамасын онытмаска тырышты. Ә бит иректә ул жай чыкканда эчүнең кимен куймады. Мәжлес кызган саен, биредә утыручылар арасында субординация дигән нәрсә югала барды. Хәмернең шундый бер асыл сыйфаты бар: ул үзара мөнәсәбәтләрне яки тигезли, яки кискенләштерә. Ә монда бу кешеләр

арасында ачуланышыр, бүлешер нәрсә кайдан булсын.

Корпухин белән кабат очрашырга сүз биреп аерылышканнар иде. Салган баштан бирелсә дә, ул сүзендә торды: шушы очрашудан соң, җае чыкканда Мөниржан янына килә торган булып китте. Әлбәттә, фронтташ дусты янына буш кул белән килми, мөмкин булган хөрмәтне күрсәтергә тырыша. Инструкция буенча алай ярагандырмы, хәтта бер-ике тапкыр сорап, өенә дә алып чыкты. Алар хатыны Мария Давидовна белән икесе өч бүлмәле квартирада торалар, полковник хәрби училищеда укыта, ә хуҗабикә, пенсиягә чыкканчы, мәктәптә директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары булган, хәзер исә бар сәләтен ирен тәрбияләүгә бирә.

Мөниржанның менә-менә амнистия булыр дип көтеп йөргән көннәре иде. Тиздән туган җиргә кайтам дип яшәгәндә, Валерий Афанасьевич кайгылы хәбәр җиткерде: алдагы көнне аның фронтташ дусты Иван Корпухин инфаркттан үлгән.

—Менә шулай, Исламов, үлем хәтта геройларны да аямый,—дип үзенчә нәтиҗә ясады төрмә начальнигы.—Яхшы кеше иде мәрхүм, урыны оҗмахта булсын. Иртәгә күмәләр икән, барасыңмы?

Нәрсә нәрсә, Мөниржан мондый тәкъдимне көтмәгән иде, аптырап, өстендәге төрмә киеменә карады. Валерий Афанасьевич тоткынның хәлен аңлады.

—Борчылма, берәр кием табарбыз.

Корпухинны күмәргә халык күп җыелды. Хәрби училище бинасына куелган гәүдә янында курсантлар да, офицерлар да, гади киемдәгеләр дә сакта торды. Бу чыннан да шәһәр тормышында зур вакыйга. Полковниклар, бигрәк тә герой полковниклар көн дә үлеп тормый.

Шушы кадәрле халык арасында Мөниржан мәрхүмнең бердәнбер фронтташы булып чыкты. Күмүне оештыручыларга бу хакта төрмә башлыгы әйткәндерме, әллә башына төшкән әче хәсрәттән бөгелеп-сыгылып калган Мария Давидовнадырмы—анысын Мөниржан белмәде—көтмәгәндә аңа да сүз бирделәр. Аңа—зекка шушындый дәрәҗәле җирдә сүз бирсеннәр әле! Йөрәгең тотып, егылып китәрсең.

Мөниржан кайда да булса чыгыш ясап өйрәнгән кеше түгел, ә сөйләргә кирәк. Әнә ич барысының да күзләре аңа текәлгән, сүз көтәләр. Нидән башларга?

—Ваня дустым, бер-беребезне үлгән санап йөргән җирдән язмыш безне кабат очраштырды.—Ул кайда очрашулары хакында сөйләп тормады.—Күпме үлемнән, ядрә, снарядтан исән калып та, шушы яшьтә, шушындый тыныч, матур тормышта көтмәгәндә арабыздан китеп баруың һич кенә дә башка сыймый. Сиңа яшәргә дә яшәргә иде әле. Хуш, командир, каберендә тыныч йокла, урының оҗмахта булсын. Үзем исән чагында сине онытмам.

Төрмәдә булса, ул оялыр иде, бередә кыенсынып торуны кирәк санамады. Хәер, санаса да тыелып кала алмас иде—Мөниржан елап җибәргәнен сизми дә калды. Аңа Мария Давидовна кушылды.

Сүз сөйләүчеләр тагын да булды, ләкин Мөниржан кем сөйләгәнен дә, нәрсә сөйләгәнен дә аңларлык хәлдә түгел иде. Миен бер кире кага алмаслык хакыйкать бораулады: Корпухин, аның бердәнбер исән калган фронтташы, командиры инде юк. Еласаң да, җырласаң да, Ваняны кире кайтарып булмаячак иде.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Илдус
Гыйләҗев

# ШАТЛЫКЛАРЫМ БУЛДЫ, ҖИҢҮЛӘРЕМ...

## Кәгазь калынлык кына

**Күкрәк аша пуля тишеп үткән,
Бабай исән, хәйран калырлык.
Йөрәк итен ертып узалмаган—
Ара калган кәгазь калынлык.
Сугыш арты еллар искә төшә,
Сирәк тиде татлы кабымлык.
Әй ул ипекәйнең тәмлелеге,
Акмай яксаң кәгазь калынлык.
Язмышларны шул да хәл итә шул,
Яшьлек узды, әйдә кагылмыйк:
Бербөтен үк була алмадык ич—
Ара калды кәгазь калынлык...**

## Белеп корганнар

**Мәдәнилек ягын әйтә алмыйм,
Булган диләр "сугыш белгече".
Башкаласын мәгәр бу Рәсәйнең
Белеп салган Петр Беренче.
Җәен-кышын котып салкыннары
Шуннан исә татар иленә.
Әйтерсең лә махсус җибәрәләр,
Кырау тия күңел гөлемә.
Төп башкала читкә күченсә дә,
Үзгәрмәде мәсләк -көн багыш.
Солдат килмәсә дә, салкын килә,
Юнәлеше—төньяк-көнбатыш...**

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) – *шагыйрь, "Кадерле китап", "Җир китабы", "Мәгарә" һ. б. шигырь китаплары авторы, Татарстан Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Азнакай районының Түйкә авылында яши.*

## Төнәмәсә, төнәми бит...

**Бүтән Иван килер иде,**
**Явыз Иван килмәсә.**
**Дошман керә... акыл гына**
**Керми ул, бер кермәсә.**
**Илне харап иткән нәрсә –**
**Читләр түгел, таркаулык.**
**Нәтиҗәсе күз алдында:**
**Ваклану да таркалу.**
**Кая барып төртелербез?**
**Кем чистартыр тапларны??**
**...Үткәннәрдән сабак алмау**
**Төп чиредер татарның.**

## Шигырь базары

**Язу белән күпләр мавыгалар,**
**Булмаса да әҗер-мазары.**
**Тәкъдим ягы муддан күренсә да,**
**Бик сәер ул шигырь базары.**
**Башка җирдә хакны сатучылар**
**Тәгаенләп ача бәйрәмне.**
**Ә биредә хәлләр үзенчәрәк—**
**Үзе куя халык бәяне...**

## Рәхәткә чыкты берәү...

*Элекке рәис җыруы*

**Яуды ни дә, яумады ни...**
**Җәй үткән, күзләр җиткән.**
**...Пенсионер булып кына**
**Туасы калган икән...**

## Һәрберебез—әллә кем

*Син үзеңне кем дип белдең,*
*Бигрәк текә карашың.*
*Андый булсаң, беркемгә дә*
*Кирәгең юк, җанашым.*
"Эссе" төркеме башкаручы җырдан

**"Җыр" тыңлыйм да, сезне уйлыйм,**
**Безнең чордаш туташлар.**
**Дорфа сөйләшми идек бит,**
**Тыйнак идек тоташтан.**
**Матур үтеп китте яшьлек,**
**Төртмә сүзләр әйтешми.**
**Ярны җайлап сайлыйсың бит**
**Бездә, халык әйтмешли.**
**Үз итмәсә, нишләтәсең,**
**Булмый көчләп тагылып.**
**Горур калдык, яшәсәк тә**
**Кемнәрнедер сагынып.**
**Яшьлек дәрте—ярат тыра,**
**Сорап тормый милләтен.**
**Мәхәббәттә һәркем—тигез,**
**Үз-үзенә әллә кем...**

## Ялгышмадыммы?

Абыемның күргәч тоныкланган,
Газап белән тулы күзләрен:
—Тиз ал, Ходам, хәлен җиңеләйт,—дип,
Пышылдадым кинәт, түзмәдем.
Күктәгеләр мине ишеттеләр...
Зур югалту җанны тырнады.
Чак җитештем алып бәхиллеген—
Җиңеләйде... озак тормады.
Минем генә хәлем авырайды,
Аңны кыра шикләр ташкыны:
Гөнаһ җыймадыммы дип борчылам,
Ходай кодрәтенә тыкшынып...

## Аптырарсың да...

*Аптыраган үрдәк суга*
*арты белән чума.*

Мәкаль

Акыл сатып яшәсәк тә,
Богауны кисәлмәдек.
Әллә соң бер ду китереп
Алыйкмы исәрләнеп?
Башка юллар бар микән соң
Чыгарга әкәмәттән?
...Җүләргә суд юк, диләр бит,
Әле бу мәмләкәттә...

## Такташны яклап

*Зәңгәр төндә*
*Күрше карчыгының*
*Ак әтәчен кереп урладым...*

Һади Такташ

Әтәчкә үк барып житмәсәм дә,
Мин дә артык кимен куймадым:
Тәмен беләм күрше бакчасында
Үртәп яткан сары кыярның.
Үзебездә юкса тулып ашкан
Ямь-яшеле, тыгыз, сусылы.
Шуклык бит ул—малай-шалайларның
Үзен таныттыру ысулы.
Кул уйнату, әйе, начар гадәт –
Була алмый монда ташлама.
...Тыелганны кабып, татып карау
Адәм- Хәуадан ук башлана...

## Кәбисә елы

Бер-бер артлы тора килеп кенә:
Китте дуслар, китте туганнар.
Әйтерсең лә бөтен хәсрәтләрне
Шушы елга җыеп куйганнар.

Бер көн өстәп февраль азагына,
Дүрт елга бер фасыл төзәтеп,
Ялгышканмы саный башлаучылар,
Кеше язмышларын үзгәртеп?
Күкләр шуңа риза түгелләрме,
Торалармы кат-кат кисәтеп?
Уф, монсыннан исән чыгам бугай,
Алдагысы ниләр күрсәтер...

## Язып куелганмы?

Бөтен нәрсә үзе килде миңа:
"Бирегез!"—дип кулым сузмадым.
Шатлыкларым булды, җиңүләрем,
Кайгылар да читләп узмады.
Гел үзгәреп торды холык-фигыль,
Үсте, камилләште буй-сыным.
Гашыйк булдым, күп балалы әти...
Илаһи бер көчкә буйсындым.
Үзгәрешләр тагын булыр әле...
Ни күрсәм дә—башым югары!
Кем үзгәртә шулай?
Үзем бит мин
Сабый булып тудым нибары...

## Хуш, Чатыртау

Чатыртауны биш урадым
Әйләнеп карый-карый.
Шунда узган көннәремнең
Исәбен саный-саный.
Чатыртауда таш түгел ул,
Бодай бөртеге генә.
Хәлләремне аңлар кебек
Дала бөркете генә...
Чатыртаудан китеп барам
Борылып карый-карый.
Җирдә үткән гомеремнең
Елларын саный-саный...

## Урын башка, тел башка

Сүзләр ятлап йөрим. Ике телне
Камил белергә дип омтылам.
Татарчамны җиңел үзләштердем,
Монсы—җәфа... бик тиз онтыла.
Ни сәбәптән шулай тинтерәтә,
Аңга сеңми, чыгып йөдәтә?
Ят сүзләр бит керә башка гына,
Ә туган тел—төптә, йөрәктә...

## Бу халыкмы? Бу халык...

Әллә хәер тараталар пенсия дип?—
Санап карыйм хәйраннар калып.
Шуңа яши алган өчен генә дә бит
Ихтирамга лаек бу халык!

## Яшьлектә дә, картлыкта да

Яшьлегемдә иң-иң татлы сүзне
Бер гүзәлдән килде ишетәсе.
Өлгермәдем... ятка китеп барды,
Килмәгәндер инде иш итәсе.
Бабай булып йөргән бу көннәрдә,
Күшектерсә җанны кич-иртәсе,
Нигә һаман иң-иң җылы сүзне
Шул әбидән килә ишетәсе?...

## Кузгата күрмә

Өстәл өстем—давыл үткән төсле,
Тәртипсезлек, исең китмәле.
Аунап ята каләм, яза башлап
Туктап калган дәфтәр битләре.
Ябылмаган сүзлек мәрткә киткән,
Китап йоклый—укый башлаган...
Күпме гәҗит, журнал борсалана,
Әштер-өштер җәеп ташлаган.
Чәем калган—эчеп бетермәгән,
Өсте элпәләнгән-суынган.
Үземә бик ошый, һәммәсе дә
Мин дигәнчә, дөрес куелган.
Шулай торсын, берүк тия күрмә,
Таркау ятсын, җыйма, уйнама.
Тәртипсезлек күрсәм—җен кузгала,
Ул китүгә—илһам уяна...

Илүсә
Нәбиуллина

# ГӨЛҖИҺАН ӨЯНКЕСЕ

ХИКӘЯ

Кызы эштән кайтканда Гөлҗиһан тәрәзә янында уйланып утыра иде. Уйлары еракка, яшьлек елларына ук кайтып киткәнгәме, ул ишек ачылып-ябылганын да ишетмәде. Кызы эндәшкәч кенә сискәнеп китте, дөньясын онытып, уйга батып утыруыннан уңайсызланып куйды. Болай да матур итеп, озынчалап бәйләгән ак яулыгын рәтләгәндәй итте.

—Исәнме, әни!

Гөлҗиһан, яшьләрчә җиңел хәрәкәтләр белән, ялт итеп кызына борылды, матурлыгын югалтып бетермәгән сөйкемле йөзе яктырды. Кызының елмаюдан балкып торган нурлы йөзе аны тәмам тынычландырды. Ул җиңел генә торып бер-ике адым кызына таба атлады.

—Исән-имин генә эшләп кайттыңмы, кызым?

—Рәхмәт, әни, бар да яхшы.

Гөлҗиһан күнелендәгесен яшерү өчен чәчләрен яулык астына керткән хәрәкәтләр ясады. Анының бераз гына чал кергән чәчләре озынчалап бәйләнгән яулык астыннан да күренеп тора иде.

—Әтиеңне уйлап утыра идем әле...

Үз сүзләре үзенә дә ят ишетелдеме, унайсызланып кына көлемсерәп куйды.

—Әтине?

—Әйе, әтиеңне. Бүген төшемә керде, үзенә чакыра.

—Юкны сөйләмә инде, әни.

—Юк сүз түгел, кызым, вакыт инде.

—И, әни!

Кызы әнисе янына килеп анының иңнәреннән кочты, сабый баланы сөйгән кебек аркасыннан бәпләде.

—Ашыкма әле, әни, бер киткәч, кайтып булмый бит аннан.

Кызының сүзләреннән соң ананың йөзе тагын да яктыра төште. Төсен җуймаган кара күзләре нурланып китте.

—Анысы шулай инде.—Ул бераз гына икеләнеп торды да, тагын баягы сүзләрен кабатлады.—Әтиең янына барырга вакыт инде, кызым. Бик вакыт.

—Әни!

Гөлҗиһан, әйттем исә, кайттым, дигәндәй кулларын җәйде.

Кызы өс-башын алыштырып, кухняга узды. Анда анының табак-савыт

шалтыратканы, плитә өстендәге кәстрүлне ачып караганы ишетелде. Аннан зал ишегеннән башын тыгып, әнисенә сүз катты.

—Әни, бүген тагын бернәрсә дә ашамадыңмыни?

—Үземнең генә ашыйсы килми шул, кызым, сезне көтеп тордым. Менә кияү кайтыр да бергә-бергә түгәрәкләнеп утырып ашарбыз.

—Һич югы чәй куеп эчәргә иден.

—Эчмәдем инде, плитәгезнең дә рәтен белмим. Ул электр чәйнегенең тәмен дә тапмыйм.

—Авылдагы күмер самавырың юк инде, әни. Мин дә башта самавыр чәен нык сагына идем, аннан күнектем.

—Адәм баласы бар нәрсәгә дә күнегә.

Ләйлә әнисенең авылны сагынганын, жирсегәнен бик яхшы аңлый. Сигез дистәне тутырган ананы ялгызы гына авылда да яшәтеп булмый. Аны алып килгәнгә инде ун ел, ә ул һаман шәһәр тормышына күнегә, бу ыгы-зыгылы тормышны үз итә алмый.

Әнисе жае чыккан саен авылны, үзенең яшьтәшләрен сөйли. "Кифая исән микән", "Гөлсем ни хәлләрдә генә яши икән?"—дип, ахирәтләрен барлый. Көн саен диярлек күнеле белән балачагы, яшьлеге узган Ык буйларына кайта. Анда үсеп утырган талларны сагына. Яз саен ап-ак шомырт, балан чәчәгенә күмелгән, ә көзләрен кызыл карлыган, бөрлегән пешкән әрәмәләрен исеннән чыгара алмый.

Әнисе утыз биш яшендә, Ләйләгә нибары дүрт ай чагында биш бала белән тол калган. Күпме сулар аккан, һаман түшенә керә яраткан ире, аны оныта, аны югалтуы белән килешә алмый. Ире үлгәч, сылу хатынны биш баласы белән дә сорап килгәләгәннәр. Риза булмаган, әтисен яратып, аны сагынып, аның рухына тугры калып яшәгән.

Вакыт дәва, диләр. Вакыт дәва булса да дәвалап бетерә алмый торган яралар бар күрәсең.

Көндез әнисе сүзен башлап кына куйган икән әле. Кичке аштан соң, кызы дәфтәрләр тикшереп утырганда, Гөлжиһан йомшак кына басып аның янына килде. Дәфтәрләргә иелеп утырган кызына озак карап торды. Аның йөзеннән иренең чалымнарын эзләде.

Кызының мөһим эшен бүлдерергә базмыйча, озак кына сүз башлый алмый торды. Кузгатыргамы йөрәк яраларын, әллә юкмы дигәндәй, бераз уйланып утырды.

Әниләре серле сандык кебек. Эчендәгесен тиз генә түгеп сала торганнардан түгел. Авызында кара кан булса да төкермәс, ятларга сер бирмәс. Нәкъ менә әнисе кебекләр хакында «эчендә жигуле ат ята", диләр. Бүген исә әнисенә нидер булган, ул сер тутырылган сандыгын аз гына ача төшкән. Чит кешегә түгел бит—төпчегенә бераз гына күнелендәгесен бушатасы килгәндер. Эчен бушаганчы кемгәдер серләреңне сөйләү—сагынуга дәва бит инде ул. Аның башкача дәвасы да, име дә юк.

Ләйлә әнисенең үзенә сүзе барлыгын аңлады. Дәфтәрләрен бер читкә өеп куйды. Әни, мин тулысы белән синең карамакта, дигәндәй, елмаеп әнисенә борылды. Гөлжиһан кызының йомшак карашыннан эреп китте, батыраеп, күне буе чорналган уйлар йомгагын төпчегенә сүтә башлады.

—Кызым, безнең бакча башында, Ык буенда өянке бар иде, хәтерлисенме?

—Хәтерләмичә, бик яхшы беләм.

Ләйлә әнисенең сүзен куәтләп башын селкеде.

Бүлмәдә аз гына вакытка тынлык урнашты. Залда зур сәгатьнең "тек-тек" йөргәне ишетелде.

—Ул өянкегә без әле көймә бәйләп куя идек,—дип, Ләйлә өзелгән

әңгәмәне ялгап җибәрде..

—Әйе, көймәбез дә бар иде шул.

—Ник әле кинәт кенә ул өянкене исенә төшерде.

—Ул берәү генә түгел, парлашып үсә иде анда. Өйләнешкән елны әтиең белән утырткан идек. Әтиең үләр елны язгы ташу аның берсен алып китте... Шул җәйне әтиең үлде. Син әле бик кечкенә идең.

Әни кеше тынып калды. Аның күнелен хисләр ташкыны биләгән иде.

—Әни, нишләп бу хакта моңа кадәр сөйләгәнең булмады?

—Әйтәм бит, әтиең үлгәндә син сабый гына идең.

—Күпме еллар узгач...

Ләйлә сүзен әйтеп бетермәде.

—Ә апаларың, абыйларың бу хакта белә. Сиңа никтер сөйләнелмәгән. Гомер бит ул тормыш вак-төякләренә алдана-алдана тиз уза.

Гөлҗиһан кызына якынрак килеп утырды, аның үзенеке кебек үк кечкенә кулын учларына алды.

—Бер җәйне әтиеңнең күршебездәге яшь хатынга күзе төште.

Ләйләнең сулышы тукталгандай булды. Ул гаҗизләнеп әнисенә карап торды. Ул тыныч иде. Әнисе бу хәлләрне күнеленнән мең дә бер кат кичергәндер, хәзер исә шул күренешләрне кабат күз алдыннан уздыра булыр.

—Әтиенне минем өстән йөрер дип уйламадым да. Бу хакта белми дә калыр идем, күземне күрше апа ачты. Беркөнне чакырып алды да: "Гөлҗиһан, син иренә бераз күз-колак бул. Ул бит күршегез белән чуала,"—ди.

Гөлҗиһан тамагын кырып куйды. Кипшенеп киткән иреннәрен ялап алды.

—Әни, эчәсең киләме?

—Бер йотым су бирсәң әйбәт булыр иде.

Ләйлә тиз генә кухнядан кәсә белән су алып килде. Әнисе чыннан да бер генә йотым эчте дә сүзен дәвам итте:

—Әтиең йөрер дигән уй исемдә дә юк иде. Яратышып яшибез.

Күргәне берсе: «Шушы кадәр дә пар килерсез икән!»—дип соклана. Ышанасы килми, кеше сүзенә, көнчелектән янган хатын-кыз гайбәте генәдер дип уйлыйм. Ләкин күрше апа юк-бар сүз сөйләп йөри торганнардан түгел. Төпле акыллы, сүзен үлчәп әйтә торган хатын. Әтиеңә күз-колак була башладым. Ничек мин андагы үзгәрешләрне сизми калдым икән. Иренең читтәге хәлләрен иң соңыннан хатыны белә диләр. Хак икән. Ничек шулкадәр сукыр булганмын. Әтиең бөтенләй үзгәргән, икенче кешегә әйләнгән икән ләбаса, танырлык та түгел. Аны гүя алыштырып куйганнар, эче-тышы балкып тора. Егерме яшендәге кебек җитез, дәртле, аяк астыннан ут чыгарып йөри. Күзләре генә моңсу, мәхәббәт утын кешеләргә сиздермәс өчен эченә йотып, эчендәге уты күзенә моң булып саркып чыккан.

Гөлҗиһанның тавышы аз гына калтырап китте. Ләйлә янә күтәрелеп карады. Юк, еламый икән, әнисенең йөзе һаман да шулай тыныч. Битенә алсулык йөгергән.

Әни белән кыз бераз тын утырдылар. Икесенең дә күңелләре урыныннан кузгалган иде. Хис ташкынын хәзер эчтә калдырып булмаячак, ул үзеннән-үзе бәреп чыгачак.

—Кырык яшькә җитәрәк ирләрнең янтыгына шайтан төртә диләрме әле. Әтиең белән дә нәкъ шул хәл. Ул яшь егетләр кебек, ул гашыйк, ә мин көнчелек утында янам. Үзе газаплана, мескенем. Теге хатынны да ярата, безне дә ташлап китә алмый.

—Әни, авыр булса сөйләмә.

—Юк, кызым, авырлыгы аның теге елларда ук калды.

—Дулкынланасың бит.

—Дулкынланам, дулкынланмыйча инде...

—Аннан кан басымың күтәрелә.

—Кан басымының эше бер күтәрелеп, бер төшеп тору инде аның.

—Аннан төне буе йоклый алмыйча борсаланып чыгасың.

—Төнлә йокламасам, көндез йокгармын. Минем эш беткән.

—Бәлки бүтән көнне сөйләрсең,—дип, Ләйлә бу авыр сөйләшүгә нокта куймакчы иде, тик үз уеннан үзе куркып куйды, ахырынча сөйләттермәсәң әнисе нәүмизләнеп калыр.

—Ул мәхәббәт тарихы ни белән бетте соң?

—«Мәхәббәт тарихы» дип дөрес әйттең син. Менә шушы тарихны дөрес итеп сөйли алсам гына ярар иде.

Гөлҗиһан караңгы тәрәзәгә төбәлде, аннан нәрсәдер күрергә теләгәндәй озак кына карап торды.

—Теге күрше хатын да әтиеңне яраткандыр инде. Юк-юк, мавыгу, азгынлык кына түгел, чын-чынлап ярату булгандыр. Ул да ике ут эчендә янгандыр. Ул мина караганда яшь. Арада киртә булып торырлык балалары да юк. Нәрсәдер хәл итү әтиеңнән генә тора. Тик әтиең утта янса да үлчәү тәлинкәсенә мәхәббәт белән балаларын сала алмый. Мине дә ярата. Аратирә очрашканда теге хатын мина күтәрелеп тә карамый. Мин дә очраганда аңа бер сүз дә әйтмим. Бергә була алмасларын уйлаптырмы, бер төндә, хәтта туганнарына да бер сүз әйтмичә, адресын-мазарын калдырмыйча, авылдан чыгып китте бахыр. Әтиең озак тынычлана алмады. Ябыкты. Төнлә йоклый алмый, көрсенеп чыга.

Шул язда Ыкка су күп төште. Язгы ташкын әтиең утырткан өянкене алып китте. Җәйдә әтиеңнең йөрәге тибүдән туктады. Бәлки ул мәхәббәтен сагынып саргайгандыр. Бәлки аңа яшәүнең яме беткәндер. Ике арада талпынган йөрәге арыгандыр. Соңарып килгән мәхәббәт бигрәк көчле, бигрәк газаплы була диләр бит.

Ләйлә әнисен юатырга да, юатмаска да белмәде. Ул ишеткәннәрен күңеленә сеңдереп, тын гына утырды. Әнисенә сыена төшеп, аның кулларын учына алды.

—И, әнием, күрмәгәннәрең калмаган икән.

Ләйләнең әнисен кызганудан йөрәге кысылды. Ятим килеш биш баланы аякка бастыру җиңел генә булмагандыр. Әнисенең ул вакытта киңәшләшергә, сыенырга әнисе дә, әтисе дә булмаган бит. Ялгыз башың биш бала белән тормыш итеп кара әле. Йә, Ходам!

Ләйлә үзе бәхетле. Әтисен күрмәсә дә, ул ятимлекне тоймады. Әни белән үсте. Аның абыйлары, апалары бар иде. Менә үзенең дә ике баласы бар, үзе дә әни кеше. Казанда улы институт тәмамлый, ә кызы да шунда кердә генә әле. Зур терәге—алтын багана кебек ире бар. Менә шушы бөтен бәхет янына да әни кирәк.

Ниләр генә булса да, әни кирәк. Ничә яшьтә булсаң да әни кирәк. Әниләр булганда адәм баласы һәрчак бала булып кала.

Ләйлә үзен сабый баладай хис итте. Әнисенең йомшак тавышына оеп, дөньясын онытып утырды. Кияү кеше аларның сөйләшүенә комачауламас өчен аяк очларына гына басып йөрде дә шыпырт кына йокларга ятты. Зал ягындагы зур сәгать башта унны, аннан унберне, уникене сукты.

Ләйлә әледән-әле әнисенең кулларын сыйпады. Чәченә, аркасына кагылып алды. Үзенең аны яратканын, аның белән горурлануын белдерәсе килде.

Әллә соң әнисе аның белән бәхилләшәме? Ничә еллар эчендә йөрткән хисләрен нигә әле бүген генә түгеп салырга булды? Аның әнисен бүлдерергә

батырчылыгы житмәде. Сөйләсен, күңелен бушатсын.

Гөлжиһан әби сөйләде дә сөйләде.

Әтисе күрше хатын белән йөргәндә ничек көнчелек утында янганын да, алар артыннан Ык буйлап көймәдә барганын, аларны куып тоткач кына кире борылып, ишкәкләрне каерып-каерып, Ык суына каршы ишкәнен, хәлдән таеп яр буена чыгып авып, ярсып-ярсып елаганын сөйләде.

—И, әни, авыр булгандыр.

—Авыр инде, кызым. Ир бирмәк—жан бирмәк, димәсләр иде аны. Мин дә бит әтиеңне бик ярата идем. Йөрешеп, яратышып өйләнешкән идек. Кая аны кемгәдер бирү!

—Ничекләр түзден, әни!

—Сезнең хакка түздем.

—Әти белән бу турыда сөйләшкәнегез булдымы соң?

—Юк. Ул бит ут эчендә яна. Аның янган йөрәгенә тагын ничек итеп ялкын өстисең.

Гөлжиһан һәр әйбергә озак-озак тукталып, бүлмәне күзеннән кичерде. Тик аның күзләре бүлмә эчендәге шкафны да, өстәлне дә күрмәде. Аның уйлары еракта калган яшьлек елларында гизә иде.

Ләйлә тамагын кырган булды. Гөлжиһан елмаеп куйды. Ул ашыга-ашыга сүзен дәвам итте.

—Әтиең миннән биш яшькә зур иде. Мин бит аңа унжиде яшемдә үк чыктым. Бик яратып чыктым, яратып яшәдем, һаман да яратам. Аны алыштырырдай, һич югы аңа бераз гына охшаган бер генә кешене дә очратмадым.

Залдагы сәгать «даң» итеп бер тапкыр сукты да тынып калды. Димәк, төн икенче яртысына авышты.

—Кызым,—ана сүзен дәвам итәргә батырчылык итмичә тынып калды. Өстәлдәге кәсәне алып, тагын бер йотым су эчте.

—Сез мине кияү белән бик яхшы тәрбияләдегез. Кияү дә үз балам кебек. Ун елга бер генә тапкыр да караңгы йөзен күрмәдем. Эштән елмаеп кайтып кереп, иң элек минем хәл-әхвәлемне сораша. Рәхмәт аңа. Мин сезгә меңмең бәхил. Соңгы әманәтемне дә үтәрсез инде. Бик авыр булса да мине авылга алып кайтып күмегез. Дөрес, шәһәрдә дә зиратта урын табылыр анысы. Кайда ятсаң да жир куены бердер инде. Шулай да шәһәрдә үлеп, шәһәрдә күмсәгез, женазамны күтәреп барганда очраган кешеләр: «Кем үлде икән?»—дип сорарлар. «Бер әби үлгән»—диярләр дә онытырлар. Ә авылда жирләсәгез, женазамны зиратка алып барганда авылдашлар: «И-и, Гөлжиһан әби дә китеп барган икән,»—дип сөйләрләр...

Быелгы яз да иртә килде. Урман-кырлардагы кар язгы кояшның рәхимле кайнар нурлары астында тиз арада эреп, кечкенә елгалар булып Ыкка төште. Ык ярларыннан чыгып ташыды.

Язгы ташу Ләйләләрнең бакча башындагы ялгыз өянкене алып китте...



Гөлзадә Бәйрәмова

## СЫНАДЫҢ, ТОРМЫШ, СЫНАДЫҢ...

***

**Коя яңгыр. Күкри дөнья.**
**Котырына җил-давыл:**
**Йөз яшәр иманнәрне дә**
**Берни түгел аудару.**

**Тәрәзәмә ышыкланып,**
**Күзәтәмен дөньяны.**
**Сабый чакта, яшен күрсәм,**
**Яба идем юрганны.**

**Куркынып сыена идем,**
**Әнкәмнең кочагына...**
**Бүген никтер күзем теким**
**Яшеннең учагына.**

**Шул яшеннең бер чаткысы**
**Төшсен димме күңелгә?**
**...Кара күмер, әллә, күңел,—**
**Сүнми дә, дөрләми дә...**

***

**Ах, мәхәббәт! Син янәдән**
**Керәсең безнең өйгә.**
**Ишек ачмый мөмкин түгел:**
**Улым өлгереп килә.**

**Бар сөйләшү шул турыда—**
**Кем-кайчан, ничек сөйгән?**
**Әтисе булган кешене**
**Мин кайда, ничек күргән?..**

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА—*шагыйрә; "Әле кайчан гына..." исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Кайчан мәхәббәт аңлаткан,
Кайчан өйләнәм дигән?
Ялындырып торганмынмы,
Җавапка нәрсә дигән?..

Яшь аралаш сөйлим аңа,
Кайчакта куям көлеп.
Шигъри сүзләр дә китерәм,
Бик урынлы, бик белеп;
"Хатирәләр хәтеремне,
Алалар телеп-телеп".

Үзеңнеке—үзәктә лә,
Балаңныкы йөрәктә...
И мәхәббәт! Бу юлысы
Куркытасың бигрәк тә.

Үз бәхетең—ярты бәхет,
Тулысын бир балама:
Ялгышымны кабатлатма,
Рәхимле бул аңарга!

## Бер җыеннан кайткач

Яңалары әле таныш түгел,
Иске дуслар инде искергән.
Тумас борын әллә картаелган:
Ни кызык, дим, сезнең фикердән.

Кем күрсәтә үзен бик акыллы,
Кемгә кирәк "бөек" титулы...
(Сәрхүшләрсез җыен буламени,
Бер сәрхүше кереп утырды.)

Күз алдыма килә бер манзара;
Болын тулы казлар көтүе.
Мин ялгыз каз... гүя бу җыенда
Оя-оя казлар төркеме.

## Сырхауханәдә

Җиңел генә хәл итәбез:
"Бу юлы калмас әллә..."
(Читләргә үлем кагылса,
Үзенчә юрый бәндә.)

Ишегебез килеп какса
Әҗәл атлы ул явыз,
"Бутагансың фатирны",—дип,
Шундук ябып куярбыз.

## Сукбай зары

"–Кыйнадың, тормыш, кыйнадың,
Көчсез, сынар, диеп тормадың.
Чиктән–чиккә аттың, тынмадың,
Хәсрәтләрдә мең кат сынадың.

Кайчак кәнфит бирдең алдалап,
Кире алдың шундук юмалап.
Имеш, миңа түгел баллысы,
Бу дөньяның барлык татлысы –
Ачы гына булган язмышка
Артык булыр, дидең, ахрысы.

...Күзем төбим түшәм–күкләргә,
Мондый язмыш язган күпләргә.
"Сөям!"—дидем мин дә кайчандыр.
Ишетүчесе әле исәндер!
Искән җилдән аны көнләдем,
Мин генәме, юкса, эчкәнмен!

Бакмадым ла бала кичләрен,
Тоя алмадым аның исләрен.
Уйламадым картлык киләсен,
Картлык көндә ялгыз нишләрем...

Бүген хәлем яман—яманнан:
Адресым—кыр. Йортым—урам.
Балам уза урамымнан:
Җәяү түгел, машинада,
Тәрәзәсе кара томан.
Тик чыгалмыйм каршысына:
Аның өчен
Инде күптән
Мин бит үлгән..."

## Берәүгә

Мин сиңа теләмим начарлык—
(Уйласаң йокыңнан качарлык!)
Ул безгә барыбер киләчәк,
Үзе үк өйләргә керәчәк.
Аерма бары тик шуңарда:
Кем алдан, кем соңрак күрәчәк.

Пәрдәләр корсаң да тәрәзгә,
Салсаң да ишеккә мең йозак.
Һәркемгә корылган ул тозак.

Карамый биләгән постыңа,
Аямый яшен дә, картын да...
Котылалмас һичкем аннан,
Ришвәтләр бирсә дә алтыннан.

Мин сиңа теләмим начарлык,
Табалмыйм чара да—качарлык.
Изгелек булмады кылганың,
Гамәлең дәфтәрен ачарлык.

***

*Г. ханымга*

Ил-көндә гамәлең,
Кулыңда—каләмең,
Яныңда—хәләлең,
Нур чәчеп торганда
Кайчакта картлык та
Әйләнә шатлыкка.

***

Дөнья кайный,
Гөжли генә.
Күпләр моны—
Сизми генә.
Уртасында
Кайныйммы мин?
Әллә читтән
Күзлим генә?!

## Ялгыз карчык

И җылы сүз! Никадәрле
Тансыксың син күңелгә:
"Исәнме?"—дигән сүздән дә
Күз яшьләрем түгелә.

***

Ялгызларның—үз моңы,
Парлыларның үз җыры.
Ялгыз хәлен парлы белмәс,
Ялгыз парлыны сөймәс.

***

Вакыт үзе билгеле
Кемнең кая барасын...
Бакыйлыкта күрәчәкне
Фанилыкта саласың.

## Улым ялга киткәч

Мең чакрым ара...
Ана белән бала
Күңелендә генә—
Була алмый ара.

***

*"Кем итәгенә ут төшсә, шуныкы яна".*
Әйтем.

Итәк түгел гүя йөрәк яна,
Бу әйтемдә шуңа ишарә.
Башларыңа төшкән хәсрәтләрне
Нинди үлчәү белән үлчәргә?

Ринат Мөхәммәдиев

# КОШ БУЛЫП ОЧАР ИДЕМ...

РОМАН

## 20

Поезд төнге берләр тирәсендә Кинельнең тимер юл вокзалына килеп туктады. Вагон ишеге төбендә аны чәчәк бәйләме тоткан Рафаэль һәм аның белән килгән солдат каршы алдылар. Ул солдат шофер булып чыкты. Әйберне мөмкин кадәр азрак алырга тырышса да күченеп килүче яшь киленнең багажы шактый иде. Бер олы чемодан, ике зур төенчек. Аларның берсендә—мендәрләр, юрган, тәрәзә пәрдәләре һәм шуның ише башка тормыш кирәк-яраклары, икенчесендә кышкы киемнәре. Шулар өстенә тагы бер тартма китаплар, ике банка варенье һәм әнисе кияү өчен дип хәстәрләгән төрле тәм-том.

Алар бер-берен бик сагынган булсалар да бераз читләшә дә төшкәннәр иде. Рафаэль аның аркасына кулын салды, ул тартынып кына елыша төште. Ике ай узды ич күрешми торуларына. Ике ай дип әйтү генә җиңел, бер гомергә тиң озак узды ул вакыт аралыгы. Хәрби частька кадәр кабинада, бер-беренә шактый ук елышып янәшә утырып кайттылар. Йөрәкләре күкрәк читлегеннән менә чыгам-менә чыгам дип типсә дә, янәшәдә шофер булгангадыр инде, күбрәк сөйләшмичә генә бер-берләренә карашып бардылар. Ул кадәр ерак ара түгел икән, ярты сәгать тә узмады булса кирәк, кайтып та җиттеләр.

Рафаэль керосинкада чәй кайнатып керде. Лена өстәлгә әнисе пешереп җибәргән пәрәмәч, өчпочмак һәм бавырсаклар чыгарып куйды. Карлыган һәм чия вареньелары кабып, үз бүлмәләрендә рәхәтләнеп сөйләшә-сөйләшә озак кына чәйләп утырдылар.

—Эшемне, әнине һәм барлык хыялларымны калдырып синең янына килдем, Рафаэль,—диде Лена.

—Син декабрист хатыннарыннан бер дә ким түгел инде болай булгач, рәхмәт, гүзәлем,—дип, оялчан гына хатынының бит очыннан үбеп алды Рафаэль.

—Без зур сынау уздык бу ике ай эчендә. Мин үземне бер дә ярату һәм сагынуларга бирешермен дип уйламый торган идем. Йомшак булып чыктым...

—Юк, Ленам, ярату—ул йомшаклык түгел. Бары рухы белән көчле һәм сәламәт кешеләр генә чынлап яратырга сәләтле була.

—Ә мин дөньясын онытып яраткан кешеләрне, яратам дип дөньясын онытткан кешеләрне авыруга саный торган идем.

—Юк, Лена-гүзәлем, ярату—көч һәм гайрәт бирә, үз-үзеңә ышаныч һәм оптимизм китерә, бик беләсең килсә.

*Ахыры. Башы узган елның 11 санында.*

—Ни генә булмасын, Рафаэль, мин бөтенләй уйламаган һәм моңарчы башыма да китермәгән адымнар ясап килдем синең янга. Үзем дә ышанып бетмим бугай әле хәтта. Минме соң бу?..

—Рәхмәт, гүзәлем, син боларны минем хакка эшләгәнсең. Сиңа булган яратуым хакына. Мин шундый бәхетле хәзер... Төн уртасы булмаса, мандолинамны тартып чыгарыр идем дә бар тавышка җырлап җибәрер идем хәтта. Сиңа багышлап җырлар идем...

—Син бәхетле булсаң, миңа башка һич нәрсә дә кирәкми, җаным,—диде Лена. Һәм ире кочагына сыгылып төште...

Ике-өч сәгать йокладылармы-юкмы, ул турыда уйлаучы булмады. Иртүк торып бергәләп шаяра-көлешә чәй эчкәч тә өстен-башын киенеп эшкә чыгып йөгерде Рафаэль.

Лена аны тәрәзәдән карап озатып калды. Урамга чыккач та башта өй каршындагы койма читләп атлады Рафаэль. Тиз-тиз атлап зур урам чатына барып житте. Тукталып артына борылып карады һәм, тәрәзәдә аны күреп, кулын болгады, ике бармагын иреннәренә китереп кайнар сәлам юллады. Һәм йортлар артына кереп күздән югалды.

Тәрәзә каршында озак кына әйләнә-тирәне күзәтеп карап торды Лена. Урамда кеше-кара күренми, бушлык. Кая карама төзелеш. Әмма иртәрәк булгангамы, аларда төзүче-фәлән күренми иде әлегә. Өй эче дә тып-тыныч, ник бер аваз ишетелсен. Шомлана төшеп барып ишекне бикләп килде ул һәм өй эчендәге әйберләрне урнаштырырга кереште. Эшнең очы-кырые юк. Стенага кадакланган кадакларда Рафаэльнең шинеле һәм куртка, комбинезоннары эленеп тора. Тәрәзәләр шыр ачык. Иң элек, үзе белән алып килгән челтәрләрдән кисеп тәрәзәләргә пәрдә элде ул. Күрсеннәр барысы да, Рафаэльгә хатыны килгәнлекне белсеннәр. Берочтан нәрсәләр сатып алырга, нәрсәләр ясарга, ниләр тегәргә икәнлеген теркәп барды. Чиләк тә юк, иләк тә, чүмеч тә, дигәндәй, өр-яңадан тормыш башлап җибәрде алар шулай итеп. Эш чиләктә яисә иләктә түгел иде. Аларын вакытлыча күрше-күләннән бурычка алып тордылар. Чөнки Бобровкадагы военторг кибетендә андый кирәк-яраклардан берни дә таба алмадылар. Якын арада Куйбышевка барып кайтырга туры киләчәк.

Анын каравы Рафаэль эшкә күтәренке күңел белән китте һәм атлыгып ашыгып өйгә кайтып керә торган булды. Кайткач та Ленаны кочаклап күтәреп ала һәм үзе тирәли бер-ике мәртәбә әйләндереп чыгара. Шуннан соң Лена хәзерләп куйган бер чиләк суны күтәреп фин йортының арткы тарафына чыгалар. Рафаэль бил тиңентен чишенә, сөеклесе аңарга чүмеч белән су коеп тора. Душны шул алыштыра иде хәрби частьта яшәүчеләр өчен. Аннан өйгә кереп бергәләп ашарга утыралар. Күршедәге рус авылыннан килгән хатыннар, өй борынча йөреп, сөт, йомырка, тозлы кәбестә кебек ризыклар сата торганнар иде алар өчен. Сирәк-мирәк кенә булса да тавык та суеп алып киләләр. Кыскасы, барысы да җайга салынып килә иде инде, картлар әйтмешли, ипи-тоз һәм ачык йөз булса, тагы ни кирәк бәхетле булу өчен.

Рафаэль кеше белән бик җиңел таныша, аралашып китә һәм дуслаша да белә—бу Ходайдан бирелгән хәзинәсе иде аның. Өйләре каршысындагы төзелештә эшләүче бер татар егете белән танышып өлгергән иде ул әллә кай арада. Рафаэль аңарга үзенең иске ботинкаларын һәм курткасын бүләк иткән. Ә теге, Норлат ягыннан килеп эшләүче егет исә, аңарга төзелешкә кирәге чыкмаган иске, горбыль такталар биреп кайтарган. Шул горбыльлардан ул, кулына балта-чүкеч алып, Ленага кухня өстәле, кием элгечләре, гардероб һәм төрле шүрлекләр ясап бирде.

Рафаэльләрнең эскадрилья командиры фронтовик Владимир Абрамович

Биязович үзенең бөркетләрен еш кына табигатькә алып чыгарга ярата иде. Моның белән ул, беренчедән, летчикларның нерв системасын ял иттерергә, стрессларын киметергә омтылса, икенчедән, гаиләсез очучылар кунакханәдә эшсез ятып аракы белән мавыкмасыннар, дигәндер. Майор Биязович данлыклы очучы гына түгел, бер үк вакытта, коеп куйган аучы һәм балыкчы да иде. Рафаэль ауга йөрергә яратмый, киек-җәнлеккә мылтыктан атуга аяк терәп каршы иде ул. Атып үтерелгән куян күрәме, төлке яисә бүреме, үзалдына калтыранып куя, бер сүз белән әйткәндә, кызгана иде ул аларны.

Шулай да кышка кергәч, бер алып чыктылар аны ауга. Кабан дуңгызына дип чыкканнар иде. Дуңгызлар очрамады. Ике баласын ияртүкән ана пошый күренде урман аланында. Алар шундый матур, шундый бәхетле иде ки, карасаң, сокланып туймассың. Табигатьтә алардан да камилрәк итеп яратылган җан иясе юктыр сыман тоелды шунда. Ана пошый, муены белән үрелә төшеп бер яшь усак агачын бөкте дә, балалары шул усак кайрысын кимергәнне яратып карап тора. Кабаланып мылтыкларын төзәргә керешә барысы да.

—Туктагыз, бөркетләр, ауның үз тәртибе бар. Бер пошига биш кеше атмый берьюлы,—дип туктатты аларны эскадрилья командиры.—Кем төзрәк ата әле бездә?

Мылтыктан атарга куллары кычытып торган очучылар берсен икенчесе бүлдереп "Мин" дә "мин" диделәр.

—Командир, әйдәгез, рөхсәт итегез әле, үзем атыйм,—диде Володя Балченков.—Миннән дә төзрәк атучы юк.

—Ашыкма, Володя, синең ауга беренче генә чыгуың түгел. Әйдә, якын дустың Рафаэльгә бир үзеннең чиратны,—диде, Владимир Абрамович.—Ялгышмасам, ул безнең снайпер.

—Рафаэль җәнлекләрне кызгана бит ул,—дип, елмая төшеп пышылдады Балченков.—Поши түгел, чыпчыкка да атканы юк бит аның.

—Үзеннән сорыйк. Нигә әле син кеше өчен җавап бирәсең.—Эскадрилья командиры шунда Рафаэльнең үзенә мөрәҗәгать итте.—Лейтенант Смаков, эскадрилья исеменнән җаваплы эш сиңа тапшырыла.

Рафаэль тирән уйга калып тора иде. Икеләнә төшеп, салмак кына мылтыгын алды ул кулына.

—Башкарып чыгармын, иптәш майор...

Янәшәсендәге наратка сыена төшеп мылтыгын төбәде. Сулышын баса төште. Башкалар да тын да алмый көтә. Бер ана пошига, бер аның балаларына карады ул прицел аша. Хәзер ул аларның әниләрен атып екса, пошиның бозаулары ни эшләргә тиеш инде. Ә бозауларының берсенә атса, ана поши ничекләр түзәргә һәм алга таба ничек яшәргә тиеш?..

Ничек ата алсын ул аларга? Ул атмаса, башкалар атачак...

—Сузма. Кереп качканнарын көтәсеңмени?!.—дип зарланды шунда коллегаларыннан берсе.

Һәм урман аланындагы тынлыкны каты шартлау авазы бүлдерде. Пошилар, куркуларыннанмы, бер тын уңга-сулга карап тордылар һәм урман куелыгына кереп качтылар.

—Егылмады. Яраланды...—дигән булды шунда, дустын акларга ашыккан Володя Балченков.

—Мазила...—дип тә ычкындырды арадан берәү.

Рафаэль иркен итеп сулыш алды һәм мылтыгын аркасына салды.

—Мулла кызында да була ялгыш, дип әйтәләр бездә. Тидерә алмадым, гаеп миндә.

Соңыннан, башка бер җәнлек тә очратмыйча, кайтырга чыккач кына,

эскадрилья командиры аның аркасына кулын салды. Пышылдап кына, үзенә генә ишетелерлек итеп әйтеп куйды.

—Юри югарыга аттың, шулай бит, лейтенант?!.

—Шулай, иптәш командир.

Һәм күзләре очрашты аларның шул чак. Командир, үз итеп, елмаю бүләк итте анарга.

—Нишлисең, үз-үзеңнән ерак качып булмый.

—Мин үкенмим, иптәш командир. Яшәсеннәр, алар бергә-бергә булганда шундый бәхетлеләр. Күрдегез ич...

Ә инде бергәләшеп Иделгә балык тотарга чыксалар, Рафаэль һәрчак беренче, балык тотуны ул ярата. Һәм бер дә башкалардан ким тотмый иде балыкны.

Бобровкада урнашкан авиаполкта ир-атлар гына түгел, офицер хатыннары да бергә дустанә аралаша һәм ярдәмләшеп яши торганнар иде. Аларның үзләренә күрә Хатын-кызлар советы да эшләп килә. Анда летчик хатыннарын кыр шартларында хуҗалык алып барырга өйрәтәләр, гадәттән тыш киеренкелектә эшләгән ирләренең стрессларын киметү ысуллары хакында лекцияләр укый торганнар иде. Кышка яшелчә әзерләү, аш-су табу һәм пешерү осталыгы хакында бер-берләренә файдалы киңәшләр бирәләр.

Шул көздә үк, дустыннан калышырга теләмичә, туган ягына отпускага кайткан җирдән Володя Балченков та өйләнеп килде. Үз авылларында үскән Валя исемле кызга өйләнгән. Бер авылда үскәннәр. Озынча буйлы, ябык гәүдәле һәм тыйнак кына кыз иде ул. Яше дә шул унҗиде-унсигезләрдә генә булгандыр.

Валя бик аралашучан, һәрчак ачык йөзле һәм эчкерсез булып чыкты. Тик бер нәрсә борчый иде аны, ул үзенең ябыклыгыннан ояла иде бик тә. Лена исә аны тынычландырырга ашыкты.

—Үзеңә сер итеп кенә әйтәм, офицер хатыннары сине күргәч тә барысы да сокланып туя алмыйлар. Хәтта көнләшеп карыйлар сиңа. Юанлык һәм тазалыкка кызыкма син. Тора-бара шундый зифа чакларыңны ничек кайтарып алырга икән дип хыялланырсың әле.

—Ир-атлар бит юан хатыннарны ярата диләр,—дип пышылдады Валя.

—Володя бит сине сайлаган һәм сиңа өйләнгән.

—Анысы шулай инде. Мин сине генә яратам дигән була. Бөтен авыл кызлары чаба иде аның артыннан.

—Володя яратмаса өйләнмәс иде. Ул ошаткач, башкаларның фикере сиңа нигә...

Шулай дигәч, тынычланып китә иде ул үзе тагы.

Бобровкага килгәч тә Володя белән Валя башта берничә көн Рафаэль белән Лена янында яшәделәр. Аннан, вакытлыча гына дип, офицерлар гостиницасыннан бер бүлмә биреп тордылар үзләренә. Шунда күчтеләр. Әмма, барыбер, көн саен дип әйтерлек күрешеп, ярдәмләшеп, аралашып яшәүләрен дәвам иттеләр.

Смаков белән Балченков ахирәт дуслар иде. Алар Бобровкага килгән көннәреннән бирле бергә яшәделәр, бергә эшләделәр, бер полкта һәм бер үк эскадрильядә хезмәт иттеләр. Хәтта партия сафларына да бергә гариза язып бер үк көнне кабул ителде алар. Һәм, ниһаять, менә бер үк вакытта дип әйтерлек башлы-күзле дә булып куйдылар. Эскадрилья командиры Биязович кына түгел, полкны җитәкләгән полковник Костюченко да бер дәрәҗәдә хөрмәт белән карый, аларның профессиональ осталыкларын югары бәяли торган иде. Ниһаять, менә хатыннары да уртак тел тапты,

бергә-бергә аралашып, ярдәмләшеп һәм сер уртаклашып тормыш корып йөргән көннәре. Бу аларның ирләренә бик тә ошый иде, әлбәттә.

Игезәкләрне аерырга ярамаган кебек, командировкаларга да еш кына бергә-бергә җибәрә торганнар иде аларны. Шул көннәрдә Куйбышев шәһәрендә узган яшь коммунистлар конференциясенә дә авиачастьтан аларның икесен юлладылар.

Куйбышевта үзләренә билгеләнгән кунакханәгә килеп төштеләр. Ике кешелек бүлмә тиешле иде аларга. Ул заманнар өчен кунакханәдәге иң яхшы номер—ул ике кешелек. Әмма администратор хатын уйга калды:

—Сез урнашырга тиешле номерда бер генә урын калды,—диде ул, гаепле кеше сыман.—Югарыдан шалтыратып анда икенче бер кешене урнаштырдылар. Кайсыдыр районнан килгән колхоз председателе бугай, бик важный.

—Ә без ни эшләргә тиеш, кайтып китәргәме?—диде Рафаэль көр һәм калын тавыш белән.—Совет армиясенә һәм аларның данлы офицерларына хөрмәт гел юк икән бит сездә...

Администратор каушый калды, ни эшләргә белмәде.

—Юк-юк, зинһар андый нәтиҗә ясый күрмәгез. Мин үзем дә солдат кызы. Әтием Ватан сугышында һәлак булды. Совет армиясенә хөрмәтем бик зур...

—Анысы яхшы. Әмма урнашу мәсьәләсен ничек хәл итәбез соң?—диде Рафаэль, башындагы фуражкасын төзәтә төшеп.

—Ике вариант бар,—диде администратор, хәрбиләрнең йомшый төшүләренә куанып.—Беренчесе, икегезне ике бинага урнаштырабыз...

Тукталып, уйга калып торды ул шунда.

—Ә икенчесе?..

—Икенчесе, үзегезгә тиешле шул ук бүлмәгә керәсез. Әмма, ул очракта берегезгә раскладушкада йоклап торырга туры килер.

—Икенчесен сайлыйбыз,—диде, моңа тикле аларның сөйләшүен тыңлап кына торган Балченков.—Үзем йоклармын раскладушкада.

Аларны урнаштырдылар. Бүлмәдә колхоз председателе үзе генә түгел иде, янына кунаклар җыелган. Зур бәйрәм ясап утырулары. Өстәлдә аракы шешәләре, ачылган консерв банкалары һәм авылдан килгән ысланган дуңгыз салосы. Билгеле инде, председатель янына килгән кунаклардан да бәхетлерәк кеше булмый андый чакта. Летчикларны да чакырды алар өстәл артына. Күренеп тора, председатель чын-чынлап кунакчыл кеше. Урыныннан торып, хәтта үзе утырган урындыкны тәкъдим итте ул аларга.

—Әйдәгез, түрдән узыгыз, утырыгыз егетләр. Аракы күп, сало җитәрлек. Юлдан килгән кешене йомшартып җибәрә ул,—дип, үзләренә сала да башлады ул арада.

—Рәхмәт, безнең әле эшләребез бар. Эчмибез,—диде Рафаэль, ишек төбендә торган буш карават астына үзенең әйберләрен урнаштырып.

—Эчмәгән солдат буламы?..—дип, офтанып алды кунакчыл хуҗа.

—Солдат түгел, күрмисеңмени йолдызлары бар икесенең дә. Бер түгел, икешәр,—дип, салпы якка салам кыстырып куйды араларыннан берәве.

Кунаклар шактый ук исерә төшкән, шуңа алар белән артык сүз куертып торуны кирәк санамады егетләр.

—Күрәсе кешеләребезне күреп, бераз йөреп кайтабыз әле без,—дип чыгып китәргә ашыктылар.

Алар кире әйләнеп кайтканда инде председатель, өстен-башын һәм аяк киемнәрен салмый гына йоклап та киткән иде. Дус-ишләр аракы белән сало беткәч тә китеп барганнар.

Володя белән Рафаэль дә чишенеп йокларга яттылар. Тик менә йоклап китү генә зур проблемага әверелде, председатель җир тетрәгән тавыш чыгарып гырларга керешге. Алай да итеп карадылар, болай да—колакларын мендәр белән дә томалап карадылар—барып чыкмады. Яткан җирендә әйләндереп куйгач та гырлаудан туктамады теге, тар гына бүлмәгә К-700 тракторы кертеп куйганнармыни... Хәер, ул заманнарда бит әле андый трактор хыялда да булмаган булуын, ә тавышы әнә стеналарны дер селкетә.

Шулай итеп яшь коммунистлар йоклый алмады. Ә председатель йокысын туйдырып, яхшы, күтәренке кәеф белән торды. Калган запасын чыгарып, егетләргә хәтта баш төзәтергә дә тәкъдим ясады әле. Рәхмәт әйтеп, баш тарттылар. Башлары авыртса да, йокысызлыктан гына авырткандыр аларның.

—Эчмибез, без бит яшь коммунистларның өлкә конференциясы делегатлары,—диде Володя.

—Ә мин нәрсә, кишермени?.. Мин дә делегат. Алай гына да түгел, мин президиумның беренче рәтендә утырырга тиеш әле,—диде теге һәм шаркылдап көлеп тә җибәрде.—Обком секретаре янәшәсендә.

Рафаэль сүзгә кушылды шунда.

—Ә нигә соң, делегат та булгач, президиумга да сайлангач, кунакханәдә кеше урынына урнаштырдылар үзегезне?

—Ярты Куйбышев дуслар белән тулы минем. Туганнар да күп. Шуларда тукталырмын дип уйлаган идем башта. Сезнең бәхеткәдер инде, менә монда керергә уйладым,—диде бәхетле көлүен дәвам итеп.—Мин компаниядә ял итәргә яратам. Менә күрерсез, сезнең белән дә уртак тел табачакбыз. Армияда булмасам да, мин болай солдат халкын яратам аны...

Конференциянең президиумында утырды теге, дөрес сөйләгән булып чыкты. Төнлә генә түгел, көне буена да үзләрен йоклатмаган председательгә карап утырырга мәҗбүр булды алар. Кичен тагы алардан алдан кайтып түрдәге караватына яткан булып чыкты. Йокламаган иде йоклавын.

—Бераз хәл алырга кирәк. Президиумда утыру ул бик җиңел эш түгел, үзегез беләсез, анда көнозын коньяк эчәргә туры килә,—дип зарланып алды ул.

—Ярый, ял итегез. Без тыныч кына сөйләшеп утырырбыз,—диде Володя. Алар көндез үк үзләренә күрә бер план корып куйганнар иде инде. Бу китәргә җыенмый булып чыкты. Димәк, шул планны тормышка ашыра башларга вакыт. Аның белән бер бүлмәдә калсалар, якындагы көннәрдә ял турында, йокы турында уйларга да урын калмый аларга. Ә йокламыйча яшәп булмый. Кыскасы—тәмугь!

—Мин кичә гырламаганмындыр бит?—дип, Володядан сорап куйган булды Рафаэль, сүз иярә сүз чыккан сыман гына итеп.

—Юк, мин әйбәт йокладым. Бер ни дә ишетмәдем тагы.

—Мин дә ишетмәдем. Гырлаган кеше булмады кебек,—дип, сүз кыстырды председатель дә. Үзе, гаепле кеше сыман, башын калкыта төшеп ялт кына хәрбиләргә күз төшереп алды. Һәм бу сүзләрнең үзенә кагылышы булмауга инанып, тынычланып, стенага ук борылып ятты.

—Ә син беләсеңме, Володя, гырлаган кешедән котылу юлы бар икән бит...

—Ничек? Сөйлә әле...—дип урыныннан сикереп торды, кызыксыну күрсәтте янәсе Володя.

Урынында тын да алмый яткан председатель дә колагын сагайтты шул мәлдә. Үзе өчен сөйләшкәннәрен анламаса да, аны да битараф калдырмый иде ахыры бу мәсьәлә.

—Узган ел Саратовта өйрәттеләр мине. Күршен каты гырлап үзенә йокларга ирек бирмәсә мин гел шулай гына итәм хәзер.

—Шуннан, шуннан...—дип, тагы да кызыксына төшкән булды дусты.

Рафаэль махсус пышылдауга күчте. Пышылдаса да тавышы яхшы ук яңгырап ишетелә иде аның.

—Чәйнекне аласың да гырылдый торган кешенең борынына су агызасың. Шундук тынып кала. Гырлау түгел, сулыш та алмый бүтән.

—Ничек? Үләме...—дип, шаккатуын белдергән булды Володя.

—Йә үлә, йә кала инде,—дигән булды, күпне күргән атлы булып сөйләшкән Рафаэль.—Исән калса да, кеше булмый инде ул бүтән...

—Кара син аны, менә ничек икән. Моны бер файдаланып карарга кирәк әле.

—Ләкин минем борынга гына сала күрмә, килештекме...

—Салыр идем дә, гырламыйсың ич син,—диде Володя, елмая төшеп.

Дуслар шунда, бераз йөреп керергә дигән булып, урамга чыгып киттеләр. Бер сәгать чамасы саф һава сулап, шәһәр урамнарын гизеп кайтты алар. Кунакханәгә кереп, тыныч кына үз бүлмәләренә таба узып барган җирләреннән администратор туктатты.

—Иптәш офицерлар, иптәш офицерлар,—диде ул, кул изәп аларны үзе янына чакырып.—Ачкычыгызны алыгыз.

Егетләр төшенми тордылар башта.

—Нинди ачкыч? Безнең бүлмәдә кеше бар ич. Колхоз председателе...

—Юк, ул сезнең арттан ук бүлмәне тапшырып, әйберләрен алып чыгып китте инде,—диде администратор, аларны шатландырырга теләп.

—Ничек китте? Конференция тәмамланмады бит әле,—дигән булды Рафаэль, бер ни дә аңламаган атлы булып.—Кайда китте икән соң ул?

—Минем монда туганнар бик күп, диде. Үзләрен үпкәләтүдән куркам, бармый булмый инде, диде.

—Гаҗәп, безгә бер ни дә сиздермәде китүе хакында,—дип, җилкәләрен сикертеп, бер-беренә сораулы карашларын төбәп алды егетләр.

—Мин дә бер нәрсә дә аңламадым. Шундый әрсезләнеп, "Кунакханәдә яшәүне яратам", дип, юк урыннарны таптырып урнашкан иде. Үзе тагы, сәбәбен дә аңлатмыйча, рәхмәтләр әйтә-әйтә матур гына чыгып та китте,—диде администратор.

Егетләр үз бүлмәләренә кергәч рәхәтләнеп көләргә керештеләр. Җинел хәл ителде бит әле бу мәсьәлә дә. Җылы һәм тыныч бүлмәдә дусларча сөйләшә-сөйләшә изрәп йоклап та киттеләр бераздан.

Икенче көнне, президиум өстәле артыннан күпме генә эзләсәләр дә, теге күршеләрен таба алмады яшь коммунистлар. Эзе суынган иде диярсең. Президиумны гына түгел, конференциянең үзен үк ташлап киткән булып чыкты безнең председатель. Үзен кызганып ук куйдылар хәтта, кин күңелле, юмарт һәм ачык кеше иде бит болай...

## 21

Ноябрьда Рафаэльга күптән көтеп алган чираттагы отпускасын бирделәр. Аны кайда үткәрәсе, отпускада кая барасы күптән билгеле иде инде,—Лена белән бергәләшеп, беренче тапкыр ир белән хатын буларак, туган якларына кайтты алар. Башта, һәр икесенең дә туганнарына йөреп, берничә көн Уфаны дер селкеттеләр һәм гөр китерделәр. Ә аннан соң әкияттәге серле дөнья сыман Рафаэльне берөзлексез үзенә тартып торган Яңа Актауга юл тоттылар.

Яңа Актау әллә ни зур авыл түгел-түгелен. Әмма ул—үзе генә дә очсыз-кырыйсыз бер галәм кебек. Мондагы һәр өй һәм һәр капка таныш Рафаэль

өчен. Ул өйләрдә берсеннән-берсе кызыклы, матур һәм хикмәтлерәк кешеләр яши. Урам-тыкрыклары да күп түгел анын, бары берәү генә. Ул урам Идәш елгасынын башланган жиреннән урман читләтеп озын булып сузылган. Рафаэльләрнен өе урамнын түбән очында, яфраклы катнаш урманнын наратлыкка килеп төртелгән жирендә урнашкан.

Өлкән улы белән яшь киленен Хафаза апа авыл капкасыннан чыгып көтеп тора иде. Улы белән кул биреп исәнләште. Ә киленен кочып ук алды, үзе очырган баласын канатларына алып сөйгән кош анасыдай, аркасыннан какты.

—Исәнме, кызым,—дип эндәште ул аңарга. Һәм шул мизгелдән, гомергә, ул анын өчен кызы булып калды.

—Исәнме, әнкәй,—диде Лена, иңбашына ак шәл ябынган авыл хатынын, Рафаэльнен әнисен, шундук үз һәм якын итеп.

Капка төбендә аларны Миргалим абый каршылады. Ул житди һәм сабыр иде, әлбәттә. Әмма шулай да улы белән күрешкәндә күз яшьләрен тыеп кала алмады. Ул нык кына авырый иде инде , үзе исән чакта күрешеп калу шатлыгыннан йомшарып китүе булгандыр. Сенлесе Тамара һәм энесе Ринат килеп кушылды күрешү, хәл-әхвәл белешү йоласына. Рим белән Нур икесе ике тарафта армиядә иде әле ул вакытта. Ишегалдына уздылар. Яңа явып узган ак кар өстенә кара жимешләрен коеп бер көтү сарык бәрәннәре чабышып уйнап йөри. Ашап торган жиреннән тукталып, башмак тана мөгерәп сәламләде кайткан кунакларны. Мал лапасы ягында тавыклар кытаклашып алды, тыйнак кына итеп, мин монда дигәндәй, әтәч аваз салды. Шул рәвешле, ноябрь ахыры дип тормадылар, Яңа Актауда бәйрәм башланды.

Миргалим абзый белән Хафаза апа бөтен туган-тумача һәм күршекүләнне жыеп гөрләтеп туй ясадылар берничә көннән. Алланын биргәненә шөкер, дип әйтерлек, ноябрь авылларда муллык ае. Яшелчәсе-бәрәңгесе тулып торган чак, сугым вакыты булгач, сарык ите, үрдәге-казы дигәндәй, барысы да үзеннеке. Летчик булгач, әнә, Рафаэльнен дә мөмкинлекләре бар, авыл кибетеннән тегесен-монысын ящиклап кына алып кайткан. Өй эче кунак белән тулды, шаулап-гөрләп торды. Жыр һәм музыка авазлары өйгә генә сыеша алмыйча урамнарга ташып чыкты. Биючеләр дә кызып киткәч, салкын дип тормадылар, өй эчен тарсынып, ишегалларына чыгып парлап-парлап тыпыр-тыпыр биеделәр.

—Салкын ич, суык тидерә күрмә, улым,—диде әнисе, улынын гимнастерка изүләрен ачып жибәреп ишегалдында биегәнен күреп.

—Юк, әни, борчылма,—дип тынычландырырга ашыкты Рафаэль,—без анда, югарыда, кырыгар градус салкында очабыз бит.

—Көнне һындырган ахрысы,—дип, башкортчаны татарчага кушып шаярткан атлы булды сугышта бер аягын калдырып кайткан Хәмидулла абзый. Аягы булмаса да, дәрт ташып тора үзендә, култык таякларын шакышокы бер-берсенә сугып бер аякта сикергәләп биегән булып та алды тагы.

—Сындырмый сон, сындырган, әлбәттә. Тагы берәр тустаган жибәрсән, карга ятып ауный башларсын әле син,—дип, үз итеп төртмә сүз әйтеп алды анын хатыны.

—Кунаклар, керегез,—дип, болдырга чыгып чакыру ташлады шунда өйдә төпчек малай булып үскән Ринат.—Әни бәлеш чыгарды табынга. Барысы да керсеннәр диде...

Аны ишетмәделәр. Гармун тавышы, шаярган-көлгән авазларны жиңү өчен янабаштан игълан ясамый хәле юк иде малайнын. Бу юлы инде бар тавышына кычкырырга мәжбүр булды. Тырышып көчәнсә тавышы шактый ук әче дә чыга икән тагы үзенен.

—Рафаэль абый... Апалар... Абыйлар... Кодагыйлар-кодалар... Күрше абыйлар, күрше апалар... Барыгыз да керегез... Әни бәлеш чыгарды...

Музыка туктап, кунаклар тынып калган иде инде. Ул кычкыруга соң, тынмас җиреннән тынырсын. Берәм-берәм керү юлына борылды биючеләр. Шунда әлеге дә баягы теге Хәмидулла абзый Ринатның такыр башыннан, үз итеп, сыйпап куйгандай итте.

—Ну тавыш та икән малай синдә. Кай төшләреңнән чыкты ул синең?

—Ишетмисез ич. Әни чакырырга кушты, керсеннәр диде,—дип, борынын тартып алды да өйгә юнәлде төпчек малай. Сәрхушләр белән сүз көрәштереп торасы килмәде.

Аракысы житәрлек булса да, аның белән бик үк дуслашып өлгермәгән иде әле татар авылы ул елларда. Күбрәк шул фронттан әйләнеп кайткан солдатлар капса каба иде инде аны. Алары да чамасын белеп, кәеф күтәрелсен өчен генә диеп. Исергәнче эчү, ямьсезләнеп тавыш чыгару, кешегә бәйләнү дигән нәрсәне әле белгән кеше дә юк. Эчеп алган кеше урамга чыкса, бәйдән ычкынган колхоз үгезеннән качкан кебек, каршы очраган кеше урамның аргы ягына чыгып узып китә иде аны. Яшүсмер малайларга гына кызык, бер кәмит карагандай, көлкегә чыгарып артыннан ияреп барырлар иде бераз калыша төшеп.

Бәлештән соң чират тагы да җырга күчте. Авылның беренче гармунчысын чакырганнар иде бит, ул тартып уйнап җибәрде. Миргалим абзый, яшьлеген, "Галия" мәдрәсәсендәге кыллы оркестрда уйнап йөргән елларын искә төшереп, мандолинасын сайрата башлады. Башкалар дәррәү кушылып җырларга керешә.

*Һәй әле бик ерактан килдек без,*
*Җитмеш чакырым җирләр үттек без.*

—Һәй моңлы да соң шушы халкыбызның борынгы җырлары,—дип, тирән сулыш алып үзалдына көрсенеп куйды шулчак Миргалим абзый. Мандолинасын чирткән көйгә бер очтан җырга да кушылырга тырыша иде ул. Авызы ачыла, әмма аннан тавыш чыкмый диярлек. Күренеп тора, хәлләре яхшыдан түгел иде аның, шактый ук бетеренгән иде шул.

—Менә Миргалим абзый син безне тарихтан укыткан кеше. Шуны аңлатып бир әле син безгә,—дип, шунда кыюланып киткән фронтовик Хәмидулла сорау биреп куймасынмы.—Бик ерак җирләрдән килдек без, дип җырлыйлар. Каян килү турында бара ул сүз, без нәрсә, монда шулай ук бик еракләрдан килгәнбезмени соң?

—Әйе, Хәмидулла туган, бу туфракларга безнең ерак бабаларыбыз патшаның чукындыруыннан качып күчеп килгән.

—Каян килгән?

—Кем Казан тарафларыннан. Ә кемнәрдер Пенза һәм Касыйм якларыннан.

—Шуннан укмы... Булмас ла...—дип, уйланып торды Хәмидулла. Бераз салган булса да, үз акылында иде бит ул.

—Әйе, кем уфалла арбасы тартып, кем атка төянеп, бала-чагасын, әби-бабаларын ияртеп качарга мәҗбүр булган. Ә бу җирләрдә яшәгән башкорт халкы аларга үз итеп ярдәм кулын сузган.

—Менә бит ничек...—дип, тел шартлатып куйды Хәмидулла.—Син боларны, мәктәптә укыткан чакта нигә сөйләмәдең икән?

—Бөтенесен дә сөйләп бетереп булмый бит инде, Хәмидулла туган,—дип йомгакларга ашыкты Миргалим абзый. Туй ич, тарих дәресе түгел.

Шунда өстәл читенә таянып авырлык белән бердәнбер аягына торып басты Хәмидулла. Һәм стаканын күтәрде:

—Авылдашлар... Туганнар...—диде ул. Ни сәбәпледер күнеле нечкәреп китеп, мышык-мышык борынын тартып алды шунда.—Миргалим абзыйның исәнлеге-саулыгы өчен күтәрәм мин бу стаканны. Булдыра алган ир-атларны мина кушылырга чакырам. Миргалим абзый бит ул... Миргалим абзый бит ул авылда гына түгел, тирә якта һәм дөньясында бер генә...

Хәмидулла эчкерсез кеше иде. Ул ихластан сөйли, йомакайланучылардан түгел. Шуңадыр, эчсә дә, эчмәсә дә ир-атларның барысы да диярлек торып басты шунда, Хәмидулланың тәкъдименә кушылдылар. Рафаэль дә, әтисе турында әйтелгән җылы сүзне хуплап, стакан читеннән тагы бераз уртлап куйды.

—Рафаэль...—дип пышылдады, шелтәле караш ташлап куйды шунда, янәшәсендә утырган Лена.—Мавыгып китә күрмә.

Борчылырлык иде шул. Көн дә бәйрәм, көн дә туй, дигән сыман килеп чыкты бит. Елмаю белән генә җавап кайтарды Рафаэль, дәшмәде.

Тел ачкычларына ия булып киткән Хәмидулланың тагы бер соравы калган икән әле:

—Миргалим абзый, тагы бер генә сорау бирим әле. Әйт әле, менә сезнең нәсел—Смаковлар кай тарафлардан килеп чыккан дип уйлыйсың? Һәм каян килеп ул сездә генә шундый фамилия—Смаков... Ни татарча, ни урысча дигәндәй?..

—Бер түгел, ике сорау булды инде бу,—дип, сүз кыстырды Хәмидулланың хатыны. Иренең Миргалим абзый белән шундый мәгънәле әңгәмә корып утыруын бер горурлык белән тыңлый иде ул. Бер аяксыз булса да, аның ире ич. Күреп тора, башкалар да йотылып тыңлый иде аларның һәр сүзен. Горурланмас җиреннән горурланырлык.

Җавабын кыска тотты Миргалим абзый.

—Безнең бабайлар Касыйм тарафларыннан килгән булса кирәк. Ә Смаков—Исмәгыйл исеменнән чыкмадымы икән, дип уйлыйм. Исмәгыйлне бит кайчак үзебез дә "Исмак" дип кенә җибәрәбез. Шунын бераз урысчалатыбрак әйтелгән варианты димме...

—Ә мин сезне морзалар түгелме дип йөри идем тагы,—дип, тирә-ягына бәхетле караш ташлап куйды Хәмидулла.—Морзаларда кунакта булдык дип тә мактанырга иде әле исәп..

—Бу хакта оныт, Хәмидулла. Инде барыбыз да тигез хәзер. Совет власте ул хакта сөйләшкәнне яратмый ул. Ярлы крестиян токымы булу үтемлерәк хәзер, оныт,—диде Миргалим абзый. Әлбәттә, ул шулай сөйләнсә дә үз авызыннан чыккан сүзләре белән һич кенә дә килешми иде. Шуңа кәефсез һәм төксе дә иде бүген.

Татар авылында туй бер көндә генә тәмамланмый иде ул заманнарда. Туй атналар буена дәвам итә иде кайчак. Туган-тумачалар, һәр көнне диярлек, чират белән ашка чакырды үзләрен. Аннан күрше-күлән һәм дус-ишләр керде чакыру белән. Баш тарту ярамый, чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, дигән бит халык. Егерме-утыз көн дәвамында көн дә, көн дә кунакка йөрү шактый ук ялыктырса да, түзәргә туры килде. Аеруча, инде матур гына түгәрәкләнеп—бала көткән Ленага авырга туры килгәндер.

Ашта утыру бер хәл. Ә менә шул аштан соң, караңгы төшкәч, урамны тутырып шау-гөр килеп әңгәмә корып яисә бер-бер күңелгә ятышлы җыр җырлап кайтулар онытыла торган гына булмады.

—Кемнәр шулай матур җырлап кайта анда?—дигән сорауга, авылдашлар,

тәрәзәдән карамый гына да җавап таба торган булгандыр.

—Кемнәр булсын, Смаковлар... Миргалим абыйныкылар кайта торгандыр. Аның летчик малае Рафаэль Уфаның үзеннән кыз алып кайткан!.. Шуның туен дәвам итә торганнардыр....

Яшьләр көндезләрен авылның тирә-ягындагы табигать матурлыгына сокланып йөрделәр. Көзге пычраклар артта калган, кышның башы гына булганга, кар да тирән түгел иде әлегә. Рафаэльнең балачагы узган урман—кырларны гизеп, табигать матурлыклары белән танышып йөрү өчен шуннан да унайлырак вакытны табу мөмкин булмас иде.

Ә Лена исә шәһәрдә үскән кыз, анарга туган як табигатен—урмандагы агачлар, тереклек һәм кошлар дөньясы белән танышып йөрү икеләтә кызык һәм гыйбрәтле. Рафаэль аны, табигатьне яратуы белән генә түгел, ә аны танып белүе, бөтен серләрен аңлавы белән дә шаккатыра иде. Кыш көне булганга агачлар яфраксыз. Шунарга Лена аларны бер-береннән аера алмый азапланды. Ул бары тик чыршы белән наратны һәм ак каусәсеннән каеннарны гына таный. Ә Рафаэль өчен исә табигатьнең һичбер сере юк. Шуңа сорау арты сорау яудырып кына торды ул аңарга.

—Рафаэль, белмисенме, бу нинди агач?—дип сорамый булдыра алмады ул чираттагы мәртәбә.

—Син һаман да бер үк сорау бирәсең, гүзәлем,—диде ул, туган як табигате белән хатынының да җанлы кызыксынуына куанып. Һәм күңел күтәренкелегеннән рухланып китеп рифмалый-рифмалый җавабын тезеп китте.—Бу нинди агач, ул нигә ялангач, дисең инде. Бу, җаным, имән булыр, тамыры тирән булыр. Ябалдашлары бик тә киң, ул Алып батырга тиң...

—Рафаэль, шул шаяруларың белән мине бутап бетерәсең инде. Син йә шигырь генә сөйлә, йә минем сорауга җавап бир. Белмәсәң, алдама, килештекме? Әнә теге агачны өрәңге дидең, ә монысын имән дисең, алар арасында һичбер аерма күрмим мин...

—Син күрмисең, ә мин күрәм. Каерыларына игътибар ит син аларның. Имәннең каерысы куерак төстә була. Каусәсендә сырлар тирәнрәк һәм ботаклары да, өрәңгенеке сыман югарыга гына түгел, ә күбрәк янга таба тырпаебрак үсә. Ышанмасаң, әнә, кара, үзең чагыштыр... Ә тегесе, әнә, шома каерылысы юкә. Анда әнә буа янында күбрәк, шомырт, карама һәм элмә агачлары үсә.

—Каян беләсең, без бит әле буа янына барып та житмәдек,—дип, гаҗәпләнде Лена.

—Аның өчен яннарына бару мәҗбүри түгел, гүзәлем, су читендә, дымлы урыннарда үсә ул агачлар.

—Шомыртны беләм анысы. Ә мин, ул карама һәм элмә агачлары турында беренче ишетүем, аларны тану түгел, барлыкларын да белми идем.

Шунда, күлгә таба алданрак киткән Лена, кинәт туктап калды.

—Карале, Рафаэль, кара—монда ниндидер эзләр бар,—дип, ирен үзе янына чакырды ул.

—Бу, Ленам, төлке эзе. Әле күптән түгел генә, күп булса бер сәгать чамасы элгәре узып киткән моннан,—дип, килеп җитмәс борын хөкем чыгарды Рафаэль.

—Каян беләсең, ә ник куян түгел? Ә бәлки ул бүре булгандыр?

—Һәр җәнлекнең үзгә аяк эзләре, атлау рәвеше, адымнар зурлыгы була, җаным. Боларны ачыклау өчен тәҗрибә кирәк...

—Ә бер сәгать элгәре иканлеген ничек белдең, үтеп киткәнен күрмәдең ич син аның?

—Чөнки анын эзләре бик ачык. Күрәсеңме, әнә, тырнак эзләренә кадәр сизелеп тора. Ә вакыт узган саен, ул эзләр кар тузаны белән күмелә, тоныклана бара.

—Менә ничек...—дип куйды шәһәрдә үскән кыз.—Ә монда шулай төлкеләр дә бармы?

—Төлке һәм куяннар гына түгел, бу урманда, беләсең килсә, поши һәм кабан дуңгызлары, бүре һәм урман песие—рысь та бар. Вакыт-вакыт Урал тавы тарафларыннан аюлар да килеп чыккалый дип әйтәләр.

—Чынлап тамы?—дип, сискәнеп куйды Лена.—Алай булгач, ни эшләп йөрибез соң без монда... Әйдә, тизрәк кайтып китик, исән чакта.

Урманны яңгыратып көлеп куйды Рафаэль.

—Куркырлык сәбәп юк, гүзәлем. Ул киек-җанварлар барысы да табигать балалары. Кешегә тими алар.

—Бүре дә, аю дамы?

—Әйе, аю-бүре дә. Киресенчә, алар кеше барлыкны сизсә, ерактан ук әйләнеп узарга тырышалар. Үзең тимәсәң, сиңа тими ул табигать балалары.

—Юк, мин куркам, кайтыйк инде,—дип, барыбер үзенекен итте, өйгә таба каерды Лена.—Арылды да инде, бүгенгә җитәр, кайтыйк әйдә.

Ризалашмый чарасы юк иде Рафаэльнең, авылга бу юлы алар көндәгедән иртәрәк әйләнеп кайттылар. Әмма, иртәгәсен, яңадан сәяхәткә—бала чакларында җиләк җыеп үскән Нәгыш тавы тарафына юнәлделәр.

Туган ягының һәр калкулыгы, һәр куагына кадәр Рафаэльдә балалык һәм үсмер еллары турында хәтирәләр яңарта иде.

—Ленам, менә бу ялгыз имән без малай чакларда яшь туйра гына иде әле... Ә хәзер ул, күрәсеңме, нинди зур имән булып үскән.

—Туйра... Ул ни дигән сүз соң? Беренче ишетүем.

—Яшь имәннәрне халык туйра диеп йөртә. Имәннең, үзенә күрә, егет чагы була инде ул.

—Ә нигә егет чагы? Имән бик матур агач бит, аны кызларга да тиңләп була торгандыр,—дип, күңел күтәренкелегеннән, үзенә күрә бәхәс куерткан атлы булды Лена.

—Кызык икән син, егетләр ямьсез булырга тиешмени? Мин дә үземне матур, дип йөргән була идем тагы...

—Син бит бер генә, Рафаэль.

—Шулай дисәң генә,—дип, күтәреп алды ул хатынын һәм, яратып, югары чөйде.

—Абау, егасың ич. Онытып җибәрмә, мин үзем генә түгел, без икәү.

—Онытмадым,—диде Рафаэль, еш-еш сулыш алып.—Әтисе кебек очучы булырга әзерләнеп торсын дип чөюем.

—Ә кыз булса, ни эшләрсең?

—Куанырмын гына, шатланырмын гына, гүзәлем,—дип, иелә төшеп хатынының бит очыннан үбеп алды ул шунда.

Шул рәвешле көн артыннан көн узды, ел буе көтеп алынган ял көннәре сизелмичә дә узып китте. Көндез табигатьтә, кичләрен кунакта яисә әти-әниләре белән бергәләшеп табын артында дөнья хәлләре сөйләшеп утыра торгач, китәр көннәр дә килеп җитте.

## 22

Ә Бобровкада тормыш үз җаена ага торды. Хәрби очучының көндәлек мәшәкатьләре, бер карасаң, гел бертөрле һәм күңелсездер кебек, ә чынлыкта һәр туар көн үзенең яңадан-яңа ыгы-зыгы һәм проблемаларын китереп кенә тора. Алар хезмәт иткән авиаполк "МИГ" ларны сынау һәм

камилләштерү буенча база булып та хисаплана иде. Шуна, ай саен диярлек, самолетларга яңа төрле механизм һәм приборлар урнаштырып, гадәттән тыш шартларда аларның ничек эшләвен дә күзәтеп барырга тиеш иде очучылар. Ә инде хәрби авиация өлкәсендә өч төрле һөнәр иясе булган Смаковка бу унайдан аеруча тынгылык бирмәделәр.

—Рафаэль, аңлат әле, бу механизм нәрсәгә хезмәт итә?

—Бу прибор тагы нигә кирәк булды икән?—дигән сораулары белән коллегалары аны тинтерәтеп бетерә иде вакыт-вакыт.

Әйтерсең, ул барысыннан да хәбәрдар булырга тиеш. Әйтерсең лә, ул заводтан яисә конструкторлык бюросыннан җибәрелгән белгеч иде алар өчен. Ул, үз чиратында, белгәнен аңлатты, белмәгәннәрен аңларга тырыша иде. Чөнки ул авиациягә мөнәсәбәте булган барлык журналлардан да хәбәрдар булырга тырыша. Аларның кайсыберләре частьның китапханәсенә килә, ә инде анда булмаганнарына ул үзе язылырга тырыша торган иде.

Хезмәттәшләрен яхшы аңлый, алар бит техниканың һәммә нечкәлекләрен дә өйрәнмәгән. Очучыдан ул таләп тә ителми, аның эше техника һәм навигация приборларында казыну түгел, эшләп торган машина белән идарә итү. Хәрби реактив самолетлар аеруча зур осталык сорый. Шулар өстенә, ихтимал булган дошман авиациясенең дә техник үзенчәлекләрен, тактика үзгәлекләрен белеп торырга тиеш алар.

Бобровка полкында "МИГ-15" һәм "МИГ-17"не инде шактый яхшы үзләштергән иделәр. Тик менә соңгы араларда, төрле техник экспериментлар нәтиҗәсендә булса кирәк, очу вакытында торган саен көтелмәгән шартларга ешрак юлыга башлады алар. 1954нче елга кергәч кенә дә өч самолет һәлакәткә очрап, менә дигән якын дусларын югалттылар. Һәм алар барысы да "МИГ-17"нең яңа модификациясе булган самолетларда. Самолет яхшы гына эшли дә кебек, тиешле биеклеккә менеп маршрутны ала. Һәм киткән җиреннән әйләнеп кайтмый, югала. Әле генә дусларына кул изәп һавага күтәрелгән очучыдан, каядыр, офыклар артында тонык кына булып ишетелеп алган шартлау авазлары гына әйләнеп кайта. Бергә хезмәт иткән дуслар, шул рәвешле, хушлашмыйча да эзсез генә югала баралар. Алардан ни кала, ул мәңге ачылмаслык итеп ябылган цинк табутларда ниләр булганлыгын һичкем белми. Сорасаң, шундук авызыңны томалыйлар.

—Сез балалар бакчасында түгел, ә хәрби авиациядә хезмәт итәсез,—дип кенә җавап кайтаралар.

Чынлап та, алар бит теләсә нинди информация чыгару катгый тыелган хәрби частьта хезмәт итәләр. Шул хакта ант биреп, секретлар бүлегендә имза да калдырдылар. Әмма, кеше барыбер уйланмый тора алмый. Аның уе сорау рәвешендә яисә ялгышып кына булса да телгә чыгып алучан була кайчак.

—Инде чиратта кайсыбыз икән тагы?—дигән сорау күңелләрендә мең тапкыр кабатлана торгандыр. Вакыт-вакыт, очучылар үзләре генә калган чакларда, ул телгә дә кереп ала иде.

Мин түгел дип, һичкем әйтә алмый.

—Белеп булмый инде егетләр, белсә дә моны бер Алла гына белә торгандыр.

—Ә без—барыбыз да коммунистлар. Шулай булгач, аңардан да сорашу килешеп бетми,—дип, шаяру белән тиз генә йомгаклап куялар иде ул хактагы уйлануларны.

Шулай да көннәрдән бер көнне, алар полкындагы икенче эскадрильядән лейтенант Смирнов шартлаганнан соң, бер җитди сүз чыгып алды.

Эскадрилья командирлары Биязович белән Идел буендагы күлләргә балык тотарга килгән иде алар. Володя Балченков командирдан сорап куйды.

—Иптәш командир, балык тотканда гына булса да, бер сорау белән мөрәҗәгать итәргә рөхсәтме?

—Тынлыйм, Володя, без бит монда командир белән аңа буйсынучы офицер түгел. Без—балыкчылар.

—Самолетлар бик еш югала башлады, бу сезне дә уйландырамы?

—Уйландырмаска соң, мин дә сезнең кебек үк ике аяклы, ике күзле гади бер кеше—хәрби очучы бит.

—Бер-ике ел элгәре мондый хәлләр бик сирәк, булса да елга бер була торган иде. Ә хәзер—ай саен дип әйтерлек. Моны ничек аңларга, иптәш командир?

—Мин үзем дә аңлый алмыйм. Сугыш вакытында да сирәк очрый торган иде андый хәлләр.

—Ә нигә нәтиҗә ясамыйлар? Ә ни өчен ул тәҗрибәләрне безнең өстә уздыралар? Очучылар да кеше бит...

—Дөрес сөйлисең. Әмма башка бу хакта һичкемгә авыз ачып сүз кузгатасы булма, ишеттеңме! Замполитка яисә секретлар бүлегеннән берәрсенә житкерсәләр—эш харап булачак.

—Ни эшләтерләр? Кемдер сүз кузгатырга тиештер бит инде бу хакта? Соң чиктә, без бит ирекле Советлар Союзын саклаучылар.

—Армияда—сүз сөйләшмиләр. Армияда—приказ гына үтиләр. Капитан Голиковны хәтерлисезме?—дип, сорап куйды Биязович бераз уйланып торганнан соң.

—Белмәскә, яхшы белә идек,—дип, Рафаэль да сүзгә кушылды шунда.— Ул шундый күңелле, ачык кеше иде. Ни сәбәпледер күренми ул хәзер, башка берәр жиргә күчерделәрме икән?

—Күчермәделәр. "МИГ-17" экспериментларын летчиклар гомере белән түгел, заводта һәм полигоннарда үткәрергә кирәк дип, югарыга рапорт язган иде ул. Ике көннән секретлар бүлегенә чакырганнар үзен. Һәм шул китүдән кайтмаган, югалды. Хатыны да белми аның кайда икәнлеген. Гыйбрәт бу, шуны исегездән чыгармагыз, егетләр. Дөнья без дигәнчә генә бармый шул ул.

—Шулай да булсын ди. Очучылар да кеше бит, аларның да гаиләләре, туганнары бар. Әнә, минем хатын тиздән бала табарга тиеш,—дип, үзалдына уйланган сыман гына, иплəп анлатырга кереште Балченков.—Рафаэльнең дә Ленасы түгәрәкләнеп килә. Туачак балаларыбыз хакына булса да без бу турыда уйланырга тиештер бит, иптәш командир.

—Уйланырга тиеш. Кеше уйланмый гына яши алмый, лейтенант. Әмма, "устав" һәм "присяга" төшенчәләре армияда беренче чиратта. Аларны шик астына алу кабул ителмәгән.

—Ә миннән сорасалар, солдат һәм офицерлар гомере бар нәрсәдән дә кадерлерәк, дип язган булыр идем мин ул Уставка.

Биязович бу юлы аңарга җавап кайтармады. Балык чиртеп куйдымы, әллә эче пошканнан, кармагын тартып чыгарды ул судан. Балык эләкмәгән, суалчаны үз урынында иде.

Командирның ачуын чыгардык ахры дип уйлап алды Рафаэль һәм бәхәсне ипле генә йомгаклау җаен карады.

—Ярый, житәр Володя, юк-бар сорауларыбыз белән эскадрилья командирының башын катырмыйк әле. Владимир Абрамовичка ял итәргә бирмисең. Аннары без кычкырып сөйләшкәнгә, әнә, балык та эләкми башлады,—дигән булды.

Дәшми генә утырдылар бер тын. Биязович белән Смаковка балык,

чиртү түгел, якын да килмәде. Ә Балченков бер-бер артлы өч алабуга тартып чыгарды аның каравы.

—Ә нигә ул сина гына эләгә,—дип, тынгысызланып куйды Рафаэль.

—Кемгә эләгергә, кемгә эләкмәскә икәнлекне балык үзе белә ул,—дип, мактанып алды Балченков.—Минем дөрес сүз сөйләгәнне ишетеп килде алар.

—Балык—бик куркак бит ул. Үз ишләре санап чиртә алар сина,—дип, мыек читеннән генә елмаеп куйды командир.

Ул да түгел, нәкъ шул мизгелдә аның үз кармагындагы калкавыч су астына китеп күмелде. Биязович, куанычын кая куярга белмичә, тагы да зуррак алабуга өстерәп чыгарды.

Балченков аны шундук эләктереп алды һәм кычкырып көлеп җибәрде:

—Ни дидегез, иптәш командир, бая ни әйткәнегезне ишетми калдым, тагы бер мәртәбә кабатлагыз әле?

—Аның каравы минем балык зуррак,—диде ул, ихлас куанып. Балченковка җавап таба алмады.

—Димәк, шунардан нинди нәтиҗә килеп чыга инде, иптәш командир?..

Өчәүләшеп көлешеп куйдылар... Күп тә үтмәде, Рафаэльнеке дә чиртергә кереште. Ул да балык тартып чыгарды. Куанычтан аның да авыз колакка житте.

—Нәтиҗә турында сораган идең,—дип, шунда гына телгә килде Биязович.—Ул хакта инде хәзер лейтенант Смаковтан сорый аласың...

Шул рәвешле уен-көлке белән утыра торгач, байтак кына балык тотты алар. Ару-талуны онытып, яхшы һәм күтәренке күнел белән хәрби частька әйләнеп кайттылар. Балык тотканда сөйләшенелгән сүзләр Идел суы белән агып китте, онытылдылар.

Бобровкага тиздән техник үзенчәлекләре белән бөтенләй башка югарылыктагы яна самолетлар—"МИГ-19" нын беренче үрнәкләре кайтырга тиеш дигән хәбәр таралды шул көннәрдә. Яна самолетның идарә системасын һәм тактик-техник характеристикасын җентекләп өйрәнергә кереште очучылар. Һәр яна самолет кайткан көннән яна бер дәвер башлана сыман иде алар өчен.

## 23

Елның муллык ае булган августка кергәч тә Рафаэльгә сөеклесе кечкенә генә, әмма бик тә матур бер кыз алып кайтып бирде. Анарга Гүзәл диеп исем куштылар. Рафаэль тәкъдим итте бу исемне. Лена кабул итте, әмма сорау бирми булдыра алмады.

—Ни өчен Гүзәл?

—Чөнки, аның әнисе—минем гүзәлем!

—Бәхәсләшмим, матур исем,—дип килеште Лена.—Ләкин, бу исемгә лаек булырмы соң безнең кызыбыз?

—Гүзәлдән—гүзәл генә туа, гүзәлем,—дип, яна туган кызларына исем сайлау мәсьәләсен йомгаклап та куйды Рафаэль.

Гаиләдә бала тугач—бөтенләй яна тормыш башлана икән. Рафаэль бермә-бер олыгаеп киткәндәй хис итте үзен. Ул хәзер үзе өчен генә түгел, хатыны һәм яна туган кызы өчен дә җаваплылык тоя башлады.

Ел буе Хәрби академияга керү өчен имтиханнарга әзерләнгән иде. Математиканы, физиканы өр-янабаштан өйрәнеп чыкты. Лена ярдәме белән инглизчәне дә азмы-күпме сукалый башлаган иде. Эш урыныннан характеристика да алынган. Әмма көтмәгән-уйламаган җирдән проблема

килеп чыкты—ул үзенең урта мәктәпне тәмамлау турындагы документын таба алмады. Аны Борисоглебсктагы хәрби очучылар хәзерләү училищесына кергәндә тапшырганын хәтерли. Күрәсең, шунда калган. Аннан “Сезнең документларыгызны таба алмадык” дигән җавап килде. Бүздәккә Халык мәгарифе бүлегенә аттестатның копиясен соратып мөрәҗәгать итеп карадылар. Туган яклардан “Копияләр бирелми” дигән бюрократик җавап килде. Менә сиңа мә, уйламаган җирдән нинди кыенлыкларга килеп юлыкты бит тагы. Инде башка чара калмагач, Хәрби академияга керү турындагы хыялны бер елга кичектереп торып, кичләрен йөреп яңадан урта мәктәптә имтиханнар тапшырырга кирәк булыр дигән нәтиҗәгә килделәр. Башкача юл калмаган иде.

Ни булса да хәерлегә булсын. Укуны сәбәп итеп, хатынын яшь бала белән калдырып китү дә дөрес булмас иде.

—Мин Уфада әни янында торып торырмын, сиңа укырга кирәк, Рафаэль,—дип, Лена үзен үгетләп тә карады.

—Юк, мин синең янында, Гүзәлем янында булырга тиеш, уку качмас,—диде ул, бәхәскә урын калдырмыйча.

Нәкъ шул көннәрдә аңарга өлкән лейтенант дәрәҗәсе бирделәр. Тиздән ул башлап очучы булачак. Кыскасы, хезмәт урынындагы уңышлар, гаиләдәге шатлыклы вакыйгалар белән бергә үрелеп бара иде. Канатланып, очып эшкә китә иде Рафаэль һәм шул ук дәрәҗәдә күтәренке күңел белән өйгә ашыгып кайтып керә иде. Өйдә бер түгел, ике гүзәл—хатыны һәм кызы көтеп торалар иде бит аны хәзер.

Эштән арып кайтуга да карамастан, су китерә, кибетләргә йөри, төрле хуҗалык эшләрендә ярдәм итәргә тырыша иде ул хатынына.

Кичләрен, сабый тәмле төшләр күреп йокыга талгач, икәүдән-икәү генә киләчәккә планнар корып, хыялланып утыралар.

—Бала үстерү бик мәшәкатьле. Сиңа авырга туры килә, Рафаэль. Эшеңә зыян китерә күрмә тагы,—дип үзенең борчылуын белдерә иде Лена.

—Миңа авыр буламыни инде, җаным. Бала бит ул—адәм баласы өчен иң зур хәзинә. Мин хәзер элеккегә караганда биш мәртәбә яратыбрак башкарам үз эшемне. Ул миңа бетмәс-төкәнмәс көч һәм гайрәт кенә китерә... Белсәң икән син.

—Аз йоклыйсың. Сиңа сигез сәгать йокы тиеш, сәламәтлек белән шаярырга ярамый, Рафаэль.

—Наполеон өч кенә сәгать йоклаган диләр. Ленин бабай да аз йоклаган. Ә нигә мин ярты гомеремне йоклап үткәрергә тиеш?

—Шулай кирәк, минем сүзне тыңла син, Рафаэль.

—Ә син дә минем сүзне тыңларсыңмы соң?

—Ни дисәң, шул булыр. Син бит минем бердәнберем. Әйт кенә...

—Вәгъдәме?—дип, кулын сузды ул.

—Вәгъдә,—дип, кулын бирде Лена.—Барысы да син дигәнчә булыр.

—Алай булгач сиңа иң зур хыялымны сөйлим, тыңла.

—Тыңлыйм.

—Миңа, җаным, тагы дүрт малай да алып кайтып бирерсең әле, ярыймы. Вәгъдәме?..

—Ничә диден!.. Син нәрсә, үз акылыңдамы... Мин аларны кай арада табып үстерә алырмын. Миндә шундый сәламәтлек бардыр дип уйлыйсыңмы, акылыңа кил, Рафаэль. Шаярып кына әйтүеңме?..

—Тамчы да шаярмыйм. Безнең Смаковлар нәселендә элек-электән ишле гаилә белән яшәгәннәр, ким дигәндә биш бала табып үстергәннәр.

—Шул кадәр бала тәрбияләп үстерү бик җиңел булыр дип уйлыйсыңмы?

—Жинел булыр дип уйламыйм, жаным, шулай кирәк саныйм,—дип, кочагына кысып алды ул хатынын. Һәм яратып иреннәреннән үбеп куйды.—Мин бит үзем дә ишле гаиләдә туып үстем. Өлкән малай буларак, авырлыкларны да аз татымаганмындыр. Әмма зур гаилә һәм балалар—ул, минемчә, ин зур бәхет. Минем әткәй белән әнкәйгә жинел булгандыр дип уйлыйсынмы! Ә бабайларга? Бабайларнын бабаларына...

—Алай дип уйламыйм, Рафаэль.

—Димәк, килештекме,—дип, тагы сораулы карашын хатынына төбәде ул. Мин ул балалар һәм балаларыбызның әнисе, ягъни синен бәхетле булуың өчен барысын да эшләргә тырышырмын, гүзәлем.

Жавап бирергә ашыкмады Лена. Күзләрен тутырып үзеннән жавап көтеп утырган иренә текәлеп карады ул шунда. Юк, шаярмый иде Рафаэль. Анын өчен шул мизгелдә әлеге вәгъдәдән дә мөһимрәк һичбер нәрсә юктыр сыман иде дөньяда. Башын иренең нык һәм таза күкрәгенә салды ул.

—Рафаэль, әллә син кыз бала булганга бик куанмадын инде?—дип сорап куйды бераздан.

—Киресенчә, беренче баланын кыз булуы хәерлерәк диләр. Сина ярдәмче дә булыр. Кыз бала бит ул ата-ананы күбрәк кайгыртучан була. Каян алдын андый сүзне, күрмисенме әллә, куанычымнан атлап түгел, очып йөри башладым бит инде хәзер...

—Ә ул кадәр малайлар белән ни эшләрбез? Кемнәр итеп үстерербез сон без аларны? Бер-ике генә булса, житмәгәнме?

—Юк, гүзәлем, житми. Безгә бит гомер бер генә бирелә, шуңа без бик күп хыялларыбызны тормышка ашырып бетерә алмыйбыз. Ә балалар—безнең дәвам, алар шул хыялларны тормышка ашырачак.

—Ә мин беләмме соң ул хыялларны?

—Беләсең, жаным, беләсең. Алар бит безнең уртак хыяллар. Әйтик, минем бик тә шагыйрь буласым килә иде.

—Ә син болай да шагыйрь ич инде. Мин синең шигырьләреңне бик тә яратам.

—Улларыбызның берсе шагыйрь булса, икенчесе—жырчы яисә музыкант булыр. Өченчесе—урман үстерүче, табигатьне саклаучы. Дүртенчесе—игенче, авылда ата-баба нигезен дәвам итүче...

Һәм уйлана калды ул. Лена моны күреп, ирен туктатырга ашыкты.

—Күрәсең ич, дүрт малай да житә икән бит. Бишенчесенә эш тә калмаган,—диде елмаеп.

—Юк, гүзәлем, ашыкма. Алай уйласаң, ялгышасың. Ә соң әтисе башлаган эшне кем дәвам иттерер!.. Очучы булачак анысы. Ул заманда инде хәрби самолетларның кирәге дә калмас. Кеше сугышмыйча гына яшәргә өйрәнер, ниһаять. Алар зур галәмне иңләп очар, яна планеталарга кунакка йөрерләр...

Тагы уйга калып тора башлады ул. Күңеле йомшарып алдымы, күз төпләре юешләнде, борынын тарткаларга кереште.

—Син нәрсә, Рафаэль?—дип, дәште шулчак Лена.

—Улларым өчен куанып куйдым әле менә. Көнләшеп тә куйдым хәтта үзләреннән. Алар бит минем хыялларымны тормышка ашырачак, Лена. Аңлыйсынмы?.. Ләкин, син-гүзәлемнен ярдәменнән башка мин берни дә майтара алмаячакмын. Синнән тора барысы да...

—Син дигәнчә булыр, Рафаэль,—дип йомгаклап куйды Лена. Күнеленнән генә Аллага мөрәжәгать итте шул ук вакытта: "И, Ходаем, үтенеп сорыйм—Рафаэлемә исәнлек-саулыклар бир. Барысы да синең кодрәтеңдә..." Өч мәртәбә кабатлады ул үзенең әлеге гозерен. Чөнки, соңгы араларда летчикларның хатыннары арасында да, әледән-әле кабатланып

торган катастрофалар уңае белән, төрле чыш-пышлар активлашып киткән иде. Күрәләр ич, ирен югалткан хатыннар нинди авыр, кеше күтәрә алмас кара кайгыда калалар. Шунысы бар тагы, ирләрен озатып атна-ун көн узгач та ул тол хатыннарны, балалары белән бергә, тизрәк хәрби шәһәрчектән кая да булса озату ягын кайгырта башлыйлар. Һичкемгә кирәкләре калмый аларның. Куркуыннан калтыранып куйды Лена, чак кычкырып җибәрмәде. Андый уйларны тизрәк үзеннән еракkарак куарга, онытырга тырышты ул. Ирексездән, иренә таба елыша барды һаман.

Хатынының бу халәтен үзенчә аңлап, шаяру катыш әйтеп куйды Рафаэль:

—Нәрсә, әллә хәзер үк җиң сызганып изге эшкә тотынабызмы, җаным?

—И-и, Рафаэль, син һаман шаярасың...

—Юк, шаярмыйм, чынлап әйтәм.

—Мине нәрсә борчыганын, ни хакында уйлаганымны белмисең ич син.

—Сөйлә, тыңлыйм. Борчылыр өчен бер сәбәпләр дә күрмим мин әлегә. Син янымда, бишектә кызыбыз йоклый. Әнкәйләр һәм әткәй, туганнарыбыз исән-саулар. Барысы да Аллага шөкер ич, гүзәлем, бәхет өчен ни җитми тагы?

—Белмим шул,—дип кенә куйды Лена, үзен биләп торган авыр уйларыннан аерыла алмыйча.

—Ә мин беләм. Безгә тагы дүрт малай гына җитми. Алары да вакыт эше генә. Олылар әйтмешли, үз вакыты белән булыр, орлыгы Бохарада түгелдер әле,—дип, рәхәтләнеп көлеп җибәрде ул.

Рафаэль шулкадәр ихлас һәм бар дөньясын онытып, туарылып көлә иде ки, моны бер тапкыр гына булса да күрергә, ишетергә кирәк. Ул көлгәндә янәшәдә булсаң, битараф калу һич кенә дә мөмкин түгел. Күңел күтәренкелеге, ирексездән, янәшәдәге кешене дә үзе артыннан ияртә, аның күңелен ачып, күтәреп җибәрә. Шундый сихерле көч бар иде аның көлүендә.

Ленаны да ачып җибәрде бу көлү. Һәм шул мизгелдә ул, күптән сөйләшәсе килеп тә башлый алмый йөргән сүзен башлау өчен җай тапты.

—Син, Рафаэль, миңа үзеңнең эшең турында берни дә сөйләмисең.

—Нәрсәсен сөйлисең инде аның, синең өчен бер кызыгы да юк ич. Тимер-томыр, приборлар һәм штурвал турында өйгә кайткач онытып торуың хәерлерәк.

—Ә минем сиңа кагылган бар нәрсәне дә белеп торасым килә. Шартлаган самолет һәм һәлак булган очучылар турында да берни сөйләмисең син миңа.

—Нәрсәсен сөйлисең инде аның,—дип, җитдиләнә төште Рафаэль.— Кирәк кадәрен син үзең дә ишетеп беләсең. Летчик хатыннары арасында чыбыксыз телефон күптән җайга салынган бит ул.

—Ә мин алардан түгел, синнән ишетәсем килә. Сине бит, Бобровкадагы очучылар арасында, аеруча мәгълүматлы дип сөйлиләр.

—Дөрес сөйләмиләр. Мин дә башкалардан артык берни белмим.

—Син шуны гына әйт миңа, нигә ул самолетлар шулай еш шартлый башлады? Элекке елларда мондый хәл булмаган ич.

—Юк белән башыңны катырма, гүзәлем, күп белсәң—тиз картаерсың. Ул турыда уйлама син, бөтенләй башыңнан чыгарып ат,—дип чем кара чәчләреннән сыйпап куйды ул сөеклесен.

Ленаның күңеле нечкәреп китте шунда. Борын читләреннән күз яшьләре мөлдерәп тәгәрәде.

—Мин бит синең өчен борчылам. Мин бит куркам...

—Курыкма. Миңа берни дә булмас. Мин очар өчен туган... Мин—бөркет токымыннан, бик беләсен килсә,—дип, хатынының күңелен күтәрәсе килеп, күкрәгеп киереп куйды ул.

—Ә мин бөркетләр турында бер ни дә белмим,—диде хатын, мышык-мышык борынын тартып.—Бөркет булуың турында беренче ишетүем.

—Шуны бел, бөркетләр озак яши, гүзәлем. Бик нык картайгач та, бөркетләр очудан тәм таба. Ишеткәнең бардыр, дөнья белән бәхилләшер вакытлары житкәч тә бөркетләр очып барган көйгә кыяга ташланып үлә диләр. Нинди горур үлем бит ә!..

—Үлем турында сөйләшмик әле,—диде Лена. Һәм урынынннан торып, тәмләп йоклап яткан сабыенын өстен ябып килде.

—Әйдә, юк-бар сөйләшеп утырмыйк. Булмаса, берне жырлап алыйкмы соң әллә...

—Нинди жыр, бала йоклый ич, уятырсың.

—Ә без мандолинасыз гына, шыпырт кына жырлыйбыз аны,—дип, үзенекен итте Рафаэль. Һәм тын гына, пышылдап кына жырлый да башлады:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып житәр бу.

Ул да түгел, жырлыйм дигәч тә башта куркып калган яшь ана, ире янына килеп утырып анарга кушылып үзе дә жырларга кереште. Тукайның "Бишек жыры"н жырлый башлаган иде бит Рафаэль. Ничек итеп кушылмыйча, бер читтә калып тыңлап торсын ул аны.

Йокла, кызым, йом күзең,
Йом, йом, күзен, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезен.

Сүз берләшкәндәй, бер үк вакытта урыннарыннан торып, жырларын дәвам иткән көйгә Рафаэль үзе кабыктан ясап куйган бишеккә таба якынайды алар. Анда йоклаучы кызлары Гүзәл янына килеп бастылар. Аңарга атап, аның өчен жырлыйлар бит. Сабый күзләрен ачып жибәрде шунда һәм бәхетле елмаеп бер тибенеп куйды.

## 24

Бобровка тип-тигез далада урнашкан, ышыкланыр тау да, урманнар да юк иде монда. Агач һәм бакчалар да юк, һәр дүрт тарафта тигезлек һәм бушлык. Шуңа иртә яздан көзгәчә ком бураннары уйнап тора. Ә инде кышка кергәч, бертөзлексез үзәкләреңне өзәрлек салкын жил исә, кар тузаннары сибереп тора. Шуңа гаиләле очучылар өчен дип салынган, заманы өчен "престижлы" саналган, фин йортларында кышларын шактый ук суык була торган иде. Бертөзлексез мичкә ягып чыккан төннәре дә булгандыр. Рафаэльне бу бик тә уйландыра, борчып тора. Ярый ла узган кышта алар икәү генә иде. Инде бала бар. Ул буш вакытларында, тәвәккәлләп, өйне жылыту эшенә кереште. Иң элек, пычкы чүбе кайтартып түшәменә калын итеп шуны түшәп чыкты. Бу гына житми иде әле. Ни өчен аның стеналары шулай юка икән, дигән сорау борчый иде әле аны

тагы. Һәм тышкы яктан өйнең стенасын тәшкил иткән бер фанераны куптарып караса, исе-акылы китте, үз күзләренә ышанмый торды хәтта. Фанера астында аркылы-торкылы сугылган рейкалардан башка берни юк иде, жылыткыч-фәлән куеп тормаганнар. Менә сиңа фин йорты, имеш... Төзүче һөнәре үзенә ят булса да, башыңа төшсә башмакчы булырсың дигәндәй, моның да бер җаен тапты. Стенадагы фанераларны берәм-берәм куптарып, андагы бушлыкка салам һәм пычкы чүбе кушылган кызыл балчык сыларга кереште.

—Рафаэль, син нәрсә уйлап чыгардың тагы?—дип, кадак каккан тавыш ишетеп аның янына күрше бүлмәдә яшәүче майорның хатыны чыкты.

—Менә, күрегез, без ни өчен кыш буе тун киеп йоклыйбыз икән,—дип, ике яктан кадакланган фанерлар арасындагы бушлыкны ачып күрсәтте.

Күргәч, егылып китә язды күршеләре. Алдашу һәм ялганның әллә нинди төрләренә дә күнеккән, газап-михнәтнең бар тәмен татып караган совет офицерлары булып, алар да үз күзләренә үзләре ышанмыйча торды бертын. Менә сиңа мә, кырык градуста да өй эчен май кебек жылы тотарга тиешле фин йортлары... Баксаң, аларның исеме генә "финский" икән, ә чынлыкта үзебезнең советский Карелиядагы бер зонада житештерелгән булып чыктылар. Кыш буе суыктан калтырап чыккан берәүнең дә фанера эчендә ни барын тикшереп карарга башына килмәгән.

Икенче көнне инде Рафаэльгә ике як күршесе—майорлар да ярдәмгә килеп кушылды. Бер атна дигәндә йортны жылытып чыкты алар шулай. Аларның тәжрибәсен башка йортларда яшәүчеләр дә файдаланырга керешге. Тора-бара шунысы да ачыкланды—бөтен Идел буе хәрби округына китерелгән булып чыкты әлегедәй "жылы" фин йортлары. Шул рәвешле, Рафаэльгә, дус-иш арасында үз итеп әйтелә торган, "төзүче" кушаматы да килеп өстәлде.

Ә икенче берәүләр өчен ул бакчачы да булып тоелгандыр. Бобровка комында яшелчә үстерү турында уйлаучы да юк иде. Ә өй тирәсендәге жирләрнең шәрә һәм буш торулары Рафаэльнең эчен пошыра. Шуңа ул кичләрен эштән кайткач, өй каршында клумбалар ясап, аларга төрле-төрле чәчәк орлыклары утыртып чыкты. Ә өйнең арткы тарафындагы бушлыкта түтәлләр ясап, ул түтәлләргә яшелчә кәлшәләре төртте. Һәр көн кичен шул үзе утырткан үсемлекләргә су сибәргә тырыша иде. Туфрак начар булу сәбәпле, ул утырткан үсемлекләр начар тишелеп, бик зәгыйфь булып үстеләр. Шуңарга кәефе кырыла иде аның, күл буена балыкка барган жиреннән дә кулындагы сумкага кара туфрак тутырып кайтып, үзе утырткан гөлләрне сыйларга ярата иде. Ә инде клумбаларга утыртылган гөлләренең чәчәк аткан көне аның өчен иң зур бәйрәм булды.

Бобровка авылыннан кич савылган сөтләрен офицер хатыннарына китереп сатучы маржа хатыннары аны чын-чынлап бакча караучы кеше дип уйлап, "бакчачы" дип йөретәләр иде.

Әмма, Рафаэль Смаков төзүче дә, бакчачы да түгел, барыннан да элегрәк, ул үз һөнәрен үлеп яраткан һәм аңарга жаны-тәне белән бирелгән очучы. Аңарга нинди генә катлаулы һәм авыр сугышчан бурычлар йөкләнмәсен, аларны ул жиренә житкереп һәм үз вакытында үтәп чыгарга күнеккән. Хәрби частька заводтан сынау өчен жибәрелгән "МИГ-19"ның иң беренче ике үрнәген алып кайтырга да тәжрибәле асс капитан Клименко белән аны жибәрделәр. Бу жаваплы эшне алар төгәл үтәп чыкты.

Бер килсә, гел килеп тора бит ул куанычлы вакыйгалар. Кызлары туганнан соң ярты ел эчендә ул өлкән лейтенант званиесы һәм IIIнче дәрәжәле очучы исемнәренә лаек булды. "За боевые заслуги" медале һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамотасы белән бүләкләнде. Ә тагы

берничә айдан ул “Звено командиры” итеп билгеләнде. Санап чыгарлык түгел ич, саный башласаң, башың әйләнерлек.

Шулай да бары да ал да гөл генә булмый ул безнең дөньяда. Офицерлар чират белән частьта дежурлык итә торганнар иде. Рафаэльгә дә житте ул чират. Бер тәүлек буе Хәрби частьтагы эчке тәртип һәм барлык хужалык эшләре өчен җаваплылык дежур торучы офицерга йөкләнә. Өйгә кайту, йоклау яисә черем итеп алу турында уйларга да ярамый, әлбәттә.

Бобровкада ин кыены, әлбәттә, су проблемасы иде. Үзенең суы бары тик юыну һәм башка техник чаралар өчен генә яраклы. Шуңа эчү өчен суны машина белән Кинельдән ташыйлар. Бөтен хәрби частька бер су ташу машинасы. Ул көн саен ике рейс ясый. Беренчесе, ашханә өчен. Икенчесе—офицер гаиләләренә. Ә Бобровкада торып эшләгән төзүчеләргә һәм башка төр хезмәт ияләренә суны бирү катгый тыела. Кибеп үлсәләр дә бирергә ярамый, су табу аларның үз эше, дип куелган.

Ул көнне офицер гаиләләре өчен дип кайтартылган суның яртысы диярлек артып калды.

—Калганын ни эшләтим?—дип сорады су ташучы солдат дежур офицер Смаковтан.

—Беренче тапкыр су китерүең түгелдер ич, башка вакытта ни эшләтә идең соң?

—Кеше күрмәгәндә, качып кына эшчеләр ала иде. Офицерлар күрсә, орыша. Ә кай чакта түгәргә дә туры килә. Машинада төнгә су калдырырга ярамый бит, иртән иртүк хәрби часть өчен алып кайтасы бар. Нишләтим, түгимме?

—Суны түгәләрмени!—дип каршы төште Рафаэль.—Күрмисеңме, күпме кеше чиләк тотып көтеп тора. Бала арбасы тартып килгән хатыннар бар, әнә.

—Эшчеләргә бирергә кушмыйлар, иптәш өлкән лейтенант,—дип, кабат искәртергә кирәк тапты солдат.—Җаваплылыкны үз өстегезгә алсагыз гына. Минем өчен бер читкә илтеп түгү кулайрак. Тизрәк тә була, орышучы да булмый.

—Суны түкмисең! Кешеләргә бир, алар да безнең хәрби шәһәрчеккә хезмәт итәләр ич,—дип китеп барды Смаков.

Солдат ул кушканча эшләде. Рәхмәт әйтә-әйтә эшчеләр, төзүчеләр, аларның хатыннары суны өйләренә ташыды.

Шунда, очраклы рәвештә узып баручы полковник Прищепа күреп калган булып чыкты бу хәлне. Ул солдатка сорау биргән:

—Кем рөхсәт итте?

—Дежур офицер, өлкән лейтенант Смаков,—дип җавап биргән солдат.

Прищепага шул җитә кала.

—Ә-ә, шул татармы...—дип, яный-яный китеп бара.

Прищепа—сугыш ветераны. Югарыда дуслары, яхшы танышлары булган дәрәҗәле өлкән офицер. Аны хәтта Идел буе хәрби округын җитәкләгән генералның туганы дип тә сөйлиләр иде. Ярый әле ул икенче полкның командиры. Шулай да, олы башын кече итеп булса да, әлеге фактан мөгез чыгарырга тырышып йөрде ул. Күрәсең, нәрсә өчендер Рафаэльне ошатып бетермәгәнме, әллә үз мин-минлеген раслау шул кадәрле мөһим булган, эш хәрби часть командирына кадәр барып житте.

Ул, катгый рәвештә, өлкән лейтенант Смаковка “эчке тәртипләрне бозган өчен” дип, шелтә бирелүне таләп иткән булып чыкты. Бу хакта, бераз вакыт узгач, үзе хезмәт иткән полк командиры полковник Костюченко сөйләде анарга.

Командирлар һәм хезмәттәшләре белән үзара тату, аңлашып эшләргә һәм яшәргә күнеккән Рафаэль шактый ук авыр кичерде әлеге ыгы-зыгыны. Югыйсә, һичбер сәбәп биргәне юк иде бит аның.

Дустының шулай борчылап йөрүен күреп, көннәрдән бер көнне аэродромнан өйгә кайтышлый капитан Клименко аңарга бер гыйбрәтле тарих сөйләде.

—Исең киткән икән иске чикмәнгә,—дип башлады ул сүзен.—Юкка борчылма син, кул гына селтә Прищепаның сүзләренә. Ул хакта оныт.

—Онытып булмый шул, уйландыра. Кешеләргә игелек кылу җинаять түгелдер ләбаса.

—Ә син беләсеңме ни өчен ул сиңа каныга?—дип сорап куйды капитан.—Моның бит сәбәбе бар.

—Белмим шул. Нинди сәбәп булырга мөмкин? Минем полковник Прищепа белән һичкайчан бернинди мөнәсәбәттә булганым юк. Әллә нигә бер очрашканда Устав кушканча честь бирәм, шуның белән бетте.

—Синең ишеткәнең юкмыни, хатыннары белән яратышып яшәгән кешеләргә аллергиясы бар ич аның. Ул бит синең каршыда, урам аша гына яши. Хатының белән ничек бер-берегез өчен өзгәләнеп яшәгәнлекне күрми дисеңме әллә!..

—Тукта, Василий Иванович, мин ялгыш ишеттемме, бер ни дә аңлый алмыйм. Ничек инде гаилә өчен җан атып йөргән кешегә ачу тотарга мөмкин. Аңлатып бир, зинһар...

—Моның үз тарихы бар,—дип, сөйләп китте капитан.—Ул инде сугышка кадәр үк бик матур бер хатынга өйләнгән була. Бер-берләрен яратышкан да булсалар кирәк. Самолетын фашистлар бәреп төшергәч, парашюттан сикереп җиңелчә травма ала Прищепа. Госпитальга эләгә. Шунда ике аягын да югалткан икенче бер очучы белән дуслашып китә болар. Теге көн дә елый икән. "Минем болай ике аяксыз калуымны белсә, хатыным бер көн дә тормас, ташлап китәр" дип, борчыла икән. Бу аны тынычландыргандыр, билгеле.

"Ә минем хатын менә, ике аяк кына түгел, өченчесе сынса да китмәс иде...", дип мактана икән Прищепа.

"Үз башыңа төшмәгәнгә генә әйтәсең син. Үз башыңа төшсә, бер дә алай димәс иден әле", дип борчылуын дәвам иткән ике аяксызы.

Бераз спирт та капкан булганнар күрәсең, болар бәхәсләшеп китә. "Әйдә, сынап карыйк алай булгач", дип, хатыннарына икесе дә бер үк эчтәлектәге хат язып сала болар.

Бер атна да үтми, ике аяксыз калганының хатыны күчтәнәчләр төяп, ире янына килеп җитә. Һәм көн-төн ирен карый, юата, аның рухын, күңелен күтәрергә тырышып, кулыннан килгәннең барысын да эшли. Ә Прищепа байтак кына җавапсыз тора. Бер айлар чамасы узгач кына, инде госпитальдан терелеп чыккач кына Прищепага хат килеп төшә: "Гафу ит инде, гомер бер генә бирелә—мин башканы таптым, аңарга кияүгә чыгам. Син дә үз ишеңне табарсың, хуш!" дигән сүзләр була ул хатта.

Менә шулай, Рафаэль. Шул көннән ул хатын-кыз затын бөтенләй сөймәс булып китә. Аларга нәфрәт белән генә карый. Һәм бөтен гомерен авиациягә багышлап, ялгызы гына яши.

Рафаэльгә шактый нык тәэсир итте Клименко сөйләгән бу тарих. Күңеленең бер почмагында полковник Прищепага карата кызгану хисе дә уянып куйды хәтта.

—Менә бит ничек, уеннан уймак китереп чыгарган,—дип кенә әйтә алды. Ә бертын дәшми генә барганнан соң, өстәп куйды тагы.—Бәлки узар, башка берәүне табып өйләнер дә әле. Ялгыз яшәү җиңел түгелдер

шул. Анарга, күп дигәндә, кырык-кырык бишләр генәдер әле.

—Хатын-кызсыз тормыйдыр анысы,—дип куйды капитан да.—Әмма ул аларга һаман да нәфрәтле. Хатын-кызга ул хуҗалык өчен кирәк-яраклы бер нәрсә итеп кенә карый, диләр.

—Яратмыйча яшәү яшәүмени! Алай яшәп булмыйдыр ул,—диде Рафаэль. Башка сүз таба алмады.

Өйләренә кайтып җиттеләр. Капитан, хушлашып, үзләренә кереп китте. Рафаэльне, май кояшыдай балкып, тәрәзә каршында сөекле хатыны көтеп тора иде. Кулында кызлары Гүзәл. Сабый нәни кулын күтәрә төште шунда, акрын гына тәрәзәгә кагылды—әллә әтисен сәламләве иде шулай...

## 25

1955нче елның мартына кергәннәр иде инде. Һәр яңа көн туган саен якынлашып килүче яз сулышы ныграк сиземләнә бара. Ул көнне Рафаэль эшкә икенче сменага гына барырга тиеш иде. Шуңа кичен соңрак йокларга ятты. Йокыдан аларны офыклар артыннан тоныкк кына булып ишетелгән шартлау авазы уятты. Сискәнеп китте ул. Моны хатыны да сизмәде түгел, сораулы карашын Рафаэльгә төбәде:

—Ни булды ул?

—Белмим, бәлки төзүчеләр бер-бер нәрсә бушата торганнардыр.

—Ә нигә шулай тынгысызлана башладың?

—Тынгысызланырга сәбәп юк, гүзәлем. Болай гына,—диде ул. Әмма башына төрле уйлар килде, үз-үзен кая куярга белми башлады. Һәм ашыгыч кына тамак ялгап, юк сәбәпләрен бар итеп, эшкә дип китеп барды.

Тынгысызлануы юкка булмаган икән. Аэродромга якынлашып килгәндә үк ниндидер гадәттән тыш вакыйга булганлыгын аңлап алды ул. Чөнки барысы да арлы-бирле йөгерешә. Кемнедер эзлиләр, кемгәдер приказ биреп кычкыралар. Пожар сүндерү өчен җиһазланган ике машина очу кырыннан чыккач та күп китә алмаган, йомшак кар көртенә кереп батканнар. Март аенда мондый машиналарда ерак китеп булмый шул.

Беренче очраган кешегә үк сорау бирде Рафаэль:

—Кем?

—Володя Балченков,—дигән җавап ишетте.

—Әй, Во-ло-дя...—дигән аваз чыкты аңардан, һәм юл читендәге кар көртенә барып чүгәләде ул. Сизгән иде бит. Шартлау авазын ишеткәч тә сизгән иде. Хәерлегә түгел бу, Володя булмагае, дигән шик кергән иде күңеленә. Шуңа ашы—аш, киенүе—киенү булмады. Күңел сизә икән ул! Җан әрнүен ни эшләтергә белмичә, йодрыгы белән юл читендә карала башлаган каты карга китереп сукты ул. Һәм аэродромга таба торып йөгерде.

Үзе йөгерә, ә күз алдында якын дусты тора. Володя Балченков белән бергә-бергә укып йөргән көннәре, бергә монда—Бобровкага эшкә килүләре—барысы да тизләтелгән кино кадрлары сыман, берсен-икенчесе бүлдерә-бүлдерә аның күз алдыннан йөгерә. Бергә-бергә йөргән юллар, киләчәк турында хыялланып йокысыз үткәргән төннәре, егет чаклар, сөйгән кызлары белән хат алышкан көннәре...

Үлем аянычсыз булмый диләр. Володя белән булган бу хәл икеләтә-өчләтә аянычрак иде бит. Аның иң бәхетле көннәре иде, әле бер атна элек кенә хатыны Валентина малай алып кайткан иде аңарга. Ул әле аны күрергә дә өлгермәгән. Туган ягы Оренбургтан шул хакта телеграмма алгач та ул, шатлыгын уртаклашу өчен, иң беренче атылып аның янына килеп кергән иде. Ишектән керә-керешкә:

—Малай туды, Рафаэль, малай. Мине котлый аласың, мин дә әти булдым,—дип, такмаклый-такмаклый шар ярып кычкырды.

Рафаэль дә ихлас куанган иде ахирәт дустының бу шатлыгын ишетеп. Тагы берничә көннән, чираттагы отпускасын алып, туган якларына—хатыны Валя һәм улы Валерикны күрергә китәргә тиеш иде инде ул. Аяныч, бик тә аяныч шул.

Ике көннән Бобровка белән янәшә генә шыр ачык дала уртасында ачылган хәрбиләр каберлегендә тагы бер нәни соры калкулык барлыкка килде. Очына калайдан кисеп ясалган йолдыз урнаштырылган бер метр чамасы озынлыктагы имән такта тыгып куйдылар. Шул тактага дүрт кадак белән кагылган калай кисәгендә түбәндәге сүзләр язылган иде: “Очучы лейтенант Владимир Балченков (1931-1955)”. Туганнарын, хатынын көтеп тормадылар. Гомумән, һичкемгә хәбәр итү яисә күрсәтү кабул ителмәгән иде андый очракларда. Өенә “Хәрби задание үтәгән чагында батырларча һәлак булды” дигән гадәти хат кына юллана. Һәм вәссаләм, очулар, бер ни булмагандай, элеккечә үк дәвам иттерелә.

Башкалар кайтып киткәч, яңа кабер янында өч летчик беразга тоткарлана төштеләр—эскадрилья командиры Владимир Абрамович Биязович, капитан Василий Иванович Клименко һәм өлкән лейтенант Рафаэль Миргалим улы Смаков.

Капитан Клименко куен кесәсеннән яссы итеп эшләнгән кечкенә фляга тартып чыгарды.

—Искә алыйк Володяны,—диде. Фляганы ачып бер тапкыр йотты да, спиртны Биязовичка тоттырды. Аннан Рафаэльгә...

—Яхшы егет иде. Тыйнак һәм кешелекле,—диде Биязович.

—Кызганыч, әле шундый яшь иде бит,—диде Смаков.—Аның кебек тугрылыклы дуслар башка булмас... Эх, Володя,Володя...

—Әле биш ел элек кенә монда тип-тигез дала иде. Күрегез, инде үзе бер зур шәһәрчек булып килә икән безнең зират,—дип офтанып куйды Клименко.

—Яңа елга чыккач кына да алтынчы кабер,—дип кушылды Биязович.

—Жиденчесе кем булыр?—диде Рафаэль.

Фляганы тагы бер кат кулдан-кулга күчереп чыктылар. Һәм башларын салындырып, һәркайсы дәшми генә үзалларына уйланып, кайту юлына борылдылар. Рафаэльнен хәтеренә шулчак келт итеп кайчандыр һәм кайдадыр колагына чалынып калган шигырь юллары килеп төште. Үзалдына шул юлларны кабатлап кайтты ул күңеленнән:

Ак розалар жилдән тибрәнмәде,
Алар үскән бу жир тетрәде.
Яңа кабер—яңа авыр яра
Алды бүген жирнең күкрәге...

Иң якын дустын югалту бик авыр тәэсир ясады Рафаэльгә. Бу хакта хатынына бик сиздерергә теләмәсә дә үзенә урын таба алмый йөрде ул. Эшкә шыпырт кына ипле адымнар белән чыгып китә һәм шул рәвешле, канатларын салындырып, күңелсез генә кайтып керә. Күп сөйләшми, гадәтенчә шаярмый, көлми. Ленаны бик тә борчый иде аның бу халәте. Шуңа, җаен табып, берничә тапкыр аның белән җитди сөйләшеп тә карады.

—Сина быелдан да калмый Хәрби академияга керергә кирәк, Рафаэль,—диде менә тагын.

—Ленам, ашыктырма зинһар. Күрәсең ич, минем эштән арынып тора алганым юк.

—Ташла барысын да һәм укырга кер. Беразга булса да котылып торырсың шул очулардан.

—Ни сөйлисең, гүзәлем? Мин бит сиңа йөз мәртәбә, мең мәртәбә әйткәнем бар—мин очар өчен туган. Авиацияны, самолетларны калдырып мин һичкайда китәргә җыенмыйм.

—Үзең турында уйламасаң, безнең хакта уйла. Күрәсең ич, катастрофа артыннан катастрофа кабатланып кына тора.

—Илнең хәрби авиациясы яңабаштан үзгәртеп корылган, яңадан яңа самолетлар кайтырга торган шундый заманда мин һичкая китә алмыйм, гүзәлем, шуны аңла. Тагы бер мәртәбә кабатлыйм—очтым, очам һәм очачакмын.

—Ә синең шул рәвешле үз-үзеңә бикләнеп, газап кичереп йөрүләреңне күрү миңа да җиңел түгел, Рафаэль. Кызың һәм минем хакка гына булса да ташлап тор ул очуларыңны, укырга кер.

—Уку—кирәк эш анысы, гүзәлем. Мин моны үзем дә яхшы аңлыйм. Әмма, мин дә китсәм, башкалар да китсә, социалистик Ватаныбызның күген кем саклар соң! Мин ул адымга бара алмыйм, аңла...—дип юмаларга, тынычландырырга керешә ул.—Аннан бит әле гаиләбез дә ишле булыр дип килештек, ул балаларны да үстерәсе бар. Безнең хезмәт хакы яхшы, үзең беләсең. Әткәй-әнкәйләргә дә ярдәм итеп торабыз. Энекәшләрне һәм сеңелне дә укытып чыгарасы бар. Туган якларга кайткачтың бит үзең күрәсең, акча юк кешедә. Бирмиләр, түләмиләр...

—Ә исәнлек-саулык тагы да кадерлерәк. Күреп торасың ич, әнә. Володяны теге дөньяга озаткан көннең икенчесендә үк, бүлмәләрен бушатып, башкаларны керттеләр. Әйберләрен килеп алганны да көтмәделәр. Очучыларның да кадере исән чакта гына...

—Анысы дөрес, яхшы эшләмәделәр,—дип, килешергә мәҗбүр булды Рафаэль.

Лена, сүзне бер башлагач, җыеп килгән бөтен запасларын чыгарып салырга булды ахыры. Һөҗүмен дәвам итте ул:

—Ә теге Жора белән, Георгий Матвеев белән барган ыгы-зыгыга ничек карыйсың?

—Сиңа кем сөйләде аны? Каян беләсең?—дип, гаҗәпсенеп куйды ул. Чөнки Прищепа полкында булган бу вакыйга хакында ул хатынына бер сүз дә әйтмәгән, сиздермәскә тырышкан иде бит. Ул очучы моннан бер айлар чамасы элек, үзе идарә иткән самолет кабинасы яңа башлап төтен белән тулгач, катапульта ясап исән калган иде. Шул көннән башлап аны Округның хәрби прокуратурасына чакыртып, берөзлексез тикшерә, теңкәсенә тия башладылар. "Ни өчен самолетыңны калдырып качтың?.. Ул самолетның күпме торганлыгын беләсеңме? Үзең үлсәң дә самолетны син җиргә төшерергә тиеш идең?" дигән гаеп тагу һәм сораулар белән җанын ашадылар.

—Нигә сикергәнем өчен үкенәм инде, шунда калып шартлыйсым гына калган икән...—дип, Жораның сөйләгәнен ишетеп торган Володя әйткән иде аңарга. Нәтиҗәдә, Жораны кулга алдылар. Володя үзе дә юк инде хәзер.

Әнә ич ничек, чыбыксыз телефон яхшы эшли, летчикларның хатыннары үзләреннән күбрәк белә инде болай булгач. Ленаны бу хакта азрак уйланырга, азрак сөйләшергә чакыру белән йомгакланды әлеге сөйләшү. Юк, һич кенә дә ачуланышу түгел иде бу, бәхәсләшү дә түгел. Ә бары тик фикер алышу, тулган күңелләрне бушату гына булгандыр... Чөнки һәр икесе дә хаклы иде бит аларның. Лена хатын һәм ана буларак хаклы иде, Рафаэль—ир кеше һәм офицер буларак.

## 26

Рафаэль Смаковның 1956нчы ел өчен чираттагы ялы апрель аена туры килде. Эшендәге унышларны искә алып, анарга гаилә белән ял итү һәм сәламәтлеген ныгыту өчен Кырымда урнашкан бик тә билгеле санаторийга путевка тәкъдим иттеләр. Өлкән офицер составына да сирәк эләгә торган бәхет иде бу ул еллар өчен. Лена бу хакта ишеткәч тә шатланып туя алмады. Рафаэльгә дә кирәк иде ял, бала өчен дә әйбәт диләр иде дингез һавасын.

—Шулай да быелга барып булмас,—дигән карарга килде Рафаэль, барысын да бизмәнгә салып уйлана торгач.—Әткәйнең хәле бик борчый мине. Авылга кайтырга туры килер...

—Үзең беләсең,—дип, авыр булса да, ризалашырга мәҗбүр булды хатыны.

Путевкалардан баш тартып, язгы пычракта, юлсызлыкта, кайда ат арбасына утырып, кайда җәяүләп бата-түнә Яңа Актауга кайтып төштеләр. Аларның кайтасын алдан ук белеп торган Миргалим абзый бөтен балаларын да авылга чакырткан иде. Бу аның, үзенә күрә, хушлашырга җыенуы булгандыр күрәсең. Уфадан Әсма апа белән Мәсгут җизни ике уллары белән кайтып төште. Бертуган энесе Мәгдән, кыз туганнары Зәүҗан һәм Мөшәрифә. Кызы Тамара Уфада эшли иде инде, төпчек малай Ринат Бәләбәй педучилищесында укып йөри—алар да кайттылар. Рим армиядән соң, шоферлыкка укып, өч-дүрт авылга бер булган машинаны йөртә башлаган иде, ул якында гына—Каранда. Ерак дингездә йөзүдә булган Нур гына кайта алмады.

Аларга авылдагы туганнар да килеп кушылды. Әниләре Хафаза апа исә мич каршыннан китә алмады, иртәдән кичкә кадәр аш-су хәзерләүдә булды.

Миргалим абзый тире белән сөяккә генә калган иде инде. Әмма, шунарга да карамастан, үз-үзен көр һәм күтәренке күңел белән тотарга тырышты ул. Хәлләрен сорашканда да авыруы хакында ләм-мим сүз кузгатмады, кузгатып карауչылар булса, аларны шундук ярты сүздән бүлеп куя иде.

—Ташласанә, ул нинди сүз, авыру турында сөйләшәләрмени?! Бүген бәйрәм ич, күрмисеңме, минем улларым-кызларым гына түгел, оныкларым да кайткан кунакка,—дип кенә җавап кайтарды.

Киленнәре Лена анарга район җирендә табып булмый торган кыйммәтле дарулар һәм уколлар да юнәтеп алып кайткан иде. Аларның да уңай тәэсире булмый калмагандыр, әлбәттә.

Аннан килеп, бу бит Сталинның шәхес культын Никита Хрущев фаш итеп чыккан тарихи көннәр иде. Билгеле инде, әтисе Мәсәлимнең картайган көннәрендә сөргенгә сөрелеп, шунда эзсез югалуын бик тә авыр кичергән Миргалим абзый өчен бу мөһим вакыйга була. Патша заманында волостной старшина булып хезмәт иткән дәүләт кешесе, ягъни "халык дошманы" улы буларак аның үзенә дә төрле кимсетү һәм рәнҗетүләрне аз татырга туры килмәгәндер.

Шул хакта сүз кузгалгач, Лена да кушылып алды. Аның да бит фронттан кайткан әтисен, пленда булган дип, 1946нчы елда утыртып куйган булалар. Сталинның үлеменнән соң гына Уфага кайтып, туберкулездан китеп барган ул. Миргалим абый белән килененең бу уңайдан язмышлары гына түгел, фикерләре дә бер төрле һәм аермачык иде. Ә Рафаэль исә, хәрби кеше буларак, агымдагы сәяси мәсьәләләргә артык тирән кермәүне кулайрак күрә иде бугай. Әллә, ул чор өчен генә түгел, безнең көннәргә

дә хас булганча, Сталинның шәхесен бәяләүдә икеләнә идеме...

—Сталин барында илдә тәртип бар иде, әткәй. Армияда дисциплина бар иде,—дип куйды ул, аны җыйнаулашып гаепләргә җыенганнарын күреп.

—Куркытып, илнең иң зыялы һәм укымышлы кешеләрен сөргеннәргә сөреп, төрмәләргә утыртып, юкка чыгарып ясалган тәртип кенә бит ул,—дип каршы төште Миргалим абзый.

—Ватан сугышында җиңеп чыгуы өчен генә дә лаек түгелме ул олылауга?..

—Юк, улым, Ватан сугышында Сталин түгел, халык җиңеп чыкты. Үзебезнең авылны гына кара, әнә, сугышка киткәннәрнең яртысы кире әйләнеп кайтмады. Бөтен ил буенча шулай ич. Үз-үзен кызганмыйча атакага барган солдат җиңде сугышта. Тылда калып та, фронт өчен корал җитештергән хезмәт армиясе җиңде. Авылларда, шәһәрләрдә ачлы-туклы яшәп тә, көнне-төнгә ялгап хезмәт иткән хатын-кызлар, балалар һәм карт-карчыклар җиңде.

—Анысы да дөрес, әти, мин боларның барысын да үзем күрдем. Үз җилкәмдә татыдым, дип әйтергә була.

—Шулай булгач соң... Мин дә әнә бар сәламәтлегемне Чиләбедә—танклар заводында калдырып кайттым. Бөтен ил белән күтәрелде халык, шуңа җиңеп чыктык.

—Әйдә, әткәй, киткәннәрнең гаебен табып утырмыйк әле, шулай бит. Бүгенге тормыш һәм киләчәк турында сөйләшик,—дип, әлеге авыр теманы тизрәк урап узарга тырышты Рафаэль. Әтисе сөйләгәннәр белән килешсә дә, күңеле белән ул барыбер Сталинны гаепләүчеләр тарафында түгел иде.

Миргалим абзый үзенең олы улы белән бик тә горурлана иде. Аның кайтуын ул зур түземсезлек белән көтеп алды, шул көнгә туры китереп бөтен балаларын, иң якын туганнарын чакыртты. Хәл белешергә кергән һәммә авылдашларына, күрше күләнгә алдан ук хәбәр салып куйды ул бу хакта. Үсмер еллары нинди авыр чорга туры килсә дә, аның Рафаэле үз көче белән укып чыкты һәм әнә хезмәт иткән җирендә нинди зур дәрәҗәләргә ирешкән. Погоннарында өч йолдыз бар хәзер! Узган ел кайтканында икәү генә иде бит әле...Шуңа аның белән фикер алышып, гәпләшеп утырудан өстәмә бер рәхәтлек тә таба иде бугай ул. Ә башкалар, аларның сөйләшүенә колак салып утырсалар да, кысылмауны кулай күрде.

—Армиядә тәртип бетте дисең инде алай булгач,—дип дәвам итте Миргалим абзый, бая ук улының авызыннан чыккан сүзләрне яңартып.

—Шулайрак шул, әткәй...

—Булган тәртип кая китте икән соң ул? Әллә ул тәртип курку һәм куркытуга гына корылган булдымы икән?

—Бик мөмкин. Аннан тагы, без җиңүче, дөньяда без беренче, дип масаю чамасыз була башлады. Шул зыян итә бугай. Кеше кадерен белү юк...

—Ә кешенең кадере ул һичкайчан булмады бездә,—дип, меңдәрен күтәрә төшеп, торыбрак утырды Миргалим абзый. Тәрәзәдән төшеп торган апрель нурлары аңарга юнәлгәннәр иде шул минутта. Кояш нурлары, тәрәзә төбендәге гөлләргә генә түгел, аңарга да яшәү көче иңдерәдер иде сыман.

—Соңгы араларда самолетлар бик еш шартлый башлады, әти.

—Нәрсә булды, нигә алай икән, улым? Әллә бер-бер диверсияме икән...

—Дөньяда беренче булу өчен ашыгалар. Кабаланалар...

—Ә ул самолетларны йөрткән очучылар исән каламы соң?

—Бик сирәк очракларда гына... Үләләр шул, кызганычка каршы. Иң якын дуслар безне ташлап китә.

—Килен әйткән иде аны, иң якын дустың да китеп барган икән шул.

—Әйе, мин аның турында сөйләгәнем бар иде сиңа. Икәү бергә төшкән фоторәсем дә җибәргән идем үзегезгә.

—Шул егет мени?!—дип, офтанып алды Миргалим абзый.—Теге, Оренбург ягыннан диган идең бит әле...

—Әйе, үзе.

Улының кайгысын уртаклашып, бераз дәшми торды әти кеше. Өй эче тын калып торды.

—Аларны соң, улым, туган якларына кайтарып күмәләрме?

—Кайтару кая инде ул. Кешедән бер нәрсә калмый ул шартлаудан соң. Гробына алтмыш—җитмеш кило ком тутыралар да күмеп куялар инде шунда...

—Әнә ничек...

Өй эче тагы тынып калды. Шылт иткән аваз да чыкмый торды бертын. Бу сөйләшүне читтән шыпырт кына тыңлап торган туганнар да башларын чайкап куйдылар.

—Акчаны юкка гына бирмиләр шул,—дип куйды бераздан, кунакка кайткан апаларыннан кайсыдыр.

Рафаэль шунда җанланып китте. Акча хакындагы сүз, бу күңелсез һәм авыр сөйләшүдән чыгу форсаты биргән иде аңарга.

—Акча дигәннән, бер мәзәк хәл сөйлим әле үзегезгә,—дип башлады ул сүзен.—Безнең частьның финанс бүлеге мөдире бар, “начфин” дип йөртәләр инде аны. Исак Абрамович—үзе элекке фронтовик, бик ачык, күңелле кеше инде болай. Әмма саран. Хезмәт хакы түләгәндә, үзенекен бирәмени, летчикларның теңкәсенә тиеп бетә: “ Сезгә күп түлиләр. Бу летчикларга нигә инде ул тикле акча бирергә...”, дип тукылдый берөзлексез. “Дәүләт акчасын экономияләү кирәк...” дип, югарыга рапортлар да язып караган ул хәтта. Очучыларның тенкәсенә тиеп беткәч, монарга тәкъдим ясадык без: “Әйдә, безнең белән бер һавага менеп дөньяның матурлыгын күреп төш әле, Исак Абрамович!”—дидек. Бик теләп риза булды, үзенен бер тапкыр да самолетта очканы булмаган икән. “Күптән хыялланып йөри идем, тәвәккәллик булмаса” дип, тиз генә ризалашып та куя.

Иң тәҗрибәле очучыларыбыздан берсе булган капитан Клименко, штурман урынына утыртып, аэродром тирәли ике-өч әйләндереп төште үзен. Бер очтан штопор һәм винт та ясап күрсәтә үзенә. Башы белән җиргә каратып та очырта. Төшкәч, зур авырлык белән ике-өч кеше тартып чыгардык кабинадан. Тәмам телсез калган, манма тиргә баткан, йөзе бәрәңгедәй ап-ак , зур авырлык белән генә сулыш ала иде.

Хәзер инде хезмәт хакы түләгәндә берни дәшми аның каравы. Үзеннән шаярткалап та алабыз кайчак:

—Исак Абрамович, тагы кайчан очабыз инде?—дип теңкәсенә тиючеләр дә бар.

—Булды, егетләр, очтым. Инде үзегез очыгыз. Миңа җирдән атлап йөрү ошыйрак төшә,—дип кенә җавап бирә. Акча турындагы сүзләр дә онытылды.

—Менә шундый хәлләр, әткәй,—дип елмаеп куйды Рафаэль. Башкаларга да кызык булып китте, аңарга кушылып бер көлешеп алдылар.

...Өйне тутырып торган туган-тумача һәм туганнар ике көннән китеп тә бардылар. Һәркемнең үз тормышы—кемнең укыйсы, кемнең эшлисе бар. Әти-әниләре янында Рафаэльләр үзләре генә торып калды. Хуҗалык мәшәкатьләренә кереп чумдылар.

Кыш бик карлы булу сәбәпле, өй әйләнәсендә кар бик күп иде әле. Шуларны ыргытып чыкты Рафаэль. Ул да түгел, бакчадагы бәрәнге базына язгы су төшкән булып чыкты. Ашыгыч рәвештә, әнисе белән икәүләп, аны чыгардылар. Аннан ишегалдын һәм капка төбен боздан арчу белән мәшгуль булды. Каралты-кура түбәләрен карап, ямыйсы жирләрен ямап чыгу да анын жилкәсенә төште. Авыл кешесенең эше тавык та чүпләп бетерерлек түгел дип әйтүләре—хак инде ул. Кая барып тотынсаң да эш чыгып кына тора.

Бер атна вакыты калды нибарысы. Лenаның бераз Уфадагы туганнарын да йөреп, аларга Рафаэльне һәм кызлары Гүзәлне күрсәтәсе килә иде бик тә. Туган авыл белән, әти-әнисе белән хушлашып юлга чыгарга жыендылар.

—Улым, миннән сиңа хәер-фатиха, бик рәхмәтлемен үзенә. Игелекле бала булдың, бәхетең булсын,—диде әтисе, хушлашырга дип кулын сузган Рафаэльгә.

—Рәхмәт, әткәй,—диде ул, моңсу гына әтисенең сулып барган йөзенә туры карап.—Борчылма, боерган булса терелерсең. Жәйгә чыккач, безгә дә кунакка килеп китәрсең әле бер.

—Ни язса, шул булыр, улым,—дип, күз читләренә килеп буылган яшь тамчыларын сөртеп куйды ул.—Әниеңне, туганнарыңны ташлама. Башкача сорар кешем юк, булдыра алсаң, үзенә тагы бер үтенечем бар әле—Ринатны укытырга тырыш. Укуга, белемгә тартыла сыман ул...

—Борчылма, әткәй, күпкә аерылышмыйбыз. Тагы күрешергә язсын, яме,—әтисенең аркасыннан сөеп кочып алды Рафаэль.

—Хуш, сау бул, улым.

...Алар Уфага китеп барды. Уфадан ерак түгел генә урнашкан Чишмә районындагы Келәш исемле авылны да күреп кайттылар. Келәш—Леnаның әнисе туган авыл. Анда аның бик күп туганнары яши. Бу юлы Мөдәррис абыйлары чакыруы белән барган иделәр. Бергә-бергә Дим буйларын гизделәр, Акманай күле тирәсендәге табигать матурлыгы белән хозурландылар. Әүлия чишмәсеннән шифалы су эчтеләр, авыл яшьләре белән бергә менеп Кызлар тавының иң югаргы түбәсендә учак ягып көлгә бәрәнге тәгәрәтеп ашадылар. Кыскасы, онытылмаслык булды бу сәяхәт.

## 27

Илле алтынчы елның көзенә кереп баралар иде инде. Лена көннәрнең берендә, нинди жавап ишетерен белми генә, сак кына Рафаэльгә үзенең яңалыгын сөйләде.

—Мин авырга уздым ахры... Икенче бала булса, ни әйтерсен?

—Урра,—кычкырып, урыныннан сикереп торды Рафаэль.—Сорап торган буласың. Соң беләсең ич, гүзәлем, болай булгач, үзеңне гел кулларымда гына күтәреп йөрергә дә риза.

—Тугыз ай буе күтәреп йөрерлек булсаң гына,—дип куанып, елмаеп жибәрде хатын.

—Тугыз айдан соң, тагы тугыз ай күтәрергә дә риза мин, Ленам.

—Бала тапкан хатын тазарып та китә ул кайчак. Күтәрә алмаслык булып тазарсам, ни эшләрсең?

—Күтәрми диләр мени!—дип, шундук биленнән эләктереп алып, югары чөйде ул сөеклесен. Һәм куанычыннан ни эшләргә белми, аны үзе тирәсендә зыр әйләндерергә керешге.—Малай була димәк, малай...

—Чү, төшер инде, малаеннын башын әйләндерәсең ич,—дип әйтергә мәжбүр булды Лена.

—Юк, гүзәлем, минем малайның башы аңарга гына әйләнә торган

булмас. Аның бит әтисе кебек очучы булып үсәсе бар.

Тел очында торган соравын, әйтергәме-юкмы дип уйланып торгачтын, шулай да бирергә кирәк тапты Лена.

—Бала бит әле тумаган. Ә син инде аны самолетта очыртасың. Малай булмаса, ни эшләрсен?

—Беләм—малай,—дип кырт кисте Рафаэль. Мин аны син сүз кузгатканчы ук, төшемдә күрдем инде.

Шул көннән башлап Рафаэль малаен каршыларга әзерләнә башлады. Әллә ни арада ике як стенага, ул елларда таба алмаслык дәрәҗәдә дефицит булган, ике келәм алып кайтып элде.

—Малайга жылы булсын,—диде.

—Бер түгел, ике келәм алып кайткансың—каян таптың аны?—дип хәйран калды Лена. Келәм табу, келәм алу аның да күптәнге хыялы иде ләбаса.

—Таптым инде,—диде ул, масайган атлы булып. Әмма шундук дөресен дә әйтеп бирде.—Кинельдән спекулянтлар китереп сатты. Ике бәягә булса да алдым инде. Юкса малай туган көнне үк келәмнәрегез кая соң сезнең, дип сорап куйса.

—Алай ике бәя дә булгач, берне генә аласың булган...

—Соң, гүзәлем, күпме кабатларга була. Ел да бер малай, дип сөйләштек ич. Ә икенче малай туганчы бу спекулянтны тотып, утыртып куйсалар, мин ни эшләргә, каян табарга тиеш булам тагы,—дип шаяруында булды һаман да.

—Хыялый син, Рафаэль, романтик,—дип иренә елыша төште хатын.—Алдан кычкырган күкенең башы авырта, диләр. Алай ук ашыкма инде син, ярыймы.

—Беренчедән, мин ашыкмыйм. Үтеп барган яшьлегемне генә куып тотасым килә. Бездән яшьрәкләр дә бит инде икешәр-өчәр бала үстерә, Ленам. Икенчедән, хыял, Һади Такташка ияреп әйтсәк, ул яхшы нәрсә. Әмма һәрбер йөрәк аны янарта... Ә инде, өченчедән, халык мондый очракларда минем кебек хыялыйлар турында тагы да матуррак та итеп әйтә белә. Тыңла: "Алмаган ат, тумаган колын. Атланма, улым, билең сындырырсың",—диләр.

—Чынлап та бик тирән мәгънәле һәм урынлы сүзләр,—диде Лена, халык мәкален тагы бер кат күнеленнән уздырып.

... Бобровка авылына барып, күп итеп кыяр һәм яшел помидорлар сатып алып кайтты Рафаэль. Икәү бергә аларны кышка тозлап куйгач, кәбестәгә чират житте. Кәбестәне зур агач кисмәккә тозлап куйдылар.

—Нигә ул кадәр?—дигән сорауга, Рафаэльнең жавабы күптән әзер иде.

—Шуны онытма, гүзәлем, без бит хәзер өчәү генә түгел, дүртәү инде. Аннан соң бит әле, малайның тәпиен дә бөтен эскадрилья белән һәм дус-ишләрне жыеп, шәплләп юарга туры килер. Кабымлыклар житәрлек булсын, дим.

Гаиләдә көтелгән шатлыклы вакыйгалар белән канатланып йөргән шул көннәрнең берсендә Рафаэль эшеннән кәефсез кайтып керде. Моны хатыны шундук сизеп алды, әлбәттә.

—Ни булды, бер-бер күнелсезлек килеп чыктымы әллә?—дип сорамый булдыра алмады ул.

—Юк ла, болай гына,—дип котылмакчы иде Рафаэль. Чөнки эштәге ыгы-зыгыны өйгә ташуны хупламый иде ул. Әмма Ләнанын күңеленә шик кергәнне күреп, жавап бирергә мәжбүр булды.—Мине эшемдә күтәрергә жыеналар.

—Сон күтәрергә җыенгач, нигә кәефен кырылды сон. Куанырга кирәк түгелме?

—Куанырга иде дә бит,—дип тагы уйга калып торды ул. Ничек анлатырга икән дип баш вата идеме...—Шуны сәбәп итеп, Прищепа полкына күчерү турында приказ язып элгәннәр.

Прищепа фамилиясе аларга яхшы таныш. Димәк Рафаэльнен кәефсезләнүе бер дә юкка гына булып чыкмады болай булгач.

—Ризалаштынмы?

—Ризалашмас идем дә бит, гүзәлем. Әмма приказлар үтәлергә тиеш, ул хакта берүдән дә фикер сорамыйлар. Мин—хәрби офицер.

—Ә үзегезнең командир, полковник Костюченко ни уйлый?

—Анардан да сорап тормаганнар. Анын бер дә үзеннән җибәрәсе килми иде, әлбәттә.

—Күчерүнен нинди дә булса җитди сәбәбе бардыр ич. Нигә нәкъ менә сине күчерергә булганнар, әйтмәделәрме?

—Әйттем ич, беренче сәбәп, мине бераздан эскадрилья командирынын ярдәмчесе итеп күтәрергә җыеналар. Икенчедән, Костюченко полкында квалификацияле очучылар болай да җитәрлек. Ул аларны таба, тәрбияли һәм үстерә белә чөнки. Ә Прищепада кадрлар кытлыгы. Һәлак булучылар да күп булды, ташлап китүчеләр дә бар. Теге чакта катапульта ясап исән калган Жораны стройбатка җибәрделәр. Менә дигән очучы иде югыйсә, Прищепа үзен якламады.

—Кәефеңне төшермә, Рафаэль. Ни булса да хәерлегә була күрсен инде. Бәйләнүләреннән дә туктар әле бәлки,—дип ничек тә ирен юатырга тырышты хатын.

—Күнелемә ятыш кеше түгел. Эшләрем шундый яхшы бара иде бит. Командирларым да әйбәт кешеләр иде. Алардан аерылу авыр.

—Борчылма, барысы да көйләнер, Рафаэль. Күр дә тор, көйләнер. Әллә кая җибәрмиләр ич, шушында калабыз.

Рафаэль Прищепа полкына күчүнең кыенлыклары хакында өйдә башкача сүз кузгатмады һәм сер бирмәде. Әмма шулай да анын үз-үзен тотышыннан барыбер тоемлап була иде—анарга җинел булмады бу үзгәреш. Ә тора-бара тагы да кыенлаша барды, күрәсен. Юктан-бардан гаеп табып, полк командиры үзенә берөзлексез каныга торган булып китте. Түбәнрәк дәрәҗәдәге башка командирлар да анын кубызына биеде. Костюченко полкында Рафаэль ин яна "МИГ-19" да очкан булса, монда иске "МИГ-17" дә, вакыты белән хәтта формаль рәвештә Совет авиациясеннән инде алынган "МИГ-15"кә дә утырталар иде үзен. Кыскасы, Прищепа яман хәтерле һәм үчле кеше булып, аны төрлечә рәнҗетү ысулларынын яналан-яна төрләрен табып кына торды. Рафаэльнен буйсыну һәм дәшми генә үз эшен башкару, приказларны җиренә җиткереп үтәүдән башка чарасы юк иде. Өлкән лейтенантның полковник белән бәхәсләшү яисә анын каршында үз дөреслеген раслап сүз көрәштерү хокуклары, гомумән, юк шул.

—Ярый әле син бар һәм кызыбыз Гүзәл,—дип эштән кәефсезләнеп кайтса да, өйгә кергәч дә шаярырга, бала белән уйнарга тырыша иде ул. Шул рәвешле җанын тынычландыра, эштә булган күнелсезлекләрне онытып тора иде.

Гүзәлнен дә теле "Әттә" дигән сүз белән ачылды. Рафаэльнен шунарга куануын, сөенүен күрсәгез икән сез. Өйгә кем керсә яисә урамда нинди танышын күрсә, ул шул хакта бер зур вакыйга сыман итеп сөйли иде.

—Кыз бала әтиләрне яратучан була диләр, дөрескә чыга түгелме,—дигән булып, Лена да сирәк-мирәк иренен салпы ягына салам кыстырган булды шунда.

—Ә малай тугач, мине яратмас дип әйтәсеңме?

—Әнисен дә яратыр. Боерган булса, әтисен дә яратыр, әлбәттә.

—Дөрес сөйлисең, гүзәлем, сине яратмыйча мөмкин түгел ич. Сине без өчебез дә өзелеп яратабыз, шуны бел.

—Өчебез...—дип кабатлады да, өченчесе кем дигән сыман уйга калып торды Лена.

Аның ни әйтергә теләвен ярты сүздән сизеп алды бит Рафаэль.

—Ә улыбыз сине аеруча нык ярата торгандыр. Чөнки аның бит әле әтисе белән апасын күргәне дә юк. Ә сине ул белә, чөнки ул көн-төн синең белән.

—Фантазер син Рафаэль. Әллә ниләр сөйлисең, әллә ниләр уйлап чыгарасың. Синең белән бер дә күңелсез түгел.

—Ә нигә әле күңелсез булырга тиеш минем белән, шулаймы кызым, шулаймы Гүзәл?.. Йә әле, кызым, тагы бер мәртәбә "әттә" дип әйт. Әйт әле, мин кем—әттәме, әттә...

—Әттә,—дип, елмаеп куйды сабый. Шул шатлыгыннан кулларын чәбәләп, аяклары белән бишегендә тибенеп алды.

—Әнә, тагы "әттә" диде. Ишеттеңме, Ленам, тагы "әттә" диде,—дип, куанычын кая куярга белмәде, мандолинасына барып тотынды ул.—Хәзер мин кызыма бер җыр җырлыйм. Тыңла, кызым. Әниең дә тыңласын. Ул, әнә, мич яга, сиңа ботка пешерергә җыена.

Шул минутта, әле генә башланган моңлы җырны бүлдереп, кемдер килеп, аларның ишеген шакыды. Тынып калды өй эче. Күршеләрдән берәрсенең җыр тавышына эче пошкандыр дип, сагая калганнар иде. Түгел икән. Почтальон телеграмма китергән булып чыкты. "Әти-и-и..."

...Иртәдән кичкә кадәр берөзлексез салкын карлы яңгыр явып торган октябрьнең соңгы көнендә Миргалим абзыйны Яңа Актау соңгы юлга озатты. Аны урам уртасыннан тездән пычрак саз ерып күтәреп баручы балалары һәм туган-тумачаның хәленә кереп, төрле елларда аңардан белем алган укучылары, күршеләре һәм авылдашларының кайгысын уртаклашып, табигать үзе елыйдыр төсле иде ул көнне. Кая карама—анда саз һәм пычрак. Күк йөзен кара болыт каплаган, авыл урамы гына түгел, бөтен дөньясы пычрак сазга баткан кебек иде шул мизгелдә. Ә авыл зиратьі, гүя жылы келәм, тоташ яшел чирәм белән түшәлгән. Як-ягына тигез рәт булып утыртылган ак каеннар бизәп тора аны, кабер өсләрендә үскән ямь-яшел чыршылар. Китүчегә "Авыр туфрагың җиңел булсын" дия-дия иң соңгы, әмма изге теләкләр теләделәр.

Әти-әни исәнлегеннән дә зуррак бәхет юктыр ул. Ниһаять, менә ул да, сөекле хатыны янына, аның кебек үк ярты ятим булып кайтып керде...

## 28

Полк командиры Прищепа, очучының тирән кайгысын уртаклашасы урында, аны өч сәгатькә кичеккән өчен, шелтә белдереп һәм хәрби часть буенча чираттан тыш дежурлыкка билгеләп каршылады.

Тешен кысып булса да түзде Рафаэль, дәшмәде, берәүгә дә зарланмады. Чөнки буйсынудан башка чарасы юк иде. Аның каравы, башта бераз чит итебрәк кабул иткән үзе кебек үк очучылар һәм түбән командирлар составы, хәленә кереп, төрле ысуллар белән аның күңелен күтәрергә тырышты, ярдәм кулларын сузды. Шуңардан да кадерлерәк ни булырга мөмкин тагы.

Аларның эскадрильясына килеп кушылган яшь очучы Николай Шишкин аны, Ленасы белән бергәләп, декабрьнең алтысында булырга

тиешле туена чакырды. Шишкин Мәскәүдә туып-үскән егет, әтисе КПСС Үзәк Комитетында җаваплы урында эшли икән. Мәскәүдән зур кунаклар да киләсе билгеле булгач, аның туй мәҗлесен, башкаларныкы кебек хәрби частьта түгел, Кинель шәһәренең Үзәк мәдәният сараенда уздырырга карар кылганнар. Туйга чакыруны, үзенә күрә бер вакыйгага ясап, сөекле Ленасының кулына кайтарып тоттырды ул.

—Туйга җыена башла, сөеклем...

—Барабыз,—дип, чакыруны куанып кулына алды Лена. Үзенең кеше арасына чыгарга теләве бер хәл, Рафаэль өчен шатланды ул аеруча. Чөнки кайгы өстенә кайгы, борчу өстенә борчулар өстәлеп кенә торды анарга соңгы араларда. Мәҗлестә булып, кешеләр белән аралашу бәлки беразга гына булса да ул кайгы-борчулардан арындырып торыр үзен.

—Ә син игътибар иттеңме, бу бит гадәти туй мәҗлесе генә булмаячак. Зур мәдәният сараенда, үзенә күрә бер бал сыман узачак. Парлап бию, вальслар һәм төрле конкурслар белән.

—Ой, минем шул кадәр вальс әйләнәсем килә иде синең белән. Әйтергә җай таба алмый гына йөри идем. Биюдә беренче урын безнеке булачак!

—Булачакмы икән?.. Курсант чакта биемәкче булып караган идем мин бер, кеше көлкесенә генә калдым. Үземне "дамский вальс"ка чакырган кызның аягына басып, аксаттым. Минем уңышлар менә шундый, сөеклем.

—Ә мин сине өйрәтермен.

—Белмим, аюны биергә өйрәтеп буламы икән?

—Син онытып җибәрәсең, Рафаэль, мин бит Ленинградта балет мәктәбендә укыган кеше. Мин сине һичшиксез өйрәтәчәкмен. Репетицияләрне бүгеннән үк башлыйбыз. Һәм һәр көн ярты сәгать, ул гына җитмәсә, бер сәгать өйрәнәчәкбез, килештекме?

—Мин риза аңысы. Әмма барып чыкмас дип уйлыйм.

—Чыгар! Ничек кенә барып чыгар, күрерсең.

***

Иртәгесен гадәттәгедән бераз иртәрәк уянды алар. Кичәге туйның искә алып, аннан алган тәэсирләрне яңартып кара-каршы утырып тәмләп чәй эчтеләр. Хатыны белән кызы Гүзәл, көндәгечә, аны урам почмагындагы өйләр артына кереп югалганчы тәрәзәдән кул болгап озатып калдылар.

Ул килә-килешкә самолетлар янында ниндидер бәхәс һәм ыгы-зыгы булганлыгын чамалап өлгерде.

—Ни булган? Нигә шулай тавышланалар анда?—дип сорады ул беренче очраган летчиктан.

—Капитан Хитрич теге калтырый торган самолетта очудан баш тартты,—дигән җавап ишетте ул.

Хитрич тәҗрибәле очучы, сугыш вакытында егермедән артык фашист самолетын бәреп төшергән ас. Шуңа ул полк командиры белән дә бәхәскә керә һәм үз фикерен яклап сүз көрәштерә ала. Ә яшь очучыларга исә андый хокук бирелмәгән, аларның буйсынудан башка чаралары юк.

Капитан Хитрич юкка-барга тавыш күтәрә яисә кызып китә торган кеше түгел. Димәк, аны шул хәлгә җиткергәннәр булса кирәк. Полк командиры Прищепа белән ул турысын әйтеп сөйләшә иде.

—Бу самолетта мин очмыйм һәм минем эскадрильядагы башка очучылар да анда утырмаячак. Мин аларга моны рөхсәт итмим.

—Син кем белән сөйләшкәнеңне онытасың, капитан.

—Полк командиры белән сөйләшәм.

—Сугышны үткән булсаң да командирлар белән сөйләшергә өйрәнмәгәнсең әле.

—Мин бит сезгә чираттан тыш ял сорап килмәгән. Эш турында сөйләшәбез, иптәш полковник.

—Самолет төзек. Ул очарга әзер. Приказ үтәлергә тиеш.

—Ул очарга яраксыз. Ышанмасагыз, әнә соңгы араларда аңарга утырып һавага күтәрелгән летчиклардан сорый аласыз. Алар барысы да монда.

—Механик Шадрин,—дип кычкырды Прищепа.

Сырган калын бушлат кигән механик йөгереп командир каршысына килеп басты.

—Механик Шадрин сезне тыңлый, иптәш полк командиры.

—761нче номерлы "МИГ-17"гә ни булган?

—Барлык системалары да эшли. Әмма...—дип, төртелеп калды ул.

—Ул нинди "әмма", дәвам ит, механик Шадрин.

—Самолет инде шактый ук иске. Һәм ул бераз вибрация бирә.

—Ул нинди сүз, механик Шадрин, Совет авиациясендә иске самолетлар юк. Ә вибрациясез эшли торган техника буламы?—Механикның куркып калуына игътибар итте ул шундук.—Син әнә үзең дә калтыранасың түгелме соң? Бәлки синең үзеңне списать итәргәдер...

—Минем уемча, иптәш полк командиры, самолетны заводка җибәрергә кирәк. Безнең шартларда ул вибрациянең сәбәбе нидә икәнлегенә төгәл бәя бирү мөмкин түгел.

—Отставить, механик Шадрин. Синең үзеңне чыккан заводыңа озатырга вакыт! Акыл сатарга остарып киткәнсең. Бар, үз эшең белән шөгыльлән. Заводка җибәрү-җибәрмәү синең эш түгел.

Механик Шадрин башын салындырып китеп барды. Прищепа капитан Хитричка мөрәҗәгатъ итте тагы. Бу юлы инде ул бераз йомшара төшкәнгә охшаган иде:

—Самолет бүген дә, иртәгә дә үз нормасын очарга тиеш. Моны мин уйлап чыгармаган, беләсең...

—Минем эскадрилья бу самолетта очулардан баш тарта,—диде Хитрич. Башкача бу хакта сүз кузгатуның файдасыз икәнлеген аңларлык итеп кистереп әйтте бу юлы.—Гафу итегез, иптәш командир, минем моңа хокукым бар.

—Мин моны болай гына калдырмаячакмын, исеңдә тот, капитан.

—Китәргә рөхсәт итегез, иптәш командир,—диде Хитрич һәм бер читтә төркем булып, командирларның сүзенә колак салып торган үз эскадрильясы янына китеп барды.

Тагы күп булса, ун-унбиш минут вакыт узгандыр, полк командирыннан "761нче номерлы "МИГ-17"гә өлкән лейтенант Смаков утырырга тиеш", дигән әмер килеп төште. Рафаэль бу самолетны яхшы белә иде, аңарда ул бер генә тапкыр очмаган. Әле ун көннәр чамасы гына элек, шул самолетта штопорга эләгеп, чактан гына самолетны һәм үзен коткарып кала алды. Ул очракта да рәхмәт ишетмәде билгеле, мактау урынына, үзен гаепләргә тырышып йөрделәр. Нишлисең, Рафаэльнең капитан Хитрич кебек, йә булмаса элгәрге командиры Биязович кебек, яклаучысы юк. Приказдан баш тарта алмый иде ул. Башкача чарасы юк, очышка әзерләнде.

Самолет кабинасына ул, читтән күзәтеп торучыларга сер бирергә теләмичә, ышанычлы адымнар белән кереп утырды. Кабызды. Двигатель яхшы гына эшли. Приборлар барысы да дөрес күрсәтә. Бәлки, чынлап та, борчылыр өчен нигез дә юктыр. Шулай да бераз дулкынлана иде, ни язса—шул булыр дип, кузгалып китте. Һәм алдан билгеләнгән маршрут буенча илле алты минут чамасы очып төште. Җиргә төшергә җыенганда гына самолет кинәт ямьсез калтырана башлады. Әмма Рафаэль югалып

калмады барыбер, кыенлыкларны җиңеп булса да исән-имин төшереп утыртты ул аны.

Офицерлар ашханәсеннән тамак туйдырып, иптәшләре белән шау-гөр килеп чыгып килгәндә аны эскадрилья командирлары Дьячок чакырып алды үзенә.

—Өлкән лейтенант Смаков, полк командиры сиңа үзенең рәхмәтен белдерергә кушты.

—Менә ничек,—дип кенә әйтә алды ул, үз колагы ишеткәнгә ышанырга белмичә. Бу полкта аның беренче мәртәбә рәхмәт ишетүе иче. Анысын да кеше аша гына житкерделәр.

Эскадрилья командирының сүзе тәмамланмаган икән әле.

—Син төштән соң да шул ук самолетта очачаксың,—диде ул.

—Самолет ышанычлы түгел, иптәш капитан. Ул чынлап та аерым ситуацияләрдә чамадан артык калтырарга тотына. Приборлар алдаша,—дип аңлатырга кереште Рафаэль.

—Самолет төзек. Ниндидер җитешсезлекләре бар икән, аларны ачыклау һәм җиргә кире әйләнеп кайтканнан соң тәфсилле отчет язу сиңа йөкләнә, өлкән лейтенант. Боларны сиңа полк командиры җиткерергә кушты.

—Мин беренче ел гына очмыйм, иптәш эскадрилья командиры. Төрле самолетларда очарга туры килде, әмма моның кебек аңлаешсыз һәм тыңлаусызын очратырга туры килмәгән иде.

—Сүз артык монда. Барысын да отчетыңа теркәрсең...

—Белмим шул. Бәлки башта техник ярдәм чакырырга кирәктер.

—Бу—приказ, өлкән лейтенант. Полк командиры приказы. Телгә салынмыйча гына аны үтәргә кирәк. Аңлашылдымы!

—Аңладым, иптәш командир,—дип, теләр-теләмәс кенә, үзалдына ниләрдер уйланып, әлеге дә баягы шул проблемалы самолет янына китеп барырга мәҗбүр булды Рафаэль.

Самолет янында техник персонал кайнаша иде. Килә-килешкә үзләренә сорау белән мөрәҗәгать итте ул:

—Житешсезлекләре ачыкланмадымы?

—Нормально,—диде араларыннан берсе битараф кына.

Икенчесе үзенчә шаяртып өстәп куйган булды:

—Йә үләсең, йә каласың—монысы точно инде...

Бу шаяру, билгеле, ошамады аңарга. Әмма ачуы килгәнлекне сиздермәде, ул бит белә, аларның гөнаһы юк. Кулларыннан килгәнне эшлиләр, ә башкасы алла кулында.

Штурвал артына кереп утырды Рафаэль. Тыныч кына, беренче кат күргән кеше сыман, приборларны, рычагларны тикшереп, барлап чыкты. Барысы да үз урыннарында. Карап торганда, барысы да исән кебек анысы. Двигатель да әйбәт кенә кабынып эшли башлады. Очыш картасына күз төшереп алды ул тагы бер кат. Бу юлы шактый ук катлаулы элмәкләр ясау һәм һөҗүм тактикасын кабатларга тиеш иде ул. Кузгалып, тиешле биеклеккә менеп житте. Аэродромнан алтмыш-житмеш чакрым ераклыкта иде инде. Катлаулы элмәкләр ясарга кереште. Берсе барып чыкты. Икенчесе... Рычаглар гына менә, ни сәбәпледер, аны тыңларга теләми башлады... Алай итсә итте, өченче элмәкне дә башкарып чыкты, ниһаять. Әмма, тагы проблема... Бу юлы инде приборларда анархия. Гомер булмаган, ишетелмәгән хәл ич бу? Сәбәбе ни—һич аңламассың... Кинәт самолет ямьсез калтырана башлап, биеклекне югалта башламасынмы... Бу нәрсә? Самолет аны тыңламый түгелме соң! Катапультага басаргамы? Юк, ул моңа бара алмый, самолетын ташлап качкан диган гаептән дә авыррак нәрсә юк ул очучы өчен. Коллегалары алдында оятлы булыр.

Сөекле хатыны Ленага да бу хакта ишетү күңелле булмас. Ә ул бала көтә—малай! Аның күңелен төшерү ярамас...Ул идарә итә алмаган, аңарга буйсынмаган самолет юк иде әле моңарчы. Ни итсә итәргә, кар әлегә бик тирән түгел, япан кыр өстенә булса да төшереп утыртырга тиеш ул үзенең самолетын. Шундый уйлар белән тигезрәк урын эзли башлады. Үч иткән кебек, каршысында ниндидер авыл барлыкка килде шунда. Самолет идарә ителми, ул ямьсез гүелдәп туп-туры шул авылга таба төшә. Әнә колхоз фермалары... Арырак мәктәп булырга ошаган, икенче сменага йөргән балалар укуда булырга тиеш әле. Биеклекне ничек тә озаккарак житкерергә, самолетны читкәрәк алып китәргә иде бит. Мәктәпне һәм бу авылны узып китәргә кирәк. Ә штурвал тыңламый—унга да хәрәкәт итми, сулга да... Бар көче белән үзенә буйсынмаган рычагларны тартырга керешге ул. Самолет беразга үзенә буйсынган да кебек булып алды тагы, ничек итсә итте—авыл артта калды. Әмма жир бик якын, жир артка йөгерә, чайкала, зыр әйләнә. Жир түгел, самолет әйләнә түгелме... Самолет, әлбәттә. Баш очында, чигәдә фикер артыннан фикер йөгерә. Бер мизгел эчендә чиләк-көянтә асып судан кайтып килгән әнкәсен күз алдына китереп алды ул. Гүзәлне бишектә тибрәтеп йоклатучы сөекле хатыны Ленаны. Аның белән әле кичә генә ничек матур итеп вальс әйләнде бит алар...Онытылмаслык булды ул кичә...

Тукта, кем кычкыра анда? Самолетның ачы гүелдәү авазын җиңеп кем тавышы ишетелә. "Әти, әти-е-ем, син кайда... Минем бит сине бик тә, бик тә күрәсем килә..." Кем ул шулай ачыргаланып кычкыра?.. Чү, бу аның әле тумаган, әмма туачак улының тавышы түгелме соң?!.

Жир белән күк кушылды шунда... Авыр гөрселдәү авазы ишетелде. Авыл читендәге карт тирәкләргә кунаклаган кошлар—карга-чәүкәләр иде булса кирәк, куркуларыннан, дәррәү һавага күтәрелде һәм урманга таба очып киттеләр. Бар галәм тынып калды кинәт.

Офыклар аръягыннан тонык кына булып ишетелгән бу авазны тоеп, бишек янында кызын йоклатып утырган Лена сискәнеп куйды шунда. "Ни булды икән тагы!" Шул мизгелдә йөрәге ярылгандай булды, тумаган баласы тынгысызланып, тибенергә керешге. Хафаланып, стенадагы сәгатькә күз салып алды ул. Көндезге бер тулып унбиш минут киткән иде...

Бу коточкыч һәлакәтне, басудан ат чанасына салам төяп авылга кайтып килгән бер терлекче күреп калган булып чыкты шулай да. Аның сүзләре дөрес булса, самолет япан кыр өстенә төшеп шартлагач та, көчле гөрселдәү авазы һәм ут-ялкын эченнән ниндидер гаҗәеп бер кош уктай атылып чыккан. Һәм күз ачып йомган арада бик тә югары күтәрелеп, канатларын җилпи-җилпи, каядыр еракка, кыйбла тарафларына очып киткән диләр...

*2006 ел, октябрь—2007 ел, май.*
*Мәскәү—Казан.*

**Редакциядән:**

***Язучы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Мөхәммәдиевка 60 яшь тулды. Каләмдәшебезне юбилее белән котлап, аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.***



Ленар
Шәех

# ДӨНЬЯ ХОЗУРЫНДА

* * *

Эсселе-суыклы
яңгыр тамчылары.
Бүген тагын тышта
яңгыр тамчылады...
Тамчыламады ла,
талгын гына койды..
Болыт бөртекләре
күңелемә сыйды.

Бер эсселәп алдым,
җаннан суык үтте.
Эсселе-суыклык
бәгыремне өтте...

Өтмәде лә инде,
әкрен генә телде,
Сагыш үзәненә
боз тамчысы элде.

Гамьсез-ямьсез калдым,
бар моңнарым туңган.
Гүя бөтен күңел
суык белән тулган...
...Кышны кискән сулыш—
сөю көчлелеге,
Йөрәк тибешемнең
вулкан эсселеге.

* * *

Керләнгән күңелне
Пакьләргә теләпме,
Акларга теләпме
Битараф йөрәкне...—
Кар ява ничә көн,
Кар ява—атналар...
Гөнаһсыз дәверләр
Кар булып кайталар.

Тутыккан кылларга
Чиртергә теләпме,
Җандагы төерне
Тамакка терәпме...—

Кар ява ничә көн,
Кар ява—атналар...
Илаһи көн җирдә,
Илаһи тантана!..

Таш бәгырь өстенә
Әфсеннәр көйләпме,
Ап-ак кар йөрәктә
Ак ялкын көйрәтте...
Үткәннән иң сафә
Мизгелләр кайталар..
Кар ява ничә көн,
Кар ява—атналар...

Ленар ШӘЕХ (1982) – *шагыйрь; "Авылдан килгән мендәр", "Керпе ничек энәле булган?", "Дүртенче кат... Бишенче кат..." исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Казан—Әстерхан поезды

Казан—Әстерхан поезды
ашыга, чаба,
ашыгудан, ашкынудан,
ашалган рельсларга
гүя ут каба.
Оча поезд азат бөркет сыман,
тирә-якта урман әле, урман...
Казан салкын иде, ерак Әстерханда
эссе чиллә, диде кемнәрдер,
ул кешеләр ачык белгәндер лә—
Казан гына суык нигәдер...

Казан—Әстерхан поезды
йөгерә генә,
кан тамыры кук рельслардан
бара-бара уйга тала,
ул ачык белә:
Ата-баба җире буйлап чаба,
артта боек Сарытаулар кала...
Ә күңелдә курку-мазар тамчы да юк,
соң, туганнар, безнең җирләр бу,
борынгылар безгә васыять иткән,
без югалткан гүзәл илләр бу!..

...Казан—Әстерхан арасы—
татар яшәгән урын.
Колак кактык бу байлыктан,
без кулга алмас борын.

Җир безнеке, ә кануннар
безнеке түгел инде.
Азат еллар, көлгә әйләнеп,
кара туфракка сеңде.

Куе урман, киң далалар...
Иделкәй, Каспий диңгез...
Без нишләр идек синсез?..

Казан—Әстерхан поезды
йөгерә генә...
Ярый әле рельслар бар,
үткән салган рельслар бар,
юаныйчтай куна бәхет
кайгы бөдрәсенә...

## Айның яктысында

Болыт арасыннан,
Төннең карасыннан
Уйчан гына гүзәл ай чыга.

Дөнья хозурында,
Айның пакь нурында
Күңел белән йөзәр җай чыга.

Айның яктысында,
Еллар чаткысында
Утырам мин күккә күз салып.

Аем балкый көлеп,
Салкын җылы өреп,
Кара төнгә кайнар эз салып.

Башта айга карыйм,
Аннан йолдыз саныйм,
Үзем белән үзем сөйләшеп.

Ә ай уйчан гына,
Бик оялчан гына
Күктә йөри нурын өләшеп.

## Сагыну җыры

Утлы сөю хисләремне
Көмеш җептәй сапладым.
Ак болытка хатлар яздым,
Акты-китте хатларым.

Ай яктысын карам итеп,
Сиңа шигырь юлладым.
Аем гына качты-китте,
Таң атарга—бер адым.

Кояш нурларына төреп,
Сиңа сәлам җибәрдем.
Ул офыкка батты-китте,
Йөзгә төнге җил бәрде.

...Җил артыннан хатлар яздым,
Очты-китте хатларым...
Иң-иң кайнар хисләремне
Көрешүгә сакладым...

## Су ташый кыз...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Көянтә, чиләкләре...
Көянтәсен кочып алган
Ак шома беләкләре...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Офыкка карый-карый...
Толымлап үргән чәчләрен
Яз җиле генә тарый...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Сусавын басмакчымы?..
Юлына сөйгәне чыкса,
Йөрәген ачмакчымы?..

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Эх, чишмә булсаң икән!..
Пар чиләкнең ирнәвеннән
Су белән тулсаң икән!..

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Тамчыдай адымнары...
Мөлдерәмә күзләрендә
Саф чишмә чалымнары...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Иренендә чык суы...
Юлына сөйгәне чыкса,
Кузгалыр җан ярсуы...

* * *

Яфраклар яшел икән.
Күңелендә йөргән серне
Җаныңа яшер икән.

Яфраклар яшел икән...
Тирән серең берәр вакыт
Бәхетме чәчер икән?..

Яфраклар яшел икән.
Күк йөзендә ялт-йолт килә
Аҗаган, яшен микән?

Яфраклар яшел икән...
Сөйгән ярыңның җанына
Сереңне яшер икән!..

Яфраклар яшел икән.
Җаныңның кап уртасыннан
Берәрсе дәшер микән?



Лилия
Гыйбадуллина

# ХӘТЕРЛИМ, ХӘТЕРЛИМ...

* * *

**Кырыйдан карадым, кырыйлап карадым—**
**Кыргыйлык үземдә, үзәктә...**
**Үз итә алсам да, кадерли калсам да,**
**Алалмам үзгәртә...**

**Җанкаем,**
**Җай гына таң җиле искәндә**
**Җәй генә уяна дисеңме?..**
**Үзәктән үзәккә өзлексез үрелеп,**
**Уяна—шул Хиснең исеме...**

**Тантана!**
**Бөек Ау вакыты башлана!**
**Исерек иләслек ят аңа...**
**Сунарчы җаннарда сүрелгән кыргыйлык**
**Кайрылып уяна һәр таңда...**

* * *

**Чиксезлек турында пышылдап,**
**Урамнар ураган**
**Җил генә.**
**Читләтеп чигелгән чакларым—**
**Чиксезлек чигенә...**
**Үзәккә үтәрлек үгилек.**
**Тартылам, тайпылам, талпынам...**
**Җил дә юк, ил дә юк, МИН дә юк...**
**Тын урам.**

* * *

**Хәнҗәрләр хәтере—хакыйкать.**
**Хак кушкан хаклык бар,**
**Хаклык бер!..**

**Кан исе, җан исе, көч хисе буталып,**
**Чорларны укшытыр барыбер...**

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА—*яшь шагыйрә, "Мин бәхетне күрәм!" исемле китап авторы. Казанда яши.*

Кадерле кан бит ул, каберсез җан бит ул,
Хис бит ул—кыргыйлык, затлылык...
Бербөтен дәвамның бөтен бер өлеше—
Яшәргә, яшәргә хаклылык.

Бу—тәүге һәм соңгы хакыйкать,
Хак кушкан хаклык бу, бердәнбер...
Изге кан игез җан юлыннан
Хәнҗәрләр йөзендә йөргәндер...

Кындагы хәнҗәргә каныккан
Карлыккан тавышлы хәтерме—
Каннарда кайтаваз котыра:
"Хәтерлим! Хәтерлим!!!"

Хәтер Мин...

* * *

Барлы-юклы дөнья киңлегендә
Киерелеп очкан киек кош син.
Исемеңне күкләр белә булыр...
Ә дөньялык бүген син ишесен
Киеменә карап каршы ала.
Килгәннәргә монда шундый кадер:
Киңлекләрне кисемтәләп кисү
Сабыйлыктан карыйлыкка кадәр...

Диварларда диваналар елъязмасы,
Акшарланган күкләр—түшәм бүген.
Тынлык сыймас тарлык...
Яңа тарих. Яңа исем туар дүшәмбедән.

Ул исемне күкләр күкрәп кушар—
Яңа исем синең киемеңә...

Киерелеп очкан киек кош без
Барлы-юклы дөнья киңлегендә...

* * *

Минсезлек.
Мин—минсез калада.
Карлыгач очышы көнозын.
Табынсаң—тайпылма,
Талпынма...
"Бәхетең булсын ла, и кызым..."

Күзләрең төннәрдән карарак,
Кашларың—карлыгач канаты.
Яшәрсең йөрәгең канатып,
Уйларың еракка җан атыр,
Карлыгач очышын күзәтсәң...

Сүз әйтмәм,
Сүз әйтмәм, үзгәртмәм
Талпынып син карап калганда.
...Карлыгач очышы көнозын.
Минсезлек.
Мин—минсез калада...

Нурихан
Фәттах

# БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬ КҮК БАЛАЧАК...

ИСТӘЛЕКЛӘР

## 17. Ысбирлаудан кайтканда

Бер-ике ел үткәч, сату-алуга бәйле тагын бер вакыйга булды. Ул елны мин унны бетердем. Имтиханнар тапшырылган, барысы да “бишле”. Мәктәп директоры миңа алтын медаль алып кайту өчен Уфага китте. Күңел күтәренке. Очынып кына йөрим.

Беркөнне ничектер Рәшидәне очраттым. Ул да минем белән унны бетерде. Без аның белән дус кына. Тормышлары авыр. Яңавылның җобанай ягында үз йортлары белән тора. Әтисе юк. Инәсе дә тагын кемнәредер белән тора. Инәсе базарда сату-алу белән дә шөгыльләнә бугай. Ул елларда Яңавылда сату-алу белән шөгыльләнмәгән кеше булмагандыр да, мөгаен. Ачтан үлмәс өчен берәүләр ничектер юнәтеп станциядә узып баручы солдатларга, пассажирларга бәрәңге кәлҗемәсе, икенче берәүләр кәгазь калынлыгы көлчә саталар. Юк кына нәрсәне дә кеше акчага, ахыр чиктә үзе өчен азыкка әйләндерергә тырыша. Аларны гадәттә “эспикүлән” дип атыйлар. Алар арасында чын эспикүләне күпме булгандыр, әйтеп булмый. Вак-төякне авыш-түеш китереп, төн йокыларын калдырып тамак артыннан куган андый эспикүләннәр белән чагыштырып булмас дәрәҗәдәге ата спекулянтлар да аз булмады ул елларда. Андыйлар базар, станция таптамады. Андыйлар жылы, дәрәҗәле урыннарда утырдылар.

Очрашкач, Рәшидә әйтә, әйдә Ысбирлауга карагат алып барабыз, ди. Карагат, ягъни, китапча, карлыган. Хәзер карагат вакыты. Бездә аннан күп жимеш тә юк. Базар тулы кара карагат, кызыл карагат. Мин риза булдым. Шундук жыена да башладык.

Сарапулга караганда Ысбирлау әллә кайда. Яңавылдан дүрт йөз кырык чакрым чамасы бугай. Сарапулга барган кебек, анда көнен генә барып кайтып булмый. Бару өчен кимендә уникe-унөч сәгать китә. Кайтырга тагын шулай. Минем әле анда кадәр барганым юк. Шулай да бер китеп бара яздым.

Янавыл читендә, Буә ягында, тигез жирдә колхоз фермасы сыман каралтылар бар. Аны “Заготскот” дип йөртәләр. Авыллардан, күрше районнардан дәүләткә тапшырылган аяклы малны шунда куып киләләр дә, төрле ит комбинатларына озаталар. Тапшырылган малны гадәттә вагоннарга төяп озаталар. Озатырга тиешләр, ләкин вагоннар булмаганлыктан көтүкөтү малны бик ерак шәһәрләргә куалап алып баралар. Янавылдан малны

*Дәвамы. Башы 10 санда.*

Ысбирлауга да жибәрәләр. Ләкин анда алар вагонда бара. Вагоннарда мал карап бару өчен "Заготскот"ка кеше кирәк икән. Бардым, белештем. "Алабыз", диделәр. Тик вагон килгәнче көтүгә чыгарга куштылар. Мин монда сарык, сыер гынадыр дип уйлаган идем. Мине дуңгыз көтәргә куштылар. Иртә таңнан алып кичкә кадәр йөрдем. Ашау-эчү юк. Ачлыктан күзләр эчкә батты, аяк атлар хәл калмады. Кич бер кило эпи үлчәп бирделәр. Үземә тиешле эпине куенга кыстырдым да, кайтып киттем. Икенче көнне бармадым. Шакшы дуңгыз булгач, инәкәйнен дә жибәрәсе килмәде. Шулай итеп, ул чакта Ысбирлауны күреп булмады.

Бу юлы эш пешәргә тиеш. Рәшидәнен барганы бар. Ул юлны белә. Шулай, Янавылда очсызга гына күп итеп карагат алабыз, Ысбирлауда ике-өч бәягә сатабыз! Анда карагатның күпме торганын без, билгеле, белмибез. Белмәсәк тә ис китмәгән—анда һәрвакыт кыйбат була. Ул як—ач як. Иткә, майга, онга эшчеләре үзләре килә. Сатулашып та тормыйлар, бәрәләр дә алалар. Эшчедә акча күп. Акча ул бездә генә юк. Шулай да минем Казанга укырга китсәм дип бик тырышып жыйган күпмедер акчам бар. Шул акчага стаканын унбишәр сумнан күпмедер карагат алдым. Күп булды, авыр булды ул карагат. Фанер чемодан тулды. Чемоданны бау белән уратып бәйләдем дә, сөйләшенгән вакытка, сөйләшенгән поездга станциягә төштем.

Киттек без ничектер эләгеп. Билет-мазар алу юк. Кассага якын барырлык түгел. Без анда бармыйбыз да. Билет өчен акча да түләргә кирәк бит әле. Вагонның арткы ягына чыгабыз да баскычка сикереп менәбез. Аннан соң ике вагон арасына кереп басасың, йә булмаса баскычтан түбәгә үк менеп китәсең. Ул вакыттагы пассажир вагоннары хәзерге кебек түгел иде. Вагоннарның һәр ике башында, ике якта тышка чыгып торган баскычы, баскычның ике ягында тоткасы була. Вагон аралары ачык, вагон башларында түбәгә менү өчен озын гына баскыч бар. Һәр вагонның өстендә бак сыман ниндидер тартмасы бар. Капчыгыңны, чемоданыңны өстерәп менә шунда менеп китәсең дә, бик уңайлы бак өстенә менеп утырасың. Әгәр бак өсте буш булса, билгеле. Анда жил дә артык көчле түгел, утырып карап баруы да күңелле. Кайчагында түбә өстенә үк үрмәлисең. Түбәдән кыска гына булып вентиляция торбалары чыгып тора. Вагон түбәсендә йөгереп йөрергә, биеп барырга, ятып йокларга була. Тик шунысы яман—түбә өсте идән кебек тигез түгел,—дугасыман уртадан кабарып тора. Кызу барганда вагонны бик каты селкетә, як-якка чайкалдыра. Алай-болай яңгырява башласа, түбә юешләнсә, бетте—жинел генә түбәдән шуып төшеп калуыңны көт тә тор. Түбәдә баруның тагын бер кыен ягы бар—Янавылдан Ысбирлауга житкәнче поезд күпмедер туннельләр, күперләр аша уза. Күпернең өсте тимер челтәрле. Туннельнең дә биеклеге фәлән метр гына. Түбәдә барганда онытылып аягүрә бассаң, эш харап. Безнең якта андый хәлләр булгалый. Үз күзем белән күргәнем бар: Янавылда туктаган бер поездлан маңгае бәрелеп тишелгән бер жегетне алып төштеләр. Вагон түбәсендә барган булган. Зәңгәр майкалы, аксыл чәчле. Чәчен жил селкетә, маңгае канга баткан.

Билгеле инде, пассажир булган кеше түбәдә түгел, вагон эчендә утырып барырга тиеш. Анда жылырак, куркынычсызрак. Ләкин анда усал проводник, аннан да усалрак билет тикшерүче була. Вагонга керергә ниятләсәң, ничектер менә шулар күзенә күренмәскә кирәк. Моның өчен бераз жир тышта—баскычта барасың да, вагон эчендәге ыгы-зыгы басылгач, шыпырт кына тамбурга керәсең, тамбурдан вагон эченә үтеп китәсең. Кайчагында проводник ишекләрне эчтән бикләп куя. Ләкин без аннан гына курыкмыйбыз. Бездә ачкыч бар. Аны тимерчедән, слесарьдан ясатып аласың. Ачабыз да керәбез. Кайчагында вагон эчендә утырып барырлык

кына буш урын була. Тиз генә шуңа барып утырасың да, түземсезлек белән тикшерүче килгәнне көтә башлыйсың. Өстә, беренче кат сәндерәдә буш урын булса, анысы инде тагын да яхшырак. Менеп ятасың да, үз станцияңә житкәнче йоклыйсың ләззәтләнеп. Кайчагында контролер күрми дә узып китә яисә күрмәмешкә салына. Проводник күрсә, тиргәшә, шулай да сине кызу барган поездан беркем төшереп калдырмый.

Кичтән утырып киттек тә, икенче көнне иртән барып та төштек без Ысбирлауга. Авыр чемоданны көчкә күтәреп ниндидер трамвайга утырдык та "Уралмаш" дигән якка киттек. Иң яхшы базар шунда имеш. Йортлар биек, урамда асфальт. Шау-шу. Машиналар, трамвайлар. Бу инде сиңа Сарапул гына түгел. Базарлары да шәп. Сатучылар әйберләрен куеп сатсын өчен такта өстәлләр ясалган. Яңгыр тимәсен өчен баш өстендә түба, халкы да күп. Адым саен татар очрый. Очрамыйча, безнең якның ярты халкы шушында лабаса.

Базарда бушрак урын сайлап алдык та, чемоданнарны ачып җибәрдек тә, шаулатып сату эшенә тотындык, тотындык дип... Карагатка кытлык юк икән. Каяндыр китереп тутырганнар. Аларныкы эрерәк тә, әйбәтрәк тә. Безнеке... поездда анда-монда бәргәләнеп килә-килә, бөтен карагат изелеп беткән. Стаканына егерме-егерме биш тәнкә сорап караган идек—борылып караучы да юк. Шуннан башкаларның күпмегә сатуына колак сала башладык. Баксаң, унбиштән артыкка сатучы да юк икән! Карагатны кичкә кадәр базар беткәнче, көч-хәл белән сатып җибәрдек. Стаканын унбиштән, ундүрттән. Җиңеләеп калган чемоданнарны күтәрдек тә вокзалга киттек. Ул арада карангы төште. Тәртип монда катырак. Адым саен дигәндәй милиционер тора. Билетсыз кешеләрне перронга да кертмиләр. Ничек итсәк иттек, перронга кердек тә Янавыл ягына бара торган ниндидер поездга эләктек тә, киттек кайтып.

Бу юлы вагон эченә кереп булмады. Кая карама—безнең ише билетсыз ярлы-ябагай. Түбәгә үрмәләргә туры килде. Ләкин анда да кеше дә кеше. Кайсы утырып бара, кайсы ятып бара. Без да шунда буш урын таптык та, вентиляция торбасы янына бөгәрләнеп яттык. Буш чемоданны баш астына куйдым.

Урал ягында җәй көне дә төннәр бик салкын була. Бернича мәртәбә төнге суыкка түзә алмыйча уянып-уянып киттем. Уянгач, күзне ачып әле анда, әле монда каранам. Тирә-якта текә таулар, күлләр, яшькелт арыш басулары күренеп кала. Бездә инде күптән уракка төштеләр. Аннары шул: төне буе вагон түбәсендә дөбер-шатыр кемнәрдер ары-бире чабып йөрде. Ничек курыкмыйлар икән вагон түбәсендә йөгереп йөрергә? Йокы аралаш шул турыда уйланып, борчылып яттым.

Күпмедер вакыттан соң түбә өстендә чабып йөрү тынып калды. Бары тик вагон як-якка селкенә дә паровоз кычкырып-кычкырып куя һәм, яңгыр кебек күмер тузаны коеп, туктаусыз алга ыргыла. Борылышларда нәрсәдер бик каты шыгырдый. Аның ачы тавышыннан йокылар ачылып китә. Шул ук вакытта вагон түбәсе бик каты янтая. Үзеңнен аска таба ычкына башлавыңны тоеп, шундук вентиляция торбасына тотынасың, урыныннан шуышкан чемоданнарыңны рәтләп куясың.

Менә без куркыныч туннельләрне дә уздык, Чернушканы да уздык. Янавылга якыная башладык. Көн яктырган. Кояш чыгып килә. Шул чакны чемоданга күз төште. Нишләптер капкачы ачылган, бәргәләнеп бара. Туктале, нишләп соң аның аркылы бавы ... өзелгәнме, киселгәнме дигәндәй? Әйе, киселгән. Кискәннәр! Нидер сизенеп, мин шундук куен кесәсенә тыгылдым. Кесә буш. Җилләр искән!

Акчаны алдырып кайткан өчен инәкәй ачуланмады, сөенде генә. "Ярый әле үзең исән калгансың, шунысына шөкер",—диде. Шөкер булмыйча!

## 18. Мулла җиңгәй

Ул елларда сату-алуга кагылышлы тагын бер вакыйга булды. Утыз тугыздамы, кырыктамы, беренче мәртәбә бездә күп балалы аналарга дәүләт акчалата ярдәм итә башлады. Вәрәш очындагы Фәритләрнең жиде балалары бар иде. Аларга күпмедер акча килде. Авыл халкының, күрше-күләннең исе китте. Күктән төшкән акчага Фәритнең әтәсе-инәсе балаларына кием-салым алдылар. Монарчы өсләреннән сәләмә төшмәгән балалар—Фәритнең туганнары өр-яңадан киенделәр. Буй житкән олы кызлары Вәсимәнең чәчләрен көдрәләтеп, киенеп-ясанып, көязләнеп йөрүе истә калган.

Шулай куанып кына яшәп ятканда боларга көтмәгәндә кара кайгы килде, ни сәбәптәндер, аналары үлеп китте. Жиде бала өелешеп ятим калды. Күпмедер вакыттан соң Фәритнең әтәсе Вайжады авылыннан жиде балага яңа инә алып кайтты. Яңа инә ире үлгән тол хатын була. Бу хатын Фәритнең үлгән инәсенә туган тиешле икән. Алай гына да түгел, Фәритнең яңа инәсе кайсыдыр ягы белән безнекеләргә дә туган имеш. Дөресрәге, ул безнекеләргә килен булган, ахрысы. Яшәби дә, инәкәй белән апа да аны "мулла жиңгәй" дип йөртәләр. Чын исеме хәтердә калмаган. Мулла жиңгәйнең Вайжадыдагы үлгән ире "шәкерт абзый" булган. Шәкерт абзый исә "әбзәбинең" улы була. Әбзәби кем дигәндә, абзәби ул инәкәйнең инәсенең бертуган апасымы, сеңлесеме. Шәкерт абзый, шулай итеп, яшәбиләрнең, инәкәйләрнең туганнан туган агалары булып чыга.

Әбзәби элек безгә бик еш килә торган иде. Ул, ахрысы, Вайжады мулласының хатыны булган. Шуңа күрә безнекеләр аны әбзәби дип йөрткәннәр дә. Илнең асты-өскә килеп байларга, муллаларга көн беткәч, безнең Вайжады әбзәбиләрне дә пыр туздыралар. Төгәлен генә әйтә алмыйм, әбзәбинең ирен нишләткәннәрдер—сөрделәр микән, үз үлеме белән үлде микән. Әбзәбинең ул "шәкерт абзый" үз үлеме белән үлгән. Берзаман өйдә килен белән әбзәби генә торып кала. "Мулла жиңгәй" муллаларга карата мөнәсәбәтнең ничегрәк булганын бик яхшы күреп тора һәм көннәрдән бер көнне, кайнанасын өеннән куалап чыгара да, булган бар байлыкны үзенә ала. Инәкәйләр әледән-әле пышылдап, шомланып, кайгырышып сөйләнәләр иде: кыш көннәрендә әбзәби ялан аяк, ялан өс дигәндәй кешедән кешегә кереп туенып йөргән. Шундый кыен чакларында безгә дә килеп чыккан. Бездә ул озак кына торып киткәли торган иде. Безгә аның бернинди зыяны тигәнен хәтерләмим. Бик ягымлы, хәтта әдәпле һәм укымышлы бер карчык иде ул. Ике сүзнең берендә "бәбкәйләрем" дияр, көйләп кенә сөйләнер. Нишләптер аның шул еш кабатланган "бәбкәйләрем"е ачуны китерә торган иде. Хәреф танырга инәкәй менә шул әбзәбидән өйрәнгән. Вайжадыда Әбзәби "бәбкаләренә"—кыз балаларга сабак укыткан. Гомеренең ахырын менә шулай хурлыклы уздыра. Безнекеләрнең әйтүләренә караганда, әбзәби акылдан шашып үлә.

Көтмәгәндә безнең авылга, безнең очка "мулла жиңгәй" килен булып төшкәч, безнекеләр ничектер йомылыбрак калдылар. Алар, билгеле, яңа киленне яратмаганнар. Ярата алмаганнар. Үзара сөйләшкәндә элеккечә "мулла жиңгәй" дисәләр дә, бик ачулары килгәндә "корткыч" кебек сүзләр күбрәк кулланыла башлады. Корткыч мулла жиңгәй Вәрәш очка килен булып төшкәч, Фәритләрнең хуҗалыгын тулысынча үз кулына ала. Ул арада сугыш чыга. Фәритнең әтәсе сугышка китә дә, озакламый юк та була, ахрысы.

Атасыз-анасыз җиде бала тулысынча "мулла җингәй" кулында торып кала. "Мулла җингәй"нең артыннан килгән бер кызы белән бер малае да була. Малае Рәүф—безнең чама. Бер-ике яшькә бездән кечерәк бугай.

Сугыш елларында беркемгә дә күнелле булмады. Үги ана кулында калган җиде балага аеруча кыен булгандыр. Без моны күреп-белеп, ишетеп тордык. Корткыч мулла җингәй кансыз, шәфкатьсез һәм бозык күнелле бер хатын булып чыга. Үзенеке булмаган балаларны ул күрәләтә кыерсыта башлый. Олырак балалар өйләрен ташлап читкә китәләр. Кайчандыр чәчләрен көдрәләтеп, көязләнеп йөргән, без кызыгып тәрәзәдән карап калган Вәсимә кемнәргәдер ияреп Ысбирлауга китеп бара, шул якта торф чыгара торган җиргә эшкә урнаша. Соңыннан әкренләп ул үзенең энеләрен, сеңелләрен дә үз янына алдыра. Ләкин аларның барысын да алдырып бетерә алмый. Монда тагын берничә вак-төяк—Насир, Әлтәф, Нәфисә кала. Безнең яшьтәш Фәрит ул елларда ФЗО да була.

Сабыйлыктан чыгып та җитмәгән балаларны үги ана ачка интектерә, кыйный һәм төрлечә мыскыл итә. Ин яманы шул, корткыч мулла җингәй балаларны... урлашырга мәҗбүр итә. Балалар төннәрен колхоз басуына да барып чыгалар, күршеләрнең бакчасына да, тавык кетәгенә дә керәләр.

Сугышнын беренче елларында авыл халкы тук булды дисәм, ялгыш булмас. Сугышка кадәр колхозда ашлык бик нык унды. Хезмәт көненә колхозчылар күп алдылар. Безнең лар тулы арышы, бодае, фәләне булды. Әле дә хәтердә—чоланнын яртысын лар алып тора. Аны шулай ук бура да диләр. Киңлеге бер метр ярым чамасы, биеклеге шулай ук, озынлыгы кимендә өч-дүрт метр. Аңа бик күп ашлык керә. Ларның өсте капланмаган. Чолан астынын бүрәнәсе юк. Анда түше белән шуышып теләсә нинди бала-чага керә ала. Мулла җингәй Әлтәфне менә шунда—безнең чолан астына, дөресрәге, безнең лар астына ашлык урларга җибәрә торган булган. Әлтәф башта безнең лар-чолан идәнен астан борау белән тишкән. Тишек турысына капчыгын җайлап куя икән дә, соныннан тишекне томалап, үзе күтәрә алганча ашлык урлап алып китә икән. Сугыштан соң бик күп еллар үткәч, Әлтәф үзе сөйләгән.

Үсә төшкәч, Әлтәф тә, Насир, Нәфисә дә Вәсимә апалары янына китеп баралар. Бәлки аларны үги ана мәҗбүр иткәндер. Ни генә булмасын, өйдә мулла җингәй һәм анын балалары тулы хуҗа булып калды.

Корткыч "мулла җингәй"нең үз улы Рәүф караклык мәсьәләсендә һич тә инәсеннән калыша торган түгел. Анын бөтен таланты шул караклык булды дисән, "талант" сүзен мыскыл итү булыр иде. Теләсә кайда, теләсә нинди эштә бары үз файдасын гына карый торган, теләсә нәрсәне чәлдерергә, үзләштерергә, яшереп калдырырга тырыша торган ягымсыз, шөкәтсез бер бәндә иде ул. Кыска буйлы, кәкре аяклы, чирмеш кыяфәтле авылдашны мин Янавылда укып йөргән елларда да, Казанда укыганда да әледән-әле күргәләп, читтән генә исәнме-саумы дип йөрдем. Малай чакта бергә уйнап үссәк тә, ничектер аңа якын барасы, сөйләшәсе килмәде.

Мин Казанда икенчеме, өченчеме курста укыганда, бер елны бу мина ияреп Казанга барырга теләк белдерде. Сатарга чикләвек алып бармакчы икән. Мин риза булдым. Киттек без икәүләшеп Казанга. Икебез дә капчыклар күтәргәнбез. Ул чикләвек алып бара, мин азык-төлек. Килеп төштек Казанга. Рәүфне мин туп-туры үзебезнен студентлар торагына алып киттем. Булдыра алганча кунак иттем. Икәү бер караватта ятып йокладык та, икенче көнне базарга киттек. Казаннын "Победа" кинотеатры урынында элек базар бар иде. Рәүфне шунда калдырдым да, үзем университетка китеп бардым.

Рәүфне озатып җибәргәнемне хәтерләмим. Озата алмаганмындыр, чөнки студентның беркайчан буш вакыты булмый. Авылдан без гадәттә иртәгә уку башлана дигән көнне генә килеп җитәбез. Күрәсең, ул елны да килү белән укырга йөри башлаганмындыр.

Кышкы каникулга кайткач, авылда мине шаккатыргыч хәбәр белән каршы алдылар. Рәүф, имеш, өйләренә акчасыз кайтып кергән. "Чикләвек саткан акчаң кая?" дигәч, "Нурихан талап алып калды",—дигән. Мондый хәбәргә көлеп куйдым. Инәкәй дә, яшәби дә ничек-ничек булганын кат-кат сөйли торгач, ачу килде. Рәүф Казаннан кайтып төшкәч, мулла җиңгәй безгә килеп яшәбине, инәкәйне тиргәп йөргән. "Сезнең Нуриханыгыз карак, ятим баланың акчасын талап алган",—дип кычкырына икән. Нишләсеннәр безнекеләр, аптырап калганнар.

Шунысы кызык, мин үзем авылга кайткач, минем янга килеп беркем дәгъвалашеп йөрмәде. Күрәсең, мин юклыктан файдаланып, "мулла җиңгәй" безнекеләрдән җиңел генә "таланган" акчаны каермакчы булгандыр инде. Акча ул менә нишләтә кешене, дип шушында нокта да куярга булыр иде. Ләкин акча һәм урлашу җене кагылган бу бәндәләрнең язмышы турында бер-ике сүз әйтми булмый.

Без югында, безнең яшьтәшләр югында Рәүф бригадир дәрәҗәсенә күтәрелә. Авылга клубка дип читтән бүрәнә ташыта, бура бурата. Кем беләндер килешеп, әлеге бураны үзенеке иттерә. Иң ахырда авылдагы берәүгә сатып җибәрә дә, Фәритләрнең йортын, хуҗалыгын сатып болар Әмҗе спирт заводына күченеп китәләр. Анда йорт сатып алалар. Рәүф спирт заводына эшкә керә һәм, әлбәттә, караклык белән шөгыльләнә башлый. Анысы гына җитмәгән, ниндидер чегәннәр белән бәйләнешкә кереп, урланган ат суеп сату эшенә керешә. Моны тоталар. Өенә тентү керә. Качып барганда лапас кыегыннан егылып, умырткалыгын имгәтә, больниска керә. Бөтен гомере кыек юлда үткән бу бәндәнең ахыры да ямьсез тәмамлана. Мондый эшләргә аны һәрвакыт үз анасы "мулла җиңгәй" рухландырган була. Тентү вакытында "мулла җиңгәй"нең баш астындагы мендәре эченнән, исәр әйтмешләй, әллә кырык мең, әллә илле мең акча табалар. Бар акчаны, шулай итеп, "мулла җиңгәй" үзе җыеп яткан була.

Тагын шунысы да бар икән әле: менә шул мендәр эчендәге, баш астындагы акча өчен ана белән улы арасында бик каты талаш булып ала. Бу вакытта инде ана улын түгел, улы... анасын кыйный, кулын каерып имгәтә.

## 19. Аерылу

Янтыкта "Очкын" колхозында инәкәй күп эшләмәде. Мин өченчене бетереп дүрткә күчкән елны Яңавылга китеп барды. Авылдан китүнең сәбәбен соңыннан болай аңлатты. Ашлык сукканда инәкәй барабанга көлтә биреп торган. Шул чагында ялгышып бер көлтәне төп ягы белән биргән. Барабанчы аның хатасын төзәтеп тормый, ачу белән көлтәне кире бәрә. Көлтә инәкәйнең үзенә килеп тия. Аңа утыз дүрт, утыз биш яшь чамасы була. Яшь хатын, тол хатын мондый тупаслыкка бик хурлана. Эшен ташлый да җылый-җылый кайтып китә.

Гомер буена ул шушы вакыйганы исенә төшерде һәм бик нык рәнҗеп:

"көлтәне йөземә бәрде", дия иде.

Шушы хәлдән соң, киңәш сорап, авылдагы иң хөрмәтле кешеләрнең берсе—укытучы Садыйков абый янына бара. Садыйков абый күптәнге,

тәҗрибәле мөгаллим, укытучы. Шул елларда аны Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләделәр. Әле дә хәтеремдә, Садыйков абыйны орден белән бүләкләү турындагы карар чыккач, мәктәптә зур җыелыш булды. Садыйков абый безгә нидер сөйләде. Ул сөйләп бетергәч, мин, бик нык оялып, кызарынып: "Орденыгызны күрсәтегез әле, Садыйков абый", дидем. Бөтенесе миннән шаулатып көләргә тотынды. Ни өчен көлгәннәрен ул чакта бик озак аңлый алмадым.

Садыйков абый инәкәйгә Яңавылга, татар урта мәктәбенә барып карарга киңәш итә, анда кем белән ничек сөйләшергә кирәклеген өйрәтә. Шуннан соң инәкәй җиена да китә Яңавылга. Шундук аны мәктәпкә эшкә алалар. Кем итеп? Укытучы итеп түгел инде, идән җиештыручы итеп. Хәзер генә түгел, ул вакытта да идән җиештыручыларга кытлык булгандыр, күрәсең.

Шулай итеп, безнең инәкәй пролетариатка әйләнә. Хәер, идән себерүчеләр "пролетариат" дип аталмый бугай. Пролетариат булудан бигрәк ул люмпен пролетари булды. Идән җиештырган өчен аңа башта күпме түләгәннәрдер, әйтә алмыйм. Берничә елдан соң сиксән чамасы алганын хәтерлим. Ул чактагы сиксән сум бүгенге көннең сиксән тиененә торгандыр кебек.

Яңа гына салынган озын, биек, иркен мәктәп бинасының бер башында директор өчен дип билгеләнгән ике бүлмәле квартир була. Ике бүлмәнең дә ишекләре кухняга, кухняның бер ишеге ишегалга, икенче ишеге мәктәп коридорына чыга. Кухняда зур гына мич.

Безнең инәкәйгә кухняда бер почмак бирәләр. Чын мәгънәсендә почмак. Караватт куяр урыны юк. Идәндә йокларга. Ул, билгеле, шуңа да риза. Кухняда миңа урын табылмый. Эшкә кергәндә ул, алмаслар дип куркып, баласы барлыгын әйтмәгән, ахрысы.

Менә шул. Инәкәй мине ташлап Яңавылга китте. Мин Зәйкәт белән апа янында, яшәби янында калдым. Ник? Нигә? Кайчанга кадәр?

Әткәй үлгәннән соң бу минем өчен иң зур кайгыларның беренчесе булды. Әткәй үлгәндә мин сабый гына булганмын. Күп нәрсәне аңламаганмын. Аңласам да, ул вакыттагы күңел яралары инде онытылып беткән. Инәкәй мине ташлап киткән чакта мин инде шактый исле. Миңа унбер яшьләр чамасы. Мондый чакта бала анага омтыла. Хәер, бала һәрвакыт анага омтыла, анага сыена. "Ник мине дә үзе белән алып китмәде?" -дигәч, яшәби, "Сина мәктәптән язу бирмәгәннәр, улым",—диде. Янәсе, мине Янтыктагы мәктәптән җибәрмәгәннәр булып чыга. Мондый җавапның бик үк дөрес түгеллеген мин бик яхшы чамалыйм. Минем ничек тә инәкәй артыннан Яңавылга китәсем килә.

Шулай борчыла, кайгыра торгач көннәрдән бер көнне Садыйков абый янына барып карарга булдым. Мәктәптә без аны гына беләбез—ул хөрмәтле, орденлы укытучы. Шул ук вакытта ул завуч та. Ул көнне мин Пешәлектә көне буе җиләк җыйдым. Җир җиләге. Иң эреләрен генә сайлап, яшел күбәтә тулганчы җыйдым да, кич көтү кайтыр алдыннан, беркемгә әйтмичә, Садыйков абыйларга киттем. Без элек тә сатарга дип укытучыларга җиләк-җимеш, шомырт, чикләвек алып бара торган идек. Бит элек авылда бары укытучылар гына акчалы иде.

Үзем берсен дә кабарга җәлләп җыйган хуш исле җиләкне күтәреп бардым да, куркып кына биек кала капкадан кердем. Садыйков абый кем беләндер баскычта сөйләшеп утыра. Мине күреп бу, өйдән карчыгын чакырып чыгарды да, җиләкне алырга кушты. Күпмедер акча бирде. Мин аңа җиләкне болай гына бирермен дип уйлаган идем. Ләкин шул турыда әйтергә никтер телем бармады. Акчаны алдым да карап тик торам моңа. Беренче булып башларга да куркам, ни өчен килгәнемне әйтмичә китеп

барырга да йөрәк җитми.

Садыйков абый озын буйлы, салмак хәрәкәтле, уйчан йөзле бер кеше иде. Минем ни өчен китмәвемне ул, ахрысы, аңлап алды. Шуннан бу үзе сүз башлады. "Янавылга инәкәй янына китәргә миңа язу кирәк иде, Садыйков абый",—дидем мин. Аның йөзе миңа бик боек, күңелсез булып күренде. Укытучы буларак, өлкән кеше буларак, ул минем хәлне яхшы аңлагандыр. Ләкин шул ук вакытта ул Янавыл мәктәбендәге хәлне дә, баласын ташлап китәргә мәҗбүр булган Салиханың да хәлен яхшы аңлаган булырга тиеш. "Мәктәп андый язу бирә алмый",—диде ул күңелсез генә.

Мин жылый-жылый кайтып киттем. Ул көнне, ул кышны миңа бик күп җыларга туры килде. Дөньяда мин үземне иң бәхетсез кеше итеп, ялгыз һәм кыерсытылган итеп тойдым. Шулай көз үтте, кыш җитте. "Яңа ел" дигән вакыт якынлаша башлады. Без элек "Яңа ел"ның нәрсә икәнен дә белми идек. Укый башлагач, белдек. Класска чыршы алып кайтып утырталар да, шуны бизиләр, шәмнәр куялар. Чыршы тирәсендә әйләнеп, буталып йөриләр. Әйләнеп, буталып йөрергә безне генә куш—без гадәттә пыр туздырып чабабыз, куышабыз, әүмәкләшәбез. Бер-беребезнең бүрек колакчынын ертып чыгарабыз, төймәләрне өзеп төшерәбез. Болары аның барысы да аңлашыла. Тик шунысын гына мин беркайчан аңлый алмадым: урманнан кисеп алып кайткан туң чыршы тирәли нигә әйләнеп йөрергә? Беркайчан безнең мондый бәйрәмебез булмаган. Чыршы бизәү, чыршыга шәмнәр кую ул христианнарның рождествосыннан алынган. Хәер, моны мин соңыннан гына белдем.

Яңа елда иң кызыгы шул—каникул башлана. Ул елны мин каникулны аеруча түземсезлек белән көттем. Инәкәй безне апа белән икебезне каникулда Янавылга чакырган. Каникул башлангач та апа белән җыендык та, Янавылга киттек. Бәләкәй чанага ярты капчык чамасы бәрәңге, тагын нәрсәдер салдык та, бәрәңгене иске-москы киемнәр белән яхшылап төреп, шәпләп бәйләдек тә, таң ату белән юлга чыктык. Чананы икәүләп тартабыз. Көн суык, ләкин авыр чана тартып барганда туңып торырга вакыт калмый. Сакат аша барабыз. Таудан төшкәндә чанага утырдык та бугай әле.

Апаның инәкәй янына барганы бар икән. Алар миңа гына берни әйтмәгәннәр. Төш вакытларында, туп-туры урам як ишектән бардык та кердек мәктәп коридорына. Ишекләре зур—капка кебек, ике катлы, пыялалы. Коридоры иркен, түшәме биек. Туң чананы коридор идәненнән тартып киттек. Мәктәптә хәзер беркем юк—монда да каникул башланган. Апа шунда бер ишекне ачты да, каядыр кереп китте. Кояштай балкып инәкәй килеп чыкты. Ялан өс. Бите чак кына кызарган. Үзеннән нур бөркелеп тора. Кочаклады, аркамнан сөйде. Минем өс киеме калын, суык. Авыз тирәсе, изү тирәсе боз булып каткан. Шатлыктан күзгә яшь килә. Ят җирдә җылап тору килешә торган эш түгел—шундук читкә борылган булам, тузып беткән җиң очлары белән күз яшьләрен сөртәм.

Чананы берүзе тартып инәкәй кухняга алып керде. Без дә кердек, чишендек, җылына башладык. Инәкәй безне сөтле какао белән—бары укытучылар гына эчә торган затлы эчемлек белән сыйлады. Шуннан соң мин исем китеп якты коридорны, зур тәрәзәле иркен класс бүлмәләрен карап йөрдем. Бүрәнәләр бертигез юанлыкта, яхшы итеп юылган. Мүк урынына, аркансыман булып, тыгыз сүс кабарып тора. Бездә, авылда өйнең бүрәнәләре кап-кара, бүрәнә араларыннан искереп беткән мүкләре күренеп тора. Бер зур бүлмәдә бичара чыршы утыра. Монда да "Яңа ел" уздырганнар. Идәндә конфет кәгазьләре, бизәкле чүпләр, ылыслар аунап ята.

Ул көнне яшь кенә бер укытучы апа мине "Яңа ел"дан калган

кучтәнәчләр—конфет, прәннек ише нәрсәләр белән сыйлады. Тик шулай да иң истә калганы бөтенләй икенче нәрсә булды.

Монда мин беренче мәртәбә электр утын күрдем. Күрдем дә шаккаттым—түшәмгә шар сыман лампа элгәннәр дә, яктыртып тик тора. Безнең җиделе лампадан түгел, унлысыннан да яктырак. Бернинди исе юк, корымы юк. Искиткеч! Нечкә бау сыман ике шнур эченнән, имеш, ут йөри. Ничек йөри ул? Ничек бавы янып китми? Идәннән якын гына, стенада ниндидер түгәрәк капкач бар. Шуның кечкенә тимерен басасың да, яна да китә лампочка гөлт итеп. Гаҗәпнең гаҗәбе инде менә.

Инәкәйнен ничек итеп сүндергәнен, яндырганын карап кына тордым да, кухняда беркем юк чагында әлеге түгәрәк нәрсәнең эчен ачып карамакчы булдым. Башта капкачны алдым, аннан соң ниндидер ак тәтәйгә беркетелгән шөрепләрне боргаламакчы булдым. Кечкенә матур шөрепкә бармагымны тидерүем булды, кинәт мине нидер бәреп җибәрде. Кулдагы калай капкач чылтырап идәнгә төшеп китте, мин үзем нәрсә булганын аңлый алмыйча, шулай ук урындыктан идәнгә барып төштем.

Электр белән якыннан танышлык шулай булды.

## 20. Зәйнуллина апа һәм башкалар

Кухня янындагы бүлмәләрнең икенчесендә яшь укытучылар тора. Берсендә директор. Кияүгә чыкмаган кыз кеше. Чәче көдрә, тавышы калынрак. Каяндыр башкорт ягыннан килгән. Исеме дә, фамилиясе дә онытылган. Чынлапмы, шаяртыпмы Марго дип атаганнары истә калган. Сугыш елларында Үзбәкстанга китте, яңадан кайтты, тимер юлда эшләгән кемгәдер кияүгә дә чыкты бугай. Уңмады. Тормышы бер яктан да барып чыкмады. Мин белгән яшь укытучыларның күбесенең язмышы күңелсез тәмамлана. Аларның институт бетереп, яңа эшли башлаган чаклары. Мин аларның шаулашып, көлешеп, үзара шаярышып йөргәннәрен хәтерлим. Аларның күпмедер гомере кинодагы кебек, минем күз алдында үтте. Дөрес, мин аларның тормышын әлләни күп белмим, ләкин белгән кадәресе дә трагедия арты трагедия язарга җитәр иде.

Кухня янындагы бүлмәнең икенчесендә—завуч. Кияүдән аерылган яшь хатын. Луиза исемле кызы бар. Кызы бәләкәй генә, әле бакчага йөри. Завучның исеме—Шәрәфел, фамилиясе—Зәйнуллина. Үзенең исеменнән оялып, ахрысы, ул беркайчан үзен Шәрәфел дип әйттермәде. Инәкәй “Зәйнуллина” ди, мин “Зәйнуллина апа” димен. Бәлки ул чакта укытучыларга исеме белән эндәшү тыелгандыр, бәлки фамилиясе белән эндәшергә кирәк булгандыр? Ничек булганын мин белмәдем, ничек кушалар, шулай атап йөрдем. Гомергә ул “Зәйнуллина апа” булып калды. Мәктәп балада олыларга карата, бигрәк тә укытучыга карата хөрмәт хисе тәрбияләргә тиеш кебек. Ләкин рәсми “Зәйнуллина”да, яисә хәзергечә Фәлән Фәләновнада, Фәлән Фәләновичтә татар кешесенә карата нинди хөрмәт булырга мөмкин? Баланы телдән, халыктан, традициядән аеру менә шул рәсми атамалардан башлана түгелме соң?

Зәйнуллина апа өлкән классларда зоология, биология кебек фәннәр укытты. Тумышы белән ул каяндыр Урал ягыннан, Свердловск өлкәсеннән икән. Казанда педагогия институтында укыган. Студент чагында үзе белән укыган берәүгә кияүгә чыккан. Ләкин ире эчә торган кеше булган. Укыган чактамы, укуын бетергәчме, Луизаны алган да, иреннән качып Яңавыл ягына килеп чыккан. Аның әтисе дә эчә торган кеше булган, шуңа күрә эчкечеләрне жене сөймәгән. Авылда бик авырлык белән үскән. Әтисенең

эчкече булуы өстенә, әнисе үги булган. Үги анадан, эчкече атадан качып, бердәнбер абыйсына ияреп бердәнбер көнне бу Казанга укырга киткән. Беренче мәртәбә пассажир поездын күргәч, абыйсыннан сорый икән: "Бу пуезның кай жиренә утырып йөриләр соң, шул тоткаларына тотынып баралармени?"—дип әйтә икән. Кызык итеп Зәйнуллина апа мина да, инәкәйгә дә шул турыда сөйләргә ярата иде.

Кара кашлы, ягымлы түгәрәк йөзле басынкы гына бер хатын иде ул.

Инәкәй мәктәп җыештыру, звонок бирү кебек эшләр белән бергә, менә шушы укытучыларның хезмәтчесе кебегрәк тә була. Кухня мичена яга, ике бүлмәне жылыта торган мичкә яга, укытучыларга иртә-кич чәй кайната, ашарга пешерә. Кыскасы, аларның барлык вак-төяк эшләрен эшли. Күрәсең, эшкә алганда ук ана шундый шарт куйганнардыр. Вак-төяк эш өчен акча түләү юк. Инәкәй бөтенесен яратып, теләп эшли. Аның әле яшь, дәртле чагы. Ару-талуны белми торган чагы. Мәктәпнең ул еллардагы яшь укытучылары белән ул туганнарча дус, тату яшәде. Аны барысы да яраталар, хөрмәт итәләр, "Салихә апа" дип кенә торалар. Ул бөтенесенә дә өлгерә, иң мөһиме, беркемгә карышмый, киреләнми. Шулай хәтердә калган.

Тәнәфес вакытларында, ял көннәрендә кухняга физика укытучысы Хәниф абый да кергәли. Ул да яшь. Яңарак кына институт бетереп килгән. Аның кайда торганын хәтерләмим. Анда тагын Рима апа да була. Шат күңелле, нечкә билле, чибәр. Каяндыр Златоуст ягыннан бугай. "Ачкыч" дип әйтәсе урынга "әчкеч" ди. Шуның өчен укытучылар аннан көлеп рәхәтләнәләр. "Әчкеч" дип әйтү миңа, киресенчә, бик матур булып, бик дөрес булып тоела. Кайчагында алар кухняда, күрше бүлмәләрдә бергә туры киләләр, берәр нәрсәне искә төшереп, бер-берсенә берәр шаян сүз әйтеп, көлешергә тотыналар. Аларның ник көлешкәнен мин, билгеле, анламыйм. Аларның шатлыгы мина да тәэсир итә һәм мин дә үземне көне буе бәхетле итеп тоям. Хәниф абыйның миңа бүләк итеп биргән дүрт открыткасының икесе әле дә миндә саклана. Әледән-әле шул открыткаларны алам да, андагы рәсемне, һәрбер рәсемне, һәрбер хәрефне жентекләп карарга тотынам. Аның берсенә Зоммер дигән художникның "На окраине", икенчесенә Б. И. Грековның "Замерзшие казаки корпуса ген. Павлова (1920)" картинасының күчерелмәләре төшерелгән. Греков картинасы төшерелгән открытка 1932 елда чыккан, Зоммер картинасы төшерелгән открытканың кайчан чыгарылуы язылмаган. Бер открытканың артына латин хәрефләре белән татарча: "Истәлек, "Хәниф! Иптәш, мин сина мына шушы начар гына булган аткриткамны бүләк итәм Сафар тихникумында 2 йыл бергә укыганны искә алырсын диеп уйлыйм Сәләм белән М. Ахметыф 23/ү 33 г.", диелгән. Икенче открытканың бер кырыен бала чакта малай кимергән. Шуңа күрә кайбер сүзләре ашалган. Иң беренче сүзе: Хөсәенеф!!!" Азактарак—"укыганны искә... өчен үземнең аткритканы бүләк итәм. Ком. сәләм белән, мин. Хөсәенеф туганым, өстә күрсәтелгән адрис буенча, хат яз. Онытма" Адресы: П/о Чишмы того же р-на. Дер. Ново Сафарова, Уразлетовой С. 23/ү—33г.

Мин моны болай гына күчердем. Утызынчы еллардагы яшьләрнең рухы бөркелеп торган өчен генә. Аннары шуның өчен: Хәниф абый сугышның беренче елларында ук армиягә алынды, беренче елында ук һәлак булды. Ул, әйтерсең, менә шушы открыткаларда яши дә, минем күңелдә яши.

Зәйнуллина апа сугыш елларында Яңавылда шул ук мәктәптә укытты. Аннан соң абыйсы янына Уфага да күчеп карады. Ләкин, оя тапмаган каз сыман, яңадан Яңавылга кайтты. Яңадан мәктәпкә эшкә урнашты. Аның бар карап торганы кызы Луизасы булды. Бердәнбер бала булганга ул аны

артык яратты, кирәгеннән артык ул аңа тәэсир итәргә тырышты бугай. Зәйнуллина апа үзе татар мәктәбендә укытса да, Луиза русча укыды. Ул елларда мода шулай иде. Хәер, ул елларда гына микән! Без авыл балалары татарча укыдык, интеллигенция русча укытты. Алар үз балаларын алдан ук институтларга әзерләделәр. Аларның балалары бик зур талант булырга тиешләр иде. Луиза да яхшы укыды. Зәйнуллина апаның архитектор булырга хыяллана, Мәскәү университетына кермәкче дигән сүзләре истә калган.

Луиза архитектор була алмады. Казанда кияүгә чыкты. Кызы артыннан ияреп Зәйнуллина апа да Казанга килде. Илленче елларда Киров районындагы иске йортта торганда без аның Казанда икәнлеген белеп, үзебезгә кунакка чакырдык. Бик күп еллар аерылышып торганнан соң инәкәйнең бик күрәсе килде. Адресы буенча эзләп бардым мин аны. Үзен туры китерәлмәдем. Шулай да ул килде. Бездә кунак булды. Инәкәй белән элеккеләрне искә төшереп утырдылар.

Ләкин шунда бер нәрсә билгеле булды: Зәйнуллина апа бездә үзен ничектер унайсыз сизә кебек тоелды. Ул кызы-кияве янында тора иде. Аның андагы хәле бер дә шәптән түгел иде, ахрысы. Ул зарланырга яратмый иде. Бу юлы да зарланмады. Аларның квартиры Дербышка поселогында иде. Берничә елдан соң без дә шунда күчендек—яңа урында яңа йорт салып чыктык. Дербышкада мин аны берничә мәртәбә очраттым, үзебезнең яңа өйгә инәкәй янына кунакка чакырдым. Килмәде. Хурланды, кимсенде дип уйлыйм. Үзенең хәленнән, үзенең кысынкы тормышыннан, квартир шартларыннан кимсенде дип уйлыйм. Аның хәле инде чыннан да шәптән түгел иде. Өсте-башы начар гына, кыяфәтен шулай ук яхшы дип әйтеп булмый. Пенсиядәге карчыкның каян килеп кыяфәте яхшы булсын?! Йөреше дә, үз-үзен тотышы да элеккечә түгел. Склероз, диде, башым авырта, диде. Берсендә магазинга сөткә барган да, сөт булмыйча савытын күтәреп кайтып килә. Үзенә сиздермәсәм дә, бик кызгандым, бик әрнедем мин. Луизаның да тормышы ал да гөл түгел бугай. Шуның өчен дә кайгыра инде ул. Аннан соң—ялгызлык. Кемгә кирәк ул хәзер? Гомере буена балаларга сабак биргән, картаймыш көнендә урамга куалап чыгарылган Вайжәде әбзәби беркемгә кирәк булмаган кебек, бөтен гомерен мәктәпкә, балаларга багышлаган карт укытучының да кулыннан көче киткәч беркемгә кирәге калмагандыр.

"Әчкеч" дип сөйләшә торган Рима апа да гомере буе балалар укытты. Сугыштан соң бер-ике мәртәбә кияүгә дә чыкты бугай, ләкин тормышын барыбер җайлый алмаган. Алтмышынчы елларда, ахрысы, туберкулездан дөнья куйган.

## 21. Сабан туе

Бишенчегә күчкәч, җәй көне Янавылга, инәкәй янына торырга киттем. Җәйге каникул вакытында Зәйнуллина апа Казанга китеп барды, директор апа да каядыр ялга китте. Луиза, мин, инәкәй бөтен өйгә хуҗа булып, өй саклап калдык. Казаннан Зәйнуллина апа миңа ак күлмәк, кыска чалбар, тагын шундый вак-төяк алып кайтты. Минем магазиннан сатып алынган күлмәк, чалбар кигәнем юк—барысын да кулдан инәкәй үзе тегә. Зәйнуллина апа Казанда чиратта бик озак торуы турында сөйләде.

Икенче җәйне, ахрысы, уку беткәч, яхшы эшләгән өчен дип инәкәйгә ял йортына путевка бирделәр. Укытучы хатын-кызларның берсе аңа калын тукымадан тегелгән ап-ак костюмын сатып бирде. Шәһәрчә ап-ак юбка, ак пинжәк кигәч, ул бик чибәрләнеп китте. Ул вакытта әле аңа утыз алты,

утыз жиде булгандыр кебек. Минем күз алдында ул ап-ак костюмыннан гел елмаеп торган килеш сакланып калган. Дүртөйле янындагы нииндидер кымызлы ял йортына барып кайткач, ул сөенеченнән кая басканын белми йөрде. Гомере буена шундагы рәхәтлекләрне, анда күргән, очрашкан кешеләрен сагынып сөйләде.

Инәкәйнен дә, минем дә, башка бик күпләрнен дә ул чактагы куанычлары 1941 елгы июньнең 22сендә челпәрәмә килде.

Ул көн ял көне иде. Ул көнне Янавылда сабан туе булды. Сабан туе ул чакларда Сакат тавы астанда, Бүәнең сул ягында иркен болында була торган иде.

Төньяк-көнбатышта ямь-яшел урман белән капланган Сакат тавы калкып утыра. Артта, Янавыл ягында, тәбәнәк калкулыкта унлап-унбишләп йортлы Үрмәде авылы күренә. Болын читендә—куе әрәмәләр. Әрәмә генә дә түгел, чын урман. Якында гына Бүә агып ята. Бу турыда ул артык кызу акмый, тук сыер кебек, тулып-иркенәеп, әкрен генә кыймылдавын белә. Кечү турысында гына кызулап ала да, ары киткәч тагын салмакланып кала. Анда су тирән, куркыныч. Як-ягында чытырлык-карама, шомырт, балан.

Сабан туе вакытында тигез болын уртасына шомартылган тигез, озын багана утырталар, капчык сугышы өчен аркылы агач бастыралар, беркадәр читтә сәхнәсыман итеп калку идән җайлана. Баганадан читтәрәк төрле ярышлар, уеннар өчен урын билгеләнә. Янавылдан мороженый, морс сата торган сатучылар килә. Ул чакта әле микрофоннар юк. Бөтен нәрсә кычкырып аңлатыла. Ин уртада көрәш бара. Көрәш тынып торган арада, ерактан ат чабышына китүчеләр күренә. Халык, дәррәү кубып, шул якка агыла. Беләкләренә кызыл бәйләгән тәртип саклаучылар—таза ирләр халыкны читкә куалыйлар. Әле анда, әле монда кызыл байраклар җилферди.

Сабан туенда аракы сату, аракы эчү гомумән юк. Кешеләр шаулашып-гөрләшеп якындагы куак араларында күнел ачалар. Әле анда, әле монда кычкыртып гармун уйныйлар, җырлыйлар. Кайберәүләр самавырлар алып килгән, самавыр тирәсенә җыелып утырып күнелле итеп чәй эчәләр. Әрәмә араларында, болында, яр буйларында—һәркайда халык, ыгы-зыгы, чыр-чу.

Ул көндәге сабан туе хәтердә шулай калган. Ул көнне ярышларда мин дә катнаштым. Класстагы кара такта сыман тактага ерактан бөҗра ыргытып бер карандаш отып алдым. Без Мәгъсүм, Касыйм, өчәүләшеп ул көнне яр буендагы куакларны актарып бетердек. Кызыл карагат эзлибез. Шулай йөри торгач, ачык җиргә—болынга килеп чыктык. Чыксак, халыкка әлләни булган. Каядыр ашыгалар, тыз-быз киләләр, борчулы йөзләр дә күренә. Җыр, гармун тавышлары тынып калган. Атлылар атларын җигәләр, арбаларга кешеләр утырган. Үрмәде ягына борылып карасак, бөтен кеше кайту ягына кузгалган.

Куаклык арасында йөреп без нәрсәнедер белми, ишетми калганбыз. Без югында монда бик тә әһәмиятле нәрсә булган булырга тиеш. Нәрсә булган—берни белмибез. Башкаларга ияреп без дә Янавылга кайтып киттек. Үрмәледән соң бер-ике чакрым җир үткәч, Үрнәк дигән бәләкәй авыл бар. Үрнәкне узгач, Янавыл ягыннан җил белән радио тавышы килеп житте. Кайдадыр репродуктор сөйли. Бик шомлы итеп сөйли. Шулай да өйгә кайтып житкәнче мин нәрсә булганын аңлый алмадым. Бары кайткач кына, инәкәй "сугыш башланган" дигәч кенә аңладым.

Юк, ул әйткәч тә күп нәрсәне аңлый алмадым. Сугыш башланган. Башланса ни. Бит безнекеләр барыбер җиңәчәк! Башкалар ышанмаса

ышанмас, ләкин мин әз генә дә шикләнмәдем. Безне шулай тәрбияләделәр: без—хаклы, безне җиһәрдәй дошман юк, данлы Кызыл Армия теләсә нинди дошманның көлен күккә очырачак.

Мәктәпнең тимер юлга якынрак җирдә, иске "Заготзерно" янында авылдан килеп укучылар өчен гомуми торагы бар иде. Ул елны инәкәйне шул торакка убшежитиегә күчерделәр. Берничә бүлмәле бу борынгы агач йортның бер бүлмәсендә кызлар, икенчесендә малайлар тора. Шунда ук зур гына кухня. Кухняда зур казан. Анда балаларга су кайный. Плитә өстендә төрле зурлыктагы чуеннарда аш, бәрәңге пешә. Һәркем азыкны өеннән үзе алып килә. Инәкәй балалар торган бүлмәләрне җыештыра, мичләренә яга, кухняга яга. Инәкәй белән мин кухняда торабыз. Мич белән зур тәрәзә арасында биек, иркен сике. Минем бөтен тормыш шушы сикедә өстәл янында уза. Кухняга күршедә ике бүлмәле квартир. Анда тарих укытучысы Шиһабетдинов абый. Тагын фамилия. Исемен белмим. Без аны күбесенчә Шиаб абый дип йөртәбез. Инәкәй Шиаб ди. Шиаб абый кырыгынчы елга кадәр Архангельск шәһәрендә татар җидееллык мәктәбендә тарих укыткан, директор булган. Мәктәпне япкач, аны Янавылга эшкә җибәргәннәр. Ул үзе Оренбург ягыннан. Хатыны Хафизә апаның әтисе Казан ягыннан булган, яшь чагында сату-алу белән шунда Архангельскига барып чыккан да, төпләнеп калган. Хафизә апа шунда туган. Архангельскида татарларның аерым урамнары, мәчитләре бар икән. Йорт эшен ни дип тә белми торган, көне-төне "Новый мир" журналы укый торган, күзләреннән туктаусыз яшь ага торган бер тыныч кына хатын иде ул. Аларның берсеннән-берсе кечерәк дүрт балалары бар иде.

Сугыш башланганда Шиһаб абый Ленинградта була. Ул анда университетның тарих факультетында ничәнчедер курста читтән торып укый. Җәй көне ул анда җәйге сессиягә киткән була. Кайтканда бик авыр булды дип сөйләде. Сугыш башлану белән вокзалларга халык килеп тулган. Билет алу, кайту кыенлашкан. Һәркемне милиционерлар тикшерә икән. Вагонга кергәндә Шиаб абызның чемоданнары бик авыр булган. Чемодан тулы китап икән. Шиаб абый милиционерлар яныннан җиңел генә, тиз-тиз генә үтеп киткән, ягъни авыр чемоданнарны җиңел итеп күрсәткән. Милиционерлар аңа игътибар итмәгәннәр. Шулай дип сөйләгәне хәтердә калган.

Сугыш башлангач, Шиаб абый безгә Ленинградтан бер открытка язды.

Ленинградтан Шиаб абый миңа бик яхшы кәгазьле ике блокнот алып кайтты. Мин аларга шигырь язып, рәсем ясап бик озак сакладым.

Сугышның беренче тәэсирләре шулайрак булды. Соңга таба тәэсирләр үзгәрә төште. Иң зур үзгәрешләрнең берсе шул: Яңавылга төрле яктан атлылар килеп тулды. Атлары белән авыл яшьләре килде. Аларны озатучылар—аталар, аналар, балалар, кызлар килде. Кара сырма, кыска тун кигән, киез итекле, чалбарлы тап-таза яшьләр. Кайгылы йөзләр. Кызмача баштан урам бетереп "кәтәйсә" әйләнүләр. Капчык-капчык сохарилар, азык-төлек салынган сумкалар. Озатышу, саубуллашулар. Йөрәк әрнеткеч кайгы авазлары.

Безнең мәктәп янындагы хәрби комиссариат алдындагы киң мәйданда атлылар, җәяүлеләр аеруча күп булды. Алар анда куна-түнә яттылар. Аркаларына капчык аскан яшьләрне командага тезеп, вокзалга алып китә торалар. Алар артыннан койрык булып озатучылар төркеме тагылды.

Укытучы ирләр көн дә кич сугыш уенына йөриләр. Командага тезелеп каядыр басу ягына чыгып китәләр дә, карангы төшкәндә кайталар. Әле

анда, әле монда тетрәндергеч солдат җырлары яңгырый.

1941 елның кышында, ахрысы, Янавылда хәрби очучылар мәктәбе ачылды, дөресрәге, ачылмады, каяндыр эвакуацияләнеп килде. Безнең торактагы күп кенә үсмерләр, унынчы, тугызынчы малайлары шунда язылдылар. Бер көнне шул үсмерләрнең берничәсе хәрби киемнәр киеп кайтты. Ул вакытта алар дөньядагы иң бәхетле кешеләр иде. Соныннан инәкәй сөйләде: Муллаянны алмаганнар. Ул чагында иң элек кешенең чыгышына игътибар итәләр. Ул, ахрысы, мулла малае булган. Хәрби очучылар мәктәбенә алмагач, Муллаян җылап кайткан. Унны бетәргәндерме, юкмы, әйтә алмыйм. Вакыты житкәч, армиягә аны да алганнар. Пехотага. Сугыштан исән-имин кайткан. Кайткач үзләре авылында колхоз председателе булып эшләгән. Хәрби очучылар мәктәбендә укыган үсмерләрнең берсе дә туган якларына кире кайта алмаган. Кайдадыр, кайдалардадыр ятып калганнар. Мәңге тормаслык булып.

Янавылның татар урта мәктәбеннән үзе теләп фронтка китүчеләр арасында Сибәде авылыннанмы, Сандугач авылыннанмы Нәҗибә исемле бер кыз да бар иде. Мин аны чак-чак кына хәтерлим. Озынча ак йөзле, озын кара толымлы, калку гәүдәле. Толымын күкрәге турысына сузып салып, чәч үреп торганын әле дә күргән кебек булам.

Мең тугыз йөз кырык өченең төкерек җиргә төшмәс суык көннәрендә Сталинград янында шәһит киткән санитарка Нәҗибә бәете Янавылда кулдан кулга йөреде. Нәҗибәнең батырларча үлеме, ул вакытта, бәлки, искитәрлек вакыйга да булып тоелмагандыр. Ул елларда "батырларча үлем" турында бик күп ишетергә туры килде. Батырларча үлемнәрнең, шул хактагы бәетләрнең әһәмияте еллар узгач ныграк аңлашыла.

Сугышта турыдан-туры минем туганнардан беркем катнашмады. Озак кына уңайсызланып йөрдем. Хәзер бу тойгы бетте. Мина да, минем кебек башкаларга, да уңайсызланырга кирәкми дип уйлыйм. Унны да бетермичә үзләре теләп хәрби очучылар мәктәбенә укырга кергән һәм фронтта бер-бер артлы юкка чыккан үсмерләр, Сталинград янында батырларча һәлак булган санитарка Нәҗибә, Күчтәвылның, минем белән уйнап үскән күрше Заһир, укытучы Хәниф абый һәм башкалар... минем якыннарым, минем туганнарым булмыйча, кем соң алар?! Аларның каны—безнең кан. Һәлак булсалар да, алар юкка чыкмады. Алар мәңге безнең белән, алар мәңге безнең хәтердә.

*Дәвамы киләсе саннарда*



# МОҢ ҺӘМ КӨЧ

*(Шагыйрьнең төрле елларда язган шигырьләреннән)*

## Без—җир балалары

**Түшендәге чәчәк кебек итеп**
**Сыендырса мине үзенә,**
**Сабыйларча йомшак, саф карашлы,**
**Хыял күле булган күзеннән**
**Бөркелгән нур әгәр миңа төшсә,**
**Беләсезме, дуслар, иң башта**
**Мин тезләнеп җирне үбәр идем,**
**Аннан карар идем кояшка.**

*1935*

## Кемгә сөйлим серләремне?

(ҖЫР)

**Кемгә сөйлим серләремне,**
**Йөрәгем ялкын кебек,**
**Ялкынланган йөрәгемә**
**Берәү бик якын кебек.**

**Аның өчен кырлардагы**
**Чәчәкләр җитмәс кебек,**
**Чәчәкләр дә йөрәгемне**
**Аңлатып бетмәс кебек.**

**Ул үзе дә төн йокысыз**
**Мине уйлыйдыр кебек...**
**Янып сөймәсәң, яшьлекнең**
**Яме булмыйдыр кебек.**

*1936*

***

**Соңгы тапкыр карыйм Иделгә,**
**Соңгы кабат күрим акканын,**
**Бәлки, бик тиз бире кайтмамын,**
**Сакланыр ул бары күңелдә.**

Сакланыр ул соңгы хат кебек.
Искә алсам, йөрәк сулкылдар;
Күз алдыма килер дулкыннар,
Дулкыннарда кайнар ак күбек.

Син борчылма, күңел, яз килсен,
Кыр казлары кайтыр күлләргә,
Без кайтырбыз туган илләргә,
Башлар гына исән-сау булсын.

Безне котлап, җылы яңгырлар
Шатлык сибәр Идел буенда,
Безне котлап, иркен болында
Назлы аккош моңы яңгырар.

*1938*

## Кереш җыр

Мин рядовой солдат бу сугышта,
Тик бер нәрсәм белән аерылам:
Рядовойлар төнен йоклаганда,
Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.

Бер минут та башка тынгы бирми,
Окоп почмагында утырам,
Аламын да куен дәфтәремне,
Янып, җыр язарга тотынам.

Ут булмаган җирдә ай яктырта,
Җыр хакына кала йокылар;
Окопларда язган җырларымны
Хөрмәт белән дуслар укырлар.

*1942*

## Теләк

Матурлык сайлауда мине
Кем куып җитәр икән?
Сөюдә һәм сөелүдә
Мине кем җиңәр икән?

Яшәдем, яшел урманнар
Иркәләде, көйләде,
Инде мин сугыш кырында,
Тик бер генә теләгем:

Дошманга ялкын сибүче
Җил булып барсам иде,
Тәвәккәллек, батырлыкта
Җыр булып калсам иде.

*1942*

## Юл

Үзен аска, җиңен баш очына
Салам да мин соры шинельнең,
Карап барам ачык тәрәзәдән
Урманнарын туган илемнең.

Каеннарның көзге яфраклары
Манчып алган кебек алтынга,—
Ялтырыйлар алар тын офыктан
Кичке кояш сипкән ялкында.

Тагын барам, мин сугышка барам,
Паровозның моңсу тавышы:
—Кайтырсың!—ди, димәк, алда әле
Көтә мине тагын кавышу.

Кайту да юк ләкин, кавышу да,
Дошманнарны әгәр җиңмәсәк,
Данлы җиңү байраклары белән
Илнең кайгы яшен сөртмәсәк.

*1942*

***

Сөйләр сүзләр бик күп алар,
Иренмичә сөйләсәң;
Озын сүзнең кыскасы шул,
Күп яшәргә теләсәң:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

*1942*

## Син еракта

*Кадриягә*

... Син ерак миннән ерагын,
Ераклыкка карамый,
Яраласа мине дошман,
Ул сине дә яралый.

Ялгышмыйк без, ерак түгел
Сугышта безнең ара,
Мәхәббәтең минем белән
Атакаларга бара.

Каһәрле дошманга төзәп
Мин мылтык аткан чакта,
Гүя син патроннар салып
Торасың минем катта.

Ә шулай да... син еракта,
Мин тик хатыңны күрәм,
Хатка язган сүзләреңне
Күзләрең итеп үбәм...

Ил язмышын даулаганда
Аерылышкан кешеләр,
Зур кайгыга төшсәләр дә,
Караңгыга төшмиләр.

*1942*

## Сагындым

Идел буйларына тагын
Әйләнеп кайтсам иде;
Ал чәчәкләр арасында
Бер җырлап ятсам иде.

Җир җиләге белән мине
Иркәм сыйласа иде;
Элеккечә бер иркәләп,
Башым сыйпаса иде.

*1943*

## Кайгырма син

Яңгырый яз: кыр казлары кайта,
Кар сулары гөрли басуда;
Атыш тынган ара җай китереп,
Кулъяулыгы юам бу суда.

Ак кулъяулык элеп куям җилгә,
Җил тирбәтеп аны киптерә;
Сизәм-сизәм, язның дәртле җиле
Синнән миңа сәлам китерә.

Сагындыңмы, бәхет күгәрченем?
Мин дә менә урман буенда,
Талгын гына йомып күзләремне,
Җанландырам сине уемда.

Гүя хәзер безнең һөҗүмнәрне
Сөембикә манарасыннан,
Чәчең җилфердәтеп язгы җилдә,
Бәгърем, карап торасың сыман.

Ерагаясың дип кайгырма син,
Без дошманны куып барабыз;
Никадәрле ерак куа алсак,
Шул кадәрле якын арабыз...

Эчәр өчен салкын кар сулары,
Әй, чылтырап ага басуда;
Кар суында кулъяулыгы юам,
Мин кайгымны юам бу суда.

*1943*

## Моң һәм көч

Атлас кебек төрле төс балкыта
Язгы сыерчыкның канаты;
Канатларын җилпеп җырлый бу кош,
Мин аеруча җырын яратам.

Җырның көче—ярсу, хыялый моң,
Бу моң кайнап чыга йөрәктән;
Егет өчен кош канаты кирәк,
Егет көче ләкин теләктә.

*1943*

# ФАТИХ КӘРИМ ТУРЫНДА ӘДИПЛӘР

* * *

**Сибгат Хәким, Татарстанның халык шагыйре:**

—Дөнья хәлләре кискенләшкән саен нигәдер Фатих Кәрим кебек кешеләр искә төшә. Ә бит Фатих Кәрим—Бөек Ватан сугышы шагыйре. Ә бит сугыш беткәнгә тиздән кырык ел. Бүгенге дөнья белән узган сугышның арасы нигә шулай якыная? Нигә алар кушыла?.. Ике кырыс чор. Нигә Фатих Кәрим? Нигә бүтән шагыйрь түгел? Татар совет поэзиясендә шул чорны Фатих Кәримнән дә тулырак чагылдырган башка бер шагыйрь дә юк. Ничек ул шулай рухын тиз туплый алды? Тупланды, янадан ачылды, шул заманның иң популяр шагыйренә әйләнде, Кенигсберг янында сугышның бөек үренә күтәрелде, үзенең иҗат үренә күтәрелде, үз шөһрәтенә шул солдат үреннән карап үлде. Үзенә йөкләнгән зур эшне башкарып китте шагыйрь.

1983.

*("Башкача түгел, тик шулай..." исемле мәкаләсеннән.)*

* * *

**Зәет Мәҗитов, галим, шагыйрь, Ф. Кәрим исемендәге әдәби премия лауреаты:**

—Фатих Кәрим—әдәбиятыбызда җуелмас эз калдырган шагыйрьләребезнең берсе. Кайчан гына, кем генә татар совет поэзиясенең казанышлары турында сөйләмәсен, Һади Такташ исеме белән рәттән ул һәрвакыт ике якты исемне—Муса Җәлил һәм Фатих Кәрим исемнәрен әйтер.

...Минә атаклы француз язучысы Луи Арагон сүзләре: "Фатих Кәрим—һәр шигырь юлы белән ватанына фидакарь хезмәт иткән җырчы һәм солдат. Аның Казан музеенда изге реликвия булып саклана торган шинеле генә түгел, кульязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән".

Фатих Кәрим—якты, саф һәм патриотик тойгылар шагыйре.

1979.

*(Шагыйрьнең өчтомлыгына кереш мәкаләсеннән.)*

* * *

**Рафаэль Мостафин,**
**язучы, тәнкыйтьче, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:**

Сугыштан соңгы елларда Мәскәү тәнкыйтьчеләре татар шигърияten "Солдат шинелендәге поэзия" дип атадылар ("Поэзия в солдатской шинели"). Чыннан да, татар шагыйрьләре иң авыр сынау көннәрендә халык белән бергә алгы сызыкта булдылар, мылтык белән дә, каләм белән дә дошман белән сугыштылар. Фашист палачлары тарафыннан гильотинага хөкем ителгән Муса Җәлил Берлинның Моабит төрмәсендә үләр алдыннан

*Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,*
*Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.*
*Кирәк икән, үләм аягүрә,*
*Балта белән башым киссәң дә,—*

дип язды.

Аның шигырьләре белән Фатих Кәримнең бик күп юллары аваздаш:

*Шушы балам өчен, синең өчен,*
*Нәселем өчен, Туган ил өчен,*
*Мылтык тотып, баскан җиремнән*
*Бер адым да артка чигенмәм.*

Җәлил дә, Фатих Кәрим дә, фашизмга соңгы нәләтләрен әйтеп, батырларча һәлак булдылар. М. Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре" белән бер үк киштәдә Ф. Кәримнең "Кыңгыраулы яшел гармун"ы, "Гөлсем", "Өмет" кебек поэмалары тора. Фатих

Кәрим дә, Муса Җәлил шикелле иң авыр сынаулар һәм үлем каршында гражданлык һәм язучылык батырлыгы үрнәге булып тора. Алар икесе дә олы шагыйрь һәм көчле рухлы батыр булып безнең күңелләребезгә мәңгегә кереп калдылар.

2008.

* * *

**Рәдиф Гаташ,**
**шагыйрь, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:**

—1983 елда Испаниядә, Мадридның Республика мәйданында булганда Равил Фәйзуллин белән икәүләп—Фатих Кәрим, аның зур шәхесе, үлемсез иҗаты турында сөйләшеп йөргән идек. Минем шул елларда язылган "Европада татар шагыйрьләре" циклына керәчәк "Испания турында җыр" юллары да яралды ул көндә. Әйе, Фатих Кәрим, Муса Җәлил исемнәре кабатланды уйда... Хәтердә: без, өч туган, әтисез өч малай, сугыштан соңгы елларда, ярыша-ярыша, Фатих Кәримнең сугыш чоры шигырьләрен яттан сөйләп, әнкәйләрне елата идек. Шагыйрь исеме, чыннан да, Такташныкы кебек үк, олысының-кечесенең телендә булды ул елларда. Хәзер дә!—диясем килә.

2000.

***(Фатих Кәрим премиясен алгач, Бәләбәй һәм Уфа радиолары өчен интервьюдан.)***

## Фатих Кәрим исемендәге төбәкара премия

Билгеле булганча, Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында—шагыйрьнең туган җирендә—аның йорт-музее бар. Фатих Кәрим укыган Бәләбәй шәһәре дә аның эзләрен саклый.

Узган гасырның туксанынчы елларында исә Бәләбәй хакимияте һәм Башкортстан язучылар берлеге Фатих Кәрим исемендәге премия дә булдырды: ул өч республика—Башкортстан, Татарстан, Чуашстан язучыларына бирелеп килде. Татар әдипләреннән бу төбәкара абруйлы премиягә Ренат Харис, Әхмәт Гадел, Рәдиф Гаташ, Зәет Мәҗитов (үлгәннән соң), Роберт Миннуллин лаек булды.



*Рәсемдә шагыйрьнең туган авылы Аетка очрашуга килгән татар һәм башкорт шагыйрьләре: Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Равил Бикбаев, Абдулхак Игебаев, h. б. Дим буенда. 1984 ел.*

Тәфкил
Вафин

# МӘКРУҺЛАР

## Мир үгезе

Янгилде авылы крестьяннарының һәрберсе аерым хуҗалык булып яшәсә дә, кайбер эшләрне күмәкләшеп башкарганнар: бергәләшеп ел саен язгы ташу алып киткән тегермән буасын буганнар, чәчү җирләрен эшкәрткәннәр, бәрәңге утырткannар, йорт хайваннарын көтүгә чыгарганнар һ. б. Мал-мөлкәтнең дә кайбер төрләре уртак булган. Мәсәлән, янгыннан саклану, ягъни каравыл өен шулай ук бергәләшеп файдаланганнар. Бер нәсел үгезе һәм айгыр асраганнар. Аларны "мир үгезе", "мир айгыры" дигәннәр. Янгын насосы һәм су мичкәсе өчен аерым атлар тотканнар. Чыгымнарны Янгилде авылы халкы бергәләп күтәргән.

Арт урамда яшәгән урыс крестьяны Николай Рюриковны ел саен килешү нигезендә каравылчы итеп куйганнар. Ул көн-төн каравылда булган. Җәй көннәрендә янгын куркынычы арткан чорда дежурга өстәмә кешене куйганнар. Күп очракта ул йорт саен чират буенча билгеләнгән.

Каравыл өе клуб вазифасын да үтәгән. Кышкы кичләрдә анда авылның ир-атлары урысы-татары, яше-карты җыелышып, бер-берсенең сөйләгәннәрен тыңлый торган булганнар.

Авыл җыеннарын да каравыл өе янында үткәргәннәр. ...Мир үгезе Борис картайды. Ул артык юашлана, сүлпәнлек күрсәтә. Абзарыннан чыгарып җибәргән очракларда тыныч кына үлән ашап, яткан урынында сәгатьләр буе йоклый иде. Соңгы елларда аның коточкыч кыяфәтеннән малайлар да курыкмый башладылар, кыюраклары янына килеп, үлән җыеп бәйләгән себеркеләрен селкеп, Борисның корсак астындагы чебеннәрне куалар. Караңгы төшкәч, каравылчы Рюриков килеп алмаса, Борис үзе акрынлап каравыл өенә кайта иде. Кайбер көннәрдә аның турында бөтенләй оныталар, ул көндез йоклаган җиреннән иртән генә аякларына торып баса, хатыннар көтү куганда сыерларны күзәтеп кала...

Менә шул, Борисның бер төн эчендә кылган "батырлыгы" тирә-як авылларда яшәүче татарны-урысны шаккатырды. Ләкин ул "батырлык" ике милләтле Янгилде авылы халкы арасында төрлечә бәяләнде. Татарлар (ул вакытта көчләп чукындырылган мәкруһлар) өчен Борис—"герой", ә урыслар өчен Борис "антихрист" иде.

Бу хәл 1846 елның 19 июнендә була. Борис, көне буе урамда йөреп, яхшы гына ашагач, чишмәгә төшеп су эчеп менгән. Сатмыш авылы ягындагы басу капкасыннан 5-6 метр кырыйдарак 14 ел буе торган, кара дегеткә буялган агач тәре янына ятып йоклый. Муенчагыннан сөйрәлгән 3-4 метр озынлыкта юан арканы да үзе белән була.

17 яшьлек Мөхәммәтсабит һәм мир үгезе Борис күптәнге танышлар. Мөхәммәтсабит аның яшьрәк, усал чакларын, кан баскан коточкыч күзләрен акайтып тирә-якка карап, ямьсез тавышлар чыгарып үкергәнен, аяклары, мөгезләре белән җир актарганын яхшы хәтерли иде.

Мөхәммәтсабит күптән ниятләгән кыю эшен бүген шаһитларсыз, берүзе башкарырга уйлады. Моментны кулдан ычкындырмаска булды. Үгезнең тәре янында ук ятып йоклавы аның өчен бигрәк тә кулай иде. Ләкин әле караңгы төшмәгән. Шуңа күрә ул өенә кереп чәй эчеп чыгарга уйлады, кеше күзенә чалынмаска тырышты.

---

*Дәвамы. Башы 2008 елның 11 санында.*

Авыл халкы кайтмый калган бәрәннәрен, бозауларын эзләп табып алып кайткач, кичке урам чирәмдә йөгерешеп алҗыган малайлардан тынгач, Сабит үгез янына килде дә, муенындагы юан бауны сүтеп, аның икенче башын ике метр биеклектәге агач тәренең аскы өлешенә бәйләп куйды. Аннан соң үзе белән алып килгән тал чыбыгы белән ул тыныч кына койрыгын селкеткәләп йоклап яткан үгезнең аркасына сыдырды да "һап" дип кычкырды, үзе шапылдап җиргә сикерде. Үгез куркып, кинәт сикереп торды да, тонналы гәүдәсе белән алга ыргылды һәм тәрене җиргә беркетеп куелган тартмасы, казыклары белән җирдән йолкып алып, читән-коймаларны вата-җимерә караңгы урам буйлап каравыл өенә, үзенең абзарына таба чапты.

Ул, атлаган саен аякларына бәрелгән тәредән куркып, ярсыган хәлдә ачык капкадан абзарына кереп китте. Тәре, капка баганаларына аркылы килеп, шартлап сынды. Искергән каравыл ызбасы дер селкенеп куйды. Рюриковның яңа гына йокыга киткән чагы иде. Ул, аңышмыйча, өйдән атылып чыкты. Шартлап сынган тавыш каравыл өе янында яшәгән урыс крестьяннарына да ишетелде, тик аларның урамга чыгарга йөрәкләре җитмәде. Рюриков караңгы төндә бернәрсә дә абайламады, чөнки ул вакытта электр лампасы түгел, керосин лампасы да юк иде. Каравылчы чыккан ишегеннән ерак китмәде, тезләре калтыраудан атлый алмас булып, агач бүкән өстенә утырды.

Җәйге төн кыска. Тиз яктыра. Шул вакытта гына Рюриков эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алды. Көтү куарга чыккан хатын-кызлар да күреп алдылар. Аларның тавышына каравыл ызбасы каршындагы өйләрдә яшәгән урыс крестьяннары йөгерешеп чыкты. Әле кичә генә басу капкасы янында ыржаеп басып торган тәрене мәсхәрә хәлендә күреп аптырап калдылар. Йоклап калган бала-чагадан гайре бөтен авыл халкы тиз арада каравыл янына җыелды. Түбән очтан менгән татарлар бу хәлне күреп чиксез шатланды, урыслар һәм аларның хатыннары исә чукынуларын дәвам иттеләр.

Авыл старостасы урыс Алексей Иванов куркуга төште. Ул җавап тотачак бит. Староста Ефим Сафроновның улы Фёдорга тиз арада атына атланып урман аша Колангыга, Петропавел чиркәве побы Виктор Охотин тарафына ашыгырга, булган хәл турында аңа җиткерергә кушты. Үзе авыл халкын тынычландырырга керешге. Староста ат арбасына менеп басып "Авылдашлар, без барыбыз да христианнар..."—дип сүз башлау белән, мәкруһлар шауларга керештеләр: "Нишләп без христиан булыйк, без христиан түгел, без—Мөхәммәт өммәтләре, җаныбыз-тәнебез белән мөселманбыз, мөселманнар",—дип кычкырышып, арбада басып торган старостаны сөйрәп төшерделәр. "Көчләп Имәлле суына куып кертеп, башыбызга себерке белән су бөркәүне чукындыру дип белдегезме? Юк, без мөселманнар! Исемнәребезне бозып, урыс исемнәре таккансыз икән, без алардан баш тартабыз",—дип шаулауларын дәвам иттеләр, һәркем үзенчә берәр сүз әйтергә кирәк дип тапты. Халык котырынган бүре өерен хәтерләтә иде.

Шул арада җирән айгыр җигелгән тарантаска утырып Охотин үзе килеп җитте. Аның белән тагын дьяклар Алексей белән Александр Петровлар да килгән иде. Алексей—кучер урынында, Александр—поп янәшәсендә.

Бу ике бертуган дьякларны Охотин беркайчан да үзеннән калдырмый. Беренчедән, алар ышанычлы җансакчылар булсалар, икенчедән, поп аларны юлда, йә булмаса барган авылларда четерекле хәлләр килеп чыкканда, шаһитлар итеп файдалана иде.

Колангыдан килеп җиткән попны күргәч, җыеннарда сүзгә катнашмаучы кешеләр дә зарланырга керештеләр: "Ни җитми икән бу патшага? Иманасын түлибез, солдат бирәбез, урыс күршеләребез белән тату яшибез. Безнең түбәтәйләргә нигә каныга, нишләп үз динебезне тотарга ирек бирми? Урам саен, кизләү саен кара тәре кемгә кирәк? Алардан кешеләр түгел, хайваннар да куркып качалар",—диештеләр. Мир үгезен мактадылар. Янәсе, ул хайван булса да, авыл халкына тәреләрдән котылу юлын күрсәтте. "Ватабыз, җимерәбез!"—дип кычкырдылар. Арттан кемдер: "Ни файда, бүген ваттык икән, иртәгә имән агачыннан ясап, яңаны куярлар",—диде. "Куйсыннар, балтам белән теткәләп бетерәчәкмен, калганнарына ут төртәчәкмен!",—дип җикеренде авылның түбән очында яшәүче җитмешне узган Сафиулла бабай. "Җәмәгать,— дип сүз алды аның улы Гайнулла, — Болай шаулап мәгънә юк. Безгә бер белемле кеше яллап, үз динебезгә кайтуны сорап, "Высочайший" исеменә хат язырга кирәк", — диде. Халык һаман шаулаша иде: "Без болай да үз динебездә. Без мәкруһлар, беркайчан

да православиене кабул итмәячәкбез. Без мөселманнар!" – дип кычкырдылар.

Көтмәгәндә килеп чыккан бу җыен идарә итеп булмаслык митингка әйләнеп бара иде. Урыс авылдашлар да кайтып китмәделәр (поптан курыктылар булса кирәк), алай да сүзгә кушылмадылар, каравыл өенең бер почмагына барып бастылар. Поп алар янына барып, чукындырырга кереште, урам уртасында таралып яткан таныш агач тәрене күреп, өнсез калды. Ул, җирән озын сакалын учлап, уйга чумды, кайсының батырлыгы җитте икән дип, урыныннан кузгалалмый басып торды. Аннан, староста Алексей Иванов белән каравылчы Николай Рюриковны чакырып алып: "Бу тәре гади тәре түгел, ул күп мәртәбә освящён. Әлегә Рюриковның ишек алдына пөхтәләп җыеп куегыз. Соңыннан кая куярга кирәген үзем әйтермен",—диде.

Поп, уеннан айнып, халыкка таба борылды. Йөзләгән кешенең ник берсе аңа әйләнеп карасын, тулы битарафлык хөкем сөрә иде. Бу хәл Янгилде татарларының мөселман диненә кайтуын, мәкруһларның попны санга сукмавын күрсәтә иде.

Янгилде авылында тәрене ватуда шик уятырлык бер генә кеше бар иде. Ул да булса Әҗәле авылыннан күчеп килгән мәкруһ Иванов-Мөхәммәтсафа. Хәер, ул үзе андый эшкә бармас, яше җитмештән арткан, улы Иван-Шәрәфетдин дә иллене узган, ул да эшләмәс. Менә алар тәрбияләп үстергән унҗиде яшьлек Василийдан барын да көтәргә була.

Охотинның үгез белән бәйле тәре тарихын халыкка булганча җиткерәсе, кемнедер "заман герое" итәсе килмәде. Болай дип аңлатты ул: каравылчы үгезне ныклап карамаган, муенындагы бавы чишелгән дә сөйрәлеп барган, шул бауның икенче башындагы төен тәренең аскы аркылы агачына кереп кысылган, үгез нәрсәдәндер курыккан, кинәт тартылган да тәренең казыкларын йолкып чыгарган.

Болай ялганлау тикмәгә түгел иде. 1846 елның 19 февралендә Ходяшево авылы чиркәвенең яшь прихожаннары, чиркәүдән Спаситель иконасын алып чыгып, чиркәү коймасына салып мәсхәрәлиләр. Приход руханиеның эше Казан консисториясендә карала. Моңа охшаш вакыйгалар Зөя өязендә күбәя бара. 1834 елдагы чукындырулардан соң тулы бер буын яшьләр үсеп җитте. Алар бала чакларында попларның, чиновникларның татарларга карата вәхшилекләрен хәтерлиләр. Ләкин яшьләр мәсьәләгә саерак карыйлар, барлык явызлыкларны тәреләрдән күрәләр, аларны төрлечә мыскыллап, зыян салырга тырышалар.

Поп Охотин каравыл өе янындагы җыелган халыкка вәгазь укырга кереште, ләкин аның сөйләгәнен беркем дә тыңламады. Поп сүзен кыскартып, дьякларын да тарантаска утыртып Колангыга кайтып китте. Кайтышлый калган алты тәрене карап чыкты, староста Алексей Ивановка аларны яхшылап карап торырга кушты...

Әмәйгел әбием сөйләвенчә, тәреләрне авылдаш урыслар саклаган. Үгез белән бәйле вакыйгадан соң берничә мәртәбә тәреләрне ватып юкка чыгарсалар да, Колангыдан яңаларын китереп куйганнар. Бу гамәлләр Октябрь инкыйлабына кадәр кабатланып торган.

## Сабитның үсмер чагы

Патша хөкүмәте, чиркәү руханилары һәм миссионерлар алып барган чукындыру вәхшилекләре—татарларны урыслаштыруның бер буыны гына. Тулысынча христиан итәр өчен даими рәвештә христиан гыйбадәтен кылырга мәҗбүр итәргә кирәк була. Гыйбадәт кылмаган мәкруһлар өчен мәхшәр көннәре башлана. Аларны көчләп чиркәүгә алып бару, кыйнау, вәгазьләр сөйләү, өй почмакларына икона куйдыру һ. б. кин җәелә.

Янгилде авылы мәкруһлары аеруча көчле контроль астына алына. Янгилде, Аккужа, Салтыган авылындагы хәлләр белән Казан архиепискобы Антоний үзе кызыксынып тора. Ул, әлеге авылларның милли яктан катнаш булуларын истә тотып, аларның халкы христиан динен башкаларга караганда алдарак үзләштерергә тиеш дип исәпли.

Бу эшне Ивановск волосте старшинасына йөклиләр. Аның хезмәт хакын арттырып, Янгилде авылында чатнап торган нарат бүрәнәләрдән ике катлы өй салып бирәләр. Ул йорт авылның арт урамының аскы өлешендә урнашкан була. Старшина соравы буенча, аның ышанычлы ярдәмчесе Петрга (Лука Питашка)

да нараттан йорт җиткерәләр. Ул да Янгилдегә күчә. Бу йорт аеруча зур итеп эшләнә, чөнки анда "инородецлар"ның балалары укырга тиеш булалар. Ул гына түгел, волость старшинасы Зоя өязе исправнигыннан 4 жандарм сорап ала. Бер караганда, 70 йортлы, урыс белән татар катнаш авылдан беркая да качып котылып булмас кебек тоелса да, татарлар арасында христиан гыйбадәте кылган кеше юк дияргә була. Колангының Петропавел чиркәве тарафыннан таратылган, әле буяулары да кибеп өлгермәгән иконаларны өй почмагына куючы табылмый. Урыслардан куркып, кайбер авылдашлар өйләрен тәреләр, иконалар белән нәҗесләндерә калсалар, аларны авыл үсмерләренең адәм көлкесенә калдырырлык җәзасы көтә. Урыслар өянкегә асылып куелган чаңны кага башласалар, авыл яшьләре, авылның икенче башындагы өй башына менеп, аларны да уздырып иске чиләк төпләре кагалар.

1834 елда яңадан кабатланган чукындыру чараларыннан соң Янгилде һәм Чүкри-Алан мәкруһларын һәр якшәмбе саен Колангы чиркәвенә христианча гыйбадәт (келәү) кыларга көчләп алып баралар. Петропавел чиркәве приходына караган башка авылларда яшәгән мәкруһларны һәм керәшен дип саналган татарларны да шундый ук язмыш көтә.

Зур (хәзер Урта) Колангы авылы һәм Янгилде арасы 5 чакрым чамасы. Аның дүрт чакрымлабын урман эченнән барасы. Менә шул араны җәяүләп баручы бала-чагалар, хәтта олы яшьтәге авылдашларның күп өлеше урманны чыкканчы качып бетәләр. Поплар жандармнар ярдәмендә дә максатларына ирешә алмыйлар. Чиркәүгә йөрүче булмый. Көчләп алып барылган кешеләр дә, поп чукындырылган су бөркегән арада, күзләрен кырыйга алып, "Әстәгъфирулла... тәүбә, тәүбә" дип кабатлап торалар. Бу турыда сатлык җаннар попларга җиткерәләр. Тегеләр тәреләргә туры каратып, "келәү"не кычкырып кыларга кушалар. Алай да барып чыкмый, мәкруһлар догаларны иреннәрен селкетмичә генә укыйлар.

Поплар, патша хөкүмәте нинди генә чаралар күрмиләр, куркыту юлыннан сөйләшүләргә дә күчеп карыйлар, җирләрен арттырырга, салымнарга ташлама ясарга вәгъдә итәләр. Шулай да, "келәү"гә берәү дә бармый. Ләкин вакыт үзенекен итә. Кайбер йомшак ихтыярлы, куркаграк авылдашлар, попларның буш сүзләренә ышанып, чиркәүгә барырга ризалык бирәләр. Андыйларны Мөхәммәтсабит җитәкчелегендәге яшьләр төркеме урман эчендә көтеп ала. Аларның яшеренеп торган урыннарын әби миңа җиләккә баргач күрсәтә иде. Шундый урыннарның берсе—Бәхтияр чокырының урман эченнән башланып киткән өлеше. Беренче мәртәбә чиркәүгә баручыларны кисәткәннәр, кабат баручыларның арт сабакларын укытканнар. Чиркәүгә баручыларны озата баручы жандармнар да яклап кала алмаганнар.

Соңгы айларда, Мөхәммәтсабитның Чүкри-Алан авылы яшьләре белән сөйләшүләр алып баруы нәтиҗәсендә, уннан артык яшүсмер килеп кушыла. Аларның исем-фамилияләре ачыкланды: Тимергали Әхмәрев, Нигъмәт Ибраһимов, Фәткулла Самиков, Ильяс Мөхәммәтҗанов, Әхмәт Әбтишев, Идрис Габдерахманов, Вәлит Әбдриев, Бикмөхәммәт Бикшамәтов (әнием ягыннан дәү бабам), Җәкуб Нәҗметдинов, Хатыйп Әбдриев, Сибгатулла Әбдриев. Кызганычка каршы, Янгилде авылы үсмерләренең татарча исем-фамилияләрен хәзергә ачыклап булмады. Аларның урысча кушаматларны бу язмада искә алуның кирәге юктыр дип саныйм. Әйтеп киткәнемчә, Мөхәммәтсабитның да исеме Василий Иванов дип бирелгән.

Сабитның әтисе Шәрәфетдин белән бабасы Мөхәммәтсафа улларына бу эштән тукталып торырга киңәш бирәләр: "Болай да үзебезнең мөселман авылдашларын урыс диненнән ничә мәртәбә йолып алдың, бу болай да изге эш. Кылган гамәлең белән урыс түрәләрен аякка бастырдың, борчуга салдың, Чүкри-Алан, Янгилде мәкруһларын, Мөхәммәт өммәтендәгеләрне шатландырдың, күбесен канатландырып. Ә хәзер, Янгилде өстендәге урманда урысларның мәсхәрәләүләреннән качып ятучы качкыннар янында вакыт уздырырсың, тынычлангач, кайтырсың",—диләр. Сабит әтисе белән бабасының үгетләүләренә карамый, үзен кулга алачакларын белә торып, өендә кала.

Казан архиепископы Антоний ашыгыч рәвештә Колангы побы Виктор Охотин белән элемтәгә керә, Зоя өязе полиция идарәсе башлыгына кичектергесез чаралар күрергә кушыла. Христиан динен чын күңелдән тотмаган, үзләренең урыс исемнәрен белмәмешкә салышкан һәм башка керәшеннәргә гыйбадәт кылырга комачаулаган өчен 27 яшүсмер каравыл ызбасында 12шәр мәртәбә камчы белән

суктырыла. Әлбәттә, мондый хәл тавышсыз гына узмаган. Архиепископ Антоний андый очракларда халыкны каравыл ызбасы янына җыя. Үсмерләрнең камчы төшкән саен авыртуга чыдый алмыйча кычкырулары, аларның халык арасында басып торган әти-әниләренең кайгырулары, Казан губернаторы әйтмешли, "для большой огласки" кирәк була.

Янгилде һәм Чүкри-Алан яшүсмерләре төркеме белән җитәкчелек иткән Мөхәммәтсабитны Федоровское волосте идарәсенә алып китәләр. Анда аңа 20 мәртәбә камчы белән сугалар. Аннан соң аны Федоровское авылы каравыл өендә өч көн, өч төн ябып тоталар.

Каравыл өендә Сабит берүзе генә булмый, ул анда Аккуҗа (Азбаба) авылыннан өч яшь егет белән очраша. Алар Мөхәммәтсабитның фикердәшләре булып китәләр. Шатлыгыннан Сабитка аркасындагы җәрәхәтләрнең авыртулары да басылган кебек тоела. Иң мөһиме—хәзер ул үзе генә түгел. Бу яшь мәкруһларның исемнәре—Әбраретдин Рәхмәтуллин (Иван Петров), Габделхәбир Зиннәтуллин (Антон Иванов), Хәкимулла Талипов (Николай Никитин).

Аккуҗа яшүсмерләренең Федоровск волосте идарәсенә (Зөя өязе) килеп эләгү сәбәпләре дә, Мөхәммәтсабитныкына охшаш булып чыга. Алар да үз авылларында миссионерларның буш сүзләренә, попларның вәгазьләренә ышанган кайбер авылдашларын Ивановское авылы чиркәвенә бармаска үгетлиләр. Шулай да, куркаклар табыла, сирәк булса да, чиркәүгә баралар. Янәсе, алар гыйбадәт кылганда тәреләргә, иконаларга карамыйлар, поп вәгазь укыганда тыңламыйлар йә булмаса колакларына мамык тыгып баралар.

Чиркәүгә үз теләкләре белән йөрүчеләр арасында отставкадагы солдат Хәкимуллинның күптән түгел генә өйләнгән абыйсы да була. Аның урысча исем-фамилиясе—Антон Никитин. Антон Никитинның баласы туа, аны чукындырырга уйлап, Колангы чиркәве побы Виктор Охотинны чакыра. Энесе Хәкимулла Талипов гарьләнә, попны өйләренә кертми. Авылда яңа туган балалар берничә булуга карамастан, башкалар әнә попны чакыру түгел, хәтта капкаларын бикләп үк куялар.

Әлеге өч егет, Аккуҗа авылы мәкруһларын Ивановское авылы чиркәвенә барудан тыю нияте белән, Зөя елгасын кичү урынында чылбырларга бәйләп куелган көймәләрне, очлы тимер белән төпләрен тишеп, суга батыралар. Зөя елгасы ул заманда тулып аккан, ягъни аны көймәсез кичү мөмкин булмаган.

Аккуҗа авылында ике милләт, ике төрле дин вәкилләре яши: христианнар (чуашлар) һәм мәкруһлар (татарлар). Чуаш авылдашлары Федоровское волосте старшинасына зарланалар. Ике-өч көн эчендә Әбраретдин, Габделхәбир һәм Хәкимулланы Федоровское каравыл ызбасына ябалар. Шунда алар Мөхәммәтсабит белән очрашалар һәм гомерләренең соңгы көннәренә кадәр бергә булалар. Дүртесен дә Туруханск краена сөрәләр. Алар ислам дине, әти-әниләренең гореф-гадәтләре өчен гомерләре буе көрәшәләр, урысларга иманнарын аяк астына салып таптарга ирек бирмиләр.

## Татар Әҗәлесе һәм Карашәм

Кечкенә чагында Сабитның, ат җигелгән арбага утырып, бабасы Мөхәммәтсафа белән туган авылы Янгилдедән 17 чакрым арада урнашкан Татар Әҗәлесе авылына, берничә мәртәбә килгәне була. Үз гомерендә беренче тапкыр мәчетне дә шунда күрә. Хөсәен җизнәсе белән Нәсимә апасы аны мәчетнең эченә алып керәләр. Шунда беренче мәртәбә азан моңын тыңларга насыйп була. Мәдрәсәдәге шәкертләр Янгилде авылындагы кебек эчтән капканы бикләп куеп, качып-посып түгел, ә иркенләп, гөжләп сабак ятлыйлар. Мәчет катындагы зур гына ишек алдына салынган мәдрәсәнең бинасы да ярыйсы гына. Ул заманда парталар юк әле. Сабитлар кергәндә, малайлар көрси дигән озын тар тәбәнәк өстәл артына тезләнгәннәр, сыймаганнары аяк бөкләп идәнгә утырган. Сабакларын ачып салганнар да, төрлесе төрлечә гөжләп, сабак ятлый. Сабитның бабасы намаз артыннан укый торган Ясиндагы сүзләр ишетелеп киткән кебек була. Арада Нәсимә апа белән Хөсәен җизнәләре урамында яшәгән малайлар да күп. Ләкин бүген алар Сабитка ниндидер ят, акыл ирешмәс өстен, укыганнары кебек үк изге, башка дөнья кешеләре булып күренделәр. Сабитның да тизрәк шулар янына тезләнеп, шул изге, тылсымлы сүзләрне ятлый-ятлый селкенәсе килде. Ләкин Хөсәен җизнәсе: "Киттек, каениш, шәкертләргә комачауламыйк",—дип Сабитны

җитәкләп алып чыгып китте. Шуннан соң шактый вакытлар үтте. Сабитның да яше егермегә җитте.

1850 елда Рәсәй буенча чираттагы халык санын алу чарасы узды. Ләкин чиркәү руханилары кулындагы ревизия кенәгәләрендә бер генә мөселман исеме дә артмады. Әйтеп киткәнемчә, Янгилде авылы тулысынча православиедә дип саналды.

Нәсел шәҗәрәсе Татар Әҗәлесе авылыннан башлангангамы, әллә бабасы Мөхәмметсафаның һәм әтисе Шәрәфетдиннең туган авыллары булгангамы, балачагының шактый өлеше Татар Әҗәлесендә һәм күрше Карашәм авылында узгангамы, Нәсимә исемле бертуган өлкән апасы Татар Әҗәлесендә, иң кече Миңлеҗамал апасы 3 чакрымга ераграк урнашкан Карашәм авылында тормышта булулары сәбәбеннәнме, туганнарының ачык йөз белән каршы алулары тәэсиреннәнме, Сабит аларның үзенә тарту көчен сизә, бер сүз белән әйткәндә, Татар Әҗәлесе һәм Карашәм авылларын ул туган авылы кебек якын күрә иде.

Казан губернасының Зөя өязенә кергән бу Татар Әҗәлесе белән Карашәм, кешеләренең шактый өлеше мөселманлыкка кайткан булсалар да, шул көнгә кадәр мәкруһ авыллары булып саналалар. Һәр ике авылда да мәчет һәм мәдрәсә бар. Алар икесе дә Татар Әҗәлесе җәмигъ мәчетенә карыйлар.

Урыс хөкүмәте, чиркәү руханилары тарафыннан Татар Әҗәлесе белән Карашәм авыллары халкы әлегә "крещеные татары" булып, урыс исемнәре белән язылалар. Татар Әҗәлесе авылыннан өч чакрым, ә Карашәмнән бер чакрымдагы Паново чиркәве приходында саналалар.

Татар Әҗәлесе белән Карашәм авылларында, Сабит уйлаганча, мөселман динендәге татарлар һәм җаннары-тәннәре белән мөселман булып та, христиан динендә саналган мәкруһлар гына түгел, нәсари (христиан) диненә табынган татарлар—керәшеннәр дә яшиләр икән. Болар—"новокрещеный"лар арасыннан попларның вәгазьләренә ышанган, ихтыяр көчләре булмаган татарлар. Авыл халкы андыйларны сатлык җаннарга тиңли.

Сабит һәм аның өч фикердәшенә Зөя өязе авылларында мәкруһлар арасында мөселманлыкка кайтуны күбәйтү бурычы куелган иде. Алар дүртесе дә төрле авылларга барып, яшерен җыеннар үткәреп, күрше авыллардагы хәлләр турында сөйлиләр. Авыл мәкруһларын курыкмаска, урысның, чиркәү руханиларының вәгазьләрен тыңламаска өйрәтәләр.

Аттан гайре транспорт булмаган ул заманда төрле яңалыклар, авыллардан чыгып китү яки чит авыл кешесенең авылга килүе дә авыл халкы арасында зур кызыксыну уяткан. Янгилдедән Татар Әҗәлесенә 17 чакрымлы юл гади генә булмаган, чөнки берничә авыл, шул исәптән, Колангы, Фёдоровск һәм Паново чиркәүләр приходы аша узасы. Басу капкасыннан керүгә, таныш булмаган юлаучыга шул авылның урам этләре өерләре белән ташланалар, урыс малайлары "желудь, желудок, чаплашка, гололобый",—дип узып баручының артыннан ташлар атып, басу капкасыннан чыгып киткәнче "озатып" калалар. Көчләп чукындыру вакытында узып барган юлчыны чиркәүле авылларда чиркәүгә алып кереп чукындырып та чыгарганнар. Мәкруһ булганда аңарга христиан гыйбадәте кылдырганнар.

Мөселман саналган татар авыллары аша үткәндә исә, олы яшьтәгеләр өйрәтүе буенча, әлбәттә, бала-чага "игътибарына лаек" булганнар. Алар авылның бер басу капкасыннан икенчесенә кадәр: "Янгилде керәшене, Янгилде керәшене",—дип юлаучы артыннан кычкырып калган. Сабит Татар Әҗәлесе белән Карашәм авылларына килүне тагын да ешайта. Мөхәмметсафа бабасы тарафыннан аның өчен махсус тәрбияләнгән кара төстәге биясенә атланып, юл өстендә урнашкан авылларның күбесен кырыйлабрак узып, бер-ике сәгать эчендә килеп җитә торган була.

Ул Татар Әҗәлесе белән Карашәм авылларының мәкруһлары белән җыенда да очраша, бергәләп мәкруһлыктан мөселманлыкка кайту юлын эзлиләр. Шул җыенда ук властьларга каршы торырлык, йә булмаса, алар белән сөйләшә алырлык кешеләр арасыннан башлыклар сайлап куялар. Карашәм авылы буенча Гали Фәсхиевне (Иван Егоров) сайлыйлар. Татар Әҗәлесендә, Сабитның тәкъдиме белән, җизнәсе—Габдрахманов Хөсәенне сайлыйлар. Ул мөселманлыкка кайткан була, киләчәктә яңа оештырылган оешманың җитәкчеләре элемтәне Сабит аша тотарга килешәләр. Губерна, өяз буенча барлык яңалыкларны һәм башка мәгълүматларны да Сабит җиткерергә тиеш була.

Татар Әҗәлесе белән Карашәм мәкруһлары Сабиттан Зөя өязе авылларында керәшеннәрне яңадан мөселманлыкка кайтару буенча хәрәкәт җитәкчесе Габделлатыйф Алкинга үзләренең зарларын җиткерүне үтенәләр һәм булышуын сорыйлар.

## Сабитның гашыйк булуы

Сабитның, бигрәк тә соңгы араларда, атнага икешәр мәртәбә Янгилдедән Татар Әҗәлесе авылына килүенең башка сәбәбе булуы да ачыклана. Ул үзе белән бер яшьтәге Татар Әҗәлесе чибәре Мәхүпҗамалны күзәтеп йөри. Хәер, кызны ул балачакта, бабасы белән килгән чагында ук күргәләгән. Татар Әҗәлесе белән Карашәм авылларында чибәрләр күп булса да, Мәхүпҗамалдан башкасын ул күрми, матурлыгы, тыйнаклыгы, сабырлыгы белән аерылып торган кызга гашыйк була. Аларның яшәгән өйләре дә Нәсимә апаларыныкыннан ерак түгел. Сабит белән Мәхүпҗамалны беренче мәртәбә хатлар языштырып таныштыручы, хатларын тапшыручы да Нәсимә апасы була. Хатлар аша сөйләшү кыз белән егетнең очрашулары белән дәвам итә. Сабитның Нәсимә апасы үзе дә күптән түгел Татар Әҗәлесенә Янгилдедән килен булып төшкән. Аны димләп биргәннәр. Шуңа күрә ул Сабит белән Мәхүпҗамалның очрашуларын зур бәхеткә саный. Төрлечә булыша. Хөсәен җизнәсе Сабит белән Мәхүпҗамалны берничә мәртәбә Татар Әҗәлесе һәм Карашәм авыллары арасында урнашкан Карашәм күле буена алып бара. Ике калкулык арасына сыенган бу күл элек ике күл арасындагы ызанга туры килгән. Күл Карашәм авылы ягына кереп калган. Ул бик тирән, төбендә көчле чишмә булган. Күлнең бер ягы җылы, икенче ягы салкын сулы. Күлгә коенырга сирәк төшкәннәр, чөнки батып үлүчеләр булгалаган. Бу күл хәзерге заманда да үзенең матурлыгы белән Татар Әҗәлесе һәм Карашәм авыллары тирәсен бизәп торучы бер табигать һәйкәле булып санала. Әлегә болынлыклар, чәчәкләр, печәнлекләр, дүрт күл дә, аның тирәсендәге сазлык, куаклыклар да исәннәр, кайтыр-китәр кошлар да парлашалар, үз телләрендә мәхәббәтләрен аңлаталар. Сабит белән Мәхүпҗамалның да мәхәббәтләре һәркем сокланырлык. Алар Карашәм күле буенда вәгъдәләшәләр. Мәхүпҗамал Сабитына, вәгъдә билгесе итеп, үз куллары белән чиккән кульяулыгын һәм чәчләрен бәйләгән бизәкле чулпыларын бирә.

1851 ел була бу. Мөселманча никах укуны бер генә мулла да үз өстенә ала алмый, куркалар. Бердәнбер ышаныч кала—Сабитның бабасы Мөхәммәтсафа. Ул үзенең өч оныгын—Сабитның бертуган апаларын никахлап кияүгә бирде. Авылда беркем дә белми калды. Чөнки моның куркыныч ягы бар иде. Мөселманча никахлашу татарлыкка, мөселманлыкка кайту омтылышы дип санала. Мәсәлән, 1593 нче елның 18 июлендә игълан ителгән, һаман әле гамәлдә булган патша грамотасында өйләнергә теләүче егетнең вазифалары да берәм-берәм саналып кителә. Мәсәлән, ул христиан кануннарын төгәл үтәргә, өендә икона тотарга, тәре тагып йөрергә, марҗа яки чукынган кыз белән генә никахлашырга тиеш.

Мөхәммәтсафа белән Шәрәфетдин Татар Әҗәлесе авылында гомер кичергән туган тиешле Сәхипҗамал әбине, Янгилдедә кунакта булуына карамастан, Татар Әҗәлесе мәкруһы Садретдин Ибраһимов йортына, кызлары Мәхүпҗамалны Мөхәммәтсабитка димләр өчен алып киләләр. Мәхүпҗамалның әти-әнисе һәм туганнары Сәхипҗамал абыстайны якты чырай белән каршы алалар. Аны түр сәкедәге мендәргә утыртып, чәй белән сыйлыйлар.

Сәхипҗамал абыстай, кызның әтисе Садретдин белән килешеп, Мәхүпҗамалны аш әзерли торган почмакка кертеп җибәрә. Егеткә дә башка бүлмәдә көтәргә куша. Үзе догаларын укып, кызның әти-әниләренә саулык-сәламәтлек теләп, Садретдин йорт бусагасын атлап керүенең сәбәбенә күчә. Хуҗалар әдәп саклау йөзеннән ризалык бирмиләр. Егетнең әти-әнисе Шәрәфетдин белән Миңлекамал сүзгә кушылганнан соң гына кызның әтисенең риза булуы ачыклана. Әти-әниләр башлангыч килешүгә ирешкәч, егет белән кызны да табынга дәшәләр.

Ике як та туйга әзерләнә башлый. Егетнең әтисе Шәрәфетдин белән кызның әтисе Садретдин көн саен диярлек йә Янгилдедә, йә Татар Әҗәлесендә күрешеп, фикер алышып торалар. Кыз белән егет тә кул кушырып утырмыйлар. Мөхәммәтсабит Мәхүпҗамалга төрле тормыш кирәк-яраклары әзерли. Кайсыларын үз кулы белән эшли, булдыра алмаганнарын осталардан ясата, йә булмаса базардан сатып ала. Кыз егеткә һәм аның туганнарына төрле бүләкләр әзерли. Үзе тегә, үзе чигә. Чиккәндә якын дуслары булыша.

Мөхәммәтсабитның хәтерендә, Нәсимә апасын алырга килгән Хөсәен жизнәсе аңа, ачылып-ябылмалы агач саплы пәке бүләк иткән иде. Шундый ук бүләкне булачак каенишләре Гыйлаҗи белән Минаҗыйга тапшырырга үзенә дә чират килеп җитә.

Никах мәҗлесе Татар Әҗәлесе авылында, булачак кодалары Садретдин Ибраһимов өендә уза, алдан сөйләшкәнчә, никахны Мөәммәтсафа бабай укый. Мәҗлескә килгән кунаклар барысы да сыеша һәм буш урын да калмый. Никах мәҗлесе барганда өйдән бер кеше дә чыкмый, шулай ук керми дә. Авылдан 3,5 чакрымда гына урнашкан Паново чиркәве руханилары һәм аларның шымчылары йортта мөселманнарча никах мәҗлес уздырганны сизмәскә тиеш була.

## Туй мәҗлесе

Мәкруһлар никах укытуны зур җаваплылык тоеп җиренә җиткереп башкарганнар. Күп очракта өйләнешүләр никах белән генә чикләнгәндә, туй үткәреп тормаганнар. Мондый хәл керәшен булып саналган татарлар арасында мөселманлыкка кайтучыларның азрак булулары белән аңлатыла. Мәкруһларның саны арту белән, урыс тарафыннан тыелган гореф-гадәткә таянып барлыкка килгән йолаларны кире кайтаруны таләп итүләр дә арта. Шуларның берсе: мәкруһлар зур саклык белән генә күптән онытылган туй мәҗлесләрен уздыра башлаганнар. Килен каршылау, күңел ачу, төрле уеннар авыл халкына сиздермичә генә уздырылганнар.

Мөхәммәтсабитның әбисе Хәдичә (1780 елда туган) үзенең килен булып төшкән чакларын, кайнанасы котлау сүзләренең берсен дә онытмыйча, күңелендә саклаган була. Оныгы Мөхәммәтсабит белән яшь килене Мәхүпҗамалга бәет көенә шуларны туйга килгән кунаклар алдында җырлап күрсәтә:

*Кыңгыраулар чаң кага,*
*Урамнарда чаң кала.*
*Ике яшьнең матурлыгына*
*Бөтен дөнья таң кала.*
*Атларыбыз, атларыбыз*
*Канатлы чаптарыбыз;*
*Безнең дә булыр икән*
*Киленле чакларыбыз.*
*Әй, ай батсын, ай батсын,*
*Кызарып таңнар атсын.*
*Тулган айдай яшь киленне*
*Туганнарыгыз яратсын.*

Сабитның бабасы Мөхәммәтсафа да, Хәдичә әбидән калышмыйча, хәтерендә калган сүзләр белән йортка килен төшү шатлыгын туй кунакларына җиткерә. Ул такмак яшь киленне котлау дип атала:

*Исән генә килдеңме, балам?*
*Ак күңелдән сиңа котлау салам:*
*Төкле аягың белән, талмас кулың,*
*Таймас табаның белән кил!*
*Юраганың юш булсын,*
*Янгышагың юл булсын*
*Курыкканың куш булсын,*
*Эшең, көнең уң булсын.*
*Йөзең айдай,*
*Сүзең балдай,*
*Күңелең майдай булсын!*
*Арысландай алты батырың,*
*Җиләктәй җиде матурың тусын.*
*Батырларың мал тапсын,*
*Алтының алтындай игелеген,*
*Җиденең ефәктәй изгелеген күреп картай.*

Мөхәммәтсафа бабай, улы Шәрәфетдин, аларга кушылып, Сабитның фикердәшләре: Аккуҗадан Әбраретдин, Габделхәбир, Хәкимулла һәм Габделлатыйф Алкин (1817 елгы) яшь киленгә теләк әйтәләр:

*Алгы итәгеңне бала бассын,*
*арткы итәгеңне байлык бассын!*

Сабит белән Мәхүпҗамалның туен, фикердәшләре, дуслары һәм туганнары тәкъдиме буенча, ишек алдында чирәмдә бөтен авыл катнашында уздырырга карар кылына. Бу хәл Янгилде авылында 1851 елның июнь аенда була.

Бу көнгә кадәр беркемнең дә чиркәү "святоша"ларын санга сукмыйча,

гөрләтеп туйлап өйләнгәне булмаган. Пүнәтәйләрен (Янгилде авылының урыс крестьяннарын) иртеп поп Охотин Колангыдан килеп җитә. Ул әллә нинди сүзләр белән капканың урам ягында басып торган Мөхәммәтсафа бабайны сүгәргә керешә. Яшьләрне дә куркыта. Яшьләр попны капкадан кертмиләр. Поп Охотин туйның кызган чагына туры килгәнгәме, аның капка артында җикеренгәненә әллә ни әһәмият бирүче дә булмый.

—Синең, "кара йөрәкнең", безнең туйда ни эшең бар? Без мөселманнар. Бар, кит, безнең эшкә кысылып йөрмә,—диләр аңа. Авыл урысларыннан торган өч пүнәтәй өйләренә кереп качалар, башка күренмиләр. Ә поп Охотин аның саен тузына, бер дә басылыр чамасы күренми, аның да әле яшь чагы. "Мин,—ди,—губернатор боерыгын үтим.—Мин беләм, сезнең янда главный подстрекатель ишан Алкин, аның белән, "отпадшие из православия" из Азбабы Иван Петров (Әбраретдин Рәхмәтуллин), Антон Иванов (Габделхәбир Зиннәтуллин), Николай Никитин (Хәкимулла Талипов). Ярар!.. Мин сезне тыңлату чарасын табармын!"

Поп Охотин үз янында тыныч кына басып торган Мөхәммәтсафа бабайга: "Синең оныгың Василийны да, Акхуҗаныкыларны да, подстрекатель ишан белән барысын да Турухан краена сөрдерәм",—дип, тарантасына менеп утыра. Поп Охотинның тарантасы кузгалып китеп, берникадәр барсалар да, Шәрәфетдин ишек алдыннан яшьләрнең чыркылдап көлгән тавышлары ишетелеп тора.

Икенче көнне Мөхәммәтсабит белән Мәхүпҗамал Татар Әҗәлесенә барырга җыеналар, капкадан чыгып та җитмиләр, карасалар, түбән очтан урам буйлап десятский килә, һәр йорт каршына туктап: "Зөя өязе исправнигы белән становой килде! Җыенга барыгыз!"—дип кычкыра. Халык каравыл өенә җыела. Становой тузынырга керешә.

—Ниткән хәл бу? Кем рөхсәте белән Иван Иванов (Мөхәммәтсафа) ишек алдында мөселманча туй ясадыгыз?—дип кычкыра.

—Һич тә алай түгел, ваше благородие, берәүнең дә туй ясарга җыенганы юк,—ди Сабитның әтисе Шәрәфетдин. Аның сүзен хаклап, староста урыс Алексей Иванов та бер-ике сүз әйтә.

—Алайса, ник попны капкадан кертмәдегез?

—Ул үзе кермәде, үзе тиктомалга тавыш чыгарды...—диләр моңа каршы.—Ваше благородие, поп үзе җәнҗалчы булгач, без гаеплемени?

Охотинның поп булып эшли башлавына әле күптән түгел генә, Яшьлеге белән мөгез чыгара торган гадәте дә бар, шуңа күрә исправникның бик исе китми.

—Алай булгач, кем хөрмәтенә җырлап күңел ачтыгыз?—дигән сорауга Мөхәммәтсафа бабай җавапны әзерләп куйган була.

—Кичә воскресенье иде. Воскресенье көнен хөрмәтләп ачы бал белән сыйланып алдык,—ди.

Әлбәттә, җыенда попның катнашмавы да файдага була. Ул көнне аны Казанга архиепископ Антоний чакырган икән. Икенчедән, Мөхәммәтсафа бабайның Зөя өязе исправнигы белән күптәннән таныш булуы да үзенекен итә. Әнә бу юлы да исправник Мөхәммәтсафа (аныңча, Иван Иванов) бабайга кереп сыйланып чыга, ачы балның аңа иң шәбе куела.

Мөхәммәтсабит белән Мәхүпҗамал туе иртәнгә кадәр бара. Теләнмәгән теләкләр, уйналмаган уеннар, әйтелмәгән сүзләр калмый. Төне буе җырлыйлар, бииләр. Мөхәммәтсафа бабай да үзенә 80 яшь икәнен оныткандай, яшьләр янына утырып, төрле мәзәкләр сөйли.

Иртәгәсен Шәрәфетдин белән Садретдин кодалар кайнап торган җиз самавыр янында озаклап сөйләшеп утыралар. Алар бик канәгать. Садретдин туй мәһәренә (ике яшьлек кызыл тана) дә бик риза.

Мөхәммәтсабитның әнисе Миңлекамал һәм апаларының өчесе дә киленнең җитезлегенә, эшчәнлегенә сокланып туймыйлар. Мөхәммәтсафа йортында хатын-кызга эш җитәрлек.

Бу туйның әһәмияте гаҗәеп зур була. Ул мәкруһларны тәвәккәллеккә, батырлыкка өнди.

Мөхәммәтсабит белән Виктор Охотин арасындагы мөнәсәбәтләр исә элеккегә караганда да киеренкеләнә.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ВӘЗЕНГӘ СЫЙМАГАН УЙЛАР

Минем кулга, бераз сонарып булса да, шагыйрь Зиннур Мансуровның "Күнелдә фидаи яшәсә" дигән китабы килеп керде. "Мәгариф" нәшриятында 2006 елда бик зиннәтле тышлык белән, 500 битле итеп басылган бу калын китапның, алып укый башлаган идем, эчтәлеге дә хикмәтле булып чыкты. Җыентыкка авторның яшәешебездәге көнүзәк мәсьәләләргә кагылышлы уйлану вә күзәтүләре, әдәбият һәм сәнгать тормышына тәнкыйди күзлектән карап язылган мәкаләләре, төрле буын каләм әһелләренә багышланган иҗат портретлары, аерым китаплар унаеннан фикер-карашлары тупланган.



Әйтергә кирәк, төрле авторларның мондый кыйбладагы мәкаләләре һәм язмалары безнен матбугатта даими күренә һәм мин, татар әдәбиятының гади бер солдаты буларак, алар белән хәлдән килгәнчә танышып барам. Әмма минем Зиннур Мансуров язмаларыннан алган тәэсирләрем гадәти түгел, ә кискен төстә үзгә булды. Чөнки авторның әдәбиятыбыз, сәнгатебез һәм яшәешебез турында, гомумән, тормышыбыз турындагы уйланулары, аларга китереп биргән бәясе монарчы яшәп килгән, без инде ияләнеп беткән кысаларда түгел. Алар, ничектер, янача, үзенчәлекле, авторның ярылып яткан үз өлүбе бар. Мондый кыйбладагы китаплар, гадәттә, ник аны яшереп торырга, авырлык белән, әлләни теләмичә генә, укырга кирәк булганга күрә генә укылалар.Ә менә бу мәҗмуга , вакытны ашыктыра-кыса, гел үз янына чакырып торды. Чөнки анда килеп туган вәзгыятьләрне сабырлык белән, кызыклы һәм мавыктыргыч итеп, ничектер, ихластан бәяләү бар. Ә укучы күңеле нәкъ менә шундый сыйфатларга тартыла да бит инде. Китапка кереш сүзендә автор үзе бәян иткән фикерләрен "Вәзенгә сыймаган уйлар" дип атаган. Безнеңчә, җисеменә нәкъ туры килә торган исем бу, һәм үзебезнең язмага да шул исемне куйдык.

Беренче карашка, китап тар даирәләр, әдәбият вә сәнгать, мәдәният әһелләре өчен генә кебек. Әмма аны киң катлам әдәбият сөючеләр алып укысалар да, бу беркемгә дә зыянга булмас иде. Мондагы фикерләр, уйланулар һәр китап укучыга әдәби әсәрләрне аңларга ярдәм итәчәк, аларны шуңа әзерләячәк. Безнең татар әдәбиятында нәкъ менә шушы әзерлек мәсьәләсендә бәла бит. Гади укучыны да тотып алырлык, аны кызыксындырып игътибарын җәлеп итәрлек тәнкыйть мәкаләләре һәм бәяләмәләре юк дәрәҗәсендә. Ә бит әдәбиятлар тарихында тәнкыйтьчеләр тарафыннан киң катлам укучыларга атап язылган, аларны әдәби әсәрләрне аңларга әзерләгән мәкаләләр дә язылган. Әйтик, рус әдәби тәнкыйть бөекләре В. Белинский һәм Н. Добролюбов исемнәрен без әле дә булса яхшы беләбез. Безнең татар мәгърифәтчеләре Мәрҗани, Курсави, Максуди, Исхакый, Күлтәси һәм бөек Тукай үзе дә халыкта әдәби әсәрләре белән генә түгел, гаммәви язмалары белән дә киң билгеле булганнар, һәм менә "Күнелдә фидаи яшәсә" нәкъ әнә шундый гади укучыны да җәлеп итәрлек китап. Өстәвенә аның теле гади, халыкчан, җинел укыла. Шулардан чыгып бу мәҗмуганы мин киң катлам укучылар өчен дип бәялим.

Бәс инде телгә килеп кагылганбыз икән, кайбер шәхси фикерләремне дә әйтим әле. Мин монда, авыл җирендә, укучыларга якынрак торам, һәм чамалыйм ки, хәзерге заман укучысы әлләни бизәкләнмәгән, боргалап-сыргаланмаган, төчеләнүдән ерак торган, җинел аңлаешлы телдә язылган әсәрләрне яратып укый. Беләсезме, телнен нинди булуы укучы өчен зур әһәмияткә ия! Әлбәттә, мина шунда ук каршы төшәрләр. Укучыны гади телгә күнектерергә, анын зәвегын түбәнәйтергә кинәш итәсен, дип. Анысы шулай да булсын. Соң, җанашларым, анын укучысы хәзер әле үткән гасырдагыдан гына да шактый үзгә бит. Һәм вәзгыять бик гади килеп чыга. Артыгын әдәбиләштерелгән, беренче кат укыганда ук үзләштерелми, аңлашылмый торган әсәрләрне ул, кулына алып беренче битен укып караячак та, кире куячак. Һәм ... вәссаләм!

Ярый, китап янында сөйләнеп байтак вакыт үткәрдек. Хәзер инде анын зиннәтле тышлыгын ачып эченә кереп китик, һәм дә ки, курка-курка гына. Бик җитди, фәлсәфи-гаммәви, биниһая колачлы мәҗмуга бит бу. Хәзерге дөньяны, әдәбиятны тануда, бәяләүдә автор биеклегенә күтәрелеп булырмы? Ул утырган мөнбәрдә янәшә калып булырмы? Алланын үзенә тапшырдык...

Китап дүрт зур бүлектән тора. Беренче бүлектә автор безнен данлыклы да, тирәнтен фаҗигале дә үткәнебезгә нечкә хисле шагыйрь күнеле аша үткәреп анализ ясый. Барыбызнын да күнелендә тирән эз һәм җәрәхәтләр дә калдырган бу дәвергә фәлсәфи бәяләмә бирә. Коммунистлар партиясе һәм анын җитәкчеләре кылган җинаятьчел гамәлләргә укучысы белән бергәләп аңлатма табарга тели. "...Сезләрне үзем белән бергә уйланырга чакырам,—ди ул һәм сораулар да китереп куя.—Инде җимерелүгә дучар ителгән "уртак ватан"га нилектән озак еллар буена бәрәкәт инмәде? Үзенен озын тарихында һәртөрле "янарышлар" кичергән Русия нигә һаман тәрәккый илләр юлына чыга алмый? Бәхетсез язмышлы халыклар кайчан мантып китәр? Безне нинди авыр йөк басып тора? Хикмәт икътисадта гынамы?.. Әйдәгез, җавапларны бергә эзлик,"—ди.

Әйе, үткәнебезгә—ягъни социализм һәм Совет хакимияте дәверенә—без, менә хәзерге исеме дә җисеме дә анык булмаган җәмгыятьтә яшәп торучылар, төрлебез төрле бәя бирәбез. Шәхсән менә мин үзем илдә социализм төзүнен башлангыч гамәлләре бернинди җинаятьчел максатларда булмаган, ә изге теләктә, патша самодержавиесе гасырлар буена изеп килгән, наданлыкта һәм хәерчелектә торткан халыкларны иреккә чыгару, аларга адәм рәтле тормыш бирү максатларында булган дип саныйм, һәм бу гамәлләрне кубарып, башлап йөрүчеләр бернинди шәхси ният тотмаганнар, шәхси мәнфәгатьләрдән ерак торганнар, ә социализм идеалларына ихлас күнелдән бирелгән булганнар. Җәмгыятебездә мондый фикердә торганнар бер мин генә түгел, алар күпләр. Тик менә шул бәхетле киләчәкне төзү биниһая зур ялгышулар, чын мәгънәсендә җинаятьләр, халык иркен патша хакимлеге чорыннан да нык итеп кысулар белән башкарылган.

Кызганыч ки, безнен татар әдәбиятында, бүтән халыклар әдәбиятларыннан да уздырып, социализм идеяларын бары тик берьяклы бәяләү, аларны ахырынача хурлау гына бара. Барча каләм ияләре, хәтта зур, талантлы язучыларыбыз әсәрләрендә дә ул үткәнебезгә нәфрәтне, тоташтан тиргәүне күреп исләрен китәрлек. Шул чорларда иҗат иткән, кайчандыр мактап кына җырлаган язучыларыбыз хурлау ягына егылдылар да төштеләр. Гаделлек түгел бит бу, җәмәгать! Җанашларым, социализм идеялары һич кенә дә юкка чыкмадылар бит әле! Алар яши, Азиядәге нинди зур дәүләтләр шул кыйблада, Африкада, Америкада социализм юлына баскан дәүләтләр күпме? Изелгән, хәерчелектән интеккән халыклар шул юлны сайлыйлар. Ике система арасында көрәш дәвам итә әле. Ахыргы чиктә кайсысы җинеп чыгар? Монысын киләчәк күрсәтер.

Зиннур Мансуров язмаларынын әһәмияте шунда ки, ул социализм төзү юлында аны җитәкләүчеләр җибәргән хаталарны, алар ясаган җинаятьчел гамәлләрне бөтен тирәнлеге, фаҗигасы белән ачып бирә. Шушы юлда халыкка каршы кылынган имансызлык, кан үче алу, куркыту, үчләнү, залимнәрнен үзләре, аларнын бернинди гаепсез корбаннары турында сөйли, шушы гамәлләр өчен әлегә кадәр тәүбә кылынмавын искә төшерә.

Бу бүлекнен башлангыч өлеше кызыклы һәм үзенчәлекле. Биредә автор үз шәхесе, каләмдәшләре, әдәби хәрәкәт барышы турында сөйли, шул унайдан сораулар куя һәм... аларга үзе үк җавап та бирә. Күренеп тора, отышлы алым икән бу. Ул

үз алдына куйган максатның офыкларын киңәйтү, килеп туган вәзгыятьләрне киң колачлау мөмкинлеген биргән. Мондый очракта авторның куллары чишелеп киткән диләр.

Язмаларда автор үз фикерләрен тәфсилләп дәлилли, кайчак, гади ташлар арасында табылган якутлардай, көтелмәгән, монарчы без белмәгән җинаятьчел фактлар ачыла. Беләсезме, 1861 елда Русиядә крепостнойлыктан котылырга теләмәгән крестьяннар җитәрлек булган! Баржалар тартып йөри торган бурлаклар пароходларга каршы чыкканнар! Чөнки ...кол булу җиңел, хөр булу авыр. Теге елларда, ни кызганыч, без үзебез дә шундый тәрбия алганбыз түгелме соң?

Зиннур Мансуров тарихи фактларны яхшы белә һәм киң катлам укучыга билгеле булмаган мәгълүматлар да китерә. Мәгълүм революционер Лев Троцкий 1918 елда партиянең Курск губерна һәм шәһәр комитетлары җыелышында дөньяда беренче мәртәбә социализм төзүдә бернинди тәҗрибә булмаганын танып, менә мондый сүзләр әйткән: "Үзебезнең тәҗрибәсезлекне нәрсә белән тутырырга? Истә тотыгыз, иптәшләр, бары тик террор белән! Әзлекле һәм аяусыз террор белән!.. Әгәр бүгенге көнгә кадәр безнең тарафтан йөзләр, меңнәр юк ителгән икән, инде хәзер, кирәк булган очракта, уннарча меңне кырып салырлык оешма, аппарат булдырырга вакыт җитте." Менә, җәмәгать, дөньяда иң гадел җәмгыять төзүне җитәкләүчеләрнең берсе ошбу ниятне нинди юллар белән тормышка ашыруны тәкъдим итә. Һәм мондый тәкъдимнәр сүздә генә калса бер хәл иде. Ары таба уннарча мең түгел, уннарча миллионнар юк ителде бит. Уйласаң, чәчләрең үрә торырлык!

Авторның уйлануларында безнең фаҗигабезне бөтен тирәнлеге белән ачып салган мондый фактлар әле тагын күп. Мин инде бүтәннәрен әйтеп тормыйм. Монысы да бик җитеп торыр дип уйлыйм. Ни кызганыч, нәкъ менә шундый имансызлыклар, ерткычлыклар гадел җәмгыять төзү уен җинаятьчел юлга алып кереп китте дә инде. Күрәбез ки, беренче адымнарында ук.

"Көяләнгән күңел кыйтталары" дигән баш астында авторның нәни күләмле нәсерләре тупланган. Бу нәсерләр әдәбиятта яңа форма кебек кабул ителә, һәрхәлдә, минем монарчы андый язмаларны укыганым юк иде әле. Сүз уңаенда, "форма" дип әйтмик, "шәкел" диик. Безнең мәшһүр мәгърифәтчебез Рабит Батулла "Мәгърифәт" газетасының 29 март санында булган "Китереп кысса кыйсса" дигән үзаллына сөйләнүләрендә форманы шәкел дип әйтергә кушты. Минемчә, үз фикерләренне мондый кыска, берничә җөмләдән генә торган нәсерләр аша бәян итү, чыннан да, отышлы алым. Аларда автор яшәешебез, мәдәният һәм сәнгать, сәясәт мәсьәләләренә юнәлтеп үз алдына, димәк ки укучысы, бөтен җәмгыять алдына да кискен сораулар китереп куя һәм җавап та бирә. Әйтик, бу язмалар менә мондый нәсер белән башланып китә:

"Әвене янган кешедәй, һәрдаим кәвеш башына карап йөрү адәм баласының өстәмә көчләрен суыра, отыры... рухын бөкрәйтә. Безгә мондый басынкы халәттә күпме яшәргә туры килде! Тәмам өметсезләнмик әле. Башыбызны бераз югарырак тотыйк. Күккә багарга вакыт табыйк: кояштан—йөрәгебезгә, йолдызлардан зиһенебезгә илаһи җылылык иңгәнен тоярбыз. Беравыкка гына булса да тормыш авырлыклары онытылып торыр... Яшәү гаме тулган башыбызны калкыта төшик әле, туганнар!.."

Менә сезгә бөтен бер нәсер. Һәм ... афәрин, Мансуров! Бик мәгънәле итеп, тормыш фәлсәфәсе белән, әйбәт әйтелгән бу. Хәзерге заманда безләр нәкъ менә шундый киңәшләргә мохтаҗ. Соң, кайсыбызның гына кәвеш башына карап, өметсезлеккә калып йөргән вакытлары булмый?

Тагын. Күренекле язучыбыз Аяз Гыйләҗев әдәби мәҗлесләрнең берсендә "Мин үземнән соң өч татар калдырам", дигән. Горурлык белән. Менә бу юлларны укыгач без, хәтта әдәбият вә сәнгать әһелләре дә, кайда әле ул горурлану, башларыбызны култык астына яшерергә мәҗбүр булабыз. Аяз ага Гыйләҗев нәкъ менә миллилекне, туган телгә мәхәббәтне, гомумән, үзебезнең дәвамны гаиләләребездә тәрбияләүне искәрткән. Ә безләр исә, күпмебез генә үзебездән соң татар җанлы, татар телле дәвам калдыру белән мактана алабыз?! Мин исә, шәхсән, бу уңайдан берни дә әйтми генә калам.

Бу нәсерләр шактый күпсанлы, аларның һәркайсы тирән мәгънәле, хикмәтле, баш өлеше һәм ахыры булган, тәмамланган әдәби әсәр. Бик күбесен монда китерергә күңел кыҗырап торса да, язма кысалары мөмкинлек бирми.

Китапның икенче бүлегендә иҗат оешмаларындагы көнүзәк мәсьәләләр, шушы оешмаларны җитәкләүчеләрнең компетентлык дәрәҗәләре, мирасыбыз һәм аны аяныч төстә югалтулар, музыка сәнгатебез һәм андагы унышлар, кыенлыклар кебек бинһая әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә. Беләсезме, илдәге өлкә мәдәният идарәләренең 160 башлыгы арасында нибары 20 проценты гына махсус белемгә ия икән. Бик сәер хәл түгелме соң бу?! Әле Крылов бабай әйткәнчә, итекчегә пешекче эшен ышанып тапшырган кебек... "Белгечлеге буенча рухияткә бөтенләй бәйләнеше булмаган урын биләүчеләр ничаклы! Безнең Татарстанда күпме андыйлар! Милли мәдәниятебезнең турыдан-туры җитәкчеләре булып саналган кешеләр арасында хәтта бердәнбер техник белем белән генә коралланганнары да шактый. "Бездә лирикларны менә шулай физиклар җитәкли" ,—ди автор ачынып.

Ә бит Октябрь инкыйлабыннан соң, баштагы җиде-сигез ел дәвамында әдәбият һәм сәнгатьтә иҗат ирегенә дә юл ачылган. Мәдәниятне үстерүнең концепциясе тудырылган. Аны әзерләүчеләр үзләре күпчелеге нәселдән килгән зыялы гаиләләрдә тәрбияләнеп үскәнгә күрә, алар мәдәни алгарыш эшенә күңел кушуы буенча алынган. Сәнгатькә күңел тартылмыйча торып аны җитәкләп булмый! В. И. Ленин үзе дә һәрбер һөнәр иясенең компетентлы булырга тиешлеген әледән-әле искә төшереп торган. Сәнгать турында катгый нәтиҗәләр ясарга үзе дә җөрьәт итмәгән. "Мин монда берни дә аңламыйм, Луначарскийдан сорагыз..."—дия торган булган. Ә хәзер исә ... безнең шактый җитәкчеләргә гап-гади зыялылык җитми. Монысын инде һәркайсыбызның үз җилкәсендә татыганы бар.

Шагыйрь Зиннур Мансуров авыр тарихи юлыбызда рухи мирасыбызны югалта килүебезне дә искәртә. Чынлап та, телевизорның "Культура" каналын карасаң гына да моңа ышанасың. Анда даими рәвештә төрле халыклардан әлегә кадәр яшәп калган искиткеч архитектура үрнәкләрен, сәнгать әсәрләрен, китапханәләрне күрсәтәләр. Хәтта саны белән без татарлардан күпкә аз булган халыкларныкын да. Сорау туа: ә кайда безнең, татар халкының, андый тарихи истәлекләре? Сарай-Бату, Сарай-Бәркә, Бөек Болгардан калган гүзәл сарайлар, архитектура үрнәкләре кайда? Инде тарих үлчәме белән әле күптән түгел генә яшәгән Казан ханлыгы чоры, Кашан, Җүкәтау кебек калалар истәлекләре дә юкка чыккан. Күпме китапханәләр вәхшиләрчә таланган. Тарихыбыз юлы буенча югалтулар!

Китапта авторның милләтебез хадимнәре, татар халкының асыл затлары, аларның иҗаты турында уйланулары зур урын алып тора. Менә Бакый ага Урманче. Барыбыз да бик белгән, ихтирам иткән, моңарчы әле татар халкында тиңдәше булмаган сынчыбыз. Карап торырга ук күркәм, олпат, күпкырлы шәхес. Аның иҗаты тасвирлауга мохтаҗ түгел, ясап куйган сыннары һәркайсыбызның күз алдында. Ә менә аның искиткеч бай мәгълүматлы, һәрьяктан талантлы шәхес икәнен автор дәлилләп биргән. Бактың исә Бакый ага сынчы гына түгел, Мәскәү сәхнәләрендә чыгышлар ясаган җырчы да икән әле! Ул сыннарын да җырлый-җырлый ясаган икән. Сынлы сәнгать әсәрен, гомумән, сүзсез җырга тиңләү дә бар бит әле. Күз белән кабул ителә торган җырга. "...Рәссам ташны да җырлата белә! Борынгы тарихыбызны чагылдырган сыннарга карыйсың да, күңелдә ниндидер эчке аваз яңгырый башлый. Кайвакыт җырның сүзләре дә аерым-ачык булып шәйләнә:

*Шәһре Болгар каласында*
*Туйбикәнең*
*Коесы тирән, суы юк.*
*Шәһре Болгар каласының*
*Исеме калган үзе юк ..."*

—ди автор.

Әдәбиятыбызның якты йолдызлары, шанлы шәхесләр китап битләрендә бер-бер артлы, бөтен фидакарьлекләре һәм фаҗигаләре белән дә, шул ук вакытта горур һәм калку булып гәүдәләнәләр. Аларны сурәтләгәндә инде Зиннур Мансуров шагыйрь генә түгел, ә фәнни тикшеренүче, аналитик бәя бирүче дә. Менә халкыбызның мәңге сүнмәс кояшы Тукай. Автор аны "ике яклап янган шәм" дип бәяли. Тукайның китаплары гадәттән ерак тора, чөнки алар яшәвебез дәреслегенә әверелгән. Шагыйрьнең иҗатына үзенчәлекле итеп анализ ясый, аның фаҗигасен ачып күрсәтә һәм... Тукай дуэльдә һәлак булды, дигән нәтиҗә чыгара. Самодержавие хакимлеге белән рухани-җисмани бәрелештә һәлак булды дигән нәтиҗә бу.

Бөек Ватан сугышында Европа жирендә башларын салган татар әдипләре... Совет илендәге башка халыкларның каләм әһелләре белән чагыштырганда, шәһит киткән татар язучылары саны күпкә ишлерәк булып чыга. Дөньяның кайсы халкы шундый югалту кичергән: нибары 30 минут эчендә милләтебезнең асыл затлары булган 11 жәлилченең башлары Берлинның Плетцензее төрмәсе гильотинасында киселә. Мөжәебез көрәштәшләре белән Дахау концлагеры крематориясендә яндырылган... Барлыгы 31 язучы! Каберлеләре, каберсезләре...

1995 елның маенда автор татар халкының сөекле язучысы, үзе әйткәнчә, "мөбарәк тәсбихнең бер мәржәне" Гадел Кутуй каберенә, Польшаның Згеж шәһәренә сәяхәткә чыга. Әдипнең улы, шагыйрь Рөстәм Кутуй белән бергәләп. Әлләни күләмле дә булмаган бу юлъязманы тетрәнмичә уку мөмкин түгел! 42 яше дә тулмаган фронтовик язучы, инде сугышлар тынгач, чит илдә, туган илен, гаиләсен, дусларын, милләттәшләрен шулкадәр сагынып, физик һәм рухи газаплар дөньясында үлем көтеп ята. Инде сугыш беткәч! 1945 елның 15 июнендә вафат була. Згеж шәһәрендәге туганнар каберлегенә уңөченче булып жир астына кереп ята. Менә ул, татар язучысының фажигасе! Үзенең "Тапшырылмаган хатлар" повесте, балалар өчен язган искиткеч мажаралы әсәрләре белән халык күңелендә яшәп калган әдипнең бу кадәрле дә үкенечле язмышын бәлки күпләр белмидер дә.

Мөбарәк тәсбих тагын сузыла. Нури Арсланов. Ижатта үзенә катгый хөкем чыгарып алга, үсешкә таба кискен адым ясый алган, үзе әйткәнчә, илле яшендә танылып, алтмыш яшендә зурлауга лаек булган шагыйрь. Ижатындагы шушы батырлыгы белән, янача ачылып китүе белән Нури Арсланов узган гасырның алтмышынчы елларында әдәби хәрәкәткә йогынты ясады. Әдәбият фәне галиме, язучы Ибраһим ага Нуруллин. Ныклы иманлы, үз кыйбласыннан тайпылуны белмәгән, бик күп әдәбиятчыларның ижатларына тәнкыйди, әмма ихласлык белән бәя биргән, үзе дә халык бик көткән "Тукай" китабын яза алган фидакарь шәхес. Автор бик күп еллар буена республикабызның төп матбагасы булган "Социалистик Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасына мөхәррирлек иткән Шәмси ага Хамматовны "Тугрылык дәвамчысы" дип бәяли. Шәмси аганы мин дә бик яхшы беләм. Беренче хикәяләрем, публицистик язмаларым аның кул астындагы газетада дөнья күрде. Ул мине, әле борнап кына килгән язучыны да, танып белә, игътибарлы һәм таләпчән дә иде. Әлбәттә, Шәмси ага баштанаяк совет чоры кешесе иде. Әмма, автор искәрткәнчә, ул кырыс вәзгыять чорында да "номенклатура футлярына" сыймаган, эчке бәйсезлеген югалтмаган, үзенең рухи чынлыгын горур рәвештә раслый алган кабатланмас олы шәхес иде.

Ары таба бу тәсбих инде әдәбият мәйданына соңрак, Совет дәвере үтеп, сүз иреге килгән чорлардагы каләм әһелләрен үз жебенә ала. Милләт мәнфәгатьләренә фидаиләрчә бирелгән, жанында тоташ күкрәүләр йөрткән шагыйрь Рәшит Әхмәтжан. Искиткеч тыйнак, әмма рух ныклыгы белән гигант шәхес, аның ялкынлы шигырьләре, халкыбызга ирек даулап, мәйданда ач ятып батырлык ясавы... Бала чактан ук әти-әнисез калган, ун яшьлек малай вакытында ук шигырьләр яза башлаган, аннары, гаделлек таләп итеп, Сталинның үзенә хат язарга кыюлыгы житкән Әхмәт Рәшит... Чын шигърияткә тугры хезмәт итүнең мәжбүри бер шартын үтәп, туктаусыз яңалыкка омтылучы, бик кыю һәм үзенчәлекле шагыйрь Газинур Морат... Әдәбиятта гаять тәвәккәл, хәтта беркадәр дуамал, бар кайгысы милләт тәрәккые булган Рахмай Хисмәтулла... Әдәби жәмәгатьчелектә зур өметләр уяткан һәм аларны аклый да килгән Луиза Янсуар...

Зиннур Мансуровның эзләнүләре, уйланулары һәм , иң әһәмиятлесе, бу унайдан табышлары, ясаган нәтижәләре, безнеңчә, югары бәяләрлек зур фәнни хезмәткә тиң. Ышанабыз ки, бу хезмәт үзе белән кызыксынучыларны, китап укучыларын табар.

Йомгаклау итеп, мин "фидаи" сүзен сүзлектән карадым. Гади генә итеп әйткәндә, бу үз кыйблаңа ахырынача тугры калу, үз-үзеңне аямау икән. Ә нәрсә? Бу гыйбарә әле дә үзенең әһәмиятен һәм мәгънәсен югалтмаган, беркайчан югалтмас та. Чөнки әдәбият һәм мәдәният әһелләре теләсә кайсы чорда, теләсә нинди вәзгыятьтә дә үз халкы мәнфәгатьләренә тугры калырга тиеш. Шагыйрь Зиннур Мансуров—әнә шул фидаиләрнең берсе.

**Радик ФӘИЗОВ**

Гомәр
Бәширов

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ

## ИКЕНЧЕ ДӘФТӘР
## (1956 ел)

* * *

Хәсән Туфан белән бик һәйбәт сөйләшеп утырдык. Чын күнелле, яхшы кеше. Ләкин кайберәүләр аны бик өстән генә аңлап кайвакыт рәнжетеп куйгалыйлар. Ул андый кеше түгел, ул күңелендәген яшермичә туп-туры әйтеп бирүче, шагыйрьләрчә аңлаучы саф күңелле кеше. Аны бөтен уңай яклары һәм кимчелекләре белән тулысынча аңларга гына кирәк. Ул аны сай аңлаучы кешеләргә караганда бик күп тирән һәм мәгънәле кеше. Шуның белән бергә, теләсә кайсы яктан искән җилгә авыша торган малайлар кебек җил тегермәне дә түгел. Аның күңелендә күп нәрсә ята, бик мәгънәле, тирән эчтәлекле фикерләр ята. Ул фикерләргә үсәргә, чәчәк атарга мөмкинлек бирергә, шуңа юл ачарга кирәк, киресенчә түгел. Киресенчә булганда аны бозарга мөмкин.

**6 февраль, 1960.**

* * *

Иртәгә Аккош күленә барырга җыенам. Үзем салган дача. Ләкин күңелем бик үк тыныч түгел. Нигә? Чөнки язучылар арасында, кызганычка каршы минем шунда барып торуымнан да көнләшүчеләр бар икән әле. Нинди ваклык! Коточкыч! Мин бит анда акча түләп барам, башкалар кебек үк тиешле хакын түлим. Нәрсәгә көнләшә икән соң ул кеше? Янәсе, менә хәзер мина бер елга бирделәр. Ә тора-бара бөтенләйгә шул кечкенә өйне бирсәләр? Ә ана бирми калдырсалар? Менә алдан ук шуннан көнләшә икән? Шуннан да ваклык булырга мөмкинме? Ярый, мина әле аны бирергә уйламыйлар да бит! Ярый, бирделәр ди. Аннан ул кешегә, яисә гомумән союзга нинди зарар? 60 яшькә җиткән бер язучыга язарга иҗат мөмкинлеге генә оештырыла бит!

Шулкадәр вак булыр икән бу кешеләр!

**16 апрель, 1960ел.**

* * *

Бу дәфтәргә игътибар җитми башлады. Вакыт юктан түгел, күрәсең, монда мин бик дулкынланган чакларда гына яза торганмын. Җәйне шактый үк тыныч хәлдә Аккош күлендә уздырдым. Аннан соң Ачысу шәһәрендә булдым, дәваландым, ял иттем. Менә хәзер "Аяз"[1] романының машинкада басылган беренче бүлекләрен укып ятам. Йә, бу аның соңгы табаклары булсачы. Менә кайчан бәхетле булыр идем мин!

Язучы өчен яза торган әсәрен—газиз балаң кебек үк. Хәтта кайвакытта баладан да

[1] "Җидегән чишмә" романының исеменең беренче варианты.

*Дәвамы. Башы 2008 елның 11нче санында.*

газизрәк түгелме икән әле. Әгәр аягына басып үзалдына мөстәкыйль яши башласа, бала турында тынычрак уйлыйсын. Ә языла торган әсәрен турында бервакытта да тыныч кына, ваемсыз гына фикер йөртә алмыйсын. Ул һәр минут, һәр даим синен күнелендә. Йокыннан торуга ин элек ул башка керә, йоклар алдыннан ин сонгы фикерен—языла торган әсәрен турында. Иҗат газабын үзе язган кеше генә белә. Башыннан ниләр генә узмый, нинди генә яхшы фикер, уй-тойгы узмый—һәммәсе кульязмага, һәммәсе ана. Умарта корты нектарын умартага ташыган кебек, син дә ин яхшысын кульязмага ташыйсын. Шулай бөтен җанын-тәнен белән тырышканда гына юньле әсәр туа да. Болай язган кадәресе ошый әле үземә.

**20 ноябрь, 1960.**

* * *

Иҗат дигәнен бик капризлы, бик үзенчәлекле бер нәрсә. Ул безнен кайбер тәнкыйтчеләребез уйлаганча шоп-шома гына барып ятмый.

Алар бит болай анлаталар: менә язучынын башына бер идея килеп төште. Әһә!—дип тотып ала инде ул аны. Шуннан чыгып план корырга тотына. Менә беренче бүлек, менә өченче, дүртенче, ундүртенче... Әй шуннан китә тезеп, китә тезеп! Чыдап кына тор! Бераздан карыйсын—роман!

Тот капчыгынны! Әгәр кеше алай роман язса, укыр иде пычагым аны халык.

Менә шушы яна романымнын өченче бүлеген язарга утырдым. Армиядә хезмәт иткән офицер авылына кайта. Менә ул, әйтик, Ютазы районынын фәлән авылына кайтып килә.

Кайтып килүен килә, тау башына да кайтып житте, әнә аста анын авылы, анда анын анасы. Ул аны шәһәргә алып китәргә тиеш. Шуннан ары бармый гына бит! Бармый, язылмый, күнел тартмый, суясынмыни аны! Бер көн йөрдем женләнеп, ике көн, өч көн, дүрт көн. Һаман бармый...

**22 апрель, 1961.**

* * *

Хәзер ниләр бар?



13 гыйнварда минем 60 еллыгымны бәйрәм иттеләр. Мине орден белән бүләкләделәр, Университетнын актовый залында юбилей кичәсе булды. Рәхмәт хөкүмәткә, рәхмәт иптәшләргә. Мин үзем болай югыйсә ул юбилейны уздырмау ягында идем. Мина әйттеләр: бу синен үзен өчен генә түгел, яшьләрне тәрбияләү өчен кирәк, диделәр. Мин риза булдым. Шулай кирәк икән, әйдә, рәхим итегез.

Хәзер мине нәрсә борчый?

Хәсән Туфаннын сәламәтлеге борчый. Ул әйбәт кенә йөри иде. Әмма сонгы вакытта ничектер, бераз бирешТе. Кыш көне салкын карга чыгып ауный торган кеше, юк-бар йогынтыга бирелеп, йомшап киткәли башлады. Нишләп икән? Физик картаю анда юк. Ул һаман да егетләрчә җинел йөри, һәйбәт сөйләшә, гомумән, ул тиз картаерга тиеш түгел әле. Менә бит, көтмәгән җирдә йомшап китә, хәтта күз яшьләре чыга. Ә ул бит татар шигъриятенә сокланггыч байлык өстәгән кеше. Ул философ, ул шигъриятгә яна алым тудырган кеше...

**17 февраль, 1962.**

* * *

Татар халкында мескенлек, "шәкертлек" һаман да дәвам итеп килә. Моны бик күп мисаллар белән расларга мөмкин. Бу нәрсә башка халыкларнын вәкилләре белән очрашканда аермачык күрергә була. Мәсәлән, бездә гыйлемгә, фәнгә омтылышта салкын караш, "барыберлек" дәвам итеп килә. Революциядән сон гына язмалары

башланып киткән милләтләр, мәсәлән, гыйльми исем алуда бездән бик күп алга киттеләр. Кыргызда, хәтта төрекмәндә, мәсәлән, филология фәннәре докторлары безгә караганда күбрәк. Мин монда союз республикаларда фәнни академиясе булуны, ә бездә хәтта Филиалны җитәкләрлек татар галимнәре дә булмауны гына күзалдында тоттым. Юк! Татар галимнәре күп кенә булса да аларның бары бере генә (Мөхәммәт Гайнуллин гына)—доктор исемен алуы бик аяныч хәл. Хатип Госман докторлык диссертациясе яклаганда аны, мәсәлән, төрекмән, башкорт килеп яклый. 700-800 еллык әдәбияты булган татарның хәтта докторлык якларлык галимнәре генә дә юк. Ә аны татар әдәбиятыннан өйрәнеп бөтен дөньяга танылган бүтән әдәбиятләрнең вәкилләре яклап чыга. Үзбәктә һ.б. халыкларда теләсә нинди фәнне алга җибәрүче галимнәр хәзер бетәсе түгел. Мәсәлән, аларда фәлсәфә докторы, тагын әллә кемнәр бар, ә бездә ул юк. Һәм булмас та. Чөнки бездә әдәбиятка һәм фәнгә ачылып килә торган чишмәләр корды (татар мәктәпләре бетеп бара бит), моннан соң алар терелмәячәк тә.

**5 ноябрь, 1962.**

Бүген Мөхәммәт[2] диссертация яклады. Бик яхшы, бер тавыштан узды. 12 член бар иде, 12се дә уңай тавыш бирделәр.

Бу егет Арча районының Гөберчәк авылыннан чыккан малай. Ул мулла малае. Әмма аның атасын 1937 елда халык дошманы дип утыртып куйганнар да ул шуннан кайтмаган. Кайдадыр үлгән ул. "Кайдадыр", ни өчендер!.. Коточкыч хәл! Мондый хәлнең башта бөек Ленин җитәкчелек иткән социалистик илдә булуына ышануы да кыен. Ничек инде ул иректе илдә кеше кадәр кеше "ни өчендер", "кайдадыр" һәлак була алсын икән? Ул кешенең бит безнең бик һәйбәт язылган конституциябез буенча "ни өчендер" гаепләмәскә, "кайдадыр" югалмаска хакы бар!

"Мулла малае" дип басым ясап әйтүемнең трагик мәгънәсен аны башыннан кичергән кешеләр генә аңлый ала. Алар "прокаженный" кешеләр кебегрәк хәлдә иделәр. Монысы да безнең бөек һәм шанлы Россиядә генә була торган хәл. Менә шул егет, ягъни "прокаженный" дәрәҗәсендә йөргән мулла малае—партия члены һәм житмәсә әле фәннәр кандидаты. Чын күңелдән без аны тәбрик иттек.

**12март 1964.**



*Г. Бәширов Х. Туфан белән. 1973 ел.*

Моннан берникадәр вакыт элек Шәйхи Маннурда Хәсән Туфан белән кич утырган идек. Аның Муса турындагы романы турында, гомумән күп нәрсәләр турында сөйләштек. Билгеле, бераз гына шаярып та алдык ягъни хәзерге алама гадәт буенча, бераз кәефләндек. Шуннан соң бераз гына кәеф килгәч, һич көтмәгәндә бу ак чәчле иптәшебез әллә бераз хушланып китте, әллә күңелләре йомшарды, безгә шундый нәрсә сөйләп алды:

—Сез минем бик якын иптәшләрем, дусларым, диде. Беләсезме, минем йөрәгем бу арада бик шаяра башлады. Минем йөрәгем кирәкмәгән вакытта бик яман тыпырчына башлый. Мин дарулар гына эчеп яшим. Көн саен уколга йөрим, кайвакыт бөтенләй хәлем бетә. Беләсез бит инде, мин ялгыз кеше. Бөтен гомеремне ялгыз гына уздырам. Минем бик начар хәлдә калган вакытларым була. Минем үлеп китүем дә бик ихтимал. Әйтик, миңа бик авыр хәлләр килеп, тәмам актык чиккә житеп, минем үлеп китүем дә бик мөмкин. Минем сезгә бер васыятем бар: әгәр шулай булып китсәм, мине, әйтик, беркөнне үлек хәлдә тапсагыз, мине, жиренә житкереп, һәйбәтләп күмсәгез иде. Минем мәшәкатем бик зур булачак. Мин бит

[2] Мөхәммәт Мәһдиев – галим һәм язучы.

сездән беләсезме нәрсә телим: мине туган авылым Тулбайга алып кайтып күмсәгез иде. Минем туган авылымда күмеләсем килә.

Хәсән Туфан белән без мона бик гажәпләнеп калдык. Ничек инде шулай? Тап-таза кебек иптәшебез шундый сәер сүзләр сөйли? Бәлки ул моны күнеле артык нечкәрүдән генә шулай әйтеп ташлагандыр? Ләкин ул моны житди итеп әйтте. Безгә аны шулай житди итеп анламыйча мөмкин түгел иде. Билгеле, без анын якын иптәшләре анын васыятен үтәмичә калмабыз.

**4 апрель, 1964.**

Без Көнбатыш демократиясен сүгәбез. Алар фәлән дә фәсмәтән, ул буржуа демократиясе. Менә быел гына Арчага безнен Өлкә комитетынын икенче сәркятибе Никонов бара да әйтә: крәстияннәрнен бозавын алыгыз да чыгыгыз! Сорап тормагыз, тартыгыз да алыгыз!

Кеше сугышта яраланып кайткан. Анын шушы бозаудан бүтән бер нәрсәсе дә юк. Ул әйтә: шушы бозауны суеп бераз ит ашамаммы дип әйткән идем. Бераз хәл жыймакчы булган идем ди.

Ана әйтәләр: Фәлән абзый, хөкүмәт шулай куша, бозавынны колхозга бир инде син, барыбер бирмичә булмый.

Теге мескен риза була, алыгыз инде ди. Нишләсен инде ул?!

Бозауны муенчаклап алып чыгып китәләр. Монын балалары тәрәзәдән карап жылап калалар. Бу абзыйнын бүтән терлеге юк икән. Ашау-эчү бик начарлана. Һәм менә сина нәтижә: 15 көннән бу абзый үлеп китә.

Белмим, мондый хәл бәлки патшалар вакытында кайчандыр, бәлки, булгандыр. Ләкин безнең вакытта шундый хәл булуына, ихтимал, бер кеше дә ышанмас. Ләкин булган хәл бит бу!

Инде ниһаять, синен тәхтенә, рустан юньле кеше булмагач, гөржи килеп утырды. Ул күп "яхшылыклар" эшләде. Уннарнын кирәген бирде. Сулларны, уннарны да берсен дә калдырмыйча төрмәгә утыртты. Бик күбесен асып-кисеп бетерде. Ул бик мәгъруур кеше, дөньяда мин генә даһи кеше дип уйлаучы иде. Һәм менә нәтижә: миллионнарча кешеләр йә төрмәдә, йә эшафотта үлделәр. Йа азаплап үтерделәр. Иң аянычы шунда: Сталиннын чәһриярлары һәр миллэтнен иң актив көчләрен, ягъни революцияне үз кулы белән, үз каны белән ясаган, аны үз кулы белән аякка бастырган иң акыллы, ин булдыклы кешеләрен асып-кисеп бетерделәр. Татарнын ин зур галиме, иң талантлы әдибе Галимжан Ибраһимов иде. Анын авыру икәнен белә торып, монда кайткач үләсен белә торып (чөнки бер генә үпкә белән сулый һәм Ялтада гына яши ала иде!) аны кулга алдылар һәм монда кайткач ул берничә айдан ук үлде. Котычкыч хәл! Аны кайдадыр үләксәләр зиратына илтеп ташлаганнар. Без анын кабере кайда икәнен дә белмибез.

Ул акланганнан сон мин әлеге оешмага бардым. Мина бер папка күрсәттеләр. Ул папкада анын паспорты һәм кайбер кәгазьләреннән башка берни дә юк иде. Ягъни аны гаепләргә бер генә кәгазь дә булмаган. Кайсы илдә, кайчан шундый хәл булганы бар?

Без шунда да түздек. Шулай кирәк булгандыр инде, дидек. Чөнки без инде әллә кайчан ук сүзсез колларга әверелгән халык идек. Һәм хәзер дә шул коллык психологиясенен корбаны булып яшибез. Моны башкача анлату мөмкин түгел. Бүтән илдә бу хәл була да алмый, бары варварлык чорында, коточкыч деспотизм чорында гына болай булуы мөмкин.

**12 апрель, 1964.**

Бүген Аккош күлендә татар концерты тынладым. Г. Тукай ижаты унае белән борынгы татар көйләрен бирделәр. Йә Алла! Шулкадәр байлык, шулкадәр мон! "Гөлжамал" үзе генә дә ничә операга материал бирерлек. Анлаган кешегә ниләр генә юк анда!? Шуннан чыгып рәхәтләнеп менә дигән опера яз, рәхәтлән!

Ләкин...

Минем тормышым бик кискен ике чорга бүленә булып чыкты! Берсе, минем гражданнар сугышында катнашуым, менә шундый яна тормыш төзибез, анда минем

дә катнашым бар, без бөтен халыкны бәхетле итәбез дип, ялкынланып, дәртләнеп, илһамланып яшәгән чор. Үзеңнең шәхси тормышың турында уйлаган юк, бөтенесен революциягә корбан итәсең. Бу шулай, әйтик, 60нчы елларга кадәр дәвам итте.

Аннан соң үкенү чоры. Ленинны сагыну, әйе, Ленинны чын күңелдән сагыну. Мин ялганлый белмим. Мин Ленин бабайны бик сагынам. Без аның тәгълиматын тиешенчә җиренә житкермибез бугай. Ул болай өйрәтмәгән иде шикелле. Без аннан өземтәләр китерәбез. Ләкин ул өйрәткәнчә эшләмибез бугай. Менә нәрсәдә минем моң. Минем хәтта үләсем килә башлады.

**26 апрель, 1964.**

Әле шушы арада гына үзешчән сәнгать осталарының (авылдан җыелган егет һәм кызларның) концертын тыңладык һәм карадык. Нәрсә истә калды? Биюләр һәммәсе дә бертөрле. Йә русча түгел, йә татарча! Һаман шул тәртипсез сикерү, һай-һулар, фәләннәр. Һич яңалык юк.

Әмма шунда минем истә калган бер күренеш булды. Менә Бондюг гармунчыларының баян ансамбле булды шикелле. Алар сәхнә тәгәрмәчендә әйләнеп кенә килеп чыктылар. Безгә иң беренче булып дирижерлары күренде. Ләкин ул безгә, ягъни залга, арты белән торганлыктан без аның кем икәнлеген белмәдек. Әмма шундук аның хәрәкәтләреннән бу кешенең искиткеч дәрәҗәдә музыкаль кеше икәнлеген күреп сокланып калдык. Ул залга арты белән тора бирде. Әмма аның бөтен хәрәкәте, кулларының гына түгел, иңбашларының, башының, гомумән, бөтен гәүдәсенең хәрәкәте шундый музыкаль, шундый тәэсирле иде ки, без аңа шул номер барышында хәйран калып, аңа сокланып карап тордык. Ул шушы ансамбльгә кулы белән генә түгел, бәлки бөтен гәүдәсе, тирәнрәк итеп әйткәндә бөтен җаны-тәне, бөтен барлыгы белән дирижерлык итте. Ансамбль аның кулына гына түгел, бәлки бөтен барлыгына буйсынып, аның музыкаль рухына буйсынып уйнады. Уен беткәннән соң дирижер залга борылып карады һәм без аның мәшһүр композитор Заһид Хәбибуллин икәнлеген күрдек һәм чын күңелдән, бик рәхәтләнеп аңа озак кул чаптык. Шунысы характерлы тагын, ул дирижерлык иткәндә ягъни арты белән торганда ифрат бер яшь кеше кебек күз алдында калды. Күрәсең, музыка, гомумән сәнгать кешене яшәртә торгандыр.

**26 декабрь, 1964.**

Кичә Тукай клубында әдәби телнең киләчәктә үсешенә багышланган зур җыелыш булды. Филология фәннәре докторы Зәкиев бу турыда доклад ясады. Төп тезислары шул: татар теленең үзеннән яңа сүзләр, яңа атамалар ясамаска, бәлки аларны рус теленнән үз формасында алырга. Элек татар теленә керә башлап та әле хәзер дә халыкка аңлашылып җитмәгән сүзләрне дә шулай ук рус сүзләре белән алмаштырырга.

Аңа бик күп кеше каршы чыкты. Чөнки ул телне рус теле законнарына буйсындырып, ниһаять руска кереп китүне яклау, аның мөстәкыйльлеген бетерү дигән сүз инде. Аңа шулай ук мин дә, Маннур да, башкалар да каршы чыктылар.

Соңыннан Зәкиев чигенә башлады. Ләкин аның чигенүен кабул итмәделәр. Җыелыш тәмам булмады. Киләчәккә калдырылды.

Әмма монда төп максат ул турыда язу түгел иде әле. Шуннан без Хатип[3] белән бергә кайттык. Гадәттә, юлда гына булса да, кайвакыт гаҗәп якты, тирән фикерләр уяна.

Мин аңа үземнең бу соңгы әсәремдә халыкның шигъри җанлы булуын, Тукай, Галимҗан, Дәрдмәнд кебекләрне һәм башка бик күп талантларны бирергә сәләтле, ифрат талантлы халык булуын язарга теләгем барлыгы турында сөйләдем. Халык шигъриятеннән кайбер үрнәкләр китердем.

Ул миңа үзенең якындагы планнары турында сөйләде. Сараи дигән борынгы шагыйрьнең иҗатын өйрәнгән. Аны дөньяга чыгарырга уйлый, аңа бик соклана, талантына, гакылына хәйран калып, мисаллар китерә-китерә сөйли. Шуны өйрәнү унае белән ул моңа кадәр безнең татар әдәбиятының чыганагын, аның нигезен

[3] Госман Хатип Госман улы — әдәбият галиме.

башлыча Казан артына кайтарып калдыруның ялгыш икәнлеген ачкан. Татар теле һәм әдәбияты Казан артында гына тумаган, ул анда гына сыймаган, ул бөтен дөнья белән эш иткән. Татар халкы шул Идел—Кама—Агыйдел—Нократ елгалары тирәсендә яши торгач тормыш аның алдына башка илләр белән аралашу кирәклеген китереп куйган. Ул төньякта руслар, көньякта бик күп көнчыгыш халыклары белән сәүдә иткән. Ул аларның телләрен, культураларын үзләштергән, гореф-гадәтләрен өйрәнгән. Шуннан килеп кергән гарәп теле, фарсы теле. Әдәбият та безнең шул якка иярә башлаган. Чөнки ул яктагы бөек шагыйрьләрнең иҗаты безнең халыкка йогынты ясавы бик табигый инде.

Шулар нәтиҗәсендә Кол Гали әсәрләре, Сараи һәм башкаларның бөек әсәрләре килеп туган, гомумән татар халкы зур әдәбият иҗат иткән, һәм күршеләре арасында үзе бер дәүләт булып яшәү дәрәҗәсенә күтәрелә алган. Ләкин без моны әдәбиятта да, тарих турында язылган әсәрләрдә дә күрсәтә алмыйбыз әле. Һаман да шул Казан артыннан чыгып кына эш итәбез. Халыкның тормышын бөтен Көнчыгыш Европа илләре белән бәйләп алып, аларның тарихлары, казанышлары белән бәйләп алып бирергә, шулай күрсәтергә кирәк. Ул шулай гына дөрес булачак.

Алтын Урда дәүләтендә, Болгар дәүләтендә нинди генә зур вакыйгалар, фаҗигаләр булмаган, кешеләр һәм бөтен халыкның язмышы белән тарих нинди генә усал уеннар уйнамаган!

Болар турында романнар язарга кирәк иде. Чөнки әгәр шушы чорда эшләнмәсә, аларның һәммәсен тарих тузаны белән басып китәчәк.

**22 май, 1965.**

Нәрсә турында язмакчы идем икән соң мин? Ваклык турында. Без соңгы елларда бөтендөнья әдәбиятенә күтәрелерлек житди әсәрләр язмадык. Чыңгыз Айтматов үзенең әсәрләре белән бөтен дөнья әдәбиятына күтәрелгәч, бездә көнләшүчеләр күп булды. Алар әйттеләр: кыргыз әдәбиятында күтәрелгән һәр яна проблема үзеннән-үзе зур булып яңгырый. Чөнки кыргыз әдәбияты ул революциягә кадәр бөтенләй юк иде. Хәзер ул безнең өчен иң гади мәсьәлә булган, Г. Ибраһимов әсәрләрендә әллә кайчан ук ачылган проблемаларны күтәрсә дә, ул башкаларга яңа булып тоела. Чөнки үз вакытында Галимҗанны күтәрә алмадык. Менә хәзер ул башка, кыргыз шикелле яңа әдәбиятларда күтәрелеп чыгуга Европада яңа булып яңгырый... Ихтимал, монда берникадәр дөреслек тә бар.

Әмма Галимҗан үз хокукын, үз кешелеген нәкъ Айтматовтагы кебек сугышып, яулап алган хатын-кыз образын бирмәде. Аның вакыты да башка иде. Ул изелгән хатын-кыз образын бирде. Бездә бармы Айтматов күтәргән батыр хатын-кыз образы? Ихтимал, юктыр. Әгәр чагыштыра башласаң, ана охшаганнарны сугыштан соңгы әсәрләрдә табарга мөмкин булыр иде (мәсәлән, Миңлекамал, Нәфисә), ләкин Айтматов хатын-кызы үзенең чорына туры килде һәм ул Шәрекъ хатын-кызлары арасында (син моны телисеңме, әллә инкяръ итәсеңме) беренче урында тора. Безгә менә шуннан үзебезгә нәтиҗә чыгарырга кирәк. Без реалист кешеләр. Марксизм тәгълиматы шулай өйрәтә: тормышта ни күрсәң, шуны язасың. Безнең тормыш мохитебез бик чикле. Безнең "автономиябез" никадәр кысыла барса, безнең мохитебез дә шуның белән бергә кысыла бара. Безне казан татарлары турында гына кайгыртырга өндиләр. Казаннан тыш, башка Җөмһүриятләрдәге татарлар турында язу сезнең эшегез түгел, диләр. Анда да Совет власте. Ул кешеләрне андагы совет власте кайгырта. Сез анда кысылмагыз, диләр. Анда безнең әсәрләребезне бик кыенлык белән генә чыгаралар, анда журналларга язылу ифрат кыен. Чит өлкәләрдәге татар мәктәпләре һәммәсе дә диярлек ябылды инде. Анда укучы балаларны көчләп рус мәктәпләренә куперделәр. Болар һәммәсе дә бик зарури мәсьәлә итеп эшләнә. Ничек? Андагы ата-аналарга әйтәләр (мәсәлән, әйтик, Астрахан, Горький, Оренбург өлкәләрендә): "Татар теле ул Казанда гына ярый торган тел, ул башка өлкәләрдә берничә дә ярамый. Сезнең балаларыгыз русча укымыйча харап булалар. Алар гомуми югары уку йортларына керә алмыйлар". Һәм шулай булсын өчен барлык чараларны күрәләр. Рус телен татар мәктәпләрендә начар укыталар, ул укытучыларның әзерлеге, галәттә, башкаларга караганда түбән була. Аны күтәрергә тырышмыйлар да.

Минемчә, хәзер безнең бөтен язмышыбыз белән идарә итүче рус шовинистлары шактый ук кыен хәлдә калдылар. Аларны теге “Мең дә бер кичә”дәге малайга тиңләргә булыр иде. Малай шешәдән гыйфритне чыгарды да, гыйфрит үзалдына көч алып, малайга буйсынмый башлады. Ленин да безне Октябрь инкыйлабында хөрлеккә чыгарды да хәзерге шовинистлар милләтләрне яңадан шешәгә кертә алмыйча газаплаланалар. Шешәгә никадәр тизрәк кертсәләр, аларга шулкадәр яхшырак. Чөнки һәммәсе дә тизрәк рус булып бетсәләр, аларга мәшәкате азрак булачак. Алар, шовинистлар, шулкадәр тизрәк максатларына ирешәчәкләр.

Хәзер эшләр менә шуңа таба бара.

Бакчасарайда татар зираты бар иде. (Кырымда). Кырым җөмһүриятен теге ахмак Хрущев Украинага бүләк итеп биргәннән соң Украина шовинистлары андагы тарихи урыннарны харап итеп бетерделәр. Биналарны әйткән дә юк инде, хәтта үлекләр дә тыныч кына кала алмады. Шул ук дөнья тынычлык һәм милли хөррият турында бөтен дөньяга сөйләнеп йөрүче подхалим һәм икейөзле Корнейчук һәм аның фикердәшләре татар зиратына тракторлар, бульдозерлар җибәреп, андагы тарихи каберләрне сөреп җир белән тигезләделәр. Ташларын урамга җәйделәр. Тарихта моның кебек кыргыйлык һәм кабахәтлек бүтән милләтләрдә беркайчан да диярлек булганы юк иде әле. Ул бары безнең социализм илендә генә мөмкин булды.

**1 август, 1965. Аккош күле.**

Бер фикер туды: милли мәсьәләдәге ялгышларны әллә Үзәк комитетка язаргамы икән? Үзәк комитет безнең партиянең иң авторитетлы иптәшләреннән оешкан. Андагы иптәшләр вак милләтләрнең дә, эреләрнең дә ихтияҗларын һәммәсен дә белергә тиешләр. Белмиләр икән, өйрәнергә тиешләр. Менә шуларга бөтен булган хәлне, һичбер ялгышка юл калдырмыйча, нәкъ булганча язып җибәрсәң, алар, һичшиксез, аны дөрес аңларга тиеш булырлар иде.

Шулай эшләп карарагамы икән әллә? Чөнки монда бер кеше дә җаваплылыкны үз өстенә алмый, бер кемгә дә җавап бирми. Сул якка никадәр бөксәң дә ярый, әмма милләтләрне яклау ягына берәр сүз әйтсәң, халыкның телен, гореф-гадәтен, җолаларын яклап чыксаң, сине шунда ук милләтчелектә гаепли башлыйлар. Мин моны үз башымнан уздырдым инде.

Нишләргә икән? Болай тыныч кына яшәп тә булмый бит инде. Мәсәлән, татар авылында, бер генә рус кешесе дә булмаган бер авылда урамнарның исемен татарчадан русчага күчереп язалар. Имеш, сезнең балаларыгыз акрынлап русчага өйрәнә барсыннар, юкса алар вузларга керә алмаячаклар. Йа, Рабби! Шул “улица” дигән сүзне өйрәнүгә генә калдылармени инде?

Татар балалары русча яхшы белсеннәр өчен аларны бит русча яхшы укытырга гына кирәк һәм татарча! Әйе! Татарча! Чөнки үз телен яхшы белмәгән бала бүтән телне дә яхшы белә алмый. Бу ахмаклык!

Нигә татар телен, аның культурасын яхшы белү рус телен яхшы белүгә зарар итсен икән? Бер телдә дә туган телнең башка телне өйрәнергә зарар иткәне юк бит! Нигә хәзер генә, безнең социализм илендә генә халыкның үз теле башка телләрне өйрәнүгә кыенлык тудыра башлады соң әле? Бу бит дөньяда булмаган хәл!

**21 август, 1965. Аккош күле.**

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БӨЕК ГАЛИМЕБЕЗ

Татар халкының горурлыгы булган һәм Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Г. Курсави, Ш. Мәржани, Х. Фәезханов, К. Насыйри кебек мәрҗәннәр тезмәсен тулыландырып торучы гали зат, гаҗәеп киң карашлы, тирән энциклопедик белемле, милли тарихка һәм үз чорының рухи тормышына караган бихисап күп хезмәтләр иҗат иткән бөек галим буларак, Ризаэддин Фәхреддин XIX йөз азагы—XX йөз башында татар әдәбияте, тарихы, Ислам дине, иҗтимагый фикер үсеше һәм рухи мәдәниятендә иң алдынгы урыннарның берсен алып торды. Аның шөһрәте илебез белән генә чикләнмичә, чит мәмләкәтләрдә дә, бигрәк тә Ислам дөньясында, киң таралды.



Ризаэддин Фәхреддин 1859 елның 4 гыйнварында (яна стиль белән 17 гыйнварда) хәзерге Татарстанның Әлмәт районы Кичү Чаты авылында рухани гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне укымышлы әти-әнисеннән алганнан соң, аны 7 яшендә мәктәпкә укырга бирәләр. Кечкенә авылның кечкенә мәктәбе гаять акыллы малай өчен тар булганлыктан, озакламыйча аны күршедәге Түбән Чыршылы авылы мәдрәсәсенә укырга илтәләр. Өлкән сыйныф укучысы булып җиткәч, тырыш һәм һәр нәрсә белән кызыксынучан Ризаэддин күп вакытын китаплар күчереп язу белән мавыга һәм шулай итеп, үзе өчен бай гына китапханә дә туплый. Мәдрәсәдә татар теленнән башка гарәп, фарсы, төрек телләрен җентекләп өйрәнә, бу өлкәдә дә зур уңышларга ирешә. Шулар өстенә, инде өлкән яшьтәге шәкерт башлангыч сыйныф балаларына дәресләр бирә, беренче педагогик адымнарын ясый, балаларны әхлакый тәрбияләү эше белән мавыга һәм бу һөнәре Ризаэддиннең гомерлек юлдашына әйләнә.

Гарәп, фарсы, төрек телләрендәге китапларны күчергәндә, ул бу телләрдә иркен язарга да, сөйләшергә дә өйрәнә. Русчаны көнчыгыш телләре кебек камил белмәсә дә, Ризаэддин мәшһүр рус галимнәре белән аралашырлык һәм тарихчыларының фәнни хезмәтләрен иркен файдаланырлык дәрәҗәгә җитә.

Китаплар күчереп язганда, сәләтле шәкерт күп кенә акыл ияләренең, тарихчыларның иҗаты белән таныша, аларның карашларын өйрәнә, фәнни алымнарын үзләштерә. Аның шәкерт вакытында күчереп язган китаплары арасында Ш. Мәрҗанинең мәшһүр "Мөстәфадел—әхбар ..." дигән тарихи хезмәте дә бар. Бөек мәгърифәтченең атаклы әсәрләрен уку һәм тикшерү булачак галимгә зур йогынты ясый. Ш. Мәрҗанинең фәлсәфи фикерләре алдынгы карашлы яшь шәкертнең иҗади фикер йөртә башлавына җитди этәргеч бирә. Олы замандашын күрү һәм, җае чыкса, танышу максаты белән дә, югары сыйныф шәкерте Ризаэддин 1886 елда татарның тарихи һәм мәдәни мәркәзе Казанга юл тота. Егетнең хыялы тормышка аша: ул гомере буе үзенең рухи остазы дип йөрткән бөек зат белән танышып сөйләшә. Очрашу аның күңелендә җуелмас эз, зур тәэсир калдыра. Әүвәлге танышудан соң, Ризаэддин Казанда, Ш. Мәрҗани өендә берничә тапкыр булып китә. Очрашуларның берсендә олуг галим аңа үзенең 1886 елда басылган "Әл—газбел—фурат вәл—мазз—зәлалән—нәкыйгъ ли—гыйлләти рәвамел—әбраз ли—әсрах шәрхе Җәлал" ("Җәлал аңлатмасын ачыклауга карата бик нык эчәсе килгәндә теләкне бастыру өчен бирелгән саф һәм тәтлы су кебек дөрес фикерләр") исемле бер бик кыйммәтле китабының матбугатта басылып чыгар алдыннан үз кулы белән соңгы тапкыр төзәтүләр, искәрмәләр язган "сигнальный" нөсхәсен бүләк итә һәм шушы гамәле белән фәндә тәүге адымнарын ясый башлаган Р. Фәхреддингә гүя үзенең хәер-фатихасын бирә.

Мәдрәсәдә гыйлем алуын тәгәлләгәннән соң, Р. Фәхреддин җиң сызганып балалар укыта башлый һәм укыту эше барышында бөек мәгърифәтче Ш. Мәрҗанинең алдынгы укыту алымнарын куллана, тәрбия буенча бай тәҗрибә туплый. Ләкин киң колачлы, әзерлекле егет мәдрәсәдә белем бирү белән генә чикләнми, аның иҗади

офыклары киңәйгәннән киңәя, аңарда рухи дөньяның бай хәзинәсенә шәхси өлеш кертү омтылышы көчәя бара. Яшь галим фәнгә тартыла, ул схоластика киртәләрен җимереп, янарышны, алга карап атлауны кыйбла итә. Үз каләменең көчен, сүзенең үтемлеген сизеп алгач, Ризаэддин иҗади эш белән мавыгып китә, күп кенә китаплар, мәкаләләр яза, татарның рухи тормышына караган язма чыганакларны җыя, аларны фәнни әйләнешкә кертеп, яңа сулыш өрә. Р. Фәхреддиннең артында бу бәрәкәтле эшчәнлеген һәрдаим хуплап-дәртләндереп торган рухи көч—Ш. Мәрҗани образы тора.

1887 елда Ризаэддин имамлыкка имтихан тота. Ул үз вазифасын җиренә җиткереп үтәүче кеше буларак, мәхәллә халкы арасында гына түгел, тирә-юньдә дә зур абруй казана. Җәмәгатьчелек аны имам буларак кына түгел, байтак фәнни хезмәтләр иҗат иткән галим буларак та таный башлый, ихтирам итә. 1891 елда Р. Фәхреддинне Уфага, Диния нәзаратенә казый итеп эшкә чакыралар. Ризаэддин шул ук елны Уфага күчеп китә. Дини мәркәздә, аның бай архивында эшләү Ризаэддин алдында чикләнмәгән иҗади мөмкинлекләр ача. Ул Диния нәзарәте архивында тупланган бихисап чыганакларны өйрәнә, барлый, аларның күчермәләрен булдыра һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә.

Уфада казыйлык вазифасын үтәгән чорда Ризаэддин Фәхреддин "Сәлимә яки гыйффәт" (1899), "Әсма" (1903) повестьләрен иҗат итеп бастыра. Шул ук елларда галим үзенең "Асар" ("Эзләр") дип исемләнгән атаклы био-библиографик хезмәте өстендә актив эшли. Бу гаҗәеп әсәр әле бүген дә тикшеренүчеләр тарафыннан тиешле бәһасын алганы юк. "Асар" 1900 елдан алып 1908 елга кадәр Орынбурда (беренче китабы Казанда) 15 мәртәбә басылып чыга. Бергә тупланган очракта алар ике томны тәшкил итәр иде. Аларда Болгар чорыннан алып XX йөз башларынача Россиядәге мәшһүр ислам галимнәренең һәм дәүләт эшлеклеләренең, аларның шәкертләренең, нәсел-нәсәбләренең тормышы һәм эшчәнлеге тасвирланган. "Асар"ның беренче томы 483 бит тәшкил итә, 666 шәхесне эченә ала, ә 572 биттән торган икенче томы 343 затны, ягъни барысы 1009 күренекле кешенең тормышын сурәтли. Ләкин бу томнар галимнең био-библиографик энциклопедия буларак төзергә ниятләнгән хезмәтләрнең бер өлеше генә әле. "Асар" ның 3 нче, 4 нче томнары әлегә басылмаган, ягъни кулъязма килеш Уфадагы Россия Фәннәр Академиясенең Урал фәнни үзәге Башкортстан бүлегенең Тарих, тел, әдәбият институты архивында саклана, үзенең тикшерүчесен һәм, әлбәттә инде, дөньяга чыгарылуын көтә.

Уфада эшләү дәверендә, болардан тыш, Ризаэддин Фәхреддин "Мөталәгә", "Тәрбияле ана", "Тәрбияле бала", "Тәрбияле хатын", "Шәкертлек әдәпләре", "Адабе тәгълим" ("Укыту кагыйдәләре"), "Коръән вә тәбакать", "Гаилә", "Нәсыйхәт", "Мәшһүр хатыннар", "Исмәгыйль сәяхәте", "Ибне Рөшд" кебек тирән эчтәлекле, тәрбиягә, Ислам диненә, аерым шәхесләргә багышланган дистәләгән китабын дөньяга чыгара. Аларның кайберләре 1917 елга кадәр хәтта унар, ундүртәр мәртәбә басыла, татар халкы рухи хәзинәсенең кыйммәтле асылташларына әверелә.

Ризаэддин Фәхреддин тормышында 1906 ел—текә борылыш ясаган чор. Даны бөтен Ислам дөньясына таралган галим һәм дин эшлеклесен атаклы алтын чыгаручы миллионерлар—бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевлар Орынбур шәһәренә чакыралар. Ризаэддин, казыйлыгын читкә куеп, баштанаяк иҗат һәм мәгърифәтчелек эшенә кереп чума. Бай фәнни һәм педагогик тәҗрибә туплаган галим үзенең мөгаллимлек һөнәрен яңартып җибәрә, аннары берничә ел дәвамында татарның атаклы мәдрәсәсе "Хөсәения"не җитәкли, аны юлга салуга зур көч куя. Р. Фәхреддин "Шура" журналының башыннан алып соңгы санына чаклы (1908—1918) алыштыргысыз мөхәррире була һәм бар көчен, белемен, оештыру сәләтен халыкны агарту эшенә сарыф итә.

"Шура" журналы битләрендә дә киң колачлы галимнең төрле темаларга багышланган 700 дән артык мәкаләсе дөнья күрә. Ризаэддин Фәхреддин Уфа һәм Орынбур чорында, янә 100 томга якын зур күләмле хезмәтләр яза, әмма үзе исән вакытта аларны бастырып чыгара алмый кала. Шуларның 40 томы (әле тагын 2 том кулъязмасы табылган дип ишеттем, Аллага шөкер!...) Уфада, 24 томы Санкт—Петербургта саклана. Аянычка күрә, 20—30 томы Уфаның Диния нәзарәтеннән каядыр китеп югалган икән. Бу казаның очы 1911 елга ук барып тоташа. Шушы елның 12 февралендә галимнең фатирына полиция басып кереп, тентү ясый, "Асар"ның матбугатка әзерләп куелган 3 нче томын, "Шура" журналы өчен дип язылган бик күп мәкаләләрен, башка кыйммәтле язмаларын конфискацияли, ике ат йөге

кульязмаларын төяп алып чыгып китә. Хакимият бусагаларын бик озак таптаганнан соң, Ризаэддин Фәхреддин "Асар"ның 3 нче томы кульязмасын кайтарып алуга ирешә, ләкин калган материаллары эзсез югала.

Күп кенә шәркый телләрне ана теле кебек белгән Р. Фәхреддин Уфа, Орынбур, Казан гыйльми дөньясы белән генә чикләнә алмый, әлбәттә. Ул үзен колониализмга каршы көрәшче дип таныткан Петербург университеты профессоры Җәмаледдин Әфгани, Россия академиклары А. Н. Самойлович, В. В. Бартольд, И. Ю. Крачковский һәм кайбер чит мәмләкәтләрнең байтак галимнәре белән дә таныш була, алар белән иҗади элемтәдә тора. Русия һәм мөселман илләре галимнәреннән тыш, Ризаэддин Фәхреддин АКШ, Германия, Франция, Испания, Канада, Япония, Кытай, Скандинавия һәм башка илләрнең галимнәре белән языша, уртак фәнни проблемалар чишәргә омтыла. Бу гамәлләре өчен тынгысыз галим үз илендә төрле эзәрлекләүләргә юлыга.

1917 елның маенда Мәскәүдә мөселманнарның Бөтенрусия корылтаенда Ризаэддин Фәхреддинне кабат Диния нәзарәтенә казый итеп сайлыйлар. Шуның нәтиҗәсе буларак, Ризаэддин Фәхреддин 1918 елның башында Орынбурдан тагын Уфа шәһәренә күчеп килә. Уфа шәһәрендә бераз казый булып торгач, 1921 елның декабрендә Галимҗан Баруди вафат булганнан соң, ул баштa мөфти вазифасын башкаручы итеп, ә 1922 елдан мөфти булып эшли башлый. Совет властеның дингә карата үткәрелгән кырыс сәясәте олуг дин әһеленең иҗади һәм гамәли мөмкинлекләрен чикли. Ләкин, шуна да карамастан, ул мөфтилек вазифасыннан бушаган һәр сәгатен гыйлем, фән юлына сарыф итә, Диния нәзарәте архивын янадан җентекләп күздән кичерә, рәткә сала, дөньякүләм әһәмияткә ия тарихи хезмәтләрен язуын дәвам иттерә.

Бихисап күп чыганакларны өйрәнеп, Ризаэддин Фәхреддин үтә дә әһәмиятле "Болгар тарихы" дигән зур күләмле хезмәтен яза. Ләкин зур-зур ике кисәктән торган бу әсәрнең беренче кисәге нинди дер сәбәпләр аркасында юкка чыккан.

1925 елның сентябрендә Ризаэддин Фәхреддин, СССР Фәннәр Академиясенең Президиумы чакыруы буенча, Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилеенда Шәрыкне өйрәнүче мәшһүр галим буларак, иң хөрмәтле кунак сыйфатында катнаша. Ризаэддин Фәхреддин 1926 елда Согуд Гарәбстанына, Мәккәгә—Бөтендөнья мөселманнары Конгрессына бара, анда аны Конгрессның рәистәше итеп сайлыйлар. Мөфти һәм галим Конгресста саф гарәп телендә зур чыгыш ясый һәм бер атна дәвамында Конгресс эше белән җитәкчелек итә. Аны олуг хөрмәт күрсәтү йөзеннән, Согуд Гарәбстаны короле дә кабул итә.

Бар сәламәтлеген, иҗади омтылышларын халкыбызның бай мәдәни мирасын өйрәнүгә, пропагандалауга багышлаган галим, гомеренең соңгы елларында язмышның кырыс сынавына дучар ителә. Матди мөмкинлекләре кысылганнан-кысыла баруына, гаиләсенең ишле булуына карамастан, аннан салым өстенә салым түләтәләр, төрлечә басым ясыйлар, акчасыз, аш-сусыз утырырга мәҗбүр итәләр. Үзен һәм гаиләсен ач үлемнән саклап калу өчен, ул "дөнья бәһасенә торырлык" китапларын бик арзан бәягә сатып җибәрергә мәҗбүр була, шуның аркасында көчле рухи газаплар кичерә...

Халыкара абруйга ия булган галимгә кульязма хезмәтләрен Вена Фәннәр Академиясенә сатуын сорап берничә мәртәбә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин хәленең аяныч булуына карамастан, Ризаэддин Фәхреддин бу юлга басмый, ватанының патриоты булып кала. Үзенең күп еллык иҗат җимешләренең бер өлешен генә булса да саклап калу өчен, ул, Шәрыкне өйрәнүче галим, академик А. Н. Самойловичның үтенечен унай кабул итә, кульязмаларының берничә томын СССР Фәннәр Академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге архивына тапшыра. Алар бүген дә, Ризаэддин Фәхреддиннең мирасы буларак, шунда саклана́лар.

Энциклопедик белем иясе Ризаэддин Фәхреддин 1936 елның 12 апрелендә 77 яшендә Уфа шәһәрендә вафат була һәм шундагы татар зиратына җирләнә.

Ризаэддин Фәхреддиннең нинди тарихчы булуын, тарих фәненә булган олы һәм изге мөнәсәбәтен күрсәтер өчен аның 1993 елда "Болгар вә Казан төрекләре" исеме белән Казанда басылган китабына тукталып үтү дә җитәр дип саныйм.

Бу китапка кергән сәяхәтнамәләрнең иң борынгысы һәм иң әһәмиятлесе булып Әхмәд Ибне Фазланның Борынгы Болгар дәүләтенә сәяхәтнамәсе санала. Ул кульязма рәвешендә Россия Фәннәр Академиясе Урал фәнни үзәгенең Башкортстан Тарих, тел, әдәбият институты архивында саклана. X гасыр башында яшәгән борынгы бабаларыбызның тарихын, этнографиясен, рухи мәдәниятен өйрәнү өчен дөньяда

бердәнбер булып сакланып калган бу кыйммәтле язма чыганакның урыны да түрдән булырга тиеш. Әлеге сәяхәтнамә—Болгар дәүләтенең падишаһы Алмыш Шәлеки улының үтенече белән Багдад хәлифәсе Әл-Мөкътәдир биллаһ тарафыннан Борынгы Болгарга Ислам динен өйрәтү һәм мәчетләр салдыру, шулай ук кальгалар төзетү өчен җибәрелгән илчелектә җаваплы сәркәтиб вазифасын башкаручы мәшһүр гарәп галиме, сәяхәтче, тарихчы, язучы Әхмәд Ибне Фазланның кулъязмасы. Ул әлеге сәфәрендә Багдадтан чыгып киткән көннән башлап Болгар дәүләтенә килеп җиткәнче нинди мәмләкәтләр аркылы үтеп килгәнен, ниләр күргәнен һәм ниләр ишеткәнен язып калдыра.

Китапка кертелгән әсәрләрнең тагын берсе "Ибне Баттутаның Дәште Кыпчакка сәяхәте" дип атала. Ибне Баттута—Х1Ү гасырда яшәгән һәм сәяхәт иткән, сәяхәте вакытында Болгар мәмләкәтенә дә килеп чыккан мәшһүр гарәп сәяхәтчесе. Бу әсәр Х1Ү гасырның беренче яртысында Идел буенда урнашкан Алтын Урда ханлыгының, Дәште Кыпчак далаларының ничек яшәвен күз алдына китереп бастыра. Әгәр Ибне Баттута узган юлны картага төшерсәң, аның гаҗәеп күп җирләрдә йөргәнлеген күреп булыр иде. География һәм тарих фәннәренә бөтен гомерен багышлаган һәм мөселман илләрен бер башыннан икенче башына кадәр йөреп чыккан Ибне Баттутаның исеме борынгы гарәп китапларында телгә алынмавына Ризаэддин Фәхреддин бик гаҗәпләнә. Аның исемен һәм сәяхәтнамәсен дөньяга таратучылар—европалылар, ягъни фрәнкләр—булуын ассызыклап күрсәтә.

Бу зур күләмле сәяхәтнамә белән танышкач, үз халкының тарихын өйрәнү эшенә бөтен гомерен багышлаган Ризаэддин Фәхреддинне бер нәрсә борчый, ул да булса—Ибне Баттутаның Дәште Кыпчакта һәм Болгар дәүләтендә кайсы елларда йөрүе. Галим моның бик әһәмиятле булуын әйтә, ләкин сәяхәтнамәнең үзендә моңа ачык җавап табылмавына һәм сәяхәтченең бу җирләрдә йөргән елларын үзе сөйләмәвенә көенә. Әмма, игътибар беләнрәк карагач, ул Ибне Баттутаның Дәште Кыпчак һәм Болгарда һиҗри белән 734, милади белән 1333 елда йөргәнлеген исәпләп чыгара.

Ризаэддин Фәхреддин бу сәяхәтнамәдә дә бит саен бик күп аңлатмалар, искәрмәләр, төзәтмәләр бирен бара һәм андагы төрлелекләргә пошынып, Ибне Баттута тарафыннан сөйләнгән кайбер вакыйгаларның дөрес булуына шикләнә. Әмма мондый кыйммәтле тарихи чыганакның әлегә кадәр тәрҗемә ителми торуына аның йөрәге дә әрни.

Сәяхәтнамә башка исемдә булса да, Ризаэддин Фәхреддин аны үзенчә үзгәртә һәм китапка "Ибне Баттутаның Дәште Кыпчакка сәяхәте" дигән исем куя. Укучыны сәяхәт юлыннан, эзлеклелек һәм мәгънә ягыннан читкә җибәрмәс өчен әсәрнең структурасын да үзенчә төзи.

Ибне Баттутаның бу сәяхәтнамәсе—халкыбызның борынгы тарихын, Алтын Урда чорын күз алдына китерер өчен һәм, әлбәттә, өйрәнер өчен гаять кыйммәтле чыганак булып тора. Ризаэддин Фәхреддиннең аны тәрҗемә итеп бастырып чыгаруы да очраклы гына хәл түгел. Ул моны бик зур тарихи бушлыкны аз гына булса да тулыландыру максатыннан чыгып эшли һәм шуның белән тарих фәненә зур өлеш кертә...

Ризаэддин Фәхреддиннең рухи остазы Ш. Мәрҗанигә мөнәсәбәте турында алда бераз әйтелгән иде инде. Яшь галим мәшһүр Ш. Мәрҗанигә хөрмәт һәм рәхмәт хисләрен аңа багышлап язган язмаларында ачык белдерә.

1880 елда Ш. Мәрҗани хаҗ сәфәренә юнәлә һәм үзе өчен кызыклы бар нәрсәне язып барып, кулъязма туплый. Ш. Мәрҗанигә олы хөрмәт йөзеннән, Ризаэддин Фәхреддин әлеге гаять кызыклы кульязма чыганакны 1897 елда "Рихләтел-Мәрҗани" исеме белән бастырып чыгара. Бу китапны ул бик җентекләп әзерли, анда китерелгән мәгълүматларны күпсанлы белешмәләрдән һәм географик карталардан тикшереп ачыклый. Гадәтенчә, бу сәяхәтнамәдә дә Ш. Мәрҗани фикерен һәм мәгълүматларын тулыландыру яки ачыклау өчен күпсанлы искәрмәләр биреп бара.

Ризаэддин Фәхреддиннең сәяхәтнамәләр белән мавыгуы очраклы хәл түгел. Ул яшьтән үк шундый китаплар укырга ярата, укыган китапларыннан үзе кызыксынган һәм кирәксенгән урыннарын аерым дәфтәрләргә күчереп ала торган була. Еллар үткәч, аларны үзенең фәнни хезмәтләрен язганда файдалана.

Ризаэддин Фәхреддин Ш. Мәрҗанинең "Мөстәфадел-әхбар..." китабы үрнәгендә үзенең "Юаныч" исемле 1200 битлек китабын яза. Аның чын мәгънәсендә күпкырлы галим булуына ышаныр өчен, биредә ул күтәргән мәсьәләләрне атап чыгу да җитә:

әхлак, тәрбия, тормыш-көнкүреш, гаилә, никах, дуслык, дошманлык, сугыш, тынычлык, хөкүмәт һәм аның житәкчеләре, дәүләт эшлеклеләре, борынгы һәм бүгенге вакытларда ислам хөкүмәтләренең тәхет вә мәркәз шәһәрләре исемлеге (алфавит тәртибендә), суд эшләре (казый турындагы мәзәкләр белән), коллык, хөррият, шагыйрьләребезнең жыр һәм шигырьләре (халык жырлары), зыяфәт-туй, кунак булу, кунак итү, ашау-эчү әдәпләре, тәмәке, һәм аракының зыяны, яхшы холыклар, бозык һәм яман холыклар, милләт, миллият, фәлсәфә һәм аның тарихы һ. б.

1922 елда Ризаэддин Фәхреддинне мөфти итеп билгеләүләре турында алда әйтелгән иде инде. Бу вазифаны башкару чорында ул рәсми эштән калган вакытын бөтенләе белән фәнгә багышлый. Монда эшләве аңа Диния нәзарәтендә тупланган архивны өйрәнү мөмкинлеге бирә. Ләкин В. И. Ленин вафатыннан соң илдә дингә каршы сугыш игълан ителә һәм мәчетләр дә, чиркәүләр дә ябыла башлый. Бу шаукым Диния нәзарәтенә дә килеп тия. Сталин сәясәтен тормышка ашыручы урыннардагы түрәләр, "дингә каршы көрәш" исеме астында, Диния нәзарәте ачылганнан алып, ягъни 1789 елның 4 декабреннән башлап 1917 елга кадәр жыйналган һәм халкыбыз тарихында бәяләп бетергесез зур әһәмияткә ия булган кыйммәтле тарихи документларны, язмаларны саклаучы архив бинасын кичекмәстән бушатырга ашыгыч фәрман чыгаралар. Ризаэддин Фәхреддин кайларга гына бармый, кемнәргә генә ярдәм сорап мөрәжәгать итми. Ләкин бернигә дә ирешә алмый. Шуннан соң ул 1925 елның 11 январенда "Уфа шәһәрендә губернский исполнительный комитетка сайланган котлуг татар егетләренә һәм, гомумән, эш башында торучы иптәшләргә ачык мәктүб" белән мөрәжәгать итә. 18 биттән торган "ачык хатында" ул тирән борчылып һәм күпсанлы дәлилләр китереп, бу кадәр бай тарихи чыганакларны саклап калырга кирәклеге, аларның халкыбыз тарихын өйрәнү өчен биниһая мөһим булулары турында яза. Шулай итеп, Ризаэддин Фәхреддин Диния нәзарәтенең архивын бөтенләйгә юкка чыгудан саклап кала. Моның өчен күпме көч, күпме тырышлык кирәк була.

Ризаэддин Фәхреддин һәр мөэмин-мөселман өчен канун буларак үтәлергә тиешле Ислам диненә, башкалардан аермалы буларак, галим буларак, фән күзлегеннән чыгып карый. Аның өчен Ислам дине гади, бер төрле карашлар тупланмасы гына түгел, ә бик житди, ныклап өйрәнелергә тиешле һәм олуг игътибарга лаеклы зур бер фән өлкәсе дә булып тора. Шуна күрә, Ислам диненә кагылышлы бер генә мәгълүмат та аның игътибарыннан читтә калмый.

Ризаэддин Фәхреддин дингә кешелек җәмгыяте барлыкка килеп яши башлаганнан алып, Әдәп, Әхлак, Шәфкать, Мөрәүвәт, Изгелек, Итагатьлелек, Кешелеклелек, Намус, Сафлык, Пакьлек, Гаделлек, Яхшылык һәм башка бик күп күркәм төшенчәләрне эченә алган һәм бозык эшләрдән тыелып, яхшы эшләр генә эшләргә өндәгән кануннар тупланмасы итеп карый. Бу аның, дин әһеле булу өстенә, чын галим икәнлеген дә күрсәтеп тора.

Ризаэддин Фәхреддин яшьтән үк укыту-тәрбия эшенә бирелә һәм гомере буена аңа тугры кала. Тәрбиягә, әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышлап бик күп китаплар бастыра. Әле кульъязма хәлендә сакланып, матбугатта басылмыйча үз чиратын көтеп ятучы язмалары да мәшһүр галимебезнең әхлакый мәсьәләләребезгә нинди зур игътибар бирүен күрсәтә. Югарыда телгә алынган "Юаныч" исемле китабындагы "Зыяфәт, ягъни кунакчыллык һәм туй", "Ашау-эчү" дип аталган бүлекләр шулай ук зур әһәмияткә ия. Чөнки ул бирелә бүген инде күбесе онытылып бара торган йолалар, гореф-гадәтләр, кунак кабул итү һәм аны сыйлау әдәпләре, тәмәкенең кеше сәламәтлегенә өчен зарарлы булуы, исерткеч эчүнең зарары, исерткеч эчүдән котылу чаралары, исерткеч эчү аркасында килеп чыккан кайбер гыйбрәтле хәлләр турында һәм бүгенге көн өчен бик кирәкле булган башка бик күп кыйммәтле мәгълүматлар бирә. Жәмгыятебез әхлакый яктан шактый бозылу нәтижәсендә "әхлак" дигән югары төшенчә Ризаэддин Фәхреддин аңлаган дәрәжәдән бик күпкә түбән төшеп, әхлакый һәлакәт чигенә килеп житкән бүгенге көндә бу язмаларның әһәмияте бигрәк тә зур.

**Әнвәр ХӘЙРИ,**

*Татарстанның атказанган фән эшлеклесе,*

*Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

# ФАКТЛАР ДӘФТӘРЕННӘН



*Каты тышлы ошбу "гомуми дәфтәр"нең беренче битенә Әмирхан ага болай дип язып куйган:*
*"Фактлар дәфтәре*
*Бу дәфтәргә язучылар, шагыйрьләр турында, гомумән, әдәбият дөньясында булып узган вакыйгалар турында ишеткәннәремне һәм үзем белгәннәрне язып барырга исәп. Тәртибе—кайчан нәрсә искә төшсә, шулай язылыр".*
*Әлеге дәфтәрдән өч "факт"ны үткән елгы 11нче санда биргән идек инде. Бергәләп укуны дәвам итик.*

* * *

Миңа күрше Садыйк Дәүләткилдиев башта Уфада, соңыннан Казанда прокуратурада эшләгән кеше... Шул миңа Казахстан партиясенең беренче секретаре Динмөхәммәт Кунаев турында болай дип сөйләде:

—Без Динмөхәммәт белән бер мәктәптә укыдык. Шуңа күрә мин аны бик яхшы беләм. Чыгышы белән ул һич тә казах түгел, атасы да, анасы да саф татар... Ә казах булып китүе менә нәрсәдән: элек патша заманасында казахларны солдатка алмаганнар, ә татарны алганнар. Шул сәбәпле Казахстанда торучы татар бае үзе яки улы солдатка алынмас өчен далада яшәүче бер ишле нәселле казах белән сөйләшеп, күпмедер акча да биреп, шуңа туган булып язылган... Без мәктәптә бергә укыган чакта Динмөхәммәт казахча юньләп сөйләшә дә белми иде...

* * *

Хәсән Туфан Маяковский урамында торган чагында (1960, 70 еллар арасында) аңа Ташкенттан вакытлыча кайткан Шакир Мөхәммәдьяров күрешә килә. Ташкент кунагы янына Хәсән абзый мине дә чакырып ала. Шакир абзый Тукайлар замандашы, күпне күргән, күпне белә һәм безгә дә күп нәрсәләр сөйләде. Ул, мәсәлән, Гаяз Исхакыйны яхшы белгән, якыннан аралашкан, хәтта Гаяз Кабан күле буенда яшерен рәвештә җәмәгате белән аерылышкан чагында шаһитларның берсе булып катнашкан (бу рәвешчә аерылышу патша охранкасыннан качып йөргән Исхакыйга хатыны һәм баласының иминлеген саклар өчен кирәк булган икән)...

* * *

Күптән инде Заһидә апа Тинчурина миңа сөйләгән иде:

1921—22 елларда Кәрим Тинчурин һәм Заһидә апа Ташкентта торганнар. Шул чагында аларга авылдан Гаяз Исхакыйның үсмер кызын кемдер китергән. Кыз кыш чыкканчы аларда торган. 22 елның җәендәме, көзендәме, Галимҗан Идриси дигән мәгълүм кеше бу кызны һәм эмиграциядәге башка кешеләрнең балаларын җыеп, совет хөкүмәтенең рөхсәте белән, Төркиягә алып чыгып киткән. Барлыгы егермедән артык бала булган шикелле—шулайрак хәтердә калган.

Анкарада яшәүче Сәгадәт ханым Чыгытай (ире буенча) әнә шул Тинчуриннарда торып киткән кыз булырга тиеш.

* * *

Ишеткәнем:

Шамил Усманов хатын-кызга бик җинел караган имеш. Аларны тиз алыштырган, берсеннән икенчесенә тиз күчкән... Чын мәхәббәтне белмәгән, семья тормышына бик өстен караган.

Ә үзе дә хатын-кызга бик ошаган, унышка тизирешкән. Таза булган, чибәр булган, физкультура белән шөгыльләнгән, кышын кар белән тәнен юган.

Аннары әсәрләрен бик тиз яза торган булган. Театрдан кайтып, чәй өлгергәнче ул инде рецензия язып та ташлаган. (Моны миңа Габдулла Шнасинының беренче хатыны Мөбинә ханым сөйләгән иде. Алар кайчандыр Ш. Усманов белән күрше торганнар.)

* * *

Ни өчен Салих Сәйдәшкә, 50 яшен бәйрәм иткән чагында, орден бирмәделәр? (Мәрхүмнең хәтта медале дә юк иде бит.) Хәтерлисездер, тантаналы җыелыш вакытында залдан берәү: "Сәйдәшкә нигә орден юк?" дип тә кычкырды.

Ул елларда берәр кешене орденга тәкъдим итәр өчен иң элек Черек күлдән (Г.Б. урнашкан йорттан) аның турында белешмә алалар иде. Ягъни бу кешенең берәр төрле ярамаган кыек эше юкмы?.. Ә Сәйдәшнең андый "кыек" эше булган имеш: ул халык дошманыннан калган хатынга өйләнгән икән. Дөрестән дә Асия ханымның беренче ирен 36 елда "тройка" хөкеме белән аткан булганнар. Ләкин моны Салих түгел, Асия ханым үзе дә белмәгән. Чөнки ул елларда кешенең атылганын берәү дә, хәтта аның хатынына да әйтми торганнар иде.

* * *

Сугыш беткәч, берничә елдан соң (елы тәгаен хәтердә калмаган), Салих Сәйдәш Урта Азия якларына барып йөреп кайта. Аның белән бергә артист Илдар Мәҗитов та йөри. Дөресрәге, Илдар Мәҗитне Салих белән бергә аны карап, саклап йөртер өчен махсус билгеләп җибәрәләр.

Менә шул сәяхәттән кайткач, Илдар Мәҗитнең миңа сөйләгән кайбер сүзләре хәтердә калган.

—Салихны һәрбер җирдә бик зурлап каршы алдылар. Бигрәк тә Ташкентта аңа зур игътибар һәм хөрмәт күрсәттеләр. Очрашулар, сөйләшүләр, кунакка йөртүләр күп булды. Үзбәкстан хөкүмәте аның хөрмәтенә банкет та үткәрде. Ләкин үзбәкнең культура әһелләре, җитәкче кешеләре бер нәрсәгә бик гаҗәпләнделәр. Салихның исеме бик кечкенә (бары атказанган артист кына), лауреат-фәлән кебек исеме дә юк, күкрәгендә орден-медаль кебек нәрсәләр дә күренми. Менә килеп, әкрен генә сорыйлар: ничек инде ул алай? Шундый зур композиторыгызның бер нәрсәсе дә юкмыни?—диләр.—Сәйдәш бездә булса, без аңа исемнең дә иң зурысын бирер идек, күптән аны лауреат та итәр идек, күкрәгенә әллә ничә орден да кадаган булыр идек,—диләр...

Әхмәт
Рәшит

# ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

### Университетта...

Мин Ленар дустыма гомерем буе рәхмәтле. Янәшәмдә ул булмаса, университетка керү бәхетенә ирешә алыр идем микән? Казан дигән калага вагон түбәсендә генә килеп, ач килеш, бер тиен акчасыз диярлек имтиханнар биреп йөрүне күз алдына китерәсезме сез?! Ленар исә житеш гаиләдән: аның әтисе райком секретаре да булган, әллә ничә колхозда рәис булып та торган. Без университетка якты өметләр белән юл тоткан чагында Буаның үзендәге зур гына хужалыкны житәкли иде ул. Һәрхәлдә Ленар, артык иркен яшәмәсә дә, минем кебек бервакытта да мохтажлыклар кичермәгәндер. Тыйнак, сабыр, ярдәмчел дустым минем хәлләрнең мөшкеллеген аңлый—үзе ашаганда миңа да өлеш чыгара иде.

Беренче имтиханыбыз—татар теленнән инша иде. Икебез ике жирдә утырсак та, бер үк теманы сайлап алганбыз—"Муса Жәлилнең Моабит циклы шигырьләре". Шагыйрьнең һәр әсәренә, бигрәк тә аның каһарманлыгына мөкиббән киткән, шигырьләрен кат-кат уку гына түгел, тәмам ятлап бетергән чаклар. Житмәсә, әле яз көне генә Буага шагыйрь Рәшит Гәрәй килеп киткән, ул, икебезне дә комсомол райкомына чакыртып, шигырьләребезне күздән кичергәч, үзе дә безгә герой-шагыйрь турындагы "Заставалар аша" дигән шигырен укыган иде. Без, абитуриентлар булгач, икебез дә шуны искә төшергәнбездер, иншада Р. Гәрәй шигырен дә телгә алганбыз булып чыкты. Берничә көннән Матбугат йорты витринасындагы "Яшь сталинчы" газетасын укый башласам, үз күзләремә үзем ышанмый торам. Анда "Г. Наил" дигән кемдер (аның Н. Гыйззәтуллин дигән журналист икәнен мин инде соңрак белдем!) "Имтиханнар башланды" дигән мәкаләсендә минем иншамның аеруча дулкынландыргыч икәнен, "5"ле билгесенә лаек булганын әйткән иде. Ленар иншасы да "5" легә бәяләнгән иде. Бу сөенечле хәбәр миңа яңа көч өстәгәндәй булды. Инде сынатмаска, башка фәннәрдән дә көчне кызганмыйча тырышырга кирәк иде.

Әйтергә генә ансат: жәмгысе жиде имтихан. Татарча һәм русча язма һәм телдән, шуның өстенә тарих, география, немец теленнән дә бирергә кирәк. Конкурс каты: 25 урынга 160 мы, 170 ме гариза кергән. Әле алтын яки көмеш медальлеләр, педучилищелардан кызыл диплом белән килгән егетләр һәм кызлар күпме! Ни булса булды: 35 мөмкинлектән 33 бал жыйдым бугай—мин инде бәхетнең аръягында идем: кабул ителүчеләр исемлегендә һәрхәлдә минем фамилия дә бар иде. Ләкин шул ук вакытта шатлыгымның бер ягы кителде дә: мәктәптә миннән яхшырак укыган, бар яктан да нык әзерлекле Ленар конкурс бусагасын атлап узалмаган булып чыкты. Югыйсә нибары тагын бер балл гына кирәк иде дә... Мин инде әллә нинди Наполеон планнары корган, бер-беребезгә әйбәт терәк булырбыз дип фараз иткән идем. Юк, юк, матди яктан гына түгел—миңа стипендия мәсьәләсе шул алган билгеләрем белән тәэмин ителгән—һәрхәлдә алдагы көндә аның юмартлыгына ул кадәр үк мохтаж да түгел идем. Ленар китте, Буада механизаторлыкка укыды, кайлардадыр, башкорт якларында да эшләп йөрде, армия сафларында хезмәт итеп кайтты. Янадан, мин

---

*Дәвамы. Башы журналның 2008 елның 8 санында.*

университетны тәмамлаган, ә ул анда керергә җыенган 1960 елда гына очраштык без. Хәер, безнең элемтәләр өзелеп тормады—каникулга кайткан саен мин аларның вокзалдан ерак түгел урнашкан кунакчыл өйләренә гел-гел керә идем. Әтисе Шәйхи абый да, әнисе Рәшидә апа да, энеләре Ренат белән Рафаэль дә ничәмә-ничә еллар үз туганнарыдай якын иттеләр.

Иң зур хыялым тормышка ашса да, борчуларым, мәшәкатьләрем азаймады. Әлеге дә баягы шул ашау-эчү мәсьәләсе инде. Кесәдә җилләр исә—әле стипендияне уннарыннан соң гына бирәчәкләр. Абый бик саранланып кына күпмедер акча биргән иде дә, ана лекцияләр яза торган калын-калын дәфтәрләр алдым. Калдык-постыгына икмәк кисәге дә, тулай торактагы титанда туктаусыз кайнап торган су. Бик кысмырланып кына тоткач, бишләренә кадәр, студентлар шаяртканча, "финансым романслар җырламады". Ә аннан ни булыр? Шулай да тагын бер-ике көн түздем әле. Аннан аптырагач, декан урынбасары Леонид Тузов янына кереп киттем: "Стипендиягә хәтле генә, ун сум гына..." Аны башкалар да аптырата торгандыр инде—соравы да унайсыз. Бирде тагын үзе.

Стипендиягә мин шулай итеп ялгандым. Аннан безне бөтен группабыз белән ул вакытта Питрәч районына кергән Салмычи авылына бәрәңге алырга җибәрделәр. Ике тарихчы—Илдус белән Салих, ике филолог—Равил Усманов (кафедрабыз мөдире Хатип Госманның туганнан туган энесе, утызынчы елларда роман вә повестьлары белән шактый танылган, СССР Язучылар берлегенә 1934 елда ук, беренчеләрдән булып кабул ителсә дә, соңрак иҗат эшеннән читләшкән язучы Таһир Госмановның улы) һәм мин. Хуҗалар, башка авылдашлары кебек үк, иртән иртүк Казанга, базарда нәрсә беләндер сәүдә итәргә китеп баралар. Бөтен авылга без, студентлар баш булып калабыз. Күбебез авылдан—өйрәнеп торасы юк. Ашарга үзебез генә пешерәбез. Утыннарының чи булуы гына тенкәгә тия. Аптырагач, чаттагы иконалары янындагы лампададан ниндидер ягулыкка охшаган нәрсәне агызабыз да мич дөрләп янып китә. Хәйләбезне хуҗалар сизмәсен өчен лампадаларына чәй тутырып куябыз. Хәйләсез дөнья файдасыз шул, абый әйтмешли.

Акча дигән нәрсә юк инде ул колхоз җирендә—безгә бәрәңгеләтә, кәбестәләтә түлиләр. Ярый безгә анысы да—министр малайлары түгел бит. Тулай торак подвалында безнең капчыклар тулып ята—кысып кына тотсак, шул бер-ике капчык язга кадәр җитәчәк тә җитәчәк. Кибеттән бернинди сорт стандартларына туры килмәгән, исеме генә ит дип аталган сынык-санак аласын да, инде ачтан үлмисен дигән сүз. Юрганына карап аягыңны сузасың. Еллары бит, еллары нинди аның: дүрт ел барган каты сугыштан соң ил әле тернәкләнеп җитмәгән, без—студентларның күбесе әтисез калган кешеләр, ярдәм көтәр кешебез юк.

Без—бәрәңге, кычыткан, кузгалак, ирен яргыч, каз тәпие, чөгендер яфрагы, кыр суганы ашап үскән буын ничек сырхауларга бирешмәгәнбездер—хәзерге армиягә китәргә тиешле, әмма икесенең берсе чирле булган яшьләргә карап исләрем дә китә. Болар—конфет суырып үскән егетләр шул. Безгә ул вакыт хәзерге затлы ризыклар эләксәме?! Һәй! Сирәк булды, сирәк булды шул балачак бәйрәмнәре! Хәтерлим әле, сугыштан соң безнең кебек ятим-ятимәгә, ярлы-ябагайга "Америка ярдәме" дип кием-салым өләштеләр. Өр-яңа пальто минем өчен артык зур иде—абый аны базарга чыгарып сатты. Бик затлы күлмәк бар иде—анысы җиңәчи күнеленә хуш килде. Фәүзиягә ярарлык түгел иде шул. Шулай итеп "Америка ярдәме"нең ярдәме тәки тимәде безгә.

Апа (әнинең сеңлесе) ул вакытта инде кияүгә чыгып, Казакъстанның Семей дигән шәһәрендә яши, әни үлгәч, ул безне күршебез Кәлимулла абыйларга хат язып эзләп тапкан иде. Шуннан соң ел саен аннан безгә посылкалар килеп торды. Күрәсең, безгә җизни тиешле кеше бик ярдәмчел, кечелекле кеше булгандыр—өскә-башка өр-яңа киемнәр җибәргән була иде. Кайсыдыр елны ул нәкъ мина яраклы күн итек тә җибәрде. Ана әйтеп бетергесез шатлансам да, кайбер күнелсезлекләре дә килеп чыккалады. Җиңәчи язгы-көзге пычракларда суга дип барганда, шул минем итекне кия торган булды яки минем үземне су алып кайтырга җибәрә иде.

Посылкалар аларның үзләренә дә килә иде. Җиңәчинең Мәскәүдәге туганнары үзләреннән арткан бөтен вак-төякне авылга озатып тордылар. Посылка ящигы ачылуга, андагы хат-хәбәрләрне укыганчы ук, аннан чыккан әйберләргә хуҗа табыла, "бусы мина", "бусы мина" дип тарткалашып бүлешкәч, бер читтә шактый киелгән

галстук кына торып кала иде. Ул башкалар өчен фәкать "сыер муенчагы", шуңа күрә анысы инде, әлбәттә, мина тия иде. Шулай да файдасын күрдем мин аның. Галстук галстук та, ә салкын вакытта муенны, изүләрне җылытып тора. Анысы да начар түгел бит.

Ә менә пионер галстугы бәйләп йөргәнебезне гомумән хәтерләмим. Ничек алай булгандыр инде ул. Югыйсә без бөтен классыбыз белән, кәгазьдә генә булса да, пионер саналып йөри идек. Чын ал галстукны мин тәмам олыгайгач кына, теге яки бу мәктәпнең почетлы пионеры булгач кына тага алдым. Хәер, хәзер аның да кадере бетте бугай инде.

Университет, ни әйтсәң дә университет шул. Дәресләр дә "лекция" дип атала, укытучылар сөйләгәнне мөмкин кадәр тулырак итеп язып барырга кирәк—кышкы сессиядә дә, җәйгесендә дә имтиханнар бирәсе. Мәктәптәге шикелле, өйгә бирелгән эшләрне эшләп, шуңа билге куймыйлар куюын. Семинарларда алган билгеләр укытучы дәфтәрендә генә кала. Әмма барыбер хәйләле алмыйсың—укытучың семинарда ничек җавап бирүеңне дә, аның лекцияләренә ничек йөргәнеңне дә хәтерендә тотачак—форсат чыккач, билеттагы сорауларга шартлатып җавап бирсәң дә, өстәмә сораулар яудырып... батырачак. Шуңа күрә алар белән каршылыкка кермәвең хәерлерәк.

Безгә—филологларга—математика да, физика да, химия дә, география дә һәм... хәтта тарих та юк. Аның каравы ОМЛ дигән нәрсә бар—без марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнәбез, тагын борынгы әдәбият тарихы, рус әдәбияты тарихы, чит илләр әдәбияты, тел белеме тарихы, педагогика, логика, психология, татар һәм рус фольклоры, гарәп теле... Чит телләрдән күбебез урта мәктәптә аз-маз немец телен үзләштергән булсак та, безне "инглиз" ясадылар. Югыйсә элек сүзләрнең әйтелеше язылышыннан әлләни аерылмый иде, ә монда "бут" дип язганны да "бат" дип укырга кирәк икән. Өйрәнәсең, өйрәнми кая барасың—"внеаудиторка"ны тапшыра алмасаң, имтиханга кертмиләр дә, койрыкларың күбрәк җыелса, уку белән хушлашырга гына кала. Монда "укы инде, тырыш инде..." дип үгетләп тормыйлар. Өлгергәнлек аттестаты күтәреп килгәнсең икән, димәк, бар яктан өлгер, чын гражданин инде син! Мин беренче семестрда рус фольклорыннан да, логикадан да "отл." дигән билгеләр алып, югарырак түләнә торган стипендиягә дә лаек булган идем, ләкин соңрак һәммәсен шул дәрәҗәдә саклап барып булмады. Аның каравы үзара сөйләшкән чагында кайчакларда дусларны шаярткалап та куям—"Ленин булып Ленинның гимназиядә логика буенча билгесе "дүртле" генә, ышанмасагыз музейдагы аттестатына карагыз, ә мин аннан уздырганмын бит",—дим.

Торуны без Красная Позиция урамындагы алтынчы тулай торакта, егермеләп кеше сыешлы зур бүлмәдә башлаган идек, берәр ай үтте микән—Н. Ершов урамындагы КАИ карамагындагы йортка күчерделәр. 535 нче бүлмәдә без бишәү—булачак журналистлар Мидхәт Миншин һәм Хәмзә Зарипов, группабыз старостасы Зиннур Гыйззәтуллин (ул укуны тәмамлагач, Арча ягында аз гына балалар укытты да, милиция системасына күчеп, майор дәрәҗәсенә күтәрелде. Кызганычка каршы, дөньядан иртә китеп барды—шул яшьлектә күргән газаплы тормыш нәтиҗәседер инде) һәм мин. Бишенчебез—Актаныш районының Дербышка поселогыннан килгән Николай Привалов. Ул безнең арада чит кеше кебек—әллә бар ул, әллә юк. Юаш, базык гәүдәле, бөтен күнелен укуга биргән бер егет шунда. Без аның чыгып киткәнен генә көтеп торабыз да, торыпша белән форточканың тышкы ягына асып куйган салосына һөҗүм итәбез. "Сало" дигән нәрсәне ашау безгә язык инде язгын да, ләкин нишлисең. Ипи телеменә бер-ике кәгазь калынлыгы гына ягарлык итеп кисеп алабыз да, кайнар су белән сыпыртабыз гына. Тәмле икән үзе, каһәр. Белеп торабыз—сизә инде Николай безнең бу угрылыкны—тик никтер дәшми генә.

Шул ачлык безне кайдандыр акча юнәтергә дә мәҗбүр итә. Без "подушка" дигән, чын йөкчеләр өчен патша заманнарында ук уйлап табылган җайланма сатып алабыз да, елга портына баржалар бушатырга төшеп китәбез. Анда да безне көтеп кенә тормыйлар. Пәһлевандай таза ирләр борын асты кибеп житмәгән яшь-жилкенчәккә өстән генә карыйлар: янәсе, буыннары бик сыек түгелме?!

Буыннарын сыек булса да, нишлисең: ачлык юмарт түтәең түгел—трюмда бер метрлы юан гына бүрәнәне китереп салалар да, тез буыннары сыгылып куя. Аннан баскычтан күтәреләсе, траптан чыккач, яр буенча тагын йөз метрлап барасы бар.

Йөгенне илтеп житкереп, жиргә ташлагач кына, жинел сулап куясын. Тагын 24 мәртәбә чыгасы, 23 мәртәбә... 25 мәртәбә чыксан, бер "стук"ка саныйлар да, бераз ял итәргә туктыйлар. Зур тәжрибәле, нык бәдәнле абзыйлар бераз көч туплап алалар. Алларында батон, колбаса, кыяр, помидор... Безнең исә бераз тамак ялгарга кара икмәгебез дә юк. Аннан... тагын бер "стук"... Тагын... тагын... Хәзер гажәпләнеп тә куям: ничек түзелгәндер? Минем алтышар "стук" йөк ташыганнарым бар иде. Бервакыт авыл хужалыгы институтында укып йөргән якташым Әшрәфжанны (анын әтисе һәрвакыт кешеләр алдында: "Әй чая да инде минем бу малай, мичтән кереп мич астыннан чыга..."—дип мактанырга ярата иде) да шул "шабашкага" ияртеп барырга булдым. Ул гәүдәгә миннән калкуырак, матди яктан да бик интекми иде шикелле. Ялга туктагач, алып килгән ризыкларыннан мина да өлеш чыгаргалады. Ләкин егетебез көч-хәл белән... ике "стук"ка гына түзде дә, эшләгәненен әжерен минем исемгә яздырып кайтып китте.

Әшрәфжан дигәннән, әтисе Жамалетдин абзыйның малае белән ничек мактанганын әле дә авылда мәзәк итеп сөйлиләр. "Әй зирәк тә инде минем малай..."—анын сүзе һәрвакыт шулай башланыр иде—"беркөнне алгибер дигән китабын караган идем—А хәрефе белән В хәрефен кушсаң, С хәрефе килеп чыга икән бит. Минем Әшрәфжаным шуларны әллә нишләтеп мәтәштерә дә, цифыр килеп чыга. Валлаһи, минем баш житмәс иде... Үземә ошаган шул, үземә... Анасы кебек тавык мие ашаган булса, тулык чыкмас иде..."

Атасы сөекле малаен ничек кенә күкләргә чөймәсен, йөк ташыганда, буыны шулай сыек булгач, минем алдагы абруе да әлеге вакыйгадан сон чәлпәрәмә килде.

Без утыннан башка цемент та, кавын-карбыз ише нәрсәләр дә бушаткаладык. Хәер, ул сонгысыннан акча әлләни төшми, шул бер рәхәтләнеп сыйланып кына кала идек. Утын яки цемент табышны күбрәк китерә. Хәтта 90—100 сум алган чаклар бар иде. Ә бәйрәм көннәрендә исә бер ярым тапкыр күбрәк тә түләделәр, чөнки баржаларнын тоткарланып торуы елгачылар өчен тагын да кыйммәткәрәк төшә. Шуны алдан ук белеп торган "босслар", ягъни бу кыргый бригаданы укмаштыручылар, хужалар белән аяк терәп сөйләшә, зур сумма каералар иде. Конкурентлар исә аларга комачауламаска тырыша. Югыйсә монда кануннар үзгә, арада төрмә шулпасын эчеп шомарган, кеше жанын кыюны бернигә дә санамаучы башкисәрләр дә юк түгел иде.

Мина болар бөтенесе Максим Горькийнын заманында кызыксынып укыган "Челкаш", "Макар Чудра" кебек хикәяләрендәге персонажларны хәтерләтәләр иде: шул ук суыгаяклар, күз төпләренә фонарь эленгән фахишәләр, бер сынык икмәк сoранып йөргән, инде тәмам сәлперәйгән карт вә карчыклар, әрсез чегән балалары... Әйтерсен, революцияләр дә булмаган, әйтерсен, сонгы сугышта инде тәмам коргаксыганбыз, әйтерсен, алдагы көнгә өмет-ышаныч та юк. Жил иссә, тузан болыты күтәрелә, янгыр яуса, бөтенесе пычракка әверелә. Кайчагында, баржалар килгәнне көтә-көтә мужиклар акча чөеш уйный башлыйлар. Бервакыт мин дә бәхетемне сынап карарга уйладым. Кесәдә байлык әлләни булмагандыр инде: кайладыр ике-өч тәнкә чамасы. Кайдан килеп, кая китмәгән! Чөям—күн ягы төшә, чөям—кабат отам. Рәттән әллә ничә тапкыр шулай бәхет елмайгач, отышым илле тәнкәдән артып китте. Студент өчен зур байлык бит инде. Аннан исә акчаны тиенләп кенә чыгара башладым. Уенчыларнын ачуы килә, мина: "Нишләп алай саранланасын, без кәгазь акча сала идек бит... Иделгә ыргытабыз үзенне..." дип яный ук башладылар. Әле ярый, таза гына бер абый яклап калды, колагыма гына: "Тиз генә ычкыну ягын кара, болардан мәрхәмәт көтә алмыйсын",—дип пышылдады. Мина шул гына кирәк иде дә...

Безнең тагын бер финанс чыганагы: мәкаләләр язу. Университетта берәр яналык булдымы—башкалар өлгергәнче редакциягә чабу ягын карыйсын. Кайчагында көндәшләрен синнән дә уздыра. Әжере әлләни түгел инде түгелен дә, шулай да иш янына куш булып куя. Безнен группа егетләреннән Мидхәт Миншин, Фәсих Хисмәтуллин (сонынннан ул үзенә Фаяз Дунай дигән тәхәллүс сайлады), Минвәгыйз Зәйнетдинов, Хәмзә Зарипов, Мөкатдәс Юсупов һәм мин—һәркайсыбыз сонынннан матбугат дөньясында мәгълүм шәхесләр булып житештек. Безнен мондый мәкаләләр язуыбыз бер яктан матди якны ныгытса—икенче яктан кулны шомартырга, тирәнрәк фикер йөртергә ярдәм итте.

Җомга көннәрне инде без язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубына эләгергә, анда килгән тере язучыларны күрергә, форсат чыкса, алар белән берничә сүз алышырга тырыша идек. Хәзерге кебек үзенне сөмсез сыер шикелле тоту кая: ул абыйларның һәм апаларның бөтенесе классик булмаса да, әдәбиятның тоткасы, горурлыгы. Без—төрле тарафлардан җыелган авыл гыйбадлары—алар белән исәнләшеп узуны да зур бәхеткә саный идек. Шул ук вакытта башка югары уку йортларында белем алучылар алдында үзебезне эрерәк тә тота идек—янәсе, күрегез, безнең университет инде моннан йөз илле ел элек, Россиядә беренчеләрдән булып ачылган, сезнең институт исә бездән бүленеп кенә чыккан... Врач булсагыз да, химик булсагыз да, авиатөзүчеләр булсагыз да, укытучылар булсагыз да, университет белгечләре белән ярыша алмыйсыз! Юбилей уңаеннан безне яшь Ульяновның музей-кабинетында да йөрттеләр, аудиторияләрдә җиһазланган стендлар белән дә таныштырдылар, alma materыбызның А. Е. Арбузов, Б. А. Арбузов кебек атаклы кешеләре белән дә очраштырдылар. Безнең теләкләр, әлбәттә, зуррак, конкретрак—университетка орден бирсеннәр дә, стипендияне арттырсыннар иде. Орден мәсьәләсе, соңлап булса да, хәл ителде—указ алдагы елның июль аенда чыкты. Әмма стипендия белән сөендермәделәр.

Аның каравы укуы кызыклы, гаять мавыктыргыч иде. Академик, профессор кебек дәрәҗәле исемнәр йөртмәсәләр дә (ярамаган тагын татарга дигәннәрдер инде!), зур тормыш мәктәбе үткән, бәхәсләрдә, сүз көрәштерүләрдә Мәскәүнең бик күп мактанчык галимнәрен сыртына салырлык, үз мәктәбен булдырган олы галимнәр иде алар. Бер Латыйф ага Җәләй (докторлык диссертациясен соңрак булса да, барыбер яклады ул!) үзе генә дә ни тора! Ул борынгы татар телен җентекләп өйрәнгән, диалектология буенча үз концепциясен булдырган олы шәхес, һәммәбез тарафыннан ихтирам ителгән укытучыбыз иде. Аның лекциягә бераз соңлабрак кереп, сүзен башлаганчы безнең алда папирос көйрәтеп җибәрүен дә, кемнәргәдер каты гына бәрелеп алуын да гафу итә идек. Берәр конфликт чыга калса, син, кызым, (яки, улым), татар телен өйрәнә-өйрәнә муены кәкрәйгән Латыйф аганны өйрәтмә инде, дип каты гына әйтеп тә куя иде.

Икенче яраткан укытучыбыз—Якуб ага Агишев булгандыр. Пенза ягы мишәре, ул бервакыт Г. Тукай шигыренең бер строфасын:

*Терәлгәнсең цатта столбага,*
*Яфрак кевек сары япәкләрең,*
*Җәлләмицә сине цыдый алмыйм,*
*Бигрәк җалка бага бәбәкләрең,—*

дип, шул як сөйләшенә әйләндереп тә көлдергән иде. Аның да студентлар алдында (еш кына тәнәфескә чыккач) тарта торган гадәте бар иде.

Алардан аермалы буларак, кафедра мөдире Хатип ага Госманның талканы корырак: ул укытучыларны да, студентларны да билгеле бер кысаларда тотарга тырышты. Үзе безгә инде мәктәп дәреслекләренә кергән "Мин күккә күтәреләм" дигән хикәясе белән үк таныш иде. Заманында шигырьләр дә, хикәяләр дә язган. Минем егерменче, утызынчы елларда йә гарәп, йә латин алфавитында чыккан газеталарны актарганым бар. Аларда Хатип аганың материаллары байтак күренә. Кайбер саннарда әле икешәр, өчәр мәкалә...

Татар халык иҗаты белгече Хәмит ага Ярмины беренче тапкыр кайда, ничек күргәнемне алдарак әйткән идем инде. Язмыш безне кабат очраштырды. Ул гына да түгел, Пенза өлкәсе авылларына фольклор экспедициясенә чыкканда, фатиха бирүче нәкъ менә ул булды.

Гаҗәп хәл: безнең остазларыбыз Советлар Союзы дигән биниһая зур илнең төрле-төрле төбәкләреннән булып чыкты. Хәер, исең киткән икән: бу татар дигән халык төрле җиргә сибелгән бит: Диләрә Тумашева исемле апабыз да, Хәмит ага кебек, Себер якларыннан икән. Чибәр, әмма кайбер кешеләргә карата шактый кырыс бу галимә бик күп шәкертләр тәрбияләде, күп кенә фәнни хезмәтләрнең авторы иде. Хатын-кыз филологлардан иң беренче булып академик дәрәҗәсе алды.

Антик дөнья һәм чит ил әдәбиятын без ярымлегендар Гомердан башлап француз язучысы Луи Арагонгача, урысныкын—былиналардан, "Повесть временных лет" кулъязмаларыннан М.Шолохов, А.Фадеев һ.б. әдипләр романнарынача, СССР

халыкларыныкын—Шота Руставелиның "Арыслан тиресе ябынган батыр"ыннан Павло Тычина, Максим Танк шигырьләренәчә, татар шигърияте чорларын исә Мөхәммәдъяр, суфый шагыйрьләрдән (Колгали, С. Сараи кебек бөекләрнең мирасы фәнни әйләнешкә кереп житмәгән иде әле—"Кыйссаи Йосыф" поэмасының мәдәниятебезгә нисбәте мәсьәләсендә кызу-кызу бәхәсләр бара һәм кайбер фаразларны дәлилләр өчен Жәвад Алмаз кебек галимнәрнең фидакарьлеге кирәк иде!) Сибгат Хәкимгәчә инләп өйрәндек. "Өйрәндек" дип кистереп әйтүем белән мин бик үк хаклы да түгелмендер. Һәрхәлдә, без бу өлкәләрдә азмы-күпме мәгълүмат ала алдык. Рус фольклоры буенча лекцияләрне безгә К. Назаретская укыды. Аның бездә—милли традицияләрдә тәрбияләнгән егет һәм кызларда—башка халык җырларына, әкиятләренә һәм былиналарына мәхәббәт уята алуына мин әлегәчә гажәпләнәм. Чит ил әдәбиятлары буенча укыткан Л. Савельева антик каһарманнар турында сөйләгәндә, артык мавыгып китә—баштарак без аның әледән-әле кабатларга яраткан "обесчестил" сүзен анламый да кала идек. Мәгънәсенә төшенгәч, аның "женси көчләү" икәнен белеп алгач, бу сүзне үзара мәзәк-анекдот сөйләгәндә, шактый еш куллана торган булдык.

Мөгаен, марксизм-ленинизм нигезләре, политик экономия, диалектик һәм тарихи материализм, философия тарихы, логика, психология, педагогика кебек фәннәр безнең өчен шактый каты чикләвек булгандыр. "Жепшетү заманы" дигән нәрсә юк иде әле ул вакытта. Без марксизм-ленинизм классиклары белән бәрәттән Мао Цзедун кебек бөтендөнья коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәтләре житәкчеләренең хезмәтләрен дә ятлап йөрдек. Алардагы атамалар, формулалар, исемнәр...—ничек кенә чыдагандыр безнең миләр?!

Хәрби әзерлек дәресләре дә безнең тенкәгә тиде. Атнасына сигез сәгать буе (яртысы—занятиеләр, яртысы үзлегеннән әзерләнү) һәртөрле уставлар, сугыш кораллары, тактика, топография, стройда йөрү... тагын әллә ниләр... Университет һәм кайбер башка уку йортлары армия резервы өчен офицерлар да әзерли иде бит ул заманнарда. Ә таләпләр бүтән бер жирдә дә булмаганча каты иде. Бездән алда да, бездән соң да фәкать шул хәрби әзерлек сабакларын тиешенчә үзләштерә алмаган өчен генә студентларның берничәсе университет белән хушлашырга мәжбүр булды. Кырыс армия таләпләренә буйсындырырга күнеккән полковниклар һәм подполковниклар (безнең хәрби кафедрада аннан да түбән чин юк иде шикелле!) һәр әмернең төгәл үтәлүенә ирешергә, үзләренә бирелгән хокуклардан мөмкин кадәр тулырак файдаланырга тырышалар иде. Аннары безнең бу уку йортыннан алар кебек офицер гына түгел, ә югары белем алып та чыгуыбыз эчләрен пошыра торган булгандыр. Үзләре исә, тормышларын инде шул хәрби тәртипләргә буйсындырганнар һәм яшәү рәвешләрен һичничек тә үзгәртә алмыйлар иде. Без алар өчен, дөньяда берәр житди хәл килеп чыккан очракта, кемнәрнеңдер мәнфәгате хакына солдатларны һәм сержантларны һөҗүмгә әйди-әйди теләсә нинди корбанга барырга тиешле запас торган "пушка ите" генә идек. Хәрби лагерьга баргач, Саврасов фамилияле бер капитанның студентларны ничек түбәнсетүен һич кенә дә онытасым юк. Ул безнең кебек буласы "милләт хадимнәрен" мыскыл итүдән үзенә тәм таба иде бугай. Үзе жиде класс кына бетергән булса да, сугыш вакытында офицер дәрәжәсенә күтәрелгән бу кеше кирәксә-кирәкмәсә дә безне плац буйлап чаптыра, юк-бар гаеп табып, бәдрәф чистартырга "наряд" бирә, "мин сезнең университетыгызны оныттырам әле",—дип яный иде. Аерча ул безнең булачак атаклы шагыйребез Рөстәм Кутуйга каныкты. "Эй, ты, плоскостопый поэт" дип кенә эндәшә иде ул аңа. "Марш-бросоклар" вакытында "аю табанлы" булу—ул бәланең дә бәласе икән! Шинелеңне бөтәрләп ясаган "скат", противогаз салынган сумка, автомат, аякта авыр кирза итек белән кырыклап чакрым араны үтеп кара әле син! Чолгавыңны дөрес урамаган булсаң, тәмуг газапларыннан бер дә ким түгел. Артта калсаң, йә сукрана башласаң... алдагы көнеңдә—гауптвахта!

Хәер, анысына гына түзәр идең әле. Дөнья да тыныч ук түгел иде бит. Кайчагында, көн буе чабу-йөгерүләрдән арып-талып, төнге вакытны чак-чак көтеп алып, башыңны эченә печән тутырылган мендәргә терисең генә, "Подъем!" дигән каһәр суккан аваз яңгырый. Син инде ике минуттан сафта басып торырга тиеш! Атаклы маршал Жуков Оборона министры иде ул вакытта. Тарих аны ничек кенә күкләргә чөеп мактамасын, күрсәтте ул безгә күрмәгәннәрне! Армиядә ныклы

тәртип урнаштыру өчен андый кырыслык бәлки кирәк тә булгандыр. Әмма без... барыннан да бигрәк тыныч хезмәт кешеләре—булачак галимнәр, инженерлар, язучылар, табиблар, укытучылар... идек бит... Шуна күрә катгый кагыйдәләрне өнәп тә бетермәгәнбездер. Ул хәрби сабаклар университеттагы классләр һәм плацлар белән генә тәмамланмады бит—илле яшь тулганчы, ягъни "отставкага чыкканчы" дәвам итте. Хәрби комиссариат дигән кодрәтле көч ел саен "запастагыларны" нәрсәгәдер "өйрәтү" өчен йә Кремльдә урнашкан гарнизон казармаларына җыя яки, кырык эшен кырык җирдә кырылып ятса да, көнкүрештә кичекмәстән хәл итәсе туксан төрле мәшәкатең булса да, ай-ваена карамый ерактагы лагерьларга җибәрә иде...

"Тоцкий" дигән хәрби лагерьда өйрәнүләр вакытында күргән газапларны искә төшерәм... Элекке комиссарлар кебек "сәяси" дигән рангтагы танышларым (И. Ихсанов, Н. Гыйззәтуллин, Н. Гыйндуллин) әңгәмә үткәргән, гәҗит чыгарган булып, зур-зур командирлар тирәсендә генә ышкылып йөрделәр. Ә миңа 28 солдатымны вакытында ашатып, алай-болай булмасын дип хафаланып (чөнки башка частьләрдә ялгыш пуля тиеп, танкка тапталып үлүчеләр дә булды!), кыскасы, хәрби уставтагы бөтен таләпләрнең төгәл үтәлешенә ирешергә кирәк иде. Уен-муен түгел, Кытай белән араларның шактый кискенләшкән чагы. Бу зур өйрәнүләрдән соң, безне, һичшиксез чик буендагы "Җунгар капкасы" дигән җиргә җибәрергә тиешләр—өйрәнүләребез дә "максимально приближенные к боевой обстановке" дип атала. Ходай кушып, ике ил җитәкчеләре дә вакытында акылына килә белде—эш зурга китмәде. Куанганым шул булса, икенчесе... эчне тырнаганы—минем взводта, заманында армиядә хезмәт иткән булсалар да, кулларына автомат тотып карамаган, штаб тирәсендә кәгазь-мазар ташып кына "ике еллык срокларын тутырган" егетләр дә бар иде. Аннан Жуков заманындагы кырыс тәртипләр дә инде тәмам какшаган иде. Аның нәтиҗәләре үзен әнә бүген аеруча сиздерә.

...Чирәм җирләр... Казандагы югары уку йортлары студентларын ул заманнарда "телячий" дип йөртелгән ябык вагоннарга төяп алып киттеләр. Ниндидер уңайлыкларга, җайлылыкларга күнеккәнмени—"ярый безгә—каткан тезгә..." дип йөргән чак. Шаярыша-шаярыша, җырлар суза-суза бардык. Вагоннарыбызны азмы-күпме җайлаштырганнар—калын такталардан ике катлы сәкеләр корыштырганнар иде. Минем урын икенче "этаж"га—ул вакытта инде танылып килгән язучы Нурихан Фәттах янәшәсенә туры килде. Ул Казакъстанның бу җирләрен инде бер тапкыр күреп кайткан, анда эшләүче якташлар турында зур гына әсәр язарга җыена иде. Соныннан ул чыннан да "Бала күнеле далада" романы булып басылып чыкты. Анда безнең бик күп сабакташларның йөз чалымнары абайлана.

Нурихан абыйны студент халкы яратырга өлгергән иде инде. Ул безнең белән гел аралашып яшәде. "Сезнеңчә ничек?" дигән романы белән дә без башкаларга караганда иртәрәк таныштык. Күпмедер вакыт онытылып торгач, яңадан үзенә лаеклы урынны биләгән сөекле шагыйребез Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирү мәсьәләсе күтәрелгәч, татар язучылары даирәсендә дә, студентлар арасында да имза җыеп йөргән фидакарь зат—шул Н. Фәттах булды. Аның "Социалистик Татарстан" газетасында Куйбышев сусаклагычы астында каласы борынгы Болгар дәүләте җирләрендә тарихи ядкарьлар язмышын кайгыртып язган зур гына мәкаләсе дә безне битараф калдырмады. Ул чакта "Этил суы ака торур", "Сызгыра торган уклар" романнары, "Колгали" трагедиясе, "Фест дисбесе", "Шәҗәрә" дигән фәнни хезмәтләре юк иде әле аның, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә дә, башка мәртәбәләргә дә лаек булмаган иде. Шулай да без аны үз итәргә өлгергән идек.

Павлодар өлкәсенең "Казанский" совхозына барып, түбәсе булып та, тәрәзәсе куелмаган бер бинага урнашкач, ул безне ташлап, җайлырак урын эзләп китмәде, көндәлек мәшәкатьләрне безнең кебек яшь-җилкенчәк белән уртаклашып, мондагы гореф-гадәтләрнең үзенчәлекләренә төшендереп (ул үткән ел биредә булган инде) яшәде. Ә бер көнне ул безне—үзе якын күргән берничә татар малаен—күршедәге казакъ авылына алып барды. Нурихан абый, "әнә генә ич ул, күренеп тә тора" дип әйтсә дә, "әнә дигәне шактый ерак—унбиш чакрымлап булып чыкты. Ул монда былтыр ук юл салган икән инде—без беренче кергән саман йорт хуҗабикәсе, әллә кайчангы туганнарын каршылаган кебек, безгә ачык йөз күрсәтте, чәй эчертте, милли ризыклары белән сыйлады. Бу—безне шактый гаҗәпләндергән бөтенләй

башка дөнья иде. Ул ишекне безгә булачак мәшһүр язучыбыз Нурихан Фәттах ачып күрсәтте.

Чирәм жирләргә барганда, мин тагын бер кызыклы кеше белән таныштым. Педагогия институты студенты Харис Фәхретдинов иде ул. Күптәннән кинематограф булырга, Мәскәүдәге шул уку йортына керергә жыена икән. Ул мине дә шунда барырга кодалап карады. Ләкин... Хәер, бу турыда сонрак...

Матбугатта, ил житәкчеләренең көндәлек чыгышларында шау-шулы мактаулар, шөкрана кылулар, шапырынулар күп булса да, чынбарлык андый идиллияләрдән күпкә, бик күпкә кайтыш икән ул. Узган ел игелгән ашлык ерак элеваторларга илтәсе урында якындагы Иртыш суына гына агызылган. Шоферларга чөнки рейс саны гына кирәк—аны исә фәкать төяп киткән жирдә исәплиләр. Совхозның үзәк утарындагы брезент белән ябылган шактый биек таута игътибар иткән идек—ул өске каты инде тәмам эштән чыккан бодай көшеле булып чыкты. “Чирәм жирләрне үзләштерергә” дип килгән яшь малайлар өр-яңа тракторларны сөзештереп яки бер-берсеннән тарттырып та уйныйлар икән.Ватылсанн! “Партиябез һәм хөкүмәтебез” өр-янасын бирәчәк. Чирәм һәм яткын жирләр менә шулай да... “үзләштерелде”. Без—саф күнелле студент халкы, бигрәк тә мал кадерен белеп авыл жирендә үскәннәр—бу кыргыйлыкка гажәпләнә идек, әлбәттә. Ләкин гажәпләнүдән ни файда... дөньясы шулай булгач... Без, татар малайлары, дөресен әйтергә кирәк, сынатмадык. Аеруча тырышып эшләгәннәр шул унай белән чыгарылган махсус значокка да, хәтта “Чирәм жирләрне үзләштергән өчен” медаленә дә лаек булдылар. Безнең “Әдәби сүз” стена газетасында инде хәзер шактый мәгълүм журналист Әгъзам Фәйзрахманов турында:

*Күкрәгемдә—значок,*
*Яхшы эшләгәнмен, значит,—*

дигән шарж чыккач, аны шаяртып көлгәнебез әле дә хәтердә.

Чирәм жирләр безгә үзенең дәһшәтен дә күрсәтте. Без хәрби әзерлек курсларында кат-кат сөйләнгән коточкыч манзараның шаһиты да булдык. Ул көнне Иртышка коючы”Белая” дигән бик үк тирән булмаган елга буена кавын жыярга дип жибәргәннәр иде безне. Иренә-иренә генә кавын жыябыз... “Жыябыз”дан бигрәк ипи шүрлеге турында кайгыртабыз. Коточкыч эссе көн—әледән-әле елгада чумып чыгабыз. Кинәт кенә яр буендагы куаклыклар арасыннан көлтә булып яктылык балкыды. Нәрсәдер яна, дисәк, бөтен тараф ап-ак төскә керде. Ерактагы офыктан нинди болыт күтәрелде. Аннан, чалт аяз күк йөзендә пәйда булган йомгактан сабак салынып төшеп, жирдән күтәрелгәне белән кушылды. Кавын кырына безнең башлык булып барган Фәрваз Миннуллинның: “Егетләр, тизрәк капланып ятыгыз—атом бомбасы...” дип ачыргаланып кычкыруына, хәрби әзерлек дәресләрендә өйрәтелгәнчә, башларны кире якка борып, жиргә аудык. Йөрәкләр дөп-дөп тибә, куркудан йөзләр агарган, сөйләшик дисән, хәтта телдән дә калган идек. Бераздан, без азрак тын алгач, “атом гөмбәсе”нең сабагы сынып, аска төште, ә өске өлеше, әллә кайдан килеп чыккан болыт кисәгенә кушылып, каядыр, еракка китеп барды. Мондый хәлләр Казакъстанда табигый санала, жирле халык, үзләре белән ике-өч күнлек азык-төлек алып, Иртыш буена, ышыграк урынга төшеп утыра икән—бу кадәресен, алдан ук: “Кешегә сөйли күрмә тагын”, дип безгә соңыннан гына аңлатканнар иде. Әлбәттә, пышылдап кына...

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ӨР-ЯҢА ЭЧТӘЛЕК

Элегрәк без Г. Ибраһимовның "Тирән тамырлар" романын анализлаганда бик шома үтеп китә идек: мәгънә юнәлешен билгеләү өчен бердәнбер чыганак булып ачыктан-ачык белдерелгән автор позициясе хезмәт итә иде. Ләкин хәзер бу позициянең бик алай гади булмаганлыгы сизелә. Әгәр романда сурәтләнгән күренешләрне дикъкать белән укысаң, юл араларында шактый гыйбрәтле хәлләр ачыла бара. Шул ягы белән әсәр бүгенге укучы алдына көтелмәгән сораулар да китереп куя.

Ошбу роман бездә авыл хуҗалыгын күмәкләштерү турындагы романнар рәтендәрәк йөртелде. Ләкин Фәхринең "артель, коммун, колхоз" дигән сүзләре монда әле теоретик планда, фараз рәвешендә генә әйтелә.

Билгеле булганча, роман "Фәхрине үтереп ташладылар" дигән динамик җөмлә белән ачыла, "Вәли Хәсәнов караңгы төндә урманга чыгарылып атылды" дигән шундый ук җыйнак, шомлы фраза белән ябыла. Ягъни монда детектив материал яктыртыла булып чыга. Автор аны башка тармаклар: "хуҗалык, сәяси момент, үлем" юнәлешләре белән бәйләп күрсәтергә тырыша. Икътисади эшчәнлекнең нинди булуы Вәли Хәсәнов һәм Фәхри образлары аркылы бәян ителә.

Әсәрдән беленүенчә, инкыйлапка кадәр Вәли Хәсәнов җир-сулар, тегермәннәр, зур кибетләр хуҗасы була. Автор аның бу дәвердә халыкка, җәмгыятькә файдалы күп гамәлләр кылганлыгын күрсәтә. Даменла Фәриделгасри аның турында болай ди: "...Мөхәммәтвәли әфәнде дин вә милләт юлында күп изге эшләр эшләүче иде. Юллар төзәтте. Коюлар казытты, күп мәдрәсәләр, мәктәбләр, мәсҗед-җамигълар булдырды",—ди. Вәли Хәсәнов мәктәпләрне үз тәрбиясендә тота, аларда җиде мөгаллим укыта.

Революциядән соң, әсәрдә тасвирланган вакытта, ул инде мөлкәт иясе түгел,—бар милеге дәүләткә күчкән. Вәли Хәсәнов хатыны белән сөйләшеп утырганда болай ди: "Бер өендә—балалар бакчасы, бер өендә—техникум, бер өендә—диспансер түгелме? Магазиннар кая? Берсенә—Татурман, икенчесенә—Татмашина, өченчесенә—Таткитап хуҗалык итә түгелме?" "Күпме җир бар иде. Күпме урман бар иде. Хәзер нәрсә калдырдылар? Үлсәң, үзеңне күмәрлек тупрак таба алмассың бит!"

Бу елларда Вәли Хәсәнов совет тире заводында, совнархозда эшли. Аннан соң яна хөкүмәт аны кутәрәмгә калган бер совхозга башлык итеп билгели. Галимҗан Ибраһимов геройның шундагы эшчәнлеген аеруча тәфсилләп тасвирлый. "Хезмәт"кә куелганнан алып мин советка ихлас күңел белән эшләдем",—ди Вәли Хәсәнов. Бу сүзе реаль фактларда да раслана. Ул килгәндә совхоз милкендә эшкә яраксыз дүрт чирле ат, дүрт кысыр сарык, чүп басып бетергән сигез дисәтинә арыш, бодай, тары, солы кишәрлекләре була. Шушы хуҗалыкны рәткә кертер өчен Хәсәнов, әсәрдән аңлашылганча, тәүлегенә унсигезәр сәгать эшли һәм күркәм нәтиҗәләргә ирешә. Дүрт ел эчендә аяклы мал йөз башка җитә. Шул җөмләдән совхоз тирә-юньдәге терлекләр токымын яхшыртырдай нәсел айгырлары, үгезләр, тәкәләр булдыра, күрше игенчеләргә арзан хак белән югары сортлы орлыклар өләшеп тора, тирә-юньдәге авылларга тракторлар белән ярдәм итә, өч басудан күп басулы чәчү әйләнешенә күчә, бөтен Идел буенда беренче үрнәк совхозга әйләнә. Әсәрдә бу күрсәткечләр тикшерү вакытында да, хөкем барышында да кире кагылмый, тик уңышка килү юллары гына тәнкыйтьләнә, эшчеләрне тәүлегенә ундүртәр сәгать эшләтү, бүтән совхозларга тиешле дотацияне йоту, бөлгәннәрнең милкен, килгән тракторларны үзенә үзләштерү хисабына ирешелгән дип бәяләнә, ягъни совет кануннары, тәртипләре монда юл куйган булып чыга. Әмма бу тарафтан Вәли Хәсәновның

нинди дә булса законны бозганы романда телгә алынмый. Тик Вәли Хәсәновнын, белгеч буларак, үткенрәк икәнлеге күренә. Әле хәзер дә хужалык житәкчеләренен һәммәсенен дә зирәклеге, сәләте бердәй түгел бит.

Фәхри дә, нигездә, хужалыкка мөнәсәбәттә тасвирлана. Ләкин анын үз йортында нинди дә булса берәр практик эш майтарганы күренми. Өйләнешкәч, "байтак еллар кемдә туры килсә шунда өйдәш торып гомер иттеләр",—дип яза автор. "Үзенә аерым бер өй салып керү ничектер анын башыннан ук чыгып киткән иде". Мәгълүм ки, тормыш иткәндә мондый ирнен гаиләдә абруе югары булмый. Өйне, Фәхри читтә чакта, хатыны Гайшә салып керә.

Анын каравы Фәхри "Уртак" исемле коммуна төзи. Әмма житәкчеләрнен тәҗрибәсезлеге, хатын-кызларнын талашып, ызгышып бетүләре нәтиҗәсендә коммуна таркала. Авыл кешеләре бу хакта: "Алар, коммун ясыйбыз дип, Фон Киллернен менә дигән хужалыгын ничә айда ашап бетерделәр!",—дип сөйлиләр.

Шулай итеп, бер герой хәлсез совхозны алдынгылар рәтенә чыгара, икенчесе әзер хужалыкны тарката.

Кайбер хезмәтләрдә "Фәхри "Хезмәт" совхозынын алдынгы эшчесе" дип раслана. Ләкин романда анын совхозда эшләве турында бер сүз дә әйтелми бит. Әдип аны партия-совет органнарындагы житәкче буларак тасвирлый. "Хезмәт" совхозына исә Фәхри хужалык башлыгы Вәли Хәсәнов белән ызгышу, аны эшеннән алдырту теләге белән, артель, коммунаны пропагандалау нияте белән генә килеп йөри. Тик унай үрнәк белән түгел, сүз белән анлатуга исәп тота. Әмма крестьяннар ошбу яналыкка шикләнеп карыйлар. Әдип кайберләренен алдан ук мона баш-аягы белән каршы торуларын яктырта. "Уртак" коммунасы таралганнан сон итекче Кәмалинын әниче Зифа карчык болай уйлый: "Шуннан сон да бит акылга утырмый. Кая барса, шунда әртил дип, коммун дип димләп йөри бирә. Шулайдыр, мона коммун жене кагылгандыр. Шунын белән дивана булгандыр. Бу—каммун тилеседер".

Инде фажига мәсьәләсенә килик. Әсәрдә тасвирланганча, Гыймади Әхмигә Фәхрине "бераз өйрәтергә, бераз акылга утыртырга кирәк" дигән кинәш бирә, кулына тимер кендек тоттыра, куак артында сагалап торырга куша. Бу хакта Гыймади үзе икърар итә.

Әхми дә Фәхрине үтергәнен таный. "Куак артыннан чыгып, ике тапкыр селтәндем дә кендекне шунда ташлап качтым"—ди. Димәк, Гыймади—жинаятьне оештыручы, Әхми үтерүче була. Гыймади Фәхри мәетен Яманкул чокырына илтеп ташлый.

Ә Вәли Хәсәновнын мона катнашы бармы? Бу мәсьәләдә Вәли Хәсәнов судта болай сөйли:

"—Гыймади карт мина әйтте: бу эт Фәхриләрнен авызларын капламый булмас, диде. Акчасыз эш чыкмый, майламый таба купмый, диде. Мин ваклап тикшермәдем. Берәрсен сыйларга уйлыйдыр, берәрсенә бүләк бирәдер дип исәпләдем. Менә үзен карарсын шунда, дидем дә утыз сумны бирдем". Ягъни, әйтүенә караганда, Вәли Хәсәнов Фәхрине үтерергә кушмаган. Бу эшне башлап йөрмәгән. Тик, гадәттәгечә, сорап килгән кешегә акча гына биреп жибәргән. Бөтен мәгълүмат—әнә шул. Вәли Хәсәновнын конкрет гаебе турында 257 битле бу романда бер сүз дә әйтелми, сынар дәлил дә китерелми. Шулай да суд, чын жинаятьчеләрне белә торып, бер гаепсез Вәли Хәсәновны атарга дип хөкем чыгара. Гаебе исбатланмаган шәхесне ату тикле атуга хөкем итү өчен әлеге бер-ике жөмлә генә житми, әлбәттә. Ошбу карар әсәрдә юридик яктан да, сәнгатьлелек жәһәтеннән дә мотивлаштырылмаган, димәк, укучы моны кабул итә алмый.

Биредә реаль гаептән дә бигрәк элекке мөлкәт иясенә карата ул вакытта жәмгыятьтә урнашкан тискәре мөнәсәбәт роль уйнаган булса кирәк. Әсәрдә сурәтләнгәнчә, Вәли Хәсәнов урамнан барганда малайлар ана: "менә сина, контр бабай, дип, таш атып калалар", хакимият исә мылтыктан ата: әүвәл анын милеге тартып алына, сонbackslashыннан гомере өзелә. Әсәрдә әнә шулай элеккегә байларнын тамырын корыту максат итеп куелган кебек күренә. Кайбер персонажлар авызыннан бу омтылыш ачыктан-ачык янгырый. Алар, әлеге тамырларны йолкып ташлагач, житешлек, иркенлек килеренә өметләнәләр.

Романда сурәтләнгән Зирекле ишанынын язмышын да шушы хөкем белән бер рәттән карарга була. Әсәрдә ул шактый күренекле зат итеп бирелә. Волбашкарма,

авыл советы кешеләре, рәсми вәкилләр аның хакында:

"—Ишанның даны бик зур. Бөтен тирә-якның мөселман крәстиәне аны әүлия дип карый",—диләр. Әмма кызыл гаскәр командиры Садыйк Минлебаев башкача уйлый, ул Шәмсигә Зирекле авылына кораллы армеецлар ияртеп барырыга куша, "кирәген күрерсең. Атарлык булса, безгә хәбәр итәрсең", ди. Бу җөмләнең стиле игътибарга лаеклы. Җан кыю турында ничек җиңелдән сөйли! Чебен үтерү турында сүз бара диярсең.

Шәмсиләр, волбашкармага да, авыл советына да хәбәр итмичә, түшәктә яткан авыру ишан өенә басып керәләр, мөлкәтен факыйрьләргә тараталар. Әмма төнен бу ярлылар барча әйберләрне дә кире ишан йортына китереп өяләр. Өстәвенә ишан ябылган өйнең ишек төбендә дога-фатиха алып калырга дип килүчеләрдән су буе чират тезелә.

Ишан иманына тугры кала. "Без фәкать Аллаһы тәгаләнең әмерләренә генә буйсынабыз",—дип белдерә. Гайнетдинов Шәмси аңа, берәү белән дә киңәшмичә, стенага терәп атып җибәрә. Үлеп җитмәгән кебек күренгәч, "Егет ишанның маңгаена төзәп тагын берне атты. Шуның белән тыны киселде". Автор аңлатмасында "кануннан матдәләр тикшерергә вакыты булмады" диелә. Күрәсез, кеше гомерен өзәргә вакыт табыла, статья карарга, законга таянырга вакыт табылмый. Ә асылда моның нигезендә ишанның абруеннан курку ята.

Менә шулай: җан кыю бер очракта җинаять санала, бөтен роман шуның тамырларын юллауга багышлана, икенче мәлдә исә кеше үтерү үзенә күрә бер егетлек кебегрәк итеп бирелә, аның өчен берәүне дә хөкем каршына китереп бастырмыйлар. Бу җәмгыятьтә, әсәрдән аңлашылганча, төрле кешенең кадере төрлечә булып чыга.

Икенче бер очрак белән романда персонажның мондый уйлары теркәлгән:

"—Сәвит үз баласын үзе ашый башлады. Бу хәерлегә булмас". Үкенечкә каршы, әлеге сүзләр кара күрәзәлек булып яңгырый. Рәсми вәкилләр әсәрдәге конфликтны "ике кеше арасындагы ызгыш түгел, социализм белән капитализмның авыл хуҗалыгында көрәше" дип бәялиләр. Ләкин кем соң монда капиталист? Совхоз директорымы?.." Совхоз" бит капиталистик экономиканы түгел, "совет хуҗалыгы" дигәнне белдерә.

Роман кырыс реалистик буяуларда язылган. Г. Ибраһимов илдәге кытлык, бөлгенлек, мохтаҗлыкны яшермичә, риясыз сурәтли. Зифа карчык, ачлыктан интеккәч, бигрәк тә оныкларын кызганып, авылга юнәлә һәм, вак-төяккә алыштырып, аз-маз азык юнәтә, онын, ярмасын куенына яшерә. Ләкин кайтканда махсус отрядлар тарафыннан "кадак ярым ит тә, өч чирек кадак атланмай да, егерме йомырка да—һәммәсе алынды. Болар урынына Зифа карчык "Заградительный отряд" дигән имзалы кәгазь кисәге тотып кайтып керә. Дәүләт үзе ярдәм итми, әмма карчыкның гөрәнкәләп юнәткән ризыгын алып кала. Шулай итеп, әсәрдән күренгәнчә, совет дәүләте байның милкен дә, ярлыныкын да бердәй гайрәт белән каерып ала. Романда әдип гүяки әнә шундый янәшәлек үткәрә.

Моңа кадәр без яшеннең куәтле имәнне аударып ташлавын революциянең буржуаз җәмгыятьне җимерүенә ишарәли дип аңлата идек. Ләкин табигать күрке имән үзе зарарлы күренеш түгел бит. Чынында бу гарасатны инкыйлапның табигый яшәешкә афәт китерүе дип карау урынлы булмас микән?

Г. Ибраһимов персонаж сөйләмен мөмкин кадәр индивидуальләштереп бирергә омтыла. Юстиция эшләренең башлыгы Гайфуллинның сөйләшү рәвеше болай бирелә:

"—Сезнең хәл авыр күренә. Может быть, башка кешегә поручить итәргә кирәк. Мондый сложный процессларда сезнең үзегезнең, как председатель главсуда, непосредственно судта председатель булып руководить итүегез, конечно, бик желательно... Но, әгәр здоровье ягы бик катастрофический булса, сезнең урынга данный процесса председательлеккә башка берәүне назначить итәрбез". Бу юллар бик тә инде хәзерге хакимият әһелләренең сөйләмен хәтерләтә, автор өлгесен шуннан күчергән кебек тоела.

Романда Г. Ибраһимов сүздә Фәхриләрне, коммунистларны яклый. Ләкин бөтен әсәр буена диярлек автор раславы белән конкрет күренешләр үзара каршылыкка керә. Гәрчә раслау, симпатия бик ачык итеп, турыдан-туры белдерелсә дә, асылда

алар гомум фразалар белән бәян ителә, вазифаларның исемнәре генә атап кителә, гамәлләр конкрет сурәтләрдә гәүдәләнмиләр. Хәлбуки гомум сүзләр образлы, предметлы була алмый, хәтергә барып житми, тойгы-кичерешләр уятмый. Тик жанлы картиналар, поэтик детальләр генә күнелдә, хистә аваздашлык таба, билгеле бер мөнәсәбәтне барлыкка китерә... "Тирән тамырлар" да шундыйлардан, әйтик, Фәхринең эш рәте белмәве, әзер хужалыкны таркатуы, Вәли Хәсәновның олпат меценат, эшлекле белгеч булуы, жинаятькә катнашы дәлилләнмәве, Зирекле ишанының зур абруйлы булуы, дәүләтнең мохтажларга да кырыс карашы бәян ителә. Мондый яктыртылыш укучылар алдына житди сораулар китереп куя. Идея белән объектив чагылышның кискен контрасты кайдан килә? Идеология диктатурасыннанмы? Әйе, Октябрь көннәреннән соң әхлак принциплары кискен үзгәрде. Хакимиятнең мөлкәт ияләренә, дин әһелләренә, руханиларга карата үтә кырыс, каты сәясәте матур әдәбиятка да үтеп керде. Идарә системасы әдәбиятның гуманистик кыйбласын үзгәртте, бүтән якка борып жибәрде. Язучылар яна жәмгыятьнең барлык гамәлләрен сүзсез кабул итәргә һәм хупларга бурычлы иде.

Ләкин, әгәр дә әдип коммунистик идеяләрнең өстенлеген яктыртуны бу романда ният итеп куйган булса, мона бит, фаразан, Фәхринең йомшаклыкларын тасвирламыйча, унай гамәлләрен генә сурәтләп тә ирешә алган булыр иде. Вәли Хәсәновның да эшлекле сыйфатларын калку итеп күрсәтү мәжбүри булмас иде. Ул чагында ике төрле шәрехләүгә дә урын калмас иде. Әмма Г. Ибраһимов ул юлдан китмәгән. Ул әсәрен каршылыклар төене рәвешендә төзүне мәслихәт күргән. Аның да Фәхрине тәнкыйтьләү, Вәли Хәсәновны аклау ягы, калкурак булып, күзгә бәрелебрәк тора.

Әнә шуларны истә тотып, мәсьәләгә бөтенләй көтелмәгән, монарчы кабул ителмәгән яктан килеп гөман кылу урынлы булмас микән? Ягъни әдип үз алдына идеологиягә тугрылык саклау пәрдәсе артына ышыкланып хакимият органнарын тәнкыйтьләү, фаш итү бурычын куймады микән? Бик житди күренешләр шулай фараз итәргә нигез бирә бит. Автор гаепсез гражданнарны бер дәлилсез атып үтерүләрнең алга таба тагын да киңрәк күләмдәге репрессияләргә юл ачу ихтималын кисәтергә теләмәде микән? Шушы яктылыкта караганда әлеге эчке каршылыкның да мәгънәсе, сере ачыла төшә. Үкенечкә каршы, илдә хәрәкәт нәкъ менә шул юнәлештә барды да.

Бер әсәр гадәттә үз эченә бер теманы сыйдыра торган була. Әйтик, детектив материал алына икән, бөтен хикәяләү әнә шуны ачуга хезмәт итә. Әлеге романда исә автор өч "моментны" берләштерергә ниятләгән. Бу хәл, табигый ярашмау нәтиҗәсендә, композицияне шактый катлауландырган, ана ясалмалык, таркаулык керткән. Романның күп өлеше үзәк темага, детективка кагылышсыз вакыйгалардан тора. Автор аларны, төп сюжеттан аерып, күбесенчә эпизодик чигенешләрдә биргән. Андыйларның беришен язучы үзе дә "гайбәт" ди. Асылда алар теманың тышында торып калганнар. Дөнья әдәбиятында бу рәвешле берләштерү күзгә чалынмый. Әйтергә кирәк, "Тирән тамырлар"да урын алган мул эпизодик чигенешләр үткән гасыр татар прозасына сизелерлек йогынты ясады, аларның үрчүенә китерде. Әмма моның да берәр төрле максаты булмады микән? Автор ул чигенешләрне, темадан аерылып торган картиналарны әсәрнең тәнкыйтьләү, фаш итү пафосын бераз яшерү, маскировкалау, шул күренешләр арасында күмеп калдыру нияте белән кертмәде микән? Кыскасы, янадан-яна сораулар чыгып тора. Аларга жавап эзләү һәм табу күренекле әдипне дөрес аңлау өчен кирәк.

Билгеле, безнең бу фаразны бөтен кеше дә кинәт кабул итмәскә мөмкин. Бердәм фикергә килү өчен әсәрне тагын да җентекләбрәк, уйлабрак, бергәләп тикшерү, төрле карашларны үлчәп карау сорала.

**Фәрит ХАТИПОВ,**
*филология фәннәре докторы,*
*профессор.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Кишет һәм Яңа Кишет авыллары

Иске Кишет һәм Яңа Кишет авыллары Арча районына керә. Яңа Кишет Арчадан—28, ә Иске Кишет 29 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыллар борынгы. Иске Кишет авылы Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Эпиграфист Һарун Йосыпов Иске Кишет авылы зиратында XVI йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы тапкан. Археологлар авыл зиратында тагын XVI йөзнең беренче яртысына караган кабер ташы һәм мәетләр күмелми торган зират урыны (болгар—Алтын Урда—татар чоры) һәм анда шулай ук XVI йөзнең беренче яртысына мөнәсәбәтле кабер ташлары тапканнар. М. Әхмәтҗанов мәгълүматларына караганда, авыл болынында иске зират өстеннән алынган каберташлар ята. Язулары бозылган, бизәкләре буенча Казан ханлыгы дәверенә карыйлар. Д. А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) күрсәтелгәнчә, Иске Кишет авылында 172 ясаклы татар, ә Яңа Кишеттә, икенче төрле Булгак бушлыгында 185 йомышлы татар көн иткән. 1761—1866 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында әйтелгәнчә, авылда чукындырылмаган ясаклы татарлар көн иткән. А. Артемьев китабында (1866) Иске Кишет һәм Яңа Кишет авыллары телгә алына. Алар икесе дә Симет суы янына утырганнар. Иске Кишет авылындагы 126 хуҗалыкта 250 ир-ат һәм 464 хатын-кыз көн иткән, анда бер мәчет эшләгән. Яңа Кишет авылындагы 108 йортта 586 ир-ат һәм 467 хатын-кыз көн күргән, авылда бер мәчет булган. 1878 елда Н. Н. Вечеслав тарафыннан бастырып чыгарылган «Казан губернасы авыллары исемлеге»ндә (Казан, 1878) Иске Кишет авылында ике агач мәчет, бер мәдрәсә, ике су тегермәне, бер җил тегермәне булуы әйтелә. Бу авылда хуҗалыклар саны 196 дип күрсәтелгән, аларда 501 ир-ат һәм 523 хатын-кыз яшәгән. Болак һәм Симет суы буена утырган Яна Кишеттә 196 йорт булып, аларда 562 ир-ат һәм 546 хатын-кыз исәпләнгән. Авылда ике агач мәчет, бер җил тегермәне һәм ике су тегермәне булган. Иске Кишет атамасы И. А. Износков китабында да искә алына. Ул Симет суының сул ярына, Уржум сәүдә юлының уң ягына урнашкан. Авыл янындагы зиратта кабер ташы язмалары билгеләнгән. И. А. Износков Иске Кишеттә 174 йортта 616 ир-ат һәм 583 хатын-кыз яшәвен күрсәтә. Тормышлары уртача булган, һөнәрләре—он тарту, урман кисү, умартачылык һ. б. Яңа Кишет турында И. А. Износков түбәндәгеләрне яза. Авыл Симет һәм Болак сулары буена утырган. Бу чорда Яна Кишет авылында 178 хуҗалык булган. Анда ислам дине тота торган 616 ир-ат һәм 602 хатын-кыз яшәгән. Тормышлары әйбәт булган. Халык киндер сугу белән шөгыльләнгән. 1898 елгы җыентыкта Иске Кишет һәм Яңа Кишет авылларында татарлар яшәгәнлеге искәртелә. Н. К. Берстель җыентыгыннан Иске Кишет авылында 1203 татар, Яңа Кишеттә 1326 татар кешесе яшәгәнлеге билгеле.

Нажия Борһанова мәгълүматлары күрсәтүенчә, Иске Кишет, Яңа Кишет, Кышкар, Симетбаш, Олы Мәңгәр, Иске Мәңгәр, Яңа Мәңгәр, Бәхтияр, Симетбаш авыллары халкы җыелып Кышкар җыены үткәргән.

Кишет авылы Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтендә дә искә алына. Чыгышы белән Яңа Кишет авылыннан булган Рәхмәтулла бине Әмирхан бине Имәнколый бине Нурсәед әл-Кишети Казан шәһәре ратушасында тәрҗемәче булып эшләгән.

Авыл халкы сөйләвенә караганда, Кишет авылларының урыннары элек монда булмаган. 1552 елда Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алганнан соң татарларны Казан тирәсеннән куган. Элек Иске Кишет авылы Биектау районындагы Хохлово авылы урынында булган. Алар шуннан хәзерге урынга күчеп утырганнар. Яңа Кишет авылын бабайлар Иске Кишеттән аерылып чыккан дип әйтәләр. Казан руслар тарафыннан

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

алынган вакытта Яна Кишет авылы Казансу бассейнында хәзерге Калинино авылы янында, «Озынлыклар тегермәне» дип аталган җир тирәсендә булган. Хәзер Кишет авыллары урнашкан урында чирмеш авыллары булган, имеш. Марилар төньяккарак күчеп утырганнар. Татарлар алар урынына авыл нигезләгәннәр. Авылда ике чирмеш гаиләсе калган һәм алар исламга чыкканнар.

Авыллар урынында элек калын урман үскән.

Иске Кишет авылы Кишет суының сул ягына утырган. Олылар сөйләве буенча, авылга иң беренче килеп утырган кеше Кишмәт исемле булган. Ул йортын Пучинкә урамына салган дип әйтәләр. Еллар уза-уза Кишмәт исеме Кишеткә әйләнгән диләр.

Иске Кишет авылы табигатьнен матур җирендә урнашкан. Аның янында елга-инешләр, чишмә-кизләүләр, тау-калкулыклар, урман-куаклыклар, урман аланнары, ерымнар, болыннар һ.б. күп. Югарыда күрсәтеп үтелгәнчә, авыл елгасы Кишет Ашыт суына кушыла. Кишет суына Симет, Салам күпер, Караүгез, Кучы, Чирмеш, Чүлмәнчек, Чәләнгеч, Коттый, Әче, Бәхтияр, Ташчишмә, Туктамыш, Үләт елга-ермаклары коя. Кара үгез елгасы исемне үгезгә мөнәсәбәтле рәвештә алган. Бу елга суында бер байның кара үгезе баткак урынга кереп чумган да аны авыл халкы көч-хәл белән тартып чыгарган. Авылга якын гына Мүкле күл бар.

Тирән елгаларның сулары кипкән. Чишмәләрдән Дүрт агач чишмәсен, Илдус чишмәсен, Ташчишмәне, Караүгез чишмәсен, Кучы чишмәсен, Шыгалы чишмәсен, Чәләнгеч чишмәсен һ.б. ны атарга мөмкин. Кырлардагы күлләр кибеп беткәннәр. Сазлыклар күбесенчә Мәңгәрләр ягында урнашкан: Таллы ермак, Иске зират, Шыгалы чишмәсе тирәләрендә сазлы урыннар бар. Буалар Салам күпердә, Ташчишмәдә, Югары очта (Алтын күпердән алдарак), Мәнгәр очында (терлекләр җәйләвеннән сон), Яна Кишет ягындагы Кучыда, Яшелчә тугаенда ясалган. Чәләнгеч тавы, Коттый тавы, Яна зират, Иске зират, Шыгале һәм Кучы таулары—авылның күренекле тау-калкулыклары. Авыл янында Тау, Бәхтияр яр басулары, Шыгалы асты, Иске зират кебек урыннар бар.

Шыгалы асты урыны турында аксакаллар болай сөйлиләр: «Иске Кишет авылы янында, су буенда Шыгалы асты дигән урын бар. Анда элек Шаһ Гали хан авылы булган. Халык хәтерендә ике зират урыны сакланган. Аларның берсе сукаланган, икенчесе әлегә кадәр калган, агачлары да бар, канау белән чолгап алынган.

Авыл халкы тагын «Бишектәге бала» дигән риваять сөйли. Шыгалы зираты тирәсендә урман булган. Моннан 2-3 буын элек яшәгән бер кеше шул тирәгә урманга баргач, анда ике гөләф (гөләп) агачын сыгып бала бишеге асып куелганны күрә, эчендә баласы да була. Бу кеше баланы алып кайтып үстерә. Аның анасы кем дип сорагач: «Мәнди анасы Гөләф җинги»,—дип җавап биргән, имеш.

Авыл тирә-юнендә Яна Кырлай урманы янсә Рушша (Роща), Мүкле күлне узгач, Күшәр урманы (куаклыгы) урнашкан. Күшәр куаклыгы каен, усак, өрәнге, юкә, шомырт, чикләвек, акация, балан, миләш, тополь агачларыннан тора. Рощада чыршы, нарат, каен, усак, тополь, өрәнге, юкә, чикләвек, шомырт, миләш, кура җиләге, кыргый алмагачлар үсә.

Таллы ермак гөлҗимеш куаклары белән әйләндереп алынган. Субаш-Атыга бару юлында һәм Мүкле күлдән соң калкулыкны узгач чикләвек куаклары үсә. Авыл янында печән үсә торган чабылдык җирләр шактый. Салам күпер, Таллы ермак, Ташчишмә елгасы буйларында һәм ермакларда печән әйбәт үсә.

Авылда исемле күперләр: Кучы күпере, Чишмә күпере, Сталин күпере, Хәсби күпере, Әчегән күпере, Әче күпере. Элекке күпер исеменнән Салам күперне атарга мөмкин.

Авылда элек 2 мәхәллә һәм мәдрәсә булган. Мәчет манарасы 1935—1936 елларда киселгән. 1996 елның октябрь аенда яна мәчетнен нигезе салынган.

Иске Кишеттә хуҗалыклар саны 124 чамасы. Авылда башлангыч мәктәп, клуб, китапханә, медпункт, балалар бакчасы бар. Газ кергән, өйләрдә су бар, урамдагы колонкалар эшли, тирә-юне тотып алынган. Яна Кырлай—Кишет юлы күтәртелгән һәм аның яртысына асфальт салынган иде.

Авылда 3 зират бар. Иске зират Чүлмәнчек елгасын узып китеп Мүкле күлгә барганда сул якта кала. Шыгалы зираты Ком базыннан көньяк-көнбатышта урнашкан. Мәрхүмнәрне хәзер күмә торган зират Чишмә күперен чыккач, Кишет елгасының уң ягында. Авыл халкы зиратны карап тора. 1996 елның җәендә зиратны яна койма белән тотып алганнар.

Авылда олы буынга игътибар бар. Картлар йортына бирелгән карт-карчыклар юк.

* * *

Яна Кишет авылы, югарыда әйтеп үтелгәнчә, Иске Кишеттән аерылып чыккан.

Авыл олы юлдан 7 чакрым эчкә кереп, кечкенә генә инеш—Симет суы буена урнашкан. Олы кешеләр сөйләвенә караганда, авыл халкы бай яшәгән. Революциядән соң авыл халкының күбесе, кулак дип исәпләнеп, Себергә сөргенгә җибәрелгән.

Авылдан зыялы кешеләр дә чыккан.

Ш. Мәрҗани Казан шәһәрендә татар ратушасында тәрҗемәче булып эшләгән Рәхмәтулла бине Әмирхан бине Имәнколый бине Нурсәед әл-Кишети турында түбәндәгеләрне яза: «...Чыгышы—Казан өязенең Яна Кишет авылыннан. Яшь чагында атасы белән Казанга килеп, Пороховойда һәм Бишбалтада яшәп, бераздан соң шәһәрнең үзендә беренче мәчет янында йорт салып, анда бераздан Күл башында—Болак буенда йорт алып, анда өй салып, күп еллар яшәде. Казанда булган зур янгын вакытында йорты янып, хәле начарланды. Ахырга таба бу йортны сатып һәм дөньясы тараеп, Яна бистәгә барып йорт алса да, ул йортка икенче берәүнең дәгъвасы булганлыктан, квартирага күчәргә мәҗбүр булды. Йорт өчен биргән акчасы да югалды. Үзе шеш авыруына дучар булып, 1292 (1875) елда, чәршәмбе көнне егерме өченче Зөлхиҗҗәдә вафат булды. Яше житмештән үткән иде. Җеназасын мелла Шаһиәхмәд үтәп, яна каберлектә җирләнде».

Авылда Советлар Союзы Герое генерал-лейтенант Гани Бикки улы Сафиуллин туып-үскән. Яна Кишет авылының урта мәктәбендә аңа багышланган музей эшли. Иске һәм Яна Кишеттән күп кенә инженер-механиклар, техниклар, укытучылар, хәрбиләр, врачлар һ.б. чыккан.

Югарыда әйтелгәнчә, авыл урынында калын урман үскән. Яна Кишет топонимнары арасындагы Дүрт карама үскән урын шул урманнарның калдыгы. Куралы ышна, Эшкәч басулары да урманнан чистартылган чәчүлек җирләр. Экспедиция дәфтәремдә елга-инешләрдән Болгак, Мансыр, Әби, Эшкәч, Шәбәрде, Качкалак һәм Тукбай исемләре теркәлгән. Яссы елгасы янында чирмеш зираты бар икән, казыганда аннан сөякләр чыккан.

Авыл тирәсендә чишмә-кизләүләр күп. Әхмәт, Гарифҗан, Хәйри, Назир һәм Жиһанша чишмә-кизләүләре үзләрен карап, чистартып торган кешеләр исеменә мөнәсәбәтле рәвештә аталып йөртелә. Моннан башка тагын Сабыр, Тукбый, Шыгале, Бадиар һ.б. чишмәләре бар. Дегет базы дип аталган урында, имеш, марилар дегет кайнатканнар. Шәфи йөрәге диган исем алган урында ике елга бергә килеп кушылган.

Авыл тирә-юнендәге чишмә-кизләүләрнең күбесе юкка чыккан. Авылдан ерак түгел генә, бер агып утыра торган чишмә бар. Авыл халкы ул чишмәне саклый, югалтмый. Ул халык тарафыннан Улаклы чишмә дип йөртелә. Көтү көтәргә барган кешеләр ул чишмәнең суын савытка тутырып алып кайталар һәм чәй куеп эчәләр. Ә авылдагы коеларның буралары искергән, алар каралмый инде. Халык суны колонкалалардан эчә.

Авыл янында зур урманнар бар. Исемнәре мондый: Шәмәрдән урманы, Чиканас урманы, Кырлай урманы.

Яна Кишет авылында 3 урам. Халык урамнарны үзенчә атый: Атау очы, Иске Кишет очы, Кышкар очы.

Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, почта, китапханә, кибет, 40 сабыйга исәпләнгән балалар бакчасы, медпункт бар. Алар барысы да заман таләпләренә җавап бирәләр.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юллар асфальтланган.

Авылда мәчет ачылган. Теләгән кешеләр анда гыйбадәт кылырга баралар. Мәдрәсә дә ачылсын диган теләктә калабыз.

Авыл халкы ата-ана, әби-баба ята торган зиратны тәртиптә тота.

Авылда ялгыз яши торган өлкәннәр һәрдаим игътибар үзәгендә. Ялгыз яшәүче Кәшифә апаны Тажетдинова Гөлнур ханым карый икән.

Инде авыл халкының кушаматларын да әйтик: шәкерт, көчекләр, койрыклар, борчак, чабак, куян, ычкындыр, бүре, күселәр, үрдәк, мәтәй, пөшәлә, токарь, чыпчыклар, күке, челтер, чүмәлә һ.б.

Кушаматлар үз тормышлары белән яшиләр. Халык һәр авылда бер-берсенә ягымлы гына итеп кушамат та куя. Дөнья, тормыш...

## Иске Кырлай һәм Яңа Кырлай авыллары

Иске Кырлай авылы Арча районында, район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән—12, ә Яңа Кырлай авылы Арчадан 22 чакрым ераклыкта урнашкан.

Яңа Кырлай—билгеле авыл. 1892—1895 елларда анда Сәгъди ага гаиләсендә халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай яшәгән. Монда ул Фәтхерахман мулла мәдрәсәсендә беренче тапкыр кулына китап ала.

1895 елда Габдулланы Газизә апасы Госманова Уральски шәһәренә үзе янына алдыра.

Яңа Кырлай авылында Тукай хөрмәтенә музей ачылган. Бу музейның соклангыч экспонатлары бар, бирегә ерак төбәкләрдән, чит илләрдән дә кунаклар килә.

Кырлайга багышлап күп кенә җырлар чыгарылган. Кырлай каеннары (Рәсих Ханнанов шигыре, Мәсгут Имашев көе), «Син, изге Кырлаем» (Флера Гыйззәтуллина шигыре, Луиза Батыр-Болгари көе). Соңгы шигырь юллары Тукай исеме белән бәйләнешле:

*Синдә Кырлай, кайнар моң дәрьясы,*
*Синдә гөлләр һәрчак бөредә.*
*Үреңдәге шаулы карурманнар*
*Бигрәк серле булып күренә.*
*Кушымта:*
*Шул урман-кырларны Тукаең*
*Тылсымлы җыр белән бизәде.*

*Хаҗ кылу төбәге син, изге Кырлаем—*
*Халкымның сафлану үзәге.*

*Мәрхәмәткә, назга төреп, Кырлай,*
*Шагыйрь хакын, алла хакларын*
*Күп гасырлар, изге ана сыман,*
*Күкрәгеңә кысып сакладың.*

Кырлай атамасының борынгылыгы тарихи документлар белән раслана. Алат юлы өстендәге Иске Кырлай һәм Яңа Кырлай авыллары Казан ханлыгы чорында ук булган. Кырлай атамасы 1602—1603 еллардагы мәгълүматларны эченә алган Казан өязе теркәү кенәгәсендә күп очрый. Д. А. Корсаков хезмәтендә (XVIII йөз) Каракөек суы буена утырган Кырлай авылында (№ 154) 41 йомышлы татар, Ия суы ярындагы Кырлайда (№ 159) 81 йомышлы, 10 ясак түли торган, Кече Кырлай авылында (№ 166) 21 йомышлы татар яшәгәнлеге күрсәтелә. А. Артемьев китабында Кырлай авыллары болай сурәтләнә. Яңа Кырлай авылының 28 хуҗалыгында 133 ир-ат һәм 125 хатын-кыз яшәгән, авылда бер мәчет эшләгән. Иске Кырлай авылының 49 йортында 281 ир-ат һәм 295 хатын-кыз көн күргән, авылда бер мәчет булган. Каракөек суы янындагы Кырлайның 28 йортында 195 ир-ат һәм 169 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер мәчет эшләгән. Н. Н. Вечеслав хезмәтендә (1878) Каракөек буендагы Кырлайда 56 йортта 191 ир-ат һәм 162 хатын-кыз көн иткәнлеге хәбәр ителә. Анда бер агач мәчет тә булган. Бу чыганакта Яңа Кырлай авылы да искә алына. Андагы 68 йортта 173 ир-ат һәм 191 хатын-кыз көн иткән. Авылда ике агач мәчет булган, бер тимерче алачыгы, вак-төяк сата торган өч кибет, бер су тегермәне эшләгән. Иске Кырлай авылындагы 89 йортта 336 ир-ат, 300 хатын-кыз яшәгән. Авылда 2 агач мәчет, вак-төяк сата торган 3 кибет, бер тимерче алачыгы һәм су тегермәне булган. И. А. Износков Кырлай авылларын түбәндәгечә сыйфатлый. Кара-Көек елгасы янындагы Кырлай, Кырлай Каракөеге. Авыл Себер элемтә юлына урнашкан. Авылдагы 39 хуҗалыкта 173 ир-ат һәм 184 хатын-кыз көн күрә. Алар ислам дине тота һәм Кара-Көек авылы җәмгыятенә керәләр, тормыш-көнкүрешләре уртача.

Иске Кырлай Ия суы буена, Себер элемтә юлының сул ягына утырган. Авылдагы 91 хуҗалыкта 307 ир-ат һәм 304 хатын-кыз исәпләнгән, алар ислам дине тотканнар һәм Иске Кырлай авыл җәмгыятенә кергәннәр. Бу урынга халык хәзерге Хохлово (Өнсә суы янында булган) авылы урыныннан (XVIII гасыр ахырында) күчеп килгән. Ягъни руслар килеп утыргач татарлар бу җирне ташлап киткәннәр. Хохлово авылындагы бер кыр әле дә Мазар кыры дип йөртелә. Монда элек зират булган һәм татар телендә язылган кабер ташлары табылган. 1860 елга кадәр татарлар бу урынга гыйбадәт кылырга килә торган булганнар. Авылда өч кибет, тимерче алачыгы һәм су тегермәне булган.

И. А. Износков хезмәтендә (XIX йөз) Яңа Кырлайның тагын икенче исеме Иябаш дип бирелгән. Авыл Ия суы ярына, Себер элемтә юлының сул ягына урнашкан. Авылдагы 66 хуҗалыкта ислам дине тотучы 196 ир-ат һәм 227 хатын-кыз яшәгән. Халык Яңа Кырлай авылы җәмгыятен төзегән. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган, халык иген игү, киндер сугу белән шөгыльләнгән.

Н. Борһанова мәгълүматларына караганда, элекке заманнарда Яңа Кырлай, Ашытбаш, Кысна, Иске Иябаш, Яңа Иябаш авыллары халкы бергә җыелып Иябаш җыены үткәргән. Ул җыен икенче төрле Кырлай җыены дип тә аталган. Чиканас, Иске

Кырлай, Субаш-Аты авыллары халкы Урман жыены бәйрәм иткән. Икенче төрле ул Урман жигү дип аталган. Аны май ахырында бәйрәм иткәннәр.

Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан Яңа Кырлай авылы зиратыннан XIX йөзгә мөнәсәбәтле каберташ табылган. Тексты: «...1895 нче йылда 3 нче априлдә Йаңа Ийабашы авылының Ибраһим җәмагате Гайшә Фәтхулла кызы 70 йәшендә вафат булды. Аллаһу Тәгалә рәхмәт әйләсен».

Өлкән буын кешеләре сөйләвенә караганда да Кырлай авылы оешканга 400—500 еллар бар. Урман кырыенда утырганга күрә, ул Кырлай булып калган. Имеш, башта бу урында чирмешләр яшәгән. Татарлар бирегә Тазлардан (хәзер Ташчишмә), Наласадан, Соңгырдан күчеп килгәннәр. Чирмешләрнең чукынмаганнары исламга чыккан. Авылда әлегә кадәр чирмеш нәселләре дип йөртелә торган нәселләр бар. Соңгыр авылыннан килеп төпләнгән бер нәселнең шәҗәрәсе мондый. Ахун (ул Яңа Кырлайга мулла булып килгән) -> Ибәтулла -> Габдулла -> Төхфәтулла -> Әхмәтша -> Фәйзерахман -> Гарәфетдин -> Бакый (ул 1935 елгы). Соңгырдан килгән икенче нәселнең шәҗәрәсе: Мәннаф -> Вәли -> Галимулла -> Ярулла -> Гомәр (1927).

Яңа Кырлай тирәсендәге табигать ямьле. Өлкәннәр сөйләве буенча, авылны элек һәр яклап зур урман уратып алган була. Авылның бу урманы Габдулла Тукайның «Шүрәле» әсәрендә чагылыш тапкан.

*Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;*
*Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.*
*Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр*
*Бергә-бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.*
*Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби,*
*Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.*

Әйе, электә чәй кайнап чыкканчы әби-апалар бакча артындагы урманга барып чәй эчәргә җиләк җыеп кайта торган булганнар. Хәзер урманнар авылдан бер-ике чакрымда. Авыл халкы урманга Болын юлы, Унынчы башы дип аталган юллардан барып йөри. Исемнәреннән күренгәнчә, бу тирәләрдә кайчандыр болынлыклар булган. Болын юлында хәзер бер тирән ермак кына калган. Ермак тирәсе сукаланган, анда культуралы үсемлекләр үсә. Карлыганлык болыны дип аталган болынның аерым урыннарында карлыган үскән.

Авыл уртасында Ия елгасы (Казансу кушылдыгы) агып ята. Елганың башланган урыны авыл басуында гына булганга, ул әллә ни зур түгел, аны инеш дип әйтү дөресрәк булыр. Габдулла Тукай аны әллә кайчан «Халкының эчкән суы бик кечкенә, инеш кенә» дип язып калдырган. Хәзер көчле елгада бик шәпләп буа (плотина) төзелгән. Буа тирәләре бик ямьле. Аның ике ягында да агачлар. Биш-алты ел элек буага карп балыклары алып кайтып җибәргәннәр. Кырлай һәм башка күрше авыллардагы халык монда үскән балыкны рәхәтләнеп тота, файдалана башлаган икән дә, аянычка каршы, бу рәхәт озакка бармаган. Бер-ике ел элек суда аммиак мичкәләрен юдыру аркасында һәм фермадан агып төшкән пычрак сулар белән балыклар агуланган һәм күпләп үлгән. Буада халык су коенмый башлаган. Хәзер су акрынлык белән генә чистаруга, сафлануга таба бара диләр-диюен.

Ия суына кушыла торган суларның берсе—Зиреклек елгасы. Тирәсендә зирек агачлары күп җыелып үскәнгә бу елга шулай аталган.

Авылда чистартып һәм каралып тора торган күренекле чишмәләр юк дисәк ялгыш булмас. Чишмәләрнең кадере юк, карамау нәтиҗәсендә күбесе ябылган. Авылда су хәзер һәр йортта, һәркемдә газ. Чишмә һәм кое суларының шуңа кадере юк, чыганакларга игътибар беткән.

Яңа Кырлай урамнарының халык телендә кулланыла торган атамалары түбәндәгеләр: Таш урам, Аргы як, Пятый башы, Каклан йорты, Зират ягы.

Яңа Кырлай авылында рәсми рәвештә теркәлгән мәхәллә 1807 елда оешкан. Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган бер катлы агач бинасы Казан губерна идарәсе тарафыннан 1911 елның 29 апрелендә расланган проект буенча төзелгән. Аңарчы XIX гасыр уртасында салынган һәм Синод фәрманы белән (1887 елның 16 июне) җәмигъ мәчет итеп үзгәртелгән агач гыйбадәтханә эшләп килгән.

1849 елның 15 апрелендә имам-хатыйб булып Гатаулла Гобәйдуллин сайлана. Ул, 40 ел буена үз вазифаларын башкарып, вафат булгач, аның урынына улы Фәтхерахман Гатауллин (туган елы—09. 08. 1857) билгеләнә. Ф. Гатауллин 1917 елга кадәр имам булып тора, исеме тарихка Г. Тукайның беренче укытучысы буларак кереп кала.

1892 елның июнь уртасында авыл крәстиәне Сәгъди абзый булачак шагыйрьне Өчиле

авылыннан Кырлайга алып кайта, ә шул ук елның көзендә Габдулланы хәзрәт хатынына Мәһруйбикә абыстайга сабакка бирәләр. Малай укуга сәләте белән кешене шаккатыра, шуны истә тотып, бер елдан соң ук, Габдулланы мәхәллә мәдрәсәсенә язалар. Монда ул, Фәтхерахман хәзрәт житәкчелегендә башлангыч әдәбиятны үзләштереп, Коръән өйрәнүгә күчә. 1894 елның көзендә Г. Тукай Яна Кырлай авылыннан китә. Икенче тапкыр шагыйрь бу авылда 1907 елның октябрендә була.

Яна Кырлай авылы мәдрәсәсе артык зур булмаган. 1893 елда анда 17 малай һәм 13 кыз укыган. Мәхәлләдә 98 хужалык булып, аларда 269 ир-ат исәпләнгән.

Хәзер Яна Кырлай авылында 140 хужалык. Анда урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы эшли. Хужалыкларга газ кертелгән, үзәк урам асфальтланган.

Кырлай авылларының икесендә дә зиратларга игътибар зур икәнен әйтергә кирәк. Тирә-юньнәре рәшәткә белән тотылган, һәр елны авыл халкы, өмә оештырып, зиратларны корыган ботаклардан чистарта.

Яңа Кырлай һәм Иске Кырлай авыллары Казансуының ун кушылдыгы Ия суы буена утырганнар. Өлкәннәр сөйләве буенча, Яна Кырлай авылын нигезләүчеләрнең төп нәселләре Иске Кырлайдан күчеп килгән.

Авыл халкының түбәндәге кушаматлары бар: аю, бүре, кәчәй, чәкән, чүкеч, күсе, бәрәнге, торна, акбаш, кәжә, күгәрчен, ишәк, чемәк, әлдермеш карт, мәчтүрә, тавык, тырай, катык, әрмән, таз, немец, куян, сарык һ.б.

Иске Кырлай тирә-юнендә елга-инеш, чишмәләр күп. Балта бораy, Шалтыравык, Әпек, Карлыган елгалары суларын Иягә китерәләр. Әпек, Зират, Кырлай чишмәләре дә, әйләнә торгач, Ия суына килеп кушылалар. Иске Кырлайның горурлыгы булган изге чишмә һәм алма бакчасы турында берничә сүз әйтмичә китү гөнаһ булыр иде.

Изге чишмәне махсус карап торучы кеше юк. Ләкин аннан су алып киткән һәр кеше аны үзенчә чистартып һәм тазартып китә икән. Шәһәрдән кайтучылар аның суын савытларга тутырып алып китү ягын кайгырталар икән. Сәбәбе бик гади: суын төрле авырулардан тазарта, шифалы дип сөйлиләр. Шулай да бу чишмәне махсус ясалган чишмә йорты белән бизәсәң, улак куйсаң, ел саен күзәтеп һәм чистартып торучы бирәр кеше билгеләсәң бик игелекле эш булыр иде.

Элек авылның алма бакчасы тирә-юньдә данлыклы булган, хәтта аны саклау өчен махсус каравылчы да куелган. Хәзер бу бакчага игътибар юк, ләкин алмагачлар һәр яз саен шау чәчәккә күмеләләр һәм тирә-юньгә хуш ис таратып утыралар.

Авыл янындагы Мүксаз дип йөртелгән сазда мүк үсә. Өй салганда халык бу саз мүгеннән бик нык файдаланган. Аю сазы тирәсендә элекке заманнарда калын урман булган, аюлар да очраштырган. Авыл янында Әкәй өсте дип йөртелгән тау бар.

Иске Кырлайда сигезьеллык мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, элемтә үзәге, китапханә, кибет, такта яру цехы эшли.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән, авыл эчендәге юллар күтәртелгән.

Авылда мәчет эшли, теләгән кеше анда гыйбадәт кылырга йөри. Авыл халкы өлкәннәргә игътибарлы, жае туры килгән саен аларга ярдәм итеп торалар. Картлар йортына бирелгән өлкәннәр юк.

Авыл халкының кушаматлары да бар: буты, ык-мык, никыл, куян, күли, нутри, кисмәк, пычтыр, виржилио, шәпыйк, нәчүр, бака һ.б.

Авылда халык хөрмәт итә торган Низаметдинова Әминә Гомәр кызы яши. Ул 1940 нчы елда туган. Әминә ханымны халык ак кеше, саф кеше дип атый икән һәм өлкән яшьтәге кешеләр ана үз васыятләрен алдан ук: «Әминә сеңлем, соңгы юлга мине син озатырсың»,—дип әйтәләр икән. Ул мәрхүмнәрне соңгы юлга озатканда, аларны шәригать канунннарына туры китереп юа, ахирәт күлмәге тегә һәм киендерә икән.

Әйе, һәр эшнең үз остасы була...

*Дәвамы киләсе саннарда*

# КЕМ УЛ КИМ МИҢНУЛЛИН?

Бәрәкәтле Башкортстан туфрагында туып, үз халкына хезмәт итүче милләттәшләребез байтак. Гөлҗәүһәр апанын улларынын берсе, Роберт исемлесе әйтмешли, исемендә алфавитнын татарга гына хас бөтен хәрефләре дә сыеп бетә язган юмарт әнкәйнен биш җәүһәре дә шулар җөмләсеннән.

Һәркайсы аерым игътибарга лаек булса да, юбилей форсатыннан файдаланып, ир балалары арасыннан иң кечесе Ким Мөгаллим улы турында берничә сүз әйтмәкчемен. Танышканда ул минем өчен иң әүвәл эш буенча бәйләнешле хөкүмәт чиновнигы, аннан соң гына Роберт Миннуллин энесе иде. Еллар узган саен безнең арадагы чикләр пәрәвез җебедәй нечкәрде, ахирәтләр үк булып китмәсәк тә, ул минем эшемдә-тормышымда ышанычлы гамьдәш сурәтен алды. Кемгәдер сәер тоелыр, әмма без урамда очраклы гына күрешсәк тә, хәтта сирәк ял сәгатьләрендә телефоннан хәл белешсәк тә, гел эш турында, бары тик эш турында сөйләшәбез. Һәм бер очрашу-кинәшүебез дә сүздә генә калмый—яңа проектларга, саллы китапларга әверелә, теге яки бу проблеманың иң дөрес чишелешен табарга ярдәм итә.



*Мөдәррис Вәлиев һәм Ким Миңнуллин.*

Бүген Ким Миннуллин—танылган җәмәгать эшлеклесе һәм зур галим, илдә бер гыйльми үзәк директоры, мөгаллимнәр әзерләүче югары уку йорты профессоры, фән докторы һәм Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы... Тик ул нинди генә дәрәҗәләргә ирешмәсен, безнең риясыз багланышлар үзгәрмәде—үзара хөрмәт, ярты сүздән аңлашу, фикердәшлек, эшлекле хезмәттәшлек рухында дәвам итә.

Танышуыбыз, алда искәртелгәнчә, әле кичә генә кебек. Яшь ягыннан мине узып китә алмаса да, инде әнә ул да ир уртасы булып килә. Әйләнеп карасаң... Кемнәрдер безнең өстән шикаять арты шикаять яудырып, башлыкларның үкчә эзен ялап гомер уздырган арада, байтак эш-гамәл башкарырга өлгергәнбез икән. Яшерен-батырын түгел: халкыбызга хезмәт итү, аны тагын да зыялырак, тагын да бөегрәк күрәсе килү теләге шәхси мәнфәгатьләребезгә туры килгән; үз алдыбызга куйган максатларга ирешү өчен төп терәгебез—безгә ышанып тапшырылган эш урыннары-вазифалар булган. Безне көндәш күргән, ни өчендер бездән курыккан кемсәләр нинди дә булса эш кырырга дисән,—кәнәфиләренә чытырдап ябышканлыктан, куллары бушамаган, якты фикерләр килсен өчен—кара уйлар белән тулы башларында урын табылмаган. Әйе, безнең төп "злоупотребление"—республикада узган гасырның 90нчы елларыннан башланган тел сәясәте мөмкинлекләрен, җитәкчеләребезнең фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге кайгыртучанлыгын нәтиҗәле файдалану иде. Һәм без фикердә "әшнәлек"не берәүгә каршы да бормадык, киресенчә, уртак эшләребезгә янадан-яна талантлы галимнәрне, булдыклы яшьләрне җәлеп итәргә тырыштык, аларга үз мөмкинлекләрен тулырак ачарга ярдәм күрсәттек.

Премьер-министр урынбасарлары Илгиз Кәлимулла улы Хәйруллин, аннары Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева, шулай ук Министрлар кабинеты аппараты башлыгы Шамил Хәмит улы Гафаров кул астында эшләү дәвере—үзе бер мәктәп булса, аларнын ышанычын Ким Мөгаллим улы көндәлек фидакарь хезмәте белән аклады. Ана бу юлда ныклы иманы, зур җаваплылык хисен тоюы, кешеләр белән эчкерсез мөгамәләсе, тирән фәнни әзерлеге, фикердә принципиальлеге, зирәклеге һәм кыюлыгы ярдәм итте дип уйлыйм.

Хөкүмәт эшендә чагында туган телне саклау һәм үстерү буенча гыйльми эшчәнлекне оештыру җәһәтеннән, һич арттырусыз,—бер ялгызы бер институтка тиң булган Ким Миннуллин—сәгате суккач—үзен фән юлына алып кергән остазлары янына әйләнеп кайтты. Хәер, аспирантурада укыган чакларыннан алып, Г. Ибраһимов исемен йөрткән Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан аның киткәне дә юк кебек иде. Әмма бу кайту әнисе һәм абыйсы сабакларын алган, тормыш мәктәбен узган яшь житәкченең икенче сулышы ачылуга тиң булды... Ниһаять, әтисенең Мөгаллим дигән исемен аклап, мөгаллимлек итүгә күбрәк вакытын сарыф итү, үз шәкертләрен тәрбияләү, яшь галимнәрне үстерү мөмкинлеге, кыскасы, фәнгә һәм фикер алгарышына хезмәт итү мөмкинлеге артты... (Хөкүмәттә эшләү дәверендә дә ул үз бүлегенә булдыклы егетләр алды, аларны чын мәгънәсендә үз канаты астында тәрбияләп, яна, катлаулырак вазифаларга озатты, һәм бүген аларның барысы да диярлек—эш башында торучы дәрәжәле житәкчеләр.) Фәнни-оештыру эшчәнлегенең ябалдашы шул рәвешле куерса, тамырга ныгуы исә—гыйльми эзләнүләренең иң тирән мәдәни катламга—халык ижатына багышлавында да чагылыш тапты. Аның "Һәр чорның үз жыры", "Шигърият һәм жыр", "Басма сүз һәм татар жырлары" дигән саллы монографияләре, исемнәреннән үк күренеп торганча, "халыкның раушан көзгесе"ндә чагылган мирасыбызны, аның саф чишмә-чыганакларын барлый. Остазы Фатих ага Урманче белән бергәләп төзегән "Татар халык ижаты" дәреслек-хрестоматиясе дә, ике басма кичереп, шул юнәлештәге житди хезмәтләрнең берсе буларак бәяләнде.

Тел сәясәтенең нәзари (теоретик) һәм гамәли (практик) мәсьәләләрен киң колач белән күтәрү, аерым алганда, XX гасыр дәвамында һәм әлегә кадәр татар филологиясенең иң четерекле мәсьәләләреннән берсе булып кала килгән алфавит белән орфографияне камилләштерү, шулай ук югары белемне туган телдә алу өчен мөмкинлекләрне киңәйтү, әлеге бурычларны башкарып чыгуның юлларын ачыклап күрсәтү, аларны хәл итүнең төп авырлыгын үз иңенә алу...—Мина калса, Ким Миннуллинның көндәлек эш-ижат үзәнен әнә шул ярлар билгели, ләкин алар арасына гына да сыеп бетми кебек ул. Аның киштәсендә үз гыйльми хезмәтләре белән рәттән, аларны язгандагы кебек үк, зиһенен егәрләп, күңелен салып башкарган тау-тау китаплар тезелеп тора. Татар телендә югары уку йорты дәреслекләре, фәнни монографияләр, терминология сүзлекләре... Сүзлек димәктән, хөкүмәттә Ким Миннуллин эшләгән ун еллап вакыт эчендә "тел ачкычлары"на аеруча зур игътибар бирелгән, аларның гомуми саны да XX гасырның шунарчы туксан елында басылып чыккан кадәр икән. Шулай да бу хезмәтләр арасында "Татарстан Республикасында тел сәясәте" дигән икетомлык аеруча кадерлесе булса кирәк. Әлеге куш китап узган гасырның ике кызыклы һәм катмарлы дәверен—егерменче-утызынчы еллар белән туксанынчы елларын—тоташтыручы күпер дә, янәшә куеп караганда күп кенә гыйбрәтләр алырлык манзара да кебек. Аның гыйльми һәм гамәли әһәмияте шундый ук киң колачлы һәм ерак перспективага юнәлгән.

Гомумән, төрле трибуналардан яңгыраган, көндәлек матбугатта дөнья күргән төпле, принципиаль чыгышлары—республикабызда тел сәясәте өлкәсендә кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыруда Ким Миннуллинның акыл белән, ныклык белән, эзлекле рәвештә, шәхси катнашуын сыйфатлаучы бер дәлил. Шулай да... Туган тел хакына күпьяклы һәм нәтиҗәле хезмәт итүне, бу юлдагы һәркөнлек даими эшчәнлекне, ә кайчакта, мәгълүм Сизифның тауга каршы тәгәрәткән ташы шикеллерәк, чигенә-чигенә булса да алга этәрергә туры килгән мәсьәләләрне юбилей мәкаләсендә генә чагылдырып бетерү бик читен. Шунысы тәгаен ачык: бу—әле йомгак ясау түгел, бу—озын юл уртасында бер мизгелгә тукталып, узганнарга борылып карау гына. Алда исә—яна үрләр, яна борылышлар,—кыскасы, хәрәкәт, эш, тормыш дәвам итә! Ким Мөгаллим улы Миннуллин житәкләгән институтның якын киләчәктә, Галимҗан Ибраһимов заманнарындагы кебек, "татарны өйрәнү" (татароведение)—татар фәнен һәм мәгарифен әйдәп баручы чын Академик үзәк—креатив идеяләр фонтаны, яна ачышлар технопаркы булып житлегәсенә иманым камил минем. Галим-житәкченең шәхси уңышлары да шул биеклек-дәрәҗәләрне билгеләр, иншалла.

Әлеге язмага керешкәндә, "Кем ул Ким Миннуллин?" дигән сорауны мин үземә куйган идем. Чөнки моңа кадәр ул хакта уйланырга җае да чыкмаган, вакыты да тимәгән икән. Чыннан да, беренче карашка бик аңлаешлы, итагатьле, ачык йөзле, шул ук вакытта вакыт-вакыт күзлек өстеннән "сөзеп", кара мыеклары астыннан

серле генә елмаеп куючан бу шәхес кем соң әле минем өчен һәм, әлбәттә, башкалар өчен дә?

Аны, әлбәттә, республиканың зур җитәкчеләре дә, олпат галимнәр һәм әдипләр дә, укытучылар һәм студентлар да яхшы белә. Бер сүз белән әйткәндә, халык таный. Инде шушы урында туктап: тынгысыз эзләнүләргә чумган "эш аты", язмышына шөкер итсә дә, үз-үзеннән һичкайчан канәгать булмаган галим һәм мөгаллим, абруйлы җитәкче һәм асыл ир-егет,—бик беләсегез килсә, менә кем ул Ким Мөгаллим улы, дип әйтергә буладыр. Әмма мин аның турында сүзне ничаклы гына дәвам итсәм дә, кәгазь битеннән күпнокта белән аерылырга туры киләчәк: Ким Миңнуллинны инде тулысынча ачылган, үз мөмкинлекләрен тәмам файдаланып бетергән шәхес дип расларга кем җөрьәт итәр икән...

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**

## *Укучы сүзе*

Исәнмесез, саумы сез "Казан утлары"н сүндермичә саклаучы редакция хезмәткәрләре! Мин, Аллаһ боерса, киләсе 2009 елда да сезнең белән калам, бу—сезнең хезмәтегезгә куйган бәям икәнлекне, шәт, аңлыйсыздыр? Журналыгызны бик яратам...

Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Роберт Әхмәтҗанов, Илдар Юзеев, Харрас Әюпләрнең вафатыннан соң шигърият дәрьягыз азрак саекканы һәм ярлыланганы сизелә. Яшь гүзәл затларыбызның шигырь ятратулары һәм аларны тудырырга омтылулары җанга рәхәтлек бирә. Әмма Луиза Янсуар белән Салисә Гәрәева тудырган могҗизалар белән чагыштырып булмый инде, җир белән күк арасы. Мондый шигъри тәлгәшләрне дәфтәр-дәфтәр тезсән дә, Шәүкәт Галиевнең бер "Кыя һәм кеше"сен алыштыра алмас! Салисә Гәрәева да сүзләрен чигү чиккәндәй җинел генә тезәргә өйрәнгән. Халыкка бик якын такмак телендә язылган:

*Киек каз юлларын кичтем,*
*Сары айга атланып*
*Еладым, кайткач илемә,*
*Чирәмнәргә капланып.*

Ринат Мөхәммәдиевнең "Кош булып очар идем" романын укыганда, аның туган җирдән аерылып, читтә иҗат итүе сизелә. Соңгы берничә ел эчендә теле бераз ярлылана төшкән кебек. ("Кенәри—читлек кошы"н бер тын белән укып бетерә алган булсам, бу романын өзелгән җирдән ялгап китә алмый азапланам.)

Радик Фәизовның "Ат карагы" хикәясен укып чыгу белән өр-яңадан укыйсы килә башлады. Бу хикәя остасының якташым булуына куанам. Хәбир Ибраһимны да Арчаныкы итәсем килә, телендә Тукай теле җылысы бар. Нурихан Фәттахның балачагын сурәтләү осталыгы Әмирхан Еники мәктәбен үтүен исбатлый. Әхмәт Рәшитнең "Һәркемнең үз сукмагы" хатирәләренең дәвамын көтә-көтә арып беттем. Аларны бер санда гына биреп бетереп булмый идеме соң?..

Фәнзаман Батталның төртмә, акыллы теле дә сагындырган. "Мәгариф" нәшриятында чыккан "Балачак әдипләре" томлыклары турындагы язмасын рәхәтләнеп укыдым, татар теле укытучыларына укучыларның зәвыгын тикшерү өчен биргән киңәшен дә бик яраттым, татар теле укытучысы булсам, мин дә аның киңәшен үтәп карар идем.

Адлер Тимергалинның вәгъдә ителгән Алла турындагы фәлсәфи уйлануларын бер санга сыйдырып бетерүегезне өмет итеп калам.

Фирдәвес Гарипованың авылларыбыз тарихын чагылдырган битләрен көтеп алам. Арча районының Кышкар һәм Орнашбаш авыллары тарихын да беләсем килә. "Үр суы" атамасының (Минзәлә районы) "Урыс"ка әйләнүен Фирдәвес язмаларыннан укып белү бер ананы тынычландырырга ярдәм итте. Шул авылга укытырга җибәрделәр, татар мәктәбен тәмамлаган балама җиңел булмас дип борчыла иде ул. Мин Урыс авылында татарлар гына яшәвен әйткәч, сөенде.

"Шәхесләр һәм шәрехләр" бүлегегезне һәм тормыш үзе иҗат иткән хикәяләр бирүегезне дәвам итсәгез иде.

**Флёра МӘРДАНОВА.**
Тукай районы, Күзкәй авылы.

## Әхәт Гаффарга 60 яшь

1949 елның 1 гыйнварында Татарстанның Балык Бистәсе районы Олы Әшнәк авылында туып, Олы Солтан мәктәбендә урта, 1966—1971 елларда Казан университетының журналистика бүлегендә югары белем алган, 1971—1981 елларда Казанда басылучы республика көндәлек матбугатында: "Яшь ленинчы" (хәзерге "Сабантуй"), "Социалистик Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газеталарында хәбәрче-корреспондент, "Казан утлары" журналы редакциясендә бүлек мөхәррире булып эшләгән, 1982—1987 елларда Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасына житәкчелек иткән күренекле прозаик һәм драматург Әхәт Гаффар иҗатының башлангыч чорында ук "Әҗәт" (1972) исемле хикәясе белән укучыларда зур кызыксыну уятып кына калмый, аннан соң да бер-бер артлы дөнья күргән хикәя, повесть, драма әсәрләре аша үзен сәләтле каләм иясе итеп танытты. Аның "Яра" (1973), "Язлар моңы" (1973), "Гозер" һәм башка әсәрләре дә әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителә. Сиксәненче-туксанынчы еллар исә Әхәт Гаффар иҗатының иң өлгергән чоры дип саналырга хаклы. Бу елларда аның өч романы дөнья күрә: "Бодай бөртеге һәм тегермән ташы" (1983), "Олы юлның тузаны" (1989), "Богау" (1998).



Ә. Гаффар әдәби эшчәнлегенең башында ук драматургия жанрын да үз итә. Нигездә әхлакый мәсьәләләрне үзәккә алган "Иртәгә улың булам", "Җиләк вакыты бер генә", "Бер картлыкта, бер яшьлектә", татарның тарихи шәхесләреннән М. Вахитовка багышланган "Сызылып таңнар атканда", Г. Тукай хакындагы "Соңгы сәгать", герой-шагыйрь М. Җәлил турындагы "Хөкем" исемле драма әсәрләре үз вакытында татар театрлары сәхнәләрендә уңыш казана. "Язлар моңы" әсәрен тамашачылар аеруча яратып кабул итә. "Әхәт Гаффар әдәбиятка үз материалы, үз карашлары, ныклы принциплары белән килде. Сурәтләү манерасы ягыннан да безнең өчен яңа юнәлештән, тапталмаган сукмактан килеп чыкты. "Ул лирик җанлы шигъри проза яза",—ди Ә. Гаффар иҗаты турында Татарстанның халык шагыйре Ә. Баянов. Әдипләрдән Х. Туфан, Г. Бәширов, Г. Кашшаф, Х. Сарьян, Р. Мостафин һ. б. да Ә. Гаффар иҗатына уңай бәя биреп, матбугатта үз фикерләре белән чыктылар.

Ә. Гаффар—театр сәнгатенә, әдәбият әһелләренә, республиканың икътисади һәм мәдәни тормышына, милли мәсьәләләргә багышланган язмалары белән дә үзен тынгысыз каләм иясе итеп танытты.

Ул—1975 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Аның әсәрләре шулай ук чит телләргә дә тәрҗемә ителгән, рус телендә Мәскәүдә өч китабы дөнья күрде.

"Төннәр буена йокы күрмичә каләм тибрәтүне мин фәкать кояш баеганнан соң сайрарга тотынган сандугач моңына гына алмаштыра аламдыр шикелле",—ди әдип үзенең иҗаты хакында.

Әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеге өчен ул М. Горький исемендәге Бөтенсоюз әдәби конкурс лауреаты булды, Татарстан Язучылар берлегенең Ф. Хөсни исемендәге бүләген алды, "Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исемне йөртә.

## Дамир Гыйсметдингә 60 яшь

Милли-мәдәни тормышыбызда игелекле гамәлләре белән абруй казанган җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь, күпсанлы хикәяләр авторы, журналист Дамир Минсәгыйрь улы Гыйсметдин 1949 елның 25 гыйнварында Чуашстанның Батыр районы Татар Тимәше авылында укытучы гаиләсендә туа. 1966 елны Тойси урта мәктәбен тәмамлагач, бер ел колхозда, аннары төрле төзелешләрдә эшли, шул ук вакытта читтән торып Чуаш авыл хуҗалыгы институтының инженер-механиклар әзерләү факультетында укый. Армия сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, 1971 елны Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. Аның беренче мәкаләләре, шигырьләре "Авангард" район газетасында, "Яшь ленинчы"да басылып чыга. Университетны тәмамлагач, "Чаян" журналына эшкә урнаша. 1975-86 елларда әлеге журналда әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли. Шул чорда Д. Гыйсметдин сатирик каләмен чарлый, матбугатта аның татар һәм рус телләрендә язылган әсәрләре еш басыла, фельетоннары Мәскәүдә чыккан җыентыкларда да дөнья күрә, Үзәк һәм Татарстан радиолары аша юмористик хикәяләре яңгырый.



1986-90 елларда Д. Гыйсметдин—Татарстан өлкә комитеты инструкторы, халыкара мәсьәләләр буенча консультант. 1989-93 елларда ул "Ватан" иҗтимагый җәмгыятен оештыра һәм җитәкли, 1994—2002 елларда Финляндия татарлары белән берлектә уртак ширкәт оештырып, аның директоры була. Аннары ул "Татскан" фин компаниясенең Татарстандагы һәм Россиядәге вәкиллегенең җитәкчесе. 2003 елдан алып бүгенге көнгә кадәр Д. Гыйсметдин Бөтендөнья татар конгрессының рәис урынбасары. Ул язучы шөгылен зур җәмәгатьчелек гамәлләре белән бәйләп алып бара.

1990 елда Татарстан китап нәшрияты Дамир Гыйсметдиннең "Өметсез шайтан" дигән беренче китабын бастырып чыгара. Аннары "Әйтсәм әйтим" (1994), "Атта да, тәртәдә дә" (2007) китаплары дөнья күрә. Әлеге китапларда аның сатирик-юмористик хикәяләре, публицистик мәкаләләре, юлъязмалары, истәлекләре, уйланулары тупланган. Җыентыкларда шулай ук шигырьләре дә урын алган. Аларның күпчелеген туган җиргә, сөю-мәхәббәткә багышланган лирика тәшкил итә. Арада юморга корылган шигырьләр дә байтак. Соңгы китабында алар "Шаян шигырьләр" дигән аерым бүлеккә туплап бирелгән. Д. Гыйсметдиннең дистәдән артык шигыренә көй язылган. Арадан "Гомер уза", "Күңелең сынмасын", "Очып кайтам", "Сөю хакына" кебек җырлары халык арасында популярлык казанды.

2008 елда язучы нәшриятка сатирик хикәяләре һәм юмористик шигырьләре тупланган "Кая ашыгырга?" дигән өр-яңа җыентыгын тапшырды.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Дамир Минсәгыйрь улы Гыйсметдин бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Редакция коллективы аны ихлас котлый, исәнлек-саулык, яңа иҗат уңышлары тели.

Дамир
Гыйсметдин

# ЧӘЙНЕ ЧӘЙНЕГЕННӘН...

Илне Кытай тауарлары басып алды, җәмәгать! "Панасоник" дип күтәреп кайтасың—Кытайда эшләнгән магнитофон булып чыга. "Сименс" дигән чәйнек сатып аласың, анысы да "Мәде ин Чәйне"—ярлыгы төкерек белән ябыштырылган Кытай малы булып чыга.

Бер көнне "Татар радиосы"н тыңлап ятам—кытайча сөйли башлады бит! Мәйтәм, сарылар килеп тә життеләр ахрысы! Ул техник хата гына булгандыр дип әйтерләр беркатлы адәмнәр. Алай түгел! Телевизорны сүндереп йокларга ятасың, төнлә кинәт үзлегеннән кабынып китә, шәрә хатыннар күрсәтә башлый. Ә бит ул зәңгәр ящикне "Сания", ягъни япун техникасы дип юк акчага кредитка аласың. Монысын да начар сыйфат белән генә аңлатырга ярамый, җәмәгать! Шәрә кызлары кысык күзлеләр бит! Монда, агайне, сүз техника турында гына түгел. Тирәнрәк багарга кирәк: бу идеология! Безнең халык, үзең беләсең, күк күкрәми—сәкедән күтәрелми... Ә күкләр күкри, мин сиңа әйтим, ничек кенә әле! Кытайлар көннән-көн безгә якыная бара! Иртән эшкә барганда автобуска керәсең—почти барысы да кысык күзләр. Син уенга борма. Имештер, день тяжелый, озакка сузылган бәйрәмнәрдән соң... Яхшырак бак, тирәнрәк уйла! Ни өчен бөтен шәһәргә Кытай автобусларын китереп тутырдылар? Түрәләр зур откат алганнар дисеңме? Мин пракурур түгел, анысын белмим, тик бу кытай шаукымы икәне әллә кайдан күренеп тора...

Соңгы вакытта бу турыда еш уйлаганга күрә, йокылар качты. Шул илгә бер барып кайтасы килә, әмма хезмәт хакым, агайне, Кытай автобусында йөрергә генә житә шул. Мәйтәм, үзләре безнең якларга килеп житкәнче, бер барып күрәсе иде шул хикмәтле халыкны. Кытай бүген космоска чыкты, миллиард кешене ашата-эчертә, киендерә, панимаешь. Яхшымы-начармы, бөтен дөньяны тауар белән тәэмин итеп тора. Әле бит әкәмәте шунда—илне коммунистлар житәкләп бара. Без дә бит шул кызыл бишектән чыккан адәмнәр. Нишләп болар алга бара, ә без гел бер урында таптанабыз? Шуңа да Кытайга бик тә барасы килә, җәмәгать. Мина Кенәрие дә, Кершәвиле дә, башкасы да кирәкми! Безгә Кытай кирәк!

Кем әйтмешли, тавык төшенә тары керә, чүпли-чүпли таң ата. Күрәсең, еш кына Кытайны уйлап йөргәч, бер заман төш күрәм. Имештер, Пекинга барганмын. Халык мыжлаган. Мине ниндидер зур кешеләр каршы ала, музейларда йөртәләр, рестораннарга алып керәләр, кыстый-кыстый бака итләрен ашаталар. Иң соңыннан мәүзәлигә алып керәләр. Шунда бер гаҗәп хәл килеп чыкмасынмы? Мао җәсәде яныннан узганда ул уң күзен ачып: "Сәлам, Фәридун, котлыйм!—дип пышылдады һәм күзен тагын йомды. Шактый гына шунда хәйранга калып басып торганмын икән. Мине озатып йөргән кытай түрәләре бу хәлне күргәннәрдерме—юкмы, уянып, күземне ачып жибәрсәм, янымда хатын басып тора.

—Йә, уян тизрәк, эшкә соңга каласың! Төне буе әллә нинди телдә сөйләшеп, саташып чыктың!

Менә шул хәлләрдән соң, җәмәгать, күзгә бөтенләй йокы керми башлады. Бөек Маоның мине нәрсә белән котлаганын һич аңлый алмыйм. Ләкин сизенәм, җәмәгать, бу халык белән шаяртырга ярамый, Кытай белән якынаерга кирәк. Алга карап эш йөрткәндә, алар белән дуслашырга кирәк. Эшләр болай барса, тауарлары артыннан кытайлар тиз арада үзләре дә килеп житәрләр, мөгаен. Менә монда инде Мәүзи агайның нигә дип күз кысуын, котлавын аңлый башлыйсың, җәмәгать! Димәк, ул чакта кытайларга минем кебек мөнәсәбәтле, күрәзәчән затлар каты урындыклы кызыл автобусларда гына йөрмәсләр! Лимузиннарга утырып, кәнәфиле кабинетларда да эшләп карарбыз әле язган булса!.. Ә приёмныйдагы кысык күзле матур кызлар «Чәйне» чәйнекләреннән тәмле чәйләр ясап бирерләр!..

# ТЕЛЕВИЗОРЫ ГЫНА БУЛСЫН!

Гаҗәп нәрсә—телевизор! Шуны уйлап табучыга һәйкәлләр куярга кирәк! Һәр тыкрыкта, һәр йортның ишек алдында. Кайсыгызның нинди шөгыль белән шул хәтле мавыкканы бар?! Диванга чалкан ятып телевизор карый башласаң—көннең үткәнен генә түгел, таң атканын да сизми каласың!

Менә мине генә алыйк. Үсмер чактан бирле гел телевизор каршында. Кемнәрдер түфли туздырып, юкка үз-үзен кыздырып, вакыт уздырып кызлар артыннан чапкан чакта мин өйдә утырдым. Зәңгәр тартмадан Ленин, Чапай, Котовский, Пархоменко турында мавыктыргыч кинолар карап. Әти-әни минем трай тибеп йөрмәвемә ифрат сөенәләр иде. Институт-фәләннәр белән кызыксынмагач, охранга урнашып эшли башладым. Берәүләр эш эзләгәндә хезмәт хакы, премия турында уйлыйлар.Ә мин эшне сайлаганда сакчылар бүлмәсенә куелган биш телевизорны күреп, телсез калдым. Эштә телевизор,өйдә телевизор—дөнья рәхәте. Ул арада әти-әни якты дөньядан китеп бардылар,урыннары җәннәттә булсын, ә мин күптәнге гадәтемә тугры калдым. Башкалар перестройка, демократия, базар шартлары, ваучер-маучер, чубайс-мубайс дип шау-гөр килеп саташып йөргән чорда, мин бу галәмәтләрдән ерак тордым. Әйе, телевизордан бразил-мексиканның мавыктыргыч сериалларын карап утырдым. Миңа бандитлар, рэкетирлар килмәде: башка кешедә эшем булмады. Өйдән—хезмәткә, ә аннан туп-туры фатирыма. Телевизорым янына. Мин кемгә кирәк тә,миңа кем кирәк?.. Хәер, танышлар арасында: "Өйлән, Гыймади, гомерлек буйдак булып каласың бит инде!"—диючеләр булгалады, ләкин мин телевизорны өзелеп яратуымны беркем белән дә уртаклашырга теләмәдем. Дөрес, минем дә кинолардагы шикелле гыйшык тотып, янып-көеп, Фернандолар, Доминголар шикелле мәхәббәткә баштин чумып карыйсым килде. Эштәге ашханә пешекчесе Сания сериалдагы Элизабетка ифрат дәрәҗәдә ошаганга күрә, бер кичне, өйләрне җыештырып, кич утырырга чакырган идем. Чәй эчеп, беркүпме гапләшкәннән соң, ниһаять, күзебез телевизорга төште. Кунак кызына матур мәхәббәтләр күрсәтү нияте белән тартманы сериал каналына көйләп куйган идем. Ә ул: "Әйдә татар җырларын тыңлыйбыз "дип "ТНВ" төймәсенә басты. Ә анда нишләптер "Кәеф ничек?" тапшыруы урынына сакаллы атакайлар казанский икон-миконны күрсәтеп яталар.

—Бераз көтик инде,хәзер башлана!—дип ялварды Сания. Ә минем "Саташкан мәхәббәт" сериалы инде башланды. Какуй монда көтәргә?! Кыскасы, бик җитди каршылык килеп чыкты, агайне. Нәтиҗәдә кунак кызын тиз генә чыгарып җибәрергә туры килде. Шуның белән минем шашкан мәхәббәтем вәссәлам булды.

Шулай итеп, тормыш иске эзенә кайтып дәвам итте. Илдә ниндидер гыкычыпылар-мыпычыпылар телевизордан күренеп алды. Коммунистларны демократлар алыштырган икән. Мине алар усак башындагы карга оясы кебек кенә кызыксындырдылар. Чөнки ул дәвердә мин кабат "Санияле" булдым. Шундый исемле затлы япун телевизоры алып, сериалларны төсле сурәттә карый башладым. Менә, ичмасам, бәхет тек, бәхет! Җитмәсә, мавыктыргыч та нәрсә инде шул Барбаралар, Изауралар тормышы! Ул арада татарлар суверенитет алып,аны югалтып та өлгергәннәр икән. Коточкыч инфляция, дефолт булган чорларда телевизордан йөз серияле Әмрикә киноларын күрсәттеләр. Мин санто-мантоларның язмышы белән янып-көеп яшәгән дәвердә илдә президентлар алышынган, берничә тапкыр депутатлар сайланган икән. Урам себерүче Шиһап абзыйның әйткәне генә колагыма эленеп калган.

Бер көнне охран башлыгы Хәмит: "Син, Гимади Телевизорыч, пенсиянне оформить итәргә онытма тагын..."—дип искәртте.

Их, егетләр, гомер узган да киткән икән! Дөнья мәшәкатьләрен куганнарга да, минем кебек мыштым яшәгәннәргә дә бер үк сукмак, бер үк язмыш. Әйе... Ахирәт... Анда китәр алдыннан күпләр бик сызланалар, куркуга сабышалар икән. Ә мин андыйлардан түгел. Ник дисәң, Харис энекәшкә алдан ук әйтеп куйдым: "Мине гүргә индергәндә әбъзәтелни аяк очына төсле телевизорымны төшереп куярга онытмагыз!..". Миңа—шту бу дөнья, шту—тегесе! Телевизоры гына булсын!

Ринат Абзалов



*"...Җитмеш төрле һөнәр дә аз",—дигәндә юмор һәм сатираның үзе күз алдына килә. Башка жанрлар белән чагыштырганда форма ягыннан күпкырлы, күләме төрле-төрле һәм фикер тыгызлыгы белән искиткәле бит ул.*

*Ринат Абзалов гомер буе әнә шул юмор һәм сатираның Казанында кайный. Рәссам да ул, әдәби хезмәткәр дә; палиндромнар (алдан-арттан укысаң да мәгънәсе үзгәрми торган сүз яки җөмлә), шигъри миниатюралар, табышмаклар, тавтограммалар (бер үк хәрефтән башланган сүзләр кулланып язылган хикәя) авторы да; ребуслар, шаянвордлар төзүче дә...*

# КӨЗ КЫЙССАСЫ

ТАФТОГРАММА (*"К" хәрефенә*)

Көз.

Кошлар, көн күрү кыенлашкач, күккә күтәрелеп, көньякка качалар. Каеннарның кипкән кызгылт киемнәре коела.

... Кырларда кара көдрәле комбайнчылар, көлтә күтәргән кызыл косынкалы кызлар күренми. Кәнсәләрдә кинәшмәләр кайный. Кызыш, кычкырыш—кышны каршыларга кирәк!

...Көзге калада, Казансу кырындагы калкулыкта, күнелле кайнашу.

Коллоквиумнарын, китап-конспектларын калдырып килгән курсантлар кәпрәешеп кыз-кыркынны күзли. Күн куртка, кара колготки кигән кызыйлар, көлешеп, курсантларга карап-карап куйгалый.

Кәнтәй Кадрия-Кәүсәрияләрнең кайберләре кызу канлы Камил, Кәрим, Кәбирләрне катгый кире кага. Кайберәүләре киресенчә—килешенүнең конструктивлыгына карап, куаклыкка кереп киткәли...

Көз—кешелекнең каршылыклы кыйблалары көзгесе.

Кайдадыр кытыршы каты куллар конверторларда корыч коя.

Кемнәрдер Кипр кояшында күт кыздыра.

Кемдер, кризиска карамастан, Кремльнең керосин кибетендә кыздырылган күпдолларлы "кабартма"ларны калькуляцияли.

Көз китә.

Карлы, караңгы күкле кыш килә.

## Безнең кызлар

(негр халык жыры)

**...Басуларда банан гөрләп үсә,**
**Баобаблар чәчәк аталар.**
**Бамбук тырма салып иңнәренә**
**Сылу кызлар эшкә баралар.**

**Җилфердәтә нәфис яулыкларын**
**Сары чүлнең кайнар җилләре.**
**Нинди кызлар үсә Нил буенда—**
**Бигрәк нечкә инде билләре...**

**Кокос җыеп, өчәр п(ы)лан үтәп,**
**Талып кайта алар кырлардан.**
**Ләкин яшьлек үзенекен итә –**
**Яңгырый чүл дәртле җырлардан!**

**...Тамтам кагып егетләре көтә,**
**Уттай яна дәрттән күзләре.**
**Безнең кызлар тыйнак кызлар алар –**
**Алсулана кара йөзләре...**

## Энә җепләү

**...Инде соңгы өмет чаткылары**
**Сүнеп барган чакта күңлемдә,**
**Күрдем кинәт уктай төз сыныңны—**
**Нур балкыды соры күгемдә!**

**Сөю сирпеп, нәфис бармакларым**
**Үрелделәр сихри шәүләгә...**

**Җылы майга кашык баттымыни—**
**Кереп китте**
**җебем**
**энәгә...**

## Палиндромнар

Ат "тройка" тибә бит "Ак йорт"та.

**—Теге ел кишере шикле, егет!**

—Акча тарат ачка!

**Әле бер Ичкерия ирек чире белә.**

Эчәм әз-мәз "зәмзәм". Әче!..

**Патша, аш тап!**

Нахак кыла халыкка хан.

**Ә дәрәҗә—шәҗәрәдә.**

Латип акылы—капитал.

Арык акын нык акыра.

**—Ни бар?—Аклар! Ал карабин!**

—Әни, зур грузин, ә?

**—" Натс", апа, Апастан!**




*2008 елда Мәскәүдә «Новая антология палиндрома» исемле китап басылып чыкты. Анда Ринат Абзаловның, русчалары белән беррәттән, татарча палиндромнары да керде.*

## Эсфир Яһудинга 60 яшь

Эсфир Яһудин (Яһудин Хамис Шәмсигали улы) үзенең күпсанлы сәхнә әсәрләре белән генә түгел, хикәя-повестьлары аша да укучыларга яхшы таныш. Тумышы белән Башкортстанның (1949 ел, 4 гыйнвар) Краснокама районы Яңа Хажи авылында туган егет 8 сыйныф белемне туган авылында алганнан соң, урта мәктәпне Коелтасу район үзәгенә йөреп тәмамлый. Мәктәп елларында ук районның "Таң" газетасында шигырьләре белән катнаша. Армия хезмәтен үтеп кайтканнан соң физкультура укытучысы булып эшли, читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. 1974 елда Казанга килә, Казан органик синтез заводына эшкә керә. 1978 елда Казан дәүләт курчак театрында сәхнә эшчесе, бер үк вакытта актер булып эшли.



1979 елда Эсфир Яһудин Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Мәскәүгә, М. Горький исемендәге әдәбият институтына укырга китә. Драматургия семинарын тәмамлаганнан соң, Әлмәт дәүләт татар драма театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли башлый. Шул вакытта Б. Васильевның "А зори здесь тихие" исемле повесте нигезендә эшләнгән пьесаны татарчага тәрҗемә итеп, Әлмәт театрында куйдыра.

1992 елда ул Татарстан кинокомитеты юлламасы белән Мәскәүдә кинодраматургларның югары курсларында укып кайта. "Оҗмах газабында өч төн", "Әсфәндияр" исемле киносценарийлар иҗат итә.

Эсфир Яһудинның пьесалары К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында, Уфадагы "Нур" театрында, Минзәлә, Яр Чаллы, Әлмәт, Оренбург театрларында куела. 1993 елда тинчуринчылар тарафыннан куелган "Мәхәббәткә мәдхия" мелодрамасы тамашачылар тарафыннан озак еллар яратып карала. Берничә драма һәм комедиясен туплаган әлеге исемле пьесалар җыентыгы 2004 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә.

Ул соңгы вакытта "Яңа татар пьесасы" конкурсларында катнашып, берничә тапкыр призлы урыннар яулауга ирешә. Балалар өчен шигырь белән язылган әкиятләре дә уңышлы булды. 2008 елда драматурглар конкурсында әлеге жанрдагы әкият-пьесалары өчен берьюлы ике бүләк алды.

Эсфир Яһудин проза өлкәсендә дә эшчәнлеген дәвам итә. 1996—2006 еллар эчендә аның берничә повесте басылып чыга. Ун повестьтан торган "Мәндикән" циклы аерым игътибарга лаек.

Иҗатының "Шәхесләр" циклында Гариф Ахунов, Эдуард Мостафин, Булат Сөләйман, Фәиз Зөлкарнәй һәм башкаларның әдәби портретларын тудыра.

Эсфир Яһудин—1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

♣




*Риза Фәхреддиннең музей йорты. Әлмәт. Кичүчат авылы.*



*Өлкән әдипләр яшьләр янында. Уңнан сулга—Шамил Маннапов, Разил Вәлиев, Әхәт Гаффар, Ләбибә Ихсанова, Нури Арслан, Сибгат Хәким, Роберт Миңнуллин, Зөлфәт Маликов, Госман Зәйнетдинов. 1973 ел.*



*Совет әдәбияты классиклары. Сулдан уңга—Мостай Кәрим, Гариф Ахунов, Сергей Михалков, Мирсәй Әмир, Әсгат Мирзаһитов. 1979 ел.*



*Драматург Туфан Миңнуллин СССРның халык артисты Фоат Халитов белән. 1979 ел.*

**ПРЕЗИДЕНТ ҮЗ СҮЗЕН ӘЙТТЕ!**

Мәгълүм булганча, РФ Дәүләт Думасы депутатлары 2007 елның 1 декабрендә «Россия Федерациясе аерым закон актларының дәүләт мәгариф стандарты төшенчәсе һәм структурасы өлешенә үзгәреш кертү турында»гы канун белән укыту системасының милли-төбәк компонентын кулланыштан чыгарды. Хәзер, димәк, мәктәптә ана телен, әдәбиятын һәм төбәк тарихын дәрестән тыш кына өйрәнергә мөмкин. Бу хәл, табигый, ил күләмендә, бигрәк тә милли республикаларда һәм өлкәләрдә зур ризасызлык уятты. Шул җөмләдән ТР Дәүләт Советы РФ җитәкчеләренә мөрәҗәгать тә юллады. Думага канунны элеккеге хәленә кайтару тәкъдимен кертте.

Әмма Мәскәүнең югары даирәләре, нигезендә астыртын мәкер ятканга күрә, милли мәсьәләгә кагылышлы бу хәтәр ялгышны төзәтергә ашыкмады. Шунлыктан Президент Минтимер Шәймиевкә Дәүләт Советына Юлламасында моңа кабат игътибарын юнәлтергә туры килде. «309 нчы Федераль закон белән мәгариф стандартларыннан милли-төбәк компонентын төшереп калдыру милли республикаларда хаклы рәвештә ризасызлык тудырды,—диде Илбашы.—Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килүче шушы карар буенча без Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Дәүләт Думасына әлеге төзәтмәне гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәр җибәрдек, аны федерациянең 21 субъекты хуплады. Аек акыл өскә чыгар һәм мәсьәлә унай хәл ителер дип уйларга нигез бар. Республикабызның белем бирү программаларында милли компонентның сакланып калачагына ышанабыз... Күпмилләтле Россия Федерациясенең бөтен мәгариф системасында туган телне өйрәнүне саклап калу безнең өчен гаять мөһим».

Ниһаять, зур оештыру эшләреннән соң бу четерекле мәсьәлә 18 ноябрьдә ТР Дәүләт Советында РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчелеге, Дәүләт Думасы депутатлары, милли республикалар хакимиятләре вәкилләре һәм Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев катнашындагы Бөтенроссия киңәшмәсендә каралды. Аны Россия мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко алып барды.

Фикер алышуны М. Шәймиев башлап җибәрде. Ул күпмилләтле дәүләт куркынычсызлыгы һәм тотрыклылыгы милли телдән, халык мәдәниятеннән аерылгысыз икәнлекне тагын бер кат искәртте. Тигез хокуклы туган тел дәресләренең киметелүен кемнәрдер тарафыннан уйлап чыгарылган зыян итеп күрсәтте. Әлеге мәсьәләнең уңай чишелеше табылганчыга кадәр көн тәртибеннән төшмәячәген әйтте. Чөнки бу юнәлештәге битарафлык халыкны телсез калдыруга китерә. Мәсәлән, 2004-2005 нче уку елында РФ төбәкләрендә татар теле 712 мәктәптә укытылса, 2007-2008 нче уку елында 490 мәктәптә генә калды. Кимүне, юкка чыгуны туктатырга кирәк, диде Президент.

Киңәшмәдә катнашкан Төньяк Осетия, Башкортстан, Алтай Республикасы, Коми Республикасы, Саха Якутия, Адегея, Чечня Республикалары вәкилләре Татарстан Президенты фикерләрен дәррәү яклап чыктылар. Әмма Мәскәү вәкилләре арасында бу мәсьәләгә бүтәнчә карашлылар да бар икәнлеге ачыкланды. Бу җәһәттән РФ мәгариф һәм фән министрлыгының мәгарифне үстерү федераль институты милли проблемалар үзәге җитәкчесе Ольга Артеменко чыгышы аеруча характерлы иде. Ул ачыктан-ачык мәктәпләрдә милли телләрдә укытмауны яклап чыкты. Аның фикеренчә, милли телләрдә укыту гомумроссия үзаның тәрбияләми, гомумбердәмлекне какшата... мәктәп яшьләрне этник мобилизацияләү институты буларак файдаланыла... РФ Дәүләт Думасының мәгариф комитеты рәисе Григорий Балыхинның да фикер сөреше шул рухтарак иде. Ул Милли республикалар керткән милли компонентка кагылышлы тәкъдимнең бүгенгәчә каралмавын төрлечә акларга тырышты. Дөрес, Мәскәү делегациясе вәкилләренең берсе—Дәүләт Думасының милли мәсьәләләр комитеты рәисе Валентин Купцовның фикерләре залда утырган күпчелек белән аваздаш булды.

“Милли мәсьәлә катлаулана бара. Әгәр ул хәзер хәл ителмәсә, киләчәктә тагын да кыенрак булачак. Мәгарифтәге аңлашылмаучанлыкларга чик куярга кирәк. Тотрыклылыкны какшатмыйча, киңәшмәнең карарын кабул итәргә кирәк. Четерекле мәсьәләне чишүдә безгә бик зур җаваплылык йөкләнгәнен онытмыйк. Чөнки Россиядә милли сәясәт белән шөгыльләнүче Милләтләр эше министрлыгы юк. Бездә хәтта «милли сәясәт» төшенчәсе дә кулланыштан төшеп бара,

анын урынына «төбәкара сәясәт» сүзләре еш кулланыла"—диде ул.

Бөтенроссия киңәшмәсендә Татарстан вәкилләреннән Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан мәгариф һәм фән министры Наил Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

Киңәшмәдә җыелышны алып барган Россиянең мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко сүзен йомгаклап болай диде: "Без бер-беребезне тыңладык. Әмма сөйләшү төгәлләнмәде. Ул башлана гына әле". Шулай итеп, министр, мәгариф стандартларындагы үзгәрешләрнең төптән уйланмыйча кабул ителүен таныса да, мәсьәләнең уңай чишелешен гарантияли алмады әлегә.

Киңәшмә ахырында көн тәртибенә куелган проблема буенча тиешле резолюция кабул ителде.

**Россия Федерациясе составындагы милли республикаларның закон чыгару һәм мәгариф идарәсе органнары рәисләре һәм җитәкчеләре, РФ Дәүләт Думасы һәм Федерация Советы тармак комитетлары әгъзалары катнашында РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы уздырган киңәшмә**

## РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

**Киңәшмәдә катнашучылар түбәндәге тәкъдимнәрне кертү кирәк дип саный:**

1. «Мәгариф турында»гы РФ законына үзгәреш кертергә:

—гражданнарның туган телдә урта (тулы) гомуми белем алуының конституциячел хокукын гарантияләргә;

—РФ субъектларының төп мәгариф программалары структурасы, (кадрлар, финанс, матди-техник h.б.), гамәлгә ашыру шартлары һәм үзләштерү нәтиҗәләре таләп иткәнчә, милли һәм төбәк үзенчәлекләрен дә искә алырга;

—РФ субъектларына ул субъектларның дәүләт телләрен, РФ халыклары әдәбиятын һәм туган телен, шулай ук аерым төбәкнең этномәдәни үзенчәлекләрен—тарихын, туган халкын, крайны өйрәнүне, сәнгатьне, халык һөнәрчелеген һәм башкаларны күздә тоткан фәннәр буенча төбәкара база уку планнарын (федераль планнар нигезендә), база (үрнәк) укыту программаларын һәм укыту-методик комплектларын эшләүдә вәкаләтләр бирергә;

—туган (рус булмаган) телдә укучы чыгарылыш класс укучыларына туган телдә, шул исәптән бердәм дәүләт имтиханы формасында, гомуми аттестацияләнү мөмкинлеге бирергә.

2. Яңа буынга гомуми белем бирү федераль дәүләт мәгариф стандартын формалаштыру кысасында атнага 3-5 сәгать күләмендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт телләрен һәм Россия Федерациясе халыклары әдәбиятын өйрәтүне күздә тотучы база укыту планнарының төрле вариантларын эшләү һәм раслау кирәклеген билгеләп үтәргә.

3. Уку планнарын, программаларын һәм укыту-методик комплектларын эшләүче экспертлар советы составына Россия Федерациясе субъектлары - милли-территориаль берәмлекләр вәкилләрен 40 проценттан да ким булмаган нисбәттә кертүне тәкъдим итәргә.

4. Федераль дәүләт стандартлары нигезендә гомуми белем бирү мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында белем бирү процессында кулланырга тәкъдим ителгән федераль дәреслекләр исемлегенә Россия Федерациясе халыкларының туган тел һәм әдәбиятларын һәм туган телдәге (рус телендә булмаган) дәреслекләрен дә кертергә.

5. Туган (рус телендә булмаган) телдә укытучы һәм рус (туган телдә булмаган) телендә укытучы мәгариф учреждениеләре өчен федераль дәрәҗәдәге норматив-хокукый база эшләргә.

6. Россия Федерациясендә туган (рус телендә булмаган) тел һәм әдәбият буенча үткәрелүче олимпиадаларга, федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә, гомумфедераль статус бирергә, анда җиңүчеләргә һәм бүләкләнүчеләргә бу фәннәрдән югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләренә укырга кергәндә өстенлек бирүне тәэмин итәргә.

7. Төбәк телләре, яки аз санлы халыклар телләренең Европа хартиясен (Страсбург, 1992 елның 5 ноябре) ратификацияләү буенча эшне дәвам итү кирәклеген искәртергә.

*PS: Халык язмышында утә мөһим булган мәсьәлә хакында "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның фикерләре белән бу санда урнаштырылган кереш мәкаләдә дә таныша аласыз.*

## КИТАПНЫ САКЛАУ—ТАРИХНЫ САКЛАУ

Казанда "Дөньяның мәгълүмати киңлегенә керү шартларында китапханәнең йөзе" дип исемләнгән халыкара китапханәләр форумы булып узды. Анда Россиянең 16 төбәгеннән 200гә якын китапханәче катнашты. Форумда шулай ук Германия, Төркиядән дә вәкилләр бар иде. Китапханәчеләр җыенының пленар утырышы "Корстон" комплексында узды. Анда республика нәшриятларының китап ярминкәсе, китапханәләр нәшер иткән басмалар күргәзмәсе дә оештырылды. Җыен делегатлары алдында Татарстан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева чыгыш ясады. Ул кунакларга Президентыбыз М. Шәймиевнең сәламләү хатын да укып ирештерде.

—Соңгы дистә елда Россиядә барган катлаулы, авыр үзгәртеп корулар чорына карамастан, без Татарстанда китапханәләр системасын саклап кала алдык. Хәзер

фондларны яңарту һәм китапханә эшчәнлегенә яңа мәгълүмати технологияләр кертү белән шөгыльләнәбез. Ерак авылларда урнашкан китапханәләр дә игътибардан читтә калмый,—диде З. Вәлиева.—Ел саен Татарстан халкын социаль әдәбият белән тәэмин итүгә 49 миллион сум акча сарыф ителә. Моннан тыш, китапханә фондларын тулыландыру өчен республика бюджетында акча карала.

Форумда китапханәләрне компьютерлаштыру, интернет челтәренә тоташтыру кирәклеге турында күп сөйләнде. Россиядә бу өлкәдә 83 процент компьютерлаштырган һәм 82 проценты интернетка тоташтырылган китапханәләре булган Чуашстан алда бара икән. Дагыстан исә—иң артта калучылар рәтендә. Ә менә Ханты-Манси, Чукоткада китапханәчеләр, Россия күләмендә караганда, иң күп хезмәт хакы ала (15-16 мең сум). Шул ук вакытта Оренбургта, Мордовия, Карачай-Чиркәс республикаларында китапханәчеләр аена 3 мең сумга эшли.

М. Рудомино исемендәге Бөтенроссия дәүләт чит ил әдәбияты китапханәсе генераль директоры Е. Гениева сүзләренә караганда, компьютерлардан да бигрәк, китапның элеккеге абруен саклау мөһим. Чөнки китапны саклау—халык тарихын саклау ул. Укучыларыбыз китапханә хезмәтеннән читтән торып файдаланучыга әверелә бара.

## ЯШЬЛӘР ДӘ ЮБИЛЯР БУЛДЫ

Узган ел ахырында җәмәгатьчелек Г. Кариев исемендәге Казан Татар Дәүләт яшь тамашачы театрын 20 еллык юбилее белән тәбрик итте.

Иң башта Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева сүз алды. Ул, театрның тарихы 20 ел белән генә исәпләнсә дә, сәнгатькярләребез күнелендә шактый күптәннән яшәве һәм 1918-19, 1938-39, 1949, 1988 елларда театрны оештырырга талпыныш булуы, соңгысының уңышлы тәмамлануы турында искәртте. Мәдәният министры Яшьләр театрын авторларының төрлелеге, режиссерның кыю алымнары, яшьлек дәрте, тәҗрибә һәм югары һөнәрмәндләрнең бергәлеге өчен яратканын әйтте.

Бер төркем артистлар министрлыкның "Мәдәнияттәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе, икенчеләре мактау кәгазьләре белән бүләкләнде. Театрның баш режиссеры Р. Әюпов һәм артист Ф. Галиев Министрлар Кабинетының мактау кәгазьләренә лаек булды. Ә артистлар Х. Сөнгатуллина һәм Ф. Кәлимуллинга "Татарстанның атказанган артисты" дигән мактаулы исем бирелде. Юбиляр театрны Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин исеменнән Дәүләт Советы депутаты, драматург Т. Миңнуллин котлады.

Кичәдә бәйрәмдар театрга Татарстан Театр әһелләре берлеге рәисе Р. Таҗетдинов, республикабыз театрлары вәкилләре дә җылы тәбрикләү сүзләре җиткерде. Котлаулар спектакльләрдән күренешләр белән үрелеп барды.

## КҮРГӘЗМӘ АЧЫЛДЫ

"Казан-Эрмитаж" үзәгендә "Кытайдан Европага кадәр. Ислам дөньясы сәнгате" күргәзмәсе ачылды.

Ул ислам дөньясының Европа һәм Азия мәдәниятләре белән элемтәләренә багышланган. Бу күргәзмәдә Россиягә беренче тапкыр Париждагы Лувр һәм Декоратив-гамәли сәнгать музейларыннан китерелгән мөселман сәнгать шедеврларын күрергә була. Дәүләт Эрмитажы һәм Татарстан Республикасының милли музей фондларыннан да кабатланмас ядкарьләр куелган.

Халыкара музей проектын ачуда Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Мәдәният министры Зилә Вәлиева, Дәүләт Эрмитажы (Петербург) директоры Михаил Пиотровский, Лувр музее (Франция) президенты Анри Луаретта катнашты.

## ТАТАРНЫҢ МЕҢЪЯШӘР ӘЛМӘНДӘРЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында үткәрелгән кичәдә театр сөючеләр үлемсез Әлмәндәрне—СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровны 80 яшьлеге белән тәбрикләде.

Иң башта Г. Камал исемендәге театр артистлары тамашачыларга Шәүкәт ага башкарган рольләрне тагын бер кат искә төшереп үтте. "Беренче мәхәббәт"тә—Тәлгат, "Гүзәлем Әсәл"дә—Байтимер, "Канкай улы Бәхтияр"дә—Бәхтияр, "Бер төн"дә—Кривохатский, "Ябырылу"да—Фаюнин, "Моңлы бер җыр"да—Җәллад, "Зәңгәр шәл"дә—Ишан, "Хаҗи әфәнде өйләнә"дә—Хаҗи, "Әни килде"дә—Ислам, "Соңгы корбан"да—Дульчин, "Баһадирлар"да—Ленин, "Хуҗа Насретдин"да—Җиһангир, "Бирнәсез кыз"да Кнуров рольләрен артистлар бик яратып, сокланып искә алды. Әмма артист Ш. Биктимеров башкарган рольләрне искә төшерер өчен ике-өч кичә дә җитмәс иде, мөгаен, чөнки алар 300дән артык.

Аннан соң, бәйрәмдарны Президентыбыз М. Шәймиев тәбрикләде. Ул болай диде: "Шәүкәт Биктимеров—гаҗәеп мөлаем актер, аның елмаюы үзенә әсир итә. Шәүкәт ага, Әлмәндәре кебек үк, мәңгегә күңелләребезгә кереп калачак. Ул үлемсез, ул мәңгелек".

Президент актер Ш. Биктимеровны "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен" ордены белән бүләкләде.

Юбилей кичәсендә СССРның халык артисты Ш. Биктимеровны сәхнәдәш дуслары—камаллылар, М. Гафури, М. Җәлил, В. Качалов исемендәге театрларда иҗат итүче коллегалары, "Әкият"

Татар дәүләт курчак театры артистлары, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе исеменнән мәшһүр җырчыбыз И.Шакиров, шулай ук танылган җырчы В. Ганиева, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артистлары, күренекле каләм әһелләре Т. Миннуллин, Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, "La Primavera" Казан камера оркестры, җырчылар А. Шаһиморатова, Р. Асаев, актерның якташлары исеменнән Саба муниципаль районы башлыгы Р. Миннеханов һ. б. тәбрикләде.

Кичәдә Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева катнашты.

### ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ОЛЫЛАУ

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиевкә, 80 яшьлек юбилее белән котлап, "Фидакарь хезмәте өчен" медален тапшырды. Илбаш Шәүкәт Галиевне шәхсән үз исеменнән, Татарстан Хөкүмәте, Дәүләт Советы исеменнән олуг юбилее белән тәбрикләп, татар халкы өчен бай иҗади мирас булдырганы өчен әдипкә тирән рәхмәтен җиткерде, аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары һәм исәнлек-саулык теләде. "Сез яшьтән үк шигъриятебезгә тугры хезмәт иттегез. Сезнең күпкырлы иҗатыгыз Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Андерсен исемендәге халыкара диплом белән бәяләнде. Һәм сез хаклы рәвештә Татарстанның халык шагыйре исеменә лаек булдыгыз. Сезгә хас булган тирән акыл, кинкырлы фикер шигъриятегездә, сатира, юмор жанрындагы әсәрләрегездә ярылып ята. Бу жанрлар остасы.буларак, сез әдәбиятыбызда аерым урын алып торасыз",—дип билгеләде Минтимер Шәймиев.

Шагыйрь белән очрашуда шулай ук Президент аппараты җитәкчесе Ю. Камалтынов, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р. Вәлиев һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов катнашты.

### БӨЕК ӘДИП МИРАСЫ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Татарстан хөкүмәте карары белән татар әдәбияты классигы һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакыйның 15 томлы «Әсәрләр»е басмага әзерләнә. Әлеге басманың җиде томы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде инде. Күренекле әдәбиятчылар составында төзелгән редакцион коллегиянең чираттагы утырышында исә башка томнары буенча эшнең барышы тикшерелде, аерым томнарның структурасына үзгәрешләр кертелде, аларны төзүче текстология бүлеге фәнни хезмәткәрләренә Г. Исхакый әсәрләре текстларын эзләп табу һәм җентекле өйрәнеп, аңлатмалар белән урнаштыру эшен тизләтү өчен зарур практик чаралар турында сүз барды. Утырышта катнашучылар фикеренчә, Г. Исхакыйның 15 томлы «Әсәрләр»е 2010 елдан да калмыйча тулысы белән басылып чыгып укучылар кулына килеп керергә тиешле.

### ТӨРКИЯ ЕЛЫ УҢАЕННАН

Россиядә 2008 ел Төркия елы уңаеннан Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында Төркия пианиночысы Гөлсин Онай чыгыш ясады. Музыкантны дөньяның күп кенә шәһәрләрендә бик яхшы беләләр.

Музыка сөюче казанлылар бу кичәдә Гөлсин Онайның остазы, танылган төрек композиторы Әхмәд Аднан Сайгун иҗаты белән дә якыннан таныша алды. Талантлы шәкерт үз укытучысының иҗат җимешләрен иң оста башкаручылардан санала.

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында Төрек Республикасы Мәдәният һәм туризм министрлыгының «Мехтер» дигән хәрби оркестры чыгыш ясады. Әлеге концерт та Төрек Республикасының Казандагы Генераль консуллыгы тарафыннан оештырылган иде.

### ЗУР КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Академик Миркасыйм Госманов Ислам конференциясе оешмасы каршындагы Ислам тарихын, сәнгатен һәм мәдәниятен өйрәнү буенча халыкара тикшеренү үзәге премиясе белән бүләкләнде.

Премия ислам цивилизациясен өйрәнүнең төрле өлкәләрендә тикшеренү эшчәнлегендә ирешкән зур казанышлар, фәнни дисциплиналарны үстерүгә керткән өлеш, мәдәниятара аңлашу һәм диалогны пропагандалаган өчен бирелә.

Премия Истанбул мәдәният сараенда тантаналы төстә тапшырылды.

### ТӨРКИ ТЕЛЛӘРЕ БӘЙРӘМЕ

Төркия башкаласы Анкара шәһәрендә төрки телләрнең VI Халыкара корылтае булып узды. Корылтайга дөньяның 50 иленнән 436 төрки теле һәм әдәбияты галимнәре җыелган иде. Аның эшендә 22 кешедән торган Татарстан делегациясе дә катнашты. Аның составында профессорлар М. Зәкиев, Н. Хисамов, Ф. Ганиев, Ф. Хисамова, Т. Галиуллин, Ф. Нуриева, Казан дәүләт университеты доцентлары Э. Йосыпова, Х. Кузьмина һ. б., Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетыннан, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан фән докторлары И. Бәширова, Д. Рамазанова һ. б. бар иде.

Корылтайның тантаналы ачуда Төркия Президенты Абдуллаһ Гөл һәм хөкүмәт

житәкчеләре катнашты. Анкарада узган бу Корылтай төрки халыклар өчен бик мөһим һәм дәрәҗәле аралашу булды. Төрле илләрдән җыелган галимнәр секцияләргә бүленеп фикер алышты, һәрберсендә төрки телләрнең уртаклыгы, киләчәге турында җитди сөйләшү барды. Татарстан галимнәренең күпчелеге төрек телендә чыгыш ясап, телләр үсешенә үз карашларын белдерде, заманча уйлый, алдынгы нәзари тәгълиматларга таянып фикерли белүләрен раслады. Татар телендә чыгыш ясаган галимнәрне дә корылтайда катнашучылар игътибар белән тыңлап, аңлап, сораулар биреп, үз карашлары белән уртаклашты. Татар теле корылтайда аралашу өчен икенче төп «дәүләт» теле дәрәҗәсендә йөрде дияргә була.

Гыйрак, Македония, Алмания, Хакасия, Швеция, Мажарстаннан килгән галимнәр үзләренең телләре тарихы, аның хәзерге торышы турында фикерләре белән уртаклашып, мондый очрашуларның зарурлыгына басым ясады.

1932 елда үзенең рәсми җыелышларын башлап җибәргән «Төрек телләре берлеге» оешмасы киләсе корылтаен 2012 елда Төркиянең Измир шәһәрендә уздырырга карар кылды. 2008 елгы форумның рухландыргыч ике көче күнелләргә хуш килерлек иде. Берсе—төрки халыкларның уртак борынгы ядкәрләреннән "Кутадгу билик" сүзлеге авторы Мәхмүт Кашгариның тууына 1000 ел булса, икенчесе—Төркиянең 80 ел элек латин имлясына күчеп, дөньяның алдынгы мәмләкәтләре белән тинләшер өчен ясаган адымы.

Анкарада узган корылтай төрки халыкларның тарих, тел, әдәбият, дин, әдәпәхлак өлкәсендәге якынлыкларын раслап, елдан-ел ныгый, көчәя барган Төрек иле йөзендә таянычлары, яклаучылары барына янә бер кат инандырды.

### КАЗАНДА ПЕРМЬ ТАТАРЛАРЫ КӨННӘРЕ

Казанда "Пермь крае—илһамым минем" дип исемләнгән Пермь татарлары мәдәнияте көннәре узды. Анын Пермь крае губернаторы хакимияте, крайның татар-башкорт милли-мәдәни мохтәрияте, Бөтендөнья татар конгрессы, Барда районы хакимияте бергәләп оештырды.

Бу чара күптән түгел генә арабыздан киткән танылган галим, фольклорчы, Барда егете Рәшит Ягъфәровның якты истәлегенә багышлап уздырылды. Мондый зур чара Р. Ягъфәров тырышлыгы белән Г. Камал театрында 1993 елда беренче тапкыр үткәрелгән иде инде. Бусы—икенчесе. Әлеге көннәрдә катнашу өчен крайның Октябрь, Барда, Көнгер, Лысьва районнарыннан, Пермь һәм Чайковский шәһәрләреннән йөзгә якын кеше килде. Алар арасында житәкчеләр дә, үзешчән сәнгать осталары да бар иде.

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе концерт залында крайның үзешчәннәре катнашында зур концерт булды. Әлеге концертта Рәшит Ягъфәров истәлегенә багышланган видеоязмалар, аның шигырьләренә җырлар яңгырады.

Кичәдә Барда районы башлыгы Ихсан Үрстемиров та чыгыш ясады. "Безнең өчен Казан—икенче башкала. Безне Тукай теле берләштерә. Бездә туып-үскән якташларыбызны сез үстерәсез, таныта́сыз, һәм мин үзара элемтәләребезнең көннән-көн ныгуын телим. Тату яшик",—диде ул.

### ТАТАР ПЕН-ҮЗӘГЕНДӘ ЯҢА ЖИТӘКЧЕ

Татарстан язучыларының иҗтимагый оешмасы—Татар ПЕН-үзәге президенты, Татарстанның халык язучысы Туфан Миннуллин, 14 ел житәкчелек иткәннән соң, отставкага китүен белдерде. Оешманың уңышлы гына эшләп килгән чагында житәкчелектән китәргә уйлавын аксакал болай аңлатты: "Әлеге фикер кинәт кенә тумады. Мин барысын да җентекләп бизмәнгә салдым, өстәвенә лаеклы алмаш та бар",—диде ул. Татар ПЕН-үзәге утырышында яңа президент итеп әлегәчә вице-президент вазыйфаларын башкарган язучы Разил Вәлиев сайланды. Туфан Миннуллин исә Татар ПЕН-үзәгенең шәрәфле президенты булып калды.

ТР Милли китапханәсендә үткән утырыш "ТатПЕН: дөнья әдәбияты гаиләсендә" дигән документаль фильм караудан башланды. Чыннан да, пенчыларның күрсәтерлек һәм мактанып сөйләрлек уңышлары шактый. "Татар халык әкиятләре", Г. Тукайның "Шүрәле"се тарихчы Р. Фәхретдиновның "Татар тарихы", Татар әдәбияты антологиясе, инглиз телендә бастырылып, бөтен дөньяга таратылды. Татар ПЕН-үзәге халыкара мәйданда да актив эшли. Һәр халыкның үз теле, үз язуы һем алфавитына хокукы булуы турында безнең язучылар тарафыннан әзерләнгән резолюцияләр Македония һәм Норвегиядә үткәрелгән Бөтендөнья язучылар конгресларында бертавыштан кабул ителде.

### ЯЗУЧЫБЫЗ ДӨНЬЯ ГИЗӘ

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Германиядә булып кайтты. Ул Мюнхен шәһәрендә шушы көннәрдә үзенең 85 яшен тутырган милләттәшебез, "Азатлык" радиосына нигез салучы, хокук фәннәре докторы Гариф Солтан белән очрашты.

Язучы бу легендар шәхеснең күпьеллык архивын өйрәнеп, Татарстанга татар тарихы белән бәйле кыйммәтле материаллар алып кайтты. Алар арасында 30 нчы елларда Берлин шәһәрендә чыккан "Яңа милли юл" журналының 8 еллык нөсхәләре, Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында Германиядә төзелгән "Идел-Урал" татар-башкорт легионы материаллары, "Азатлык" радиосы белән бәйле язмалар, Гариф Солтанның

татарларны яклап дөнья мөнбәрләреннән ясаган чыгышлары, уникаль фотолар бар.

## АКЧАРЛАКЛАР КАНАТ ЧЫГАРА

Әдәбият-сәнгать дөньясының бишеге булган Казан быел кабат яшь язучыларны үзенә җыеп алды. «Иделем акчарлагы» дигән әдәби бәйгедә 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге 140 лап кеше катнашты. Алар арасында Татарстаннан читтә—Мари Иле, Пермь, Оренбург өлкәләрендә яшәүче милләттәшләребезнен дә булуы бәйге офыклары киңәюгә бер дәлил иде.

Илебезнен төрле төбәкләреннән җыелган яшь талантлар өч көн дәвамында язучы һәм журналистлар М. Хәбибуллин, Л. Лерон, Г. Морат, Н. Сафина, М. Гәрәев, Р. Рахман, М. Закиров кебек каләм иярләре белән очрашуларда әдәбият дәресләре алды, Г. Кариев исемендәге яшь тамашачы театрында «Йосыф-Зөләйха» мәхәббәте кыйссасын карады, нурлы Казан каласы белән танышты.

Яшь каләм ияләрен ТР Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, ТР Дәүләт Советы депутатлары—Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, язучы Туфан Миңнуллин котлады һәм иҗат уңышлары теләде.

Бәйгенең быел җиңүчеләре дип шигърият буенча Актаныш кызы Айгөл Закирова, прозада Балык Бистәсеннән Ләйсән Фәтхетдинова танылды. «Өмет» номинациясе буенча Язучылар берлегенен махсус премиясенә Теләче районының Алан мәктәбе укучысы Ләйлә Гатауллина һәм Әтнә районының Күшәр мәктәбе укучысы Зөлфия Габдрахманова лаек булды.

Бәйгенең иң мәртәбәле бүләге Гранпри шигърият күгендә инде үзен шактый танытып өлгергән ТДГПУ студенты Рүзәл Мөхәммәтшинга тапшырылды.

## ДРАМАТУРГЛАР СЕМИНАРЫ

Үткән ел ахырында Әлмәттә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Язучылар, Театр әһелләре берлекләре, "Татнефть" ачык акционерлык җәмгыятенең "Рухият" янарыш фонды, Әлмәт Татар дәүләт драма театры татар драматургларының республика семинарын уздырдылар. Ике дистәдән артык драматург, режиссерлар, театр директорлары, галимнәр, тәнкыйтьчеләр өч көн дәвамында милли драматургиянең бүгенге хәле проблемалары, үсеш перспективалары турында сөйләште. Семинарны Татарстан мәдәният министры урынбасары Г. Нигъмәтуллина ачты. Сөйләшүне Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов алып барды. Докладлар белән сәнгать фәннәре докторы, профессор Г. Арсланов, филология фәннәре кандидаты А. Габәши, КДУның татар әдәбияты доценты, филология фәннәре кандидаты Ә. Закирҗанов, Чаллы Татар дәүләт драма театры баш режиссеры Ф. Ибраһимов, драматург Р. Хәмид һ. б. чыгыш ясады. Семинарда РАТИ-ГИТИС институтының рус театры кафедрасы мөдире, профессор А. Степанова бүгенге татар драматургларының пьесаларына анализ ясады.

Семинарда драматургларга гонорар түләү аларның авторлык хокукларын яклау мәсьәләләренә дә ачыклык кертелде.

## КЫЗЫКЛЫ СӨЙЛӘШҮ

Тормыш һәм әдәбият өчен әһәмиятле мәсьәләгә багышлап дискуссияләр, "Түгәрәк өстәл" сөйләшүләре, иҗади бәйге-конкурслар үткәрү "Казан утлары" журналы эшчәнлегендә матур традициягә әйләнде. Күптән түгел редакциядә уздырылган "Түгәрәк өстәл" сөйләшүе татар хикәясенең хәзерге торышына һәм аның үсеш перспективаларын барлауга багышланган иде. Анда күренекле әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр Р. Мостафин, Т. Галиуллин, Р. Рахман, Х. Ширмән, М. Вәлиев, бу жанрда иҗат итүче каләм ияләре М. Әмирхан, К. Кәримов, Р. Мулланурова, Р. Низами һ. б. катнашты. Әлеге сөйләшү материаллары журналыбызның алдагы саннарының берсендә урын алачак.

## ЯКТАШЛАРЫ ЯРУЛЛИННАРНЫ ЗУРЛЫЙ

Татар халкының күренекле композиторы, Габдулла Тукайны күреп белгән, вафатыннан соң ана атап атаклы маршын иҗат иткән Заһидулла Яруллинның тууына 120 ел тулуны якташлары—мамадышлылар да зурлап билгеләп үтте. Шәһәрнең композитор Яруллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбендә лекция-концерт оештырылды. Кичәгә юбилярның улы, Казан дәүләт консерваториясе профессоры, татар музыка сәнгате факультеты деканы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәет Яруллин, аның җәмәгате Луиза ханым, консерваториянең 4нче курс студенты Айгөл Зәйдиева кайткан иде. Мирсәет Яруллин тамашачыларны әтисенең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырды. Аның шәкерте, Заһидулла Яруллинның иҗатын фәнни яктан өйрәнүче Айгөл Зәйдиева композитор иҗатына әтрафлы анализ ясады, фортепианода әсәрләрен уйнады.

Шул ук көнне Заһидулла аганың өлкән улы Фәрит Яруллинның Ватан сугышында һәлак булган көне дә иде. Сәнгать мәктәбе укытучылары Ләйсән Бикчәнтәева белән Альбина Гәрәева аның "Шүрәле" балетыннан өзекләр башкарды. Кичә барышында Мирсәет Яруллин сәнгать мәктәбенең фортепиано классы укучысы, соңгы елларда берничә мәртәбә төбәкара конкурсларда лауреат булган Валентина Иделбаевага шәхси стипендиясен тапшырды, ана укуында һәм иҗатында уңышлар теләде.

Искә алу кичәсе мәктәпнең уен кораллары ансамбленә кушылып, рояльдә Мирсәет Яруллин һәм Айгөл Зәйдиеванып Заһидулла аганың "Тукай" маршын башкаруы белән тәмамланды.

### ИЗГЕ ГАМӘЛ

Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында II Бөтенроссия Коръән укучылар конкурсы үтте. Чарага Бөтендөнья Коръән хафизлар әзерләү оешмасының генераль секретаре урынбасары Әнәс Каразон, Кувейт кунагы—шаех Хамад Әс-Синан, Россия Мөфтиләр советының Халыкара департамент житәкчесе Рушан Аббясов, Россия ислам университеты ректоры, профессор Рәфыйк Мөхәммәтшин һәм Казанда Коръән хафизлар әзерләү үзәге житәкчесе Ибраһим Сабиров килде.

Бәйге изге китапның 29-30 нчы өлешләрен яттан белүче 24 кешене тыңлаудан башланды. Коръән-Кәримнең 10 өлешен яттан белүче 6 кардәш тә мәртәбәле жюри алдында нәкъ имтихандагы кебек белемнәрен раслады, һәм, ниһаять, Коръәнне тулысынча ятлаучылар номинациясенә 9 хафиз чыкты.

Коръәнне тулысынча ятлаучылар арасында Әлмәт ислам мәдрәсәсеннән Али Яушев жиңде. Шул ук номинациядә дагыстанлы Әхмәд Залихаев—икенче, Казаннан Габделмәлик Сайдаралиев өченче урынны яуладылар. Корьәннең ун өлешен яттан белүчеләр арасында дагыстанлы М. Магомедов, Казаннан И. Сабитов һәм Буадан Р. Йосыпов призлы урыннарны бүлештеләр.

### ИДЕЛ-УРАЛНЫҢ ГОРУР КЫЗЫ

Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Гөлсем Исәнгулованы юбилее белән мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигьмәтуллина тәбрикләде, аңа Президентның Рәхмәт хатын тапшырды һәм «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнүен житкерде. Күренекле артистыбыз Равил Шәрәфиев аның турында: «Театрга башкорт булып килеп керде һәм татарча матур итеп сөйләшүнең үрнәге булды»,—диде. М. Гафури исемендәге башкорт дәүләт драма һәм академия театры режиссеры Айрат Абушахманов артистка Башкортстан Мәдәният һәм милли сәясәт министрлыгының Мактау грамотасын тапшырды. Гөлсем ханымны республикабыз театрлары да котлады. Баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев заманында Р. Батулланың «Кичер мине, әнкәй» спектаклендә Г. Исәнгулова белән бергә уйнаганын искә төшерде һәм аның бик таләпчән партнер икәнлеген дә искәртте. Театр директоры Шамил Закиров әйтүенчә, «Ул коллективны берләштереп торучы, бик горур артистларның берсе».

### ТАТАРЧА ГАЗЕТА

Татарстан Республикасы Милли музеенда татар телендә нәшер ителүче «Музейханә» исемле яшьләр газетасын тәкъдир итү кичәсе уза.

Газета нәшер итү—Милли музей эшчәнлегенең бер юнәлеше. Аның тарихы «Казанские истории» газетасына барып тоташа. Агымдагы елның гыйнвар аеннан басма «Музей К°» исемен алачак. Өченче саныннан бу газета татарчага да тәржемә ителә башлый. Ләкин редакция хезмәткәрләре, озак уйлаганнан соң, махсус татар телендә генә чыгучы газета булдырырга кирәк дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Август аеннан газета аерым бер басма буларак Милли музейда «Музейханә» исеме белән нәшер ителә башлый. Бүгенге көндә газетаның үз кыйбласы, үз укучысы бар.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

ТРның «Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр агентлыгы генераль директорының беренче урынбасары **Фәрит Шаһиәхмәтовка** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Мәдәният һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе, радиотапшырулар өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен "Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радио тапшырулары компаниясе" федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы "Татарстан" дәүләт телевидение һәм радио тапшырулары компаниясе" радиотапшырулар хезмәтенең тапшыру алып баручысы **Гайнетдинова Дания Захрый** кызына **"Татарстан Республикасының атказанган сәнгатькәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* *2009 ел—Спорт елы.*

*Дүртенче биттә:* шагыйрь **Рәниф Шәрипов**.

# Яңа китаплар




**Кафиль Амиров.** Казанских улиц имена/К.Ф. Амиров, Р. Х. Ахметзянова, Р. Г. Вениаминов.—Казань: Центр инновационных технологий, 2008.—592 стр. Тираж—3000 экз.


Рус телендә чыккан бу белешмә китап Казанда яшәүче, гомумән башкалабыз белән кызыксынучы һәркем өчен кирәкле кулланма. Теге яки бу урамның исеме, аның тарихы, кайда урнашканлыгы турында бай мәгълүмат бирелгән анда. Урам-мәйданнарның кайсы почта бүлегенә караганлыгы турында белешмәләр Казан кунаклары өчен бигрәк тә файдалы. Китап белән танышкач, меңьеллык Казанның әле без белеп бетермәгән яклары тулырак ачыла, башкалабыз тагын да мәхәббәтлерәк булып күзаллана.




**Хуҗиәхмәт Мәхмүтов.** Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр (этимологик эзләнүләр). Казан, 2008.—464 б. Тиражы—300 данә.

Туган телебездәге күп кенә мәкаль, әйтем һәм башка сурәтле тәгъбирләрнең барлыкка килүе халкыбыз тормышының төрле тарихи вакыйгалары, көнкүрештәге гыйбрәтле хәлләре, борынгы йола-ышанулар, гореф-гадәтләр, миф, риваять, легенда, әкият, мәзәк кебек фольклор әсәрләре белән бәйләнгән. Филология фәннәре докторы Х. Ш. Мәхмүтовның бу китабында 300 дән артык гыйбарәнең килеп чыгу тарихлары ачыклана, аларның мәгънәләре, әдәби телебездә кулланылыш үзенчәлекләре тәфсилләп аңлатыла.

Китап туган телебезне ихлас яратучы, аны тирәнрәк өйрәнергә омтылучы күпсанлы укучылар өчен кызыклы һәм файдалы бер кулланма.



**Рәниф Шәрипов**

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)**